ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

4.2010





Татарстан Республикасы Президенты
Рөстәм Нургали улы
МИҢНЕХАНОВ

Казан утлары
Qazan utları

2010

4
(1050)

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

*НАШИРЕ:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур.; 2*

БАШ МӨХӘРРИР

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

ИДАРӘ:

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт ӘХМӘТҖАН. Тукай катламы. *Шигырь* ..... 5
Мәдинә МАЛИКОВА. Юкә чәчәк аткан чак иде. *Роман* ..... 6
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Ватан көзгесе. *Шигъри дастан* ..... 51
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Тау артында кояш бар. *Роман* ..... 73

**БӨЕК ҖИҢҮГӘ 65 ЕЛ**

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләре ..... 45

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Индүс ТАҺИРОВ. Татарлар дәүләт төзү юлында *(Татарстан АССР төзелүгә 90 ел)* ..... 101
Әхәт МУШИНСКИЙ. «Сүздән олы берни юк!» ..... 114

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Ленар ШӘЕХ. Шигъри трагедия остасы ..... 123
Фәридә ХӘСӘНОВА. Шигърияттә—яңалык ..... 134

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ..... 143
«Татар энциклопедиясе» битләреннән ..... 146

**ТАРИХ**

Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе ..... 149

**ХӘТЕР**

Фронтовик язучыларның хатлары ..... 151

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Ирек САБИРОВ. Елау егет эшемени ..... 156

**АК ҖИЛКӘН**

Алия ГАБДЕЛХАКОВА. «Белмәү яхшырак...» *Фантастик хикәя* ..... 167
Илһам ШАКИРОВ. Бәләкәй Илһам ..... 171
Айгөл СӘЛАХОВА. Өмет сүнмәде. *Шигырьләр* ..... 174
Ким ШАКИРОВ. Ачышлар һәм ябышлар ..... 175
Интернет-кайтаваз ..... 176

**ЮМОР-САТИРА**

Рәим ГОБӘЙ. Мамадыш мәзәкләре ..... 182

«Казан утлары» архивыннан ..... 112, 180
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 185

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы М. МАЛИКОВОЙ «И сад был в цвету» (прод.),
Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ «За горою солнце»; поэма Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ,
стихи Р. АХМЕТЗЯНОВА.
«К 65-летию Победы»: «Татарские писатели—участники войны».
«Публицистика»: статья И. ТАГИРОВА «Татары на пути становления государственности»; А. МУШИНСКИЙ. «Слова, слова, слова... Ничего выше слов!»
«Литературная критика»: Л. ШАЕХ. «Мастер поэтической трагедии»;
Ф. ХАСАНОВА. «Новизна в поэзии».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.)
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«История»: А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения».
«Память»: письма писателей-фронтовиков.
«Рассказы из жизни»: И. САБИРОВ. «Не дело парню плакать».
«Белый парус»: рассказ А. ГАБДУЛХАКОВОЙ «Лучше ничего не знать».
«Юмор-сатира»: Р. ГУБАЙ. «Мамадышские байки».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Весеннее половодье»; писатель Ильдус ДИНДАРОВ.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry: novels by M. MALIKOVA «And garden was in bloom» (continuation),
R. GABDULHAKOVA «Over mountain there is sun»; poem by F. GIZZATULLINA,
poems by R. AHMETZYANOV.
«To 65th anniversary of Victory»: «Tatar writers—participants in war».
«Journalism»: Article by I. TAGIROV «Tatars towards statehood»;
A. MUSHINSKY. «Words, words, words ... Nothing above the words!»
«Literary Criticism»: L. SHAEH. «Master of poetic tragedy»;
F. HASANOVA. «Novelty in poetry».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«History»: A. HALIKOV. «500 Russian surnames of Bulgar-Tatar origin».
«Memory»: letters of writers at the front.
«Stories from Life»: I. SABIROV. «Do not cause a guy to cry.»
«White Sail»: story by A. GABDULHAKOVA «It is better to know nothing».
«Humor and Satire»: R. GUBAY. «Mamadysh tales».
From photo archives of magazine.
Diary of a social-cultural life.
On our cover: «Spring tide»; writer Ildus DINDAROV.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.04.2010, график буенча 1.04.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–382. Тираж 4753.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.

Роберт
Әхмәтҗан

# ТУКАЙ КАТЛАМЫ

«Шигырь» дигән җәүһәр эзләүчеләр,
Тукай катламына төшегез.
Шул бит безнең, ярты юлга җитеп,
Тәмамланмый калган эшебез.
Йә, син дә төш, мөтәшагыйрь, шунда—
Тукай, бәлки, талант өләшер;
Тукай данына коенып яшәүчегә,
Исемен атап, бәлки, эндәшер?!
Ерак икән Тукай катламына—
Кәйләләргә каты бу катлам!
Айлар-еллар тоташ чапканда да
Җитеп булмый, гомер—бер саплам!
Җитми икән көчегез, бау ишегез—
Комнан, йоннан, ялган моңнардан...
Кеше киткәч кенә, бушбугазлар
Мәдхияләр язып шомарган...
Тирән катламнардан, шахтер сыман,
Кем хаклыкны өскә чыгарган?
Янып төшкән тыгыз катламнарга,
Туры калып гаярь җисеменә,
Туры барган, туры ярган Тукай,
«Туры» булып калган исеме дә.
Без дә төшик Тукай катламына,
(Үземә дә дәшәм бу чакта.)
Шигырь уты кемгә—гел учакта,
Ә кемгәдер—җылы кочакта.
Төшегез сез Тукай катламына,
Намус катламына төшегез,
Дөрләтегез сүнгән шигъри утны,
Гаделлекнең кулын чишегез!
Яшь варислар, сезнең киләчәк бу—
Остазлардан олы әманәт:
Җитегез сез Тукай катламына,
Җаннарыбыз калсын канәгать!
Шигырь үрүчеләр! Җиргә бөек
Пәйгамбәрне биргән бу айда
Күп шаулыйбыз бугай, әллә азмы?
Бирик мәллә сүзне Тукайга?!

Мәдинә
Маликова

# ЮКӘ ЧӘЧӘК АТКАН ЧАК ИДЕ

**(НУРЗИФА)**

РОМАН

## Һәр рәссамның үз илһамчысы

Остаханәдә, кергәч тә сул якта, Мозаффарның студент елларда язган күчермә картинасы эленеп тора. Анда бер хатын-кыз, кулларын баш астына куеп, чалкан яткан. Элегрәк аның янәшәсендә рәссамның диплом эше—Нурзифаның кышкы бакча янында ясалган портреты эленгән иде.

Баксаң, бу картиналарның янәшә торуы очраклы булмаган, Мозаффарның аны да шул хатын кебек итеп ясыйсы килгән икән.

Бу теләген озак белгертмәде ул. Вакыты җитмәгәндер, күрәсең. Ниһаять, бер атна элек, кызның кулыннан сулы чиләген тартып алды да, зур гына зәңгәрсу ефәк кисәге тоттырды:

—Мин кылкаләмнәрне юып керәм, ә син киеменңне алыштыр!

—Ничек?

—Чишен дә, шушына уран. Аннары бер-ике сәгать менә моның төсле итеп ятып торырсың.—Һәм дивардагы картинага ишарәләде.

Нурзифа, ефәккә төренеп, ятакка урнашты...

Мозаффар сүзендә торды: ике сәгатькә якын онытылып эшләгәннән соң:

—Финита!—дип, борылып коридорга чыгып китте. Ул анда кылкаләмнәрен, кулын юган арада Нурзифа, өстен алыштырып, мольбертка күз салды. Киндердән ана күк зәңгәрлегенә төренгән фәрештә текәлгән иде.

«Минме бу?..»

Мозаффарның рәсемнәренә караган саен Нурзифа күнелендә туа иде бу сорау. Дөрес, башкалар портретлардан аны таный, әмма күзгедә ул мондый түгел шикелле.

Мозаффар кереп, кылкаләмнәрен сулы кюветка салды да:

—Ә хәзер моны кара!—диде. Һәм ефәккә төренгән хатын сурәтен элгечтән алып, тырнаклары белән тар рамның почмакларын каергалады. Рам икегә аерылды—астан тагын бер картина килеп чыкты.

—Минем сине менә шушындый итеп тә ясыйсым килә!

Картинада шул ук хатын-кыз, тик чишенгән, анадан тума ялангач иде.

---

*Дәвамы. Башы 3 санда.*

Нурзифа бит очларының пешеп чыкканын тоеп, карашын аска төшерде... Оялды дип булмый, чөнки шәрә хатын-кыз сурәтен күрмәгән кеше түгел, остаханәдә дә, күргәзмәләрдә дә андыйлар житәрлек. Нурзифаның бәгырен башка төрле, каршылыклы хисләр ялкыны көйдерде. Рәссамның сүзен аяк астына салып булмый, әмма аның каршында ничек чишенмәк кирәк?

—Беләсеңме, кем бу!

Нурзифа юк дигәнне аңлатып башын чайкады.

—Гади натурщица гына түгел, герцогиня бу! Дини инквизициянең иң котырган чорында Испаниядә яшәгән. Ә анда законнар бик каты булган, чит иргә тәнен күрсәткән хатыннарны, шайтан вәсвәсәсенә бирелгән дип гаепләп, яндырып үтерә торган булганнар. Ә бу ханым куркып тормаган... Тик мондый портретны барыбер дә ачыктан-ачык күрсәтү мөмкин булмаган, шуңлыктан рәссам аны ике катлы рамга куеп саклаган... Кайчан да булса мин шундыйракны ясый алырмын микән?

Нурзифа аның карашыннан кыенсынып, керфекләрен төшерде:

—Сез аны күргәзмәләргә куяр идегезме? Бездә бит инквизиция юк.

—Андыйны күргәзмәгә куярга ярыймыни? Турыдан-туры күчермә булмаса да, танылган әсәрне кабатлау бит бу! Үзем исән чакта ул минем остаханәмнән чыкмаячак. Син менә моны укы әле.

Мозаффар тәбәнәк өстәлдәге альбомнар астыннан калын китап тартып чыгарды..

...Алман язучысы Лион Фейхтвангерның «Гойя» исемле романы иде бу. Моннан ике гасыр элек яшәгән бөек испан рәссамы турындагы әсәрне Нурзифа, аерыла алмыйча, ике төн эчендә укып чыкты. Аны бигрәк тә Франциско Гойя белән герцогиня Альба арасындагы бәхетле дә, фажигале дә мәхәббәт кыйссасы тетрәндерде.

Китапта рәсемнәр дә күп иде. «Киенгән маха» белән «Чишенгән маха» дигәннәрен Нурзифа кат-кат, озак-озак карады. Герцогиня Альба портретлары...

Менә кайсы картиналарның күчермәсен ясый башлаган икән Мозаффар! Китап битендәге аклы-каралы сурәтләр шактый ук тоныкк, шуңлыктан йөз чалымнарындагы аерма бик үк беленми, ә менә романда бәйнә-бәйнә аңлатып бирелгән иде: киемен салыр алдыннан бу дәртле хатын жан сөйгәненең килеп кочканын тәкатьсезләнеп көткән минутларда тасвирланса, ялангачында аның йөзендә шашынып сөю ләззәтеннән соң була торган татлы талчыгу, рәхәтлек чагыла икән...

Бу картиналарны рәссам кылкаләмен сөю хисләренең ширбәтенә, кавышу бәхетенең балына манып язган икән.

Һәр рәссам эзли үзенә шундый илһамчыны. Кайберләре таба да. Саскиясен тапкан Рембрандт, Галасын тапкан Дали шикелле. Таптым, дип алданганнары да житәрлек. Мозаффар да шулай алданучылардан түгелме? Нурзифа аныкы була алмый бит!

...Әйе, аныкы була алмый, әмма аның бер теләген үти ала. Әлегә...

—Мин китапны укып чыктым,—диде ул Мозаффарга телефоннан. Аннары бераз тынып торды да:—Якшәмбе көнне сәгать уникегә киләм,—дип өстәде.

Көн уртасы—рәссамның иң яраткан чагы, чөнки бу сәгатьләрдә ян тәрәзәдән кояш төшә, яктылык бик уңай була.

Нурзифа килүгә остаханә үзгәргән—түрдәге ятакның ике ягына зәңгәр пәрдәләр эленгән, мендәр янына таныш зәңгәр ефәк җәелгән, рәссам үзе бүлмә уртасындагы мольберты янында басып тора иде.

Алар сүзсез баш иеп кенә исәнләштеләр. Нурзифа түргә узды, сумкасын өстәлгә куеп, рәссамга яны белән баскан хәлдә калтыранган бармаклары

белән ак җирлеккә кара бөрчек төшкән костюмының сәдәфләрен ычкындырырга кереште. Монда килер алдыннан ул, сәхнәгә чыгарга әзерләнгән артист кебек, һәр хәрәкәтен бик нык уйлап куйган иде. Менә ул җиңнәрен иңбашыннан аска шудырды, менә кофтасын салып, өстәлгә ташлады. Аннары итәгенең каптырмасын ычкындырып, янбашыннан түбән этте. Аны атлап чыкканда туфлиләрен калдырды.

Эчтән берни дә кимәгән иде. Чәчләрен сыпырып, салкынча ефәк өстенә шуышты. Кулларын мендәргә салып, башын куйды да йөзен Мозаффарга борды. Тик карашын аңа түгел, каршы дивардагы картинага, үзе кебек үк яткан хатынга төбәде.

Мондый чакта рәссам, «башыңны болайрак бор, кулыңны мондарак куй», дигәндәй сүзләр әйтми калмый. Башка чакта Мозаффар да аны төзәтә иде. Ләкин бу юлы дәшмәде. Кулына кылкаләмен тоткан килеш, башын арткарак ташлап, күзләрен кысып, Нурзифага төбәлде. Бүлмәнең һавасы тыгызланып, эсселәнеп киткән кебек булды. Менә ул капшанып палитрасын кулына алды, менә буяуларны изде. Менә башын алгарак сузды да, чак кына иелә төшеп, кылкаләмен киндергә сузды. Башлады...

Вакыт-вакыт ул бөтенләй мольберт артына яшеренә, аннары кырыйдан кистереп карап ала. Андый мизгелдә маңгаена тирдән чыланып ябышкан чәче күренеп китә, күзләреннән очкыннар чәчрәгән кебек була.

...Талант иясенең илһам кочагындагы чагын сүзләр белән аңлатып була микән? Җырчы—онытылып җырлаганда, шагыйрь—очынып шигырь чыгарганда, рәссам киндергә сурәт төшереп, аңа җан өргәндә ниләр кичерә? Моны сөйләп биреп булмыйдыр. Җырны тыңлаган, шигырьне ятлаган, сурәтләрне караган-күргән кеше генә аңлыйдыр. Чөнки иҗат иясенең кичерешләре аларга турыдан-туры күчә, арадашчы кирәкми.

Мозаффарның халәте болай да дулкынланган Нурзифаны тетрәндерде...

Менә ул рәссамга өлге булып ятып тора. Күп тә үтмәс, торып киенер. Һәм инде беркайчан кире килеп, киемнәрен салмас, бу ятакка ятмас. Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары аны бу төсле итеп яктыртмас. Мондый күренеш, бу мизгелләр бүтән кабатланмас.

Әмма алар җырларда җырланганча аккан су, искән җил кебек кенә узып китмәс, эзсез югалмас—сурәт булып калыр. Кайчан да булса, аны кешеләргә күрсәтергә мөмкин булыр һәм, күрә белгән нечкә күңелләрдә бу мизгелләр янарып, җаннарны иркәләр.

Мондый тойгыларны киндердәге сурәткә сеңдергәндә, рәссамнар өзелеп сөйгән ярлары белән кавышкан кебек халәттә була, дип аңлата сәнгать белгечләре. Әйе, чын талант иясенең ярсу йөрәгендә иҗат белән мәхәббәт бергә тоташа. Күпләре, эшләп аргач-талчыккач, каршыларында сәгатьләр буе өлге булып торган мәгъшукаларын кочагына ала. Шашып сөя, сөелә...

Атаклы рәссамнарның иң күп ясалган натурщицалары—хатыннары яки сөяркәләре. Рембрандтның Саскиясе, Сальвадор Далиның Галасы. Саный китсәң күп алар.

Нурзифа андый тарихларны белә, бүгенге гамәлне бүтән кылмаячак, кабатламаячак иде. Моның шулай икәнлеген Мозаффар да аңлады, шуңа бер тын белән, үрсәләнеп, бүленмичә эшләде.

Күпме вакыт узгандыр—сизелмәде. Менә бермәлне рәссамның башы-күзе күренмәс булды. Ул, мольберт артына ышыкланып, кулларын чүпрәк белән сөртә иде.

Нурзифа тавышсыз торды да, идәндә яткан итәгенең уртасына басып,

өскә тартты, ашыгып кофтасын киде. Һәм кулына сумкасын тотып, ишеккә юнәлде. Мольберттагы сурәткә дә, рәссамның үзенә дә күз салмады... Тынлыкта ишекнең чак шыгырдавы гына ишетелеп калды.

...Ә шулай да җан түзми, картинаны күрәсе килә иде. Нурзифа кичә эшкә барыр алдыннан остаханәгә кереп чыгарга булды.

Андагы тәртипсезлекне, картиналарның кайсы кайда ятканын күреп гаҗәпләнде.

Мольберт бүлмә уртасында килеш, киндер кисәге белән каплап кына куелган иде. Нурзифа аны ачты да тынсыз калып сурәткә текәлде. «Мин бит бу!»—дип уйлады ул таныш чалымнарны күреп. «Ләкин мин мондый түгел ...»—диде сурәттәге кыз тәненең тетрәнүле яктылыгына, йөзеннән сирпелгән нурга сокланып.

«Мәхәббәт сукыр, ул мәгъшугының чын йөзен күрми»,—дигән бер акыл иясе. «Мәхәббәтнең күзе үткен, ул мәгъшугында беркем күрә алмаган гүзәллекне күрә»,—дип каршы төшкән ана сөю утларында янган икенче берәү.

Чын сәнгать мәхәббәттән туа: кер-караны, яман-начарны күрми—сукыр; әмма яктыны, изгене, яхшыны башкалардан күбрәк күрә—сизгер.

Нурзифа дымланган керфекләрен кулындагы киндер белән сөртеп алды. Аерылышу ачысыннан тамган яшь бөртекләре иде бу. Чөнки шушы минутта Нурзифа, бүтән беркайчан да остаханәгә килмәм, Мозаффар белән күзгә-күз очрашмам, аны онытырга тырышырмын, дип үз-үзенә сүз бирде. Һәм мольбертны каплап куйды.

### Кыз сүзендә тора алмады

Әмма Азалиянең телефоннан шылтыратып әйткәне һәммәсен бутап ташлады. Аны-моны уйлар чак түгел, эзләшергә кирәк! Тик ничек эзләргә? Кемнән сорарга? Рәшатны борчу яхшы булмаса, башкалар бар бит!

Нурзифа куен кенәгәсен алып, «Р» хәрефе язылган битен ачты. Менә ул—Рәҗәпов. Мозаффар белән бергә укыдылар, бер остаханәдә эшлиләр. Дөресрәге, эшлиләр иде. Соңгы елларда сирәк күренә күренүен. Сабакташының юкка чыкканын белә микән? Сорау зыян итмәс.

Теге башта көтеп кенә торганнар диярсең, трубканы тиз күтәрделәр.

—Исәнмесез!

—Хәерле кич, Зифа! Гафу, хәерле төн, димме...

—Әйе, мин бу. Сез бөтен кешене шулай бер сүзеннән таныйсызмы?

—Сине башка белән бутап буламы соң! Сулышыңнан таныйм! Аннары шалтыратырсың дип уйлаган идем...

—Ничек алай?

—Күңелем сизде. Ни кирәк, әйт тизрәк! Җаным җәл түгел сиңа, Зифуш!

Аның шаяруы урынсыз булса да, Нурзифа ризасызлыгын сиздермәде.

—Мозаффар абыйны күптән күргән идегезме?

—Минме?.. Мин...—Хәнәфи ничектер тотлыгыбрак торгандай булды.— Хәтерләмим инде... Остаханәгә кереп чыгарга да вакыт тими бит... Ә-ә, күргәзмә ачылганда күрештек без. Ә син нишләп күренмәдең?

—Эштән китеп булмады...

—Минем дә мәшәкать муеннан шул...

—Сезгә Азалия ханым шылтыраткандыр инде, бәлки? Ул әле генә минем белән сөйләште.

—Ах, менә ничек! Сез аның белән аралашасызмыни?

—Мозаффар абый югалган бит!—диде Нурзифа аның кинаясен

игътибарсыз калдырып.

—Кайчан?

—Ике көн кайтмады инде, ди.

Хәнәфи җиңеләеп көлеп җибәрде.

—Шуның өчен яратам да инде мин сине, Зифуш!

—Нәрсә өчен?

—Беркатлы сабый булганың өчен. Ике-өч көнгә хатыннары күзеннән ычкынып торган ирләрне кем инде юкка чыкканга саный! Андыйларны эзләтә башласалар, Казан милициясенең кесә каракларын тотарга вакыты калмас. Бигрәк ябышкак нәрсә ул Азалия! Күрмәс өчен әллә кая качарсың. Мозаффарны да аңларга була. Шулай түгелмени? Син ничек уйлыйсың?

Соңгы сүзләрдә Азалиядән дә бигрәк әңгәмәдәшен чеметтерү сизелде. Әмма Нурзифа монысын да җавапсыз гына үткәреп җибәрергә булды. Хәнәфинең төрле даирә кешеләре белән аралашканы мәгълүм, мондый очракта кая барырга, кемгә сугылырга икәнен яхшы беләдер.

—Берәр киңәш бирмәссезме, дип уйлаган идем.

—Мин Мәскәүдә идем шул, Зифуш. Бүген генә кайттым... Шалтыратуың яхшы булды әле. Үзем ничектер һаман житешә алмый йөри идем. Бер тәкъдим бар сиңа. Дизайнер өчен зур заказ дияргә була.

—Нинди заказ?

—Самаркинның яңа йортларында эчке эшләрне башладык. Кухнясын бизәргә, җиһазларга алынсаң, яхшы булыр иде. Хуҗага ошап китсәң, бәлки, башка бүлмәләрне дә ышанып тапшырыр идек үзеңә. Бу инде сиңа сәнәктән күрәк булган гыйбатларның фатирларына шкаф тезеп кую гына түгел! Узганда күрәсеңдер, шәп корылмалар бит, ә?

—Игътибарны җәлеп итә-ә,—диде Нурзифа сузып.

—Күргәннең күзе кыза, диген! Шәһәрдә андый юк бүтән. Син менә шул хакта уйлый башла әле. Ә Мозаффар өчен борчылма. Без сөйләшкән арада, ул, бәлки, өенә кайтып утыргандыр да инде. Хатыны белән чөкердәшеп чәй эчәләрдер. Ә бәлки, пыр тузып сугышалардыр.

Ул көлгәндәй итенде. Тик кеткелдәве сәер тоелды.

—Без, давай, үз ягыбызны кайгыртыйк,—дип дәвам итте Хәнәфи.—Иң элек объектны килеп кара. Иртәгә сәгать уникеләргә машина җибәрсәм, ярармы?.. Төш туры була, чәйләп алырбыз... Шунда һәммәсен сөйләшербез, уйлашырбыз... Әгәр каршы килмәсәң...

—Ярый...—Нурзифаны аның «һәммәсен уйлашырбыз» дигәне өметләндерде. —Тик машина кирәкми...

—Җәяү килмәссең бит инде?

—Минем үз транспортым бар...

—Нинди ул?

—Өр-яңа ак «Лада», —диде Нурзифа.

—Кит аннан? Яңа «Лада»лар сатып алырлык акча түлиләрмени сезнең фирмада? Булмасны... Әллә... берәрсе бүләк иттеме? Егетең бармы әллә?

—Сау булыгыз. Иртәгәгә кадәр,—дип, элемтәне өзәргә ашыкты Нурзифа.

Хәнәфинең сүзләрендә астыртын бер мәгънә бар кебек иде. Нидер белә, нәрсәнедер әйтеп бетерми шикелле. Ә бәлки, очрашып күзгә-күз карашып сөйләшкәндә ачылып китәр?

Әмма иртәгесен Хәнәфи янына барырга һич кенә дә аяк тартмады. Алдагы көнне сөйләшкәндә ак «Лада»ны телгә алуы тикмәгә генә түгел—күнеле Рашаттан таяныч эзли иде. Чыннан да, егеткә шылтыратып: «Мине Компрессор заводы тирәсенә илтеп куя алмассың микән?»—дип үтенсән, ник каршы килсен икән ул? Анда кадәр барып житкәч, Хәнәфи янына да

бергә керерләр иде. Ә нигә шулай итмәскә? Институтта каникул вакыты, мәдәният сараенда кичен эшлиләр, вакыты бардыр. Дөрес, каядыр күздән югалды әле үзе. Өстәл-шкафлар әзер, дип шылтыратып әйткәч тә атылып килеп житмәде. Әллә берәр тыгыз эше бар микән? Билгесезлек бик тә, бик тә борчый иде Нурзифаны.

Менә хәзер тагын бер тапкыр шылтыратырга сылтау табылды. Атна буе күзгә күренми йөрүенең сәбәбен дә белеп булыр, бәлки...

—Тыңлыйм!

Нурзифа сәлам бирергә дип авызын ачкан иде, трубкадан тагын бер аваз килеп ирешге. Хатын-кыз тавышы... Чытлыкланып көлә...

—Тыңлыйм!—дип кабатлады Рашат. Бер тын тыңлап торды да:—Соңрак шылтыратыгыз, зинһар!—диде.—Мин рульдә...

Рульдә... Ниндидер хатын-кыз белән... Димәк, аның кемедер бар?! Әйе, шулай. Кемдер аның машинасында янәшә утыра, көлә-шаяра... Шуна күрә дә ул, кем шылтыратканын белмәгән кебек, чит итеп җавап бирә. Ә бит белә! Телефонына күз салмый калмагандыр...

Бу уй йөрәкне телеп үтте. «Тукта, ник болай өзгәләнәм әле?—диде Нурзифа үз-үзенә.—Кем соң әле ул мина? Гап-гади клиент, сатып алучы».

Хәзер инде Хәнәфидән гайре сүз кушар кеше калмады кебек...

## Күпердә

...Кварталдан Компрессор заводына таба барган трамвай Казансу аша күпердән чыгып килә иде. Көн уртасы булганга, вагонда халык күп түгел, басып торучы юк, йомшак утыргычлардагы абый-апалар йөзләрен тәрәзәгә борып, елганың бу як сөзәк ярындагы камышлык- таллыкларга, су өстендә елкылдаган кояш тәнкәләренә караган. Менә аларның карашы каршыдагы текә ярга төртелде. Үрнең күкрәгенә биек-биек өч кирт ясалган, һәркайсы бетон белән ныгытылган. Бетонга ак буяу белән рәттән бертөсле итеп, өске ягын түгәрәкләндереп, зур-зур тәрәзәме, ишекме сурәтләре ясалган. Иң аста, су читендә берәр катлы ике бина төзелгән: берсе зуррак, икенчесе кечерәк, мөгаен бассейн белән мунча—хәзергечә әйткәндә, саунадыр. Урта кирттә—икешәр катлы тагын ике бина, иң өстәге ике бина исә өчәр катлы, манаралы, гөмбәзле. Һәммәсе кызыл кирпечтән, бизәкле, сырлы. Ихата юл ягыннан биек кирпеч койма белән уратып алынган, койма өстендә, сөңгеләрен тырпайтып, тимер рәшәткә каралып тора.

Меңъеллык шәһәрнең үзенчәлекле бер билгесе булып саналырлык бу корылмалар күпердән туктаусыз узып торган трамвай-троллейбус-автобуслардагы кешеләрнең күзенә төртелми калмый һәм еш кына юлчылар арасында сүз кузгалуга сәбәп була иде. Бу юлы исә монда аерата зур мөмкинлек ачылды, чөнки трамвай күпергә кереп житмәс борын тукталып калды. Алдарак машиналар бәрелешкән булса кирәк, яннан ачы чыелдап, түбәсендәге озынча, шәмәхәле-кызыллы лампасын җемелдәтеп, милиция машинасы узып китте. Трамвайдагы халык янә дәррәү тәрәзәгә борылды.

—Абау, кара әле, монда сад-огород түгел идеме соң?—диде урта яшьләрдәге бер хатын.—Түтәлләр дә алачыклар гына иде. Кай арада төзеп куйганнар! Чиркәүме соң әллә бу?

Алгы утыргычтагы ак яулыклы апа аңа таба борылып:

—Чиркәү үк түгел түгелен дә, кяферләр оясы ул,—дип куйды.

—Ни дигән сүз инде бу?

—Халыкны талап җыйган акчага салган йортта кяфер яшәми, кем яшәсен.

Каршы як утыргычтагы абзый башын борып, мәгънәле көлемсерәп:

—Мал таба белгән кешедән көнләшүче күп булыр,—дип аңа каршы төште. Ак яулыклы хатын күзләрен зур ачып аңа текәлде:

—Тир түгеп тапкан маллары түгел!—диде нык итеп.—Хәләл акчага мондыйларны төзеп булмый! Менә без дә, ал димәдек, ял димәдек, эшләдек. Маңгай тиребезне сыпырып алырга да вакыт тимәде. Хәзерге көндә малайга бер фатир алырга да хәлебездән килми. Әнә, безнең Балтачта, сөтнең литрын өч тәнкәдән җыялар да, монда китереп унөч сумнан саталар. Су кушып! Менә каян килә ул байлык аларга!

—Самаркин сезнең сөтегез көненә калмаган, —диде абзый.—Ул зур заводлар белән эш итә. Миллиардлаган акча белән. Акчаның да яшеле белән!

—Анысы нинди була тагын?

—Доллар яшел була...

—Ә анысын каян алган? Менә шушы җирдән суырган! Шушыннан, шушыннан... Кулларыннан тотып алучы гына юк. Кесә каракларын тоталар—миллионнарны үзләштергәннәрне күрмәмешкә салышалар. Ул Самаркин дигәнегез дә дәүләтнекен талагандыр, бер дә әллә каян түгелдер...

—Ә син аңа барып әйтеп кара. Үз тырышлыгым белән тапкан хәләл малым, дип чатлап тора. Бер җиреннән гаеп таба алмыйсың!

—Алар белән булышуның мәгънәсе юк, —дип тыныч кына өстәп куйды арттарак утырган бер яшь ир.—Адвокатлары гына да әллә ничәшәр. Ниндиләре генә диген әле!

—Менә шул-шул... Кирәк дигән кешеләренә үзләренең мул табыннарыннан калҗа ыргыталар да бөтен халыкның авызын каплаталар. Оялмыйлар да бит, ичмасам! Байлыкларын күзгә китереп териләр. Юлдан читтәрәк, агач арасына да түгел, күпер төбенә, үр күкрәгенә чыгарып куялар! Теге күпер төбендә берсенең бастионы, монысында икенчесенеке...

—Ә Кремль янәшәсендә ни кыланып яталар әнә? Андагы коттеджларны күрсәгез сез!

—Казансуның теге ягыннан карасаң гына инде. Бу ягыннан якын килеп булмый, авылы белән әйләндереп алганнар да, сак куйганнар анда. Бакча ширкәте бу, дип документ алырга йөргәннәр икән әле.

—Ну кыланып куялар да инде безнекеләр! Мәскәүләрне уздыралар. Абрамович та Абрамович диләр, ул сон Мәскәү Кремле янында утар сала аламы?

—Халык дәшми! Халык күтәрелсә артларын кысалар иде!

—Күптән вакыт югыйсә!

—Халык күтәрелсә ни булганын беләсезме сон сез? Революция дигән сүз бит ул!

—Анысыннан Алла сакласын!

Шул рәвешле, берәүләр тавышланып, икенчеләр үзалдына төрлечә сөйләнде. Кайсының сүзләрендә ачы көлемсерәү, көнләшү сизелә, бәгъзеләренең чыраенда нәфрәт ярылып ята иде. Ничек кенә булмасын, трамвайдагыларның берсе дә битараф калмаган иде кебек. Фәкать башын тәрәзәгә борып утырган Нурзифа гына дәшмәде, кыймшанмады. Әмма дикъкать белән күз салучы булса, аның бит очлары янып чыкканын, күкрәге дулкынланудан тибрәнеп-тибрәнеп куйганын күрми калмас иде.

«Нигә шушы кадәр купшы, зәвыксыз, ямьсез итеп төзеделәр икән бу

корылмаларны?—дип уйлады ул.—Яхшы архитекторлар эшләде, дигән булалар тагын. Хәнәфи зәвыксыз кеше түгел ләбаса».

—Мондый ныгытмалар болай гына төзелми,—дип теш арасыннан сыгып чыгарды берсе.—Биек коймалар артында хәтәр серләр яшерелә. «Һәркемнең шкафында үзе генә белә торган скелеты бар», дигәнне ишеткәнегез бармы?

—Юк сүз! Безнен хрушевканың шкафына сөяк-санак тутырып булмый, эштән кайткач тузанлы бишмәтенне салып эләргә дә урын житми әле!

—Синен-минем хакта әйтелгән сүз түгел лә ул!—диде юан корсаклы, кызыл чырайлы бер адәм.—Ә менә мондыйларда скелетлы шкафлар гына түгел, жир асты зинданнары да була! Шунсыз ярамый! Бай кешенен акчасы гына түгел, дошманы да үрчеп тора. Аларны ничек тә булса тыярга кирәк бит! Әнә, кирпечне ничек сырлап куйганнар! Берничәсе чын ишектер әле. Үр күкрәген тишеп кенә керәсе, баз чокып азапланасы да юк... Бик унайлы...

Бу сүзләрдән хатыннар күзләрен зур ачып ах итеште. Ул арада трамвай урынынннан кузгалды, күперне чыгып, үргә менә башлады. Купшы ихата агачлык артына кереп чумгандай булды. Сүз ничек кинәт башланса, шулай өзелде. Берничә кеше урынынннан кузгалып, алгы ишеккә юнәлде. Алар арасында Нурзифа да бар иде.

## Ымсындыру

Трамвайдан төшкәч, бер тын светофорда яшел ут кабынганын көтеп торырга туры килде. Юлдан тоташ гүләп узып торган машиналар агымы үзенең аерым бер кешегә битарафлыгы белән күнелне төшерә иде шикелле. Бу әле генә ишеткән сүзләрнең авыр тәэсирен тагын да көчәйтә иде. Әллә сон кире борылыргамы? Рельсларны атлап кына чыгасы да, каршы трамвайга утырасы. Анда инде әле генә ишетелгән сүзләр кабатланмас, чөнки бу яктан барганда бай ихата артта кала...

Нурзифа башын күтәреп, кояш нурларына коенып, яшел толымнарын салындырган каеннарга, алтынсу чәчәккә төренгән юкәләргә карады. Кире борылса, Мозаффар турында нәрсә дә булса белү мөмкинлеге кулдан ычкыначак...

Әнә, светофор яшел күзен ачты. Нурзифа инендәге сумка бавын төзәтебрәк куйды да, тәвәккәлләп юл аша атлады.

Агачлар арасыннан үргә менә торган кин юлга вак таш түшәгәннәр, асфальт жәеп өлгермәгәннәр әле. Монда машиналар да, жәяүлеләр дә юк. Менә каеннар арасында, уңда зәнгәргә манылган зур капка күренде. Ул чак кына ачык иде. Аннан һау-һаулап зур-зур ике эт чабып чыкты. Нурзифа туктап калды. Этләр артыннан ала-кола куртка-чалбар кигән, сыек гәүдәле, көньяк кешесенә охшаган ир заты күренде. Озын муенында сәер тоелган кечкенә башын сузып:

—Фу-у, фу-у!—дип этләрне куды да:—Кем кирәк?—дип сорады.

—Мин Хәнәфи Бариевич чакыруы буенча.

—Кем син?

Нурзифа фамилиясен әйткәч, капка баганасына беркетелгән домофонга:

—Шеф! Сине бер кыз сорый монда!—диде.—Нурзифа Миннуллина ди... Юк, машина белән түгел... Жәяү...

Аннары борылып:

—Уз әйдә,—диде.

Мондый капкалар түбән каравылларга күбесенчә читтән кайткан кешеләр

яллана. Бу адәм шундыйлардан иде, күрәсең. Алардан сер чыкмый... Чөнки сүз сыярдай якын кешеләре—туган-тумача, дус-ишләре бередә түгел, еракта калган. Болар инде трамвайда гайбәт сатып йөрмәячәк.

Килә-килешкә мондый адәмнең очравы Нурзифаның күңелен шомландырып җибәрде.

Капкадан эчкә таба яна гына түшәлгән, чем-кара, йомшак һәм җылы тоелган асфальт юлдан гөмбәзле, манаралы бинага таба барганда, Нурзифаның тез башлары йомшарып киткән кебек булды. Якыннан караганда бу бина зуррак, биегрәк, тагын да сәеррәк тоела иде.

Аскы катның тәрәзәләренә челтәрле рәшәткәләр куелган. Мәрмәр баскыч борынгыга охшатып ясалган зур ишеккә алып менә. Ишек имән тактадан кебек итеп эшләнгән, әмма эче, мөгаен, бронялы тимердер. Тоткалары бронзадан, арыслан башы рәвешендә коеп ясалган, зур, авыр.

Нурзифа тоткага тотынуга, ишек тавышсыз ачылып китте, эчтә ак күлмәк, күксел чалбар кигән, ачык муенына калын алтын чылбыр таккан Хәнәфи күренде.

—Хуш киләсең, Зифуш! Нишләп тәпи-тәпи йөрисең? Транспортың бар, дип мактанган идең түгелме?

—Кабыза алмадым...

—«Лада» булдымы машина! Синең кебекләр иң яхшы иномаркада гына йөрергә тиеш. Соңгы вакытта «Смарт» дигәннәре күренә башлады. «Мерседес-бенц» чыгара. Ике генә кешелек. Шундыйны юнәтергә кирәк сина... Кер әйдә!

Биек холлда мәрмәр, көзге, алюминий патшалыгы күзләрне чагылдырды. Алсу туф белән тышланган диварларга, түгәрәк баганаларга, бизәкле идәнгә пыяла түшәмдәге тишекләреннән яктылык коела иде. Почмакларга зур чүлмәкләр белән пальмалар да куеп өлгергәннәр.

Соңгы елларда уңган егетләр чит илләргә еш йөри башладылар, әйтик, Гарәб Әмирлегендәге яна төзелешләргә күзләре бик кыза. Бер кич кунып чыгуы ким дигәндә ике мең доллар торган кунакханәләрдә ял итеп кайткач, мондагы үз йортларын да шундыйрак итәселәре килә. Пальмаларны да, бәлки, шуннан ук алып кайткannардыр.

Хәнәфи кулы белән киң мәрмәр баскычка ишарәләде:

—Рәхим итегез, туташ.

—Кухня кайда соң монда?—дип сорады Нурзифа.

—Ә нәрсәгә безгә кухня?

—Мина шуны җиһазларга тәкъдим итәсездер бит инде?

Хәнәфи күңелле итеп көлеп җибәрде.

—Эш качмас ул! Әйдәле, без синең белән чәй эчеп алыйк. Хәтерлисеңме, студент чагында син безне нинди тәмле чәйләр белән сыйлый идең? Соңгы тапкыр безгә чәй кайнатып биргәненә күпме гомер үтте инде, ә?

—Әллә тагын... Аны кем санаган...

—Кызларның хәтере кыска шул,—дип көлде Хәнәфи.—Хәер, син ул чакта мәктәп баласы гына идең әле. Без диплом эше яклагач... Остаханәдә... Безнең хөрмәткә бокал күтәргәнеңне хәтерлисеңме?

—Теге ант биргән кичне әйтәсезме? «Матурлык яки үлем» дип...

—Ну, анысы аның бер шаяру гына иде бит. Яшь чакта алай гына кыланулар була инде ул...—диде Хәнәфи.—Хәер, синең белән без ул антка тугры калдык бит! Матурлыкка хезмәт очраштырды бит безне монда да! Уз әйдә, уз!

—Сез анда ун елдан соң очрашырга вәгъдә иткән идегез. Шулай хәтердә калган.

Хәнәфинең йөзеннән күләгә шуып узгандай булды.

—Сабакташлар, вәгъдә куймаган булсалар да, ун елга бер жыелыша инде ул. Андый традиция бар... Әйдә-әйдә, безнең әни әйтмешли, чәй суынадыр анда.

Алар өскә менгәндә, аяк тавышлары буш диварларга бәрелеп янгырады. Кешеләр яшәмәгән урынга хас булганча, бу затлы бинада да үзенә бер шыксызлык хөкем сөрә, жан жылысы инмәгән иде әле.

Иркен бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәлдә аларны әзер табын көтеп тора иде. Киң бәллүр савытта яшел яфракларын сирпеп ананас тырпаеп утыра, затлы тәлинкәләрнең берсендә үтә күренмәле диярлек телемнәргә туралган балык, икенчесендә казылык, ит, тавык калҗалары, өченчесендә әфлисун, мандарин телемнәре, тагын берсендә яшелчә иде. Ике якка ике түгәрәк салфетка, тәлинкә-чәнечке куелган.

—Йә, нәрсәдән башлыйбыз?—диде Хәнәфи, сул як диварга ишарәләп. Андагы биек карасу шкафның пыялалы киштәләренә төрле-төрле шешәләр тезелгән иде.

—Минем ашыйсым килми әле,—диде Нурзифа.—Башта эш турында сөйләшербез, бәлки? Хужа үзе кая соң?

—Хужа сезнең каршыгызда, туташ!

Хәнәфи Нурзифаның чыраенда чагылган гажәпләнүне күреп көлеп жибәрде.

—Әйе, әйе, мин хужа монда. Самаркинның бу төзелеш белән шөгыльләнергә вакыты юк. Зуррак эшләре күп. Хәзерге вакытта ул әле бөтенләй Казанда да түгел. Кичә генә Франциядән шалтыратты. Лазурный берег дигән жирдән. Ишеткәнең бармы? Шуннан вилла сатып алырга йөри булса кирәк. Ә бусын тулысынча минем карамакка ышанып тапшырды.

—Сез биредә аның управляющие инде алайса?

Хәнәфи аның соравындагы кимсетүле кинаяне сизмәмешкә салышты:

—Бизәү, матурлау өчен акча житәрлек, гонорарны икеләтә түләргә була. Ни дисән дә, син мина бөтенләй үк чит кеше түгел.

Нурзифа дәшмәде, башын күтәреп, шома ак түшәмне, яшькелт обойлы диварларны күзеннән кичерде. Башта игътибар ителмәгән, сул почмакта, күләгәдә, тар гына борылмалы агач баскыч бар икән. Каядыр, берәр серле урынга алып төшәдер шикелле. Ни өчендер трамвайда ишеткәннәр хәтергә килде: «Монын ише замокларда скелетлы шкафлар булмый калмый инде ул»...—«Зинданы да була, диген, зинданы да!»

Уң як диварда ачык тәрәзә күзгә ташлана, аннан чәчәккә күмелгән алмагачлар, зәп-зәнгәр күк гөмбәзе күренеп тора иде. Туктале, ул дивар тышкы якка чыкмый бит, анда бернинди тәрәзә булуы мөмкин түгел! Алмагачлар да әллә кайчан чәчкәсен койды инде! Ялган тәрәзә артыннан ялган агачлар, ялган күк гөмбәзе карап тора иде Нурзифага.

—Монда дизайнерлар эшләгән бит инде...—диде Нурзифа.—Менә, мәсәлән, бу тәрәзәне уйлап чыгарганнар...

—Бусы тулысынча минем дизайн,—диде Хәнәфи канәгать елмаеп.—Начар түгел бит, ә?

—Бу баскыч кая алып менә?

—Менә генә түгел, төшә дә,—диде Хәнәфи канәгать елмаеп.—Хужа кешенең яшерен юллары булырга тиеш, шулай бит?

—Мина башка бүлмәләрне дә карап чыгарга кирәк,—диде Нурзифа.—Кайсы жиренә генә тотынсаң да, бинаны гомумән күз алдында тотмый булмый. Стиль бөтенлеге сакланырга тиеш.

—Менә бу чын профессионал сүзе!—дип аның иңеннән сыйпаштырды

Хәнәфи. Нурзифа дерт итеп артка тайпылды да, биек аркалы урындык аркасына ак сумкасын элеп, утырды. Беренче күрүдә үк ул Хәнәфидә нindiдер үзгәреш барын тоеп алган иде инде. Моңарчы ул бу рәвешле оятсыз елмаеп, күзләрен тасырайтып, нindiдер мәгънә белән карамый торган иде. Кул сузганы да юк иде. Артык шат кебек үзе, артык кунакчыл булып кылана. Ни булган аңа?

Менә ул янәшә урындыкка утырды да:

—Мин синең бик зәвыклы оформитель икәнлегеңне беләм, шуңа күрә бинаның гына түгел, бөтен утарның сызымнарын әзерләп куйдым,—диде.—Алар күрше кабинетта. Чәй эчкәч, кереп, әйбәтләп карарбыз.

—Кайда нәрсә урнашкан соң монда?

—Беренче катта кунакларны кабул итү өчен зур зал, икенчесендә бу кечкенә залдан тыш ике кабинет, туташ-ханымнар өчен будуарлар, өч йокы бүлмәсе. Өстә ял итү бүлмәләре, террасалар. Дүртенче катта спортзал, бер башында кышкы бакча. Анысына махсус белгечләрне җәлеп итәргә туры киләчәк. Матурлык булачак монда, Зифуш! Чын матурлык! Һәм шул матурлыкны без булдырачакбыз!

—Ә иң аскы катта нәрсә?

—Идән астында, дисеңме? Анда бит подвал... Хуҗалык өчен кирәк-ярак, азык-төлек саклана торган урын. Аларына синең талантны әрәм итәсе юк.

—Алай да архитектура үзенчәлекләрен белү өчен алары белән дә танышып чыгу комачауламас иде...

—Әйдәле, Зифуш, шул хәтле еллардан соң бер очрашканбыз икән, идән асларына кермик әле без. Капкалап алыйк бераз, сыйланыйк.

Хәнәфи урыныннан кузгалып, ян шкафка таба атлады.

—Мин инде сиңа аракы да, коньяк та тәкъдим итмим...

—Берни дә кирәкми. Мин эчмим.

—Эчмәгәнеңне беләм, шуңа күрә гел эчми торган затлар өчен ясалганын гына кабып карарга тәкъдим итәм.

Ул үрелеп өске киштәдән бөксәле аксыл шешә алды.

—Менә бу затлы эчемлек «Бейлис» дип атала. Кабып караганың бармы?

—Юк... Кирәкми дә...

—Ә син йотып кара бер. Чәй алдыннан... Кофега кушарга да була... Хәзерге вакытта байлар табынының түрендә бу эчемлек, бик модада... Безнең кибетләрдә юк әле. Егор Викторович чит илдән кайтканда Домодедово аэропортының кибетеннән алган. Су буе чират тезелгән иде, Мәскәү байларының хатыннары егылып алдылар, ди. Без алардан кимме әллә?

Ул шулай сөйләнә-сөйләнә өстәлне әйләнеп узды да, Нурзифаның җилкәсе аша үрелеп, сулышын аның колагына өреп, сөтле кофега охшаш куе сыекчаны кечкенә бәллүр рюмкага агызды.

—Моны бер-ике йотканнан берәү дә үлми. Әйдә, эшләр уң булсын өчеңгә...

Нурзифа аннан читләшергә тырышып, өстәлгә үк иелде.

—Үзегезгә дә салыгыз инде,—диде.

—Салмый каламмы соң! Салам, әлбәттә!

Ул үз урындыгына утырды да, рюмкасына шул ук шешәдән эчемлек салып, Нурзифага таба авышты, янә мәгънәле елмаеп:

—Синең уңышларың өчен!—дип рюмкаларны чәкәштерде.

Нурзифа дәшми генә куе сыекчаны бер кабып куйды. Чыннан да тәмле икән.

—Түбенә кадәр йот инде,—диде Хәнәфи аның кулыннан тотып. Нурзифа аннан ычкыну өчен ашыгып эчеп куйды да ананас калҗасы алып суырды.

—Ә хәзер әйдәле, икебезнен уртак эшебез өчен,—дип рюмкаларны янә тутырды Хәнәфи.—Бусын инде брудершафт итсәк тә була. Шулай тиеш.

Аның бу әдәпсез тәкъдименә Нурзифа туктаусыз эчен тырнап торган сорау белән җавап бирде:

—Мозаффар абый турында бирәр нәрсә белә алмадыгызмы?

Хәнәфинең йөзе тартышып куйды.

—Нәрсә, кайтмаганмыни әле?—дип сорады ул кинәт үзгәргән тавыш белән.

—Юк шул. Бик сәер бит бу, Хәнәфи Бариевич... Сез ничек уйлыйсыз?

—Берничек тә уйламыйм. Мозаффарның үз башы үзендә. Ул безнен менә шушылай кара-каршы утырып аның хакында гәпләшүебезне теләр иде микән әле?

Аның сүзен тоныйк кына зеңләү өзде. Хәнәфи урыныннан кузгалып, шкафка таба юнәлде. Аскы киштәдәге селекторның төймәсенә басып, трубканы алды.

—Шулаймы? Бертуктамыйчамы? Ялына башладымыни?—дип, Нурзифа өчен аңлаешсыз сораулар бирде ул теге баштагы кешегә.—Тоташтыр инде алайса, бездән булсын яхшылык... Ә-ә, синмени әле бу, сабакташ!—диде аннары тавышын балландырып.—Хәлләрең ничек? Карале, монда сине югалтканнар бит! Ду килеп эзлиләр. Әле менә синең хакта сөйләшеп утыра идек... Кем белән булсын, Нурзифа белән инде.

Нурзифаның йөрәге сулкылдап куйды.

—Мозаффар абыймы әллә?—дип урыныннан сикереп торып Хәнәфигә таба атылды да, чытырдап трубкага ябышты ул.—Мина бирегез әле, мина! Мозаффар абый! Синме бу? Син кайда? Без сине эзлибез...

—Ә син... Син үзең кайда?—дип сорады Мозаффар. Аның карлыккан тавышы ят булып тоелды.

—Мин монда... Хәнәфи абый янына килгән идем... Заказ бар...

—Ах шулаймыни? Хәнәфи абыең янындамыни син?

—Мин эш белән... Зур заказ турында сөйләшергә...

—Сина да заказ таптымыни?

—Мозаффар абый! Мин сине эзләп... Синең хакта белешергә...

—Кайда сез?—дип сорады Мозаффар каты итеп.

—Безме? Без... Самаркин йортында. Күпер төбендәге ихатаны беләсезме?

—Нурзифа, дөресен әйт, сине анда көчләп алып килделәрме? Шулаймы?

—Юк, мин үзем...—дип бытырдады тәмам каушап калган Нурзифа.—Син үзең кайда соң?

Хәнәфи аның калтыранган кулыннан трубканы тартып алды да, мыскыллы көлемсерәп:

—Әйт инде, сабакташ, кайда икәненне!—диде.—Адресыңны белсәләр, хатының килеп алыр, дип куркасыңмы әллә?

—Син... Нурзифага барып ябыштыңмыни инде?..

—Әйтте бит инде, уртак эшебез бар безнең.

—Нинди уртак эш?! Нишлисез сез анда?!

Нурзифа, аңына килеп, трубканы тарткалый башлаган иде, Хәнәфи сиздерми генә аппарат төймәсенә төртеп, сөйләшүне өзде.

—Менә күрдеңме,—диде тәмам коелып төшкән Нурзифага.—Кайдалыгын әйтәсе килми. Ә син аның өчен борчылып йөрисең.

—Ник шалтыратканын әйттеме соң ул?
—Синең кайдалыгыңны беләсе килгәндер, бәлки...
—Кайсы номердан шалтыратты икән?
—Күрмисеңмени, безне селектор аша тоташтырдылар.
—Тоташтырган кешедән сорарга...
—Анда гади телефон бездә. Определитель номера дигән нәрсә юк... Ташла, Зифуш! Алда шундый зур эшләр торганда, юк-бар белән баш катыралар димени! Иң мөһиме, ул исән-сау. Тынычлан. Әйдәле, шуның хөрмәтенә тагын берне күтәреп куйыйк...

Нурзифа урындыгы аркасына элеп куйган сумкасын алды.
—Минем вакытым юк. Төшке тәнәфес бетеп килә.
—Син кухняны карамадың бит әле.
—Соңыннан... Йә планың бирегез хәзергә. Караштыра торырмын.
Күңелен ниндидер шом баскан, моннан тизрәк чыгып китәсе килә иде аның.
—Хәзер машина белән озатып куярлар,—диде Хәнәфи.
—Кирәкми! Мин трамвай белән тизрәк кайтам!

## Маңгайга маңгай килеп

Нурзифаның әйткәннәре телефон чыбыгының аргы башындагы Мозаффарның башына күсәк белән китереп органдай тәэсир итте. Самаркин йортында! Аның тышкы кыяфәте күзгә төртелеп торса да, эчендәгесе караңгы! Тирә-ягында беркайчан кеше-кара күренми! Анда сине нишләтсәләр дә була. Акырсаң-бакырсаң да һичкем ишетмәячәк!..

Шунда барып, калын диварлар артында Хәнәфи белән бикләнеп утырырга Нурзифаның башына тай типмәгән. ... Мөгаен, мәҗбүр иткәннәрдер. Мозаффарның үзе белән башка сыймаслык кыланганны, кыз баланы нишләтмәсләр?..

«Кайда син?»—дип сорый. Димәк, Хәнәфи ана берни әйтмәгән. Бу хәтле явыздыр дип аны кем уйлаган!

Ә бит эче кара икәнлеге электән үк сизелгәли иде. Тик бу хакта уйланырга җитди сәбәп булмады кебек. Яшьлеген бер курста, бер остаханәдә үткәргән ике «буяудаш» соңгы елларда сирәк очраша торган булып киттеләр. Аратирә кичәләрдә, күргәзмәләрдә йөзгә-йөз бәрелешкәндә, сүзләр «исәнмесаумы»дан, аралашу—кул кысышудан ары узмады.

Алай да колакка, Хәнәфи дөньяның тоткасын үз кулына алган кәттә егетләргә, атап әйткәндә, даны шәһәргә генә түгел, бөтен илгә таралган Самаркинга елышкан, аның тирәсендә бөтерелә икән, дигән хәбәрләр килеп ирешә иде. Шәхси тормышын да акыл белән корып җибәргән—шул ук Самаркинның туганнан туган сеңлесенә өйләнгән, шәһәр үзәгеннән фатир алган, кызы үсеп килә икән. Аның турында бер дә гаепләп түгел, хуплап, хәтта кызыгып сөйлиләр иде. Шушындый вакытта да күңелен төшермәгән, башын салындырмаган, киресенчә, мантыганнан мантый барган егетне ничек гаепләмәк кирәк?

Әнә бит ул, Хәнәфи, ничек яши! Кемдер аның яңа ачылган «Якитория» дигән япон ресторанының чыгып килгәнен, кемдер кара «Джип-Чероки» машинасында выжт итеп узып киткәнен күреп калган. Менә ичмасам, яши белә кеше! Корышып каткан кылкаләменә ябышып ятмый!

Шуңа күрә күргәзмә ачылган көнне халык арасында аны да күреп, Мозаффар гаҗәпләнеп куйды. Дөрес, Рәҗәповны уртага, башка рәссамнар янына чакырмадылар, чөнки зур залның диварларында аның бер картинасы да эленмәгән иде. Бу гаҗәп тоелмады: аны кылкаләмен

күптәннән ташлаганга саныйлар, остаханәгә эзен суытуы да бу фикерне раслый иде.

Беренче көнне күргәзмәдә ыгы-зыгы житәрлек була, үзеннең дә күңел очынган чак, шуна күрә бу йөз чалынды да онытылды.

Ә ул икенче көнне дә килде. Бу юлы инде залда Мозаффар ялгызы гына иде. «Прагага кайсы картиналарны алып барырлар икән?..»—дип борчылды ул. Ә бәлки, берсен генә сайларлар? Ул исә күпкә өметләнә, шул ук вакытта күңелен шик корты кимерә иде. Ни булмас бу дөньяда...

Ул шулай уйланып торганда, Хәнәфи килеп керде. Нечкә жыерчыклар белән сыргаланган каты маңгае өстендә шактый сирәкләнгән көлсу чәчен гадәтенчә лак белән катырып, тырпайтып куйган. Бик тә пөхтә күксел пинжәгенең төймәләрен ычкындырган, керсез ак күлмәге астында, абруйны арттырырлык кына булып, корсагы беленеп тора. Ачык изүендә юан сары алтын чылбыр елкылдый. Буй-сын белән алдыра алмаса да, кыяфәте шәп!

Исәнләшеп кул кысышканда, дымлы бармаклары жинелчә калтыранган кебек тоелды. Чырай майлы, юка иреннәр дусларча елмая, ә менә куллар ихлас, алар алдый белми...

—Котлыйм,—диде ул, як-ягына карангалап. —Мондый күргәзмәләрнең түрендә булу зур нәрсә ул. Кичә рәтләп карап та булмады, бүген иркенләп йөрермен, дип килдем.

Алар зал буйлап киттеләр. Әкрен атлап барганда, Хәнәфинең карашы картиналар өстеннән шуып кына узды. Каршыдагы диварга житкәч кенә тукталып калды ул. Биредә Юлдашевның әсәрләре аерым урын алган иде. Чын натурага тугрылыклы эшләнгән «Мишә буенда көз» күренеше... «Давылда» дигән картинада ботак-сатаклары каты жилдән болганып, уралып беткән карт имән сурәте... Монысы нәкъ чынбарлыктагыча ук түгел, хыялдагыча, импрессионистларчарак.... Беренче күз салуга: «Болай булмый!»—дисең. Ләкин кузгалып китә алмыйсың. Нәрсәдер тота, нидер жибәрми. Ахыр чиктә: «Ә чыннан да шулай бит»,—дип куясың.

Мозаффар буяудашының нәкъ шушы әсәр хакында ни дә булса әйтүен көткән иде. Әмма Хәнәфи сүзсез генә алгарак узды. Натюрмортлар да, сәнгать белгечләре тарафыннан яхшы дип бәяләнгән шәһәр күренешләре дә аның аерым игътибарына лаек булмады.

Портретлар янына килеп житкәч кенә, аяклары идәнгә беректе, йөзе үзгәреп китте егетнең. Һәм Мозаффар аның бирегә нәкъ менә шушы портретларны күрер өчен килгәнен аңлады. Дөресрәге, аларның өчесенә озаклап карар өчен... Менә «Мишә буенда» дигәненә төбәлде. Анда, таллар артында бер кыз су керергә әзерләнеп чишенгән дә, агач ботакларын озын-нәфис бармаклары белән ике якка каерып, үрелеп караган. Берәрсе килеп чыгып, аны ялангач килеш күрмәгәе, дип шикләнә... Таныш йөз, таныш караш. Яфраклар белән ышыкланган гәүдәсе исә өзек-өзек сызыклар белән шәйләнә.

—Натураны яшергәнсең,—диде Хәнәфи кипшенгән иреннәрен ялап.— Нишләп алай? Натурщицасы үзеңнеке бит...

Жавап көтмәде кебек, үз уйларына бирелгән, ак чыраена майлы елмаю кунган иде. Берничә тын басып торды ул шулай. Аннары карашын идәнгә төбәп:

—Комиссия килеп карагандыр бит инде?—дип сорады.

—Ачылган көнне кайберләре күренгән иде. Соңрак бергәләшеп килеп карарлар, бәлки.

—Аларга монда килеп йөрмәсәләр дә була. Кабинетларында киңәшеп, һәммәсен хәл кылганнардыр инде. Сине алып барырлар, әлбәттә. Баеп

кайтырсың шәт, ә? Кайсыларын сатмакчы буласың инде?

—Белмим әле. Комиссия кайсын сайлар. Әгәр алып барсалар, сораучы булса, уйлап карарбыз.

—Андагыларның нәрсәгә кызыгасын да белеп булмый шул...—дип, көрсенеп куйды Хәнәфи.—Бөек рәссамнарның бик күбесенә үлгәч кенә дан килә. Ә бит адәм баласына исән чакта кешечә яшәргә кирәк! Талант иясе бүген ни ашыйм икән дә баламның тамагын ничек туйдырыйм икән, дип баш ватарга тиеш түгел!

Ул астан сөзеп, киная белән Мозаффарның таушалган джинсы чалбарын, түшенә теннис ракеткалары ясалган ак футболкасын күздән кичерде. Карашы өстән аска таба түгел, астан өскә таба шуышты. Ирен читләренә кимсетүле көлемсерәү кунды. Әллә соң бу торган саен ныграк эче поша барган Мозаффарга гына шулай тоелдымы?

—Кызганыч...—дип куйды әле житмәсә.

—Нәрсәсе кызганыч?

—Кызганыч, мондый күргәзмәләргә бөек рәссамнарның картиналарыннан күчермәләрне кую гадәте юк. Ә комачауламас иде! Бигрәк тә хәзерге көндә... Син ничек уйлыйсың?

—Берничек тә уйламыйм. Аннан башка гамьнәрем дә житәрлек.

—Димәк, килеп терәлмәгәнсең әле. Югыйсә, балама сөт алырга акчам юк, дип зарланучы рәссамнар ишәеп китте. Ә син молодец. Бирешмисең! Принцип саклыйсың! Якты өметләр, зур хыяллар белән яшисең!

Бу сүзләрне әйткәндә Хәнәфинең күзләре кысылып, шундый мәгънәле елтырады, Мозаффарның сыны каткандый булды. Нәрсәгә ишарә ясый ул? Сине хатының асрый, димәкчеме? Ай-яй каты тешли! Ир-егет өчен хатын сыртын кимереп яшәүдән дә гарьлегрәк ни бар тагын?

Мозаффарның теле дә, кулы да кычытты, әмма кызарга ярамый, урыны ул түгел иде.

—Начальниклар әйтмешли, мин сине тоткарларга батырчылык итмим бүтән, Хангилдинны күрәсе бар иде, —дип зал түрендәге кечкенә ишеккә ияге белән ымлады ул. —Хәзергә сау бул.

Һәм жавап көтмичә, саубуллашу өчен кулын да биреп тормыйча, китү ягына борылды. Хәнәфи аны куып житеп, футболкасының кыска жиңеннән эләктерде:

—Мин шушы иртәгә остаханәгә сугылып чыкмакчы идем әле,—диде.—Аренда хакын синнән сорамыйлардыр бит?

Берничә ел элек Әгъләм Талипов яңа остаханәгә күчеп , монысын ике шәкертенә калдырганнан соң хакын Хәнәфи түли иде.

—Мин чутлап барам, кайтарырмын,—диде Мозаффар.

—Ташла, мин аны бурычка бирмим! Анда эшлим дип сине борчып йөрергә дә исәбем юк. Бер казанга ике тәкә башы сыймый. Иркенләп ижат ит, рәхәтлән! Тик бер киңәшәсе бар иде.

—Кил соң, уртак мәйдан бит...—диде Мозаффар.

...Икенче көнне остаханәгә Хәнәфи майлы белен кебек ялтырап килеп керде:

—Сәлам, татар халкының алтын кылкаләменә!

Портфелен ике куллап корсагына терәп тоткан, дикъкатьне шуңа юнәлтергә теләгәне сизелеп тора. Затлы әйбер шул: тышы крокодил тиресенә охшатып эшләнгән, алтын-сары бикләре күзне ертып, елтырый. Студент чакларлагысыннан шәп булса да, элеккечә калын-буаз үзе. Өстәлгә яткырып, биген шартлатып ачуга бозаулады да: эченнән ялтыравык кәгазьле озынча соргылт шешә, махсус төрелгән—мөгаен, «Бәхетле» дигән байлар кибетеннән алынган— бик юка кызыл һәм ак балык телемнәре,

бер кечкенә савыт уылдык, телемнәргә туралган ипи чыкты. Күчтәнәчен өстәлгә тезгәндә, Хәнәфинең чыраена унган-юмарт хуҗаларга хас елмаю кунды.

—Бусы кирәкмәс иде,—диде Мозаффар кашларын җыерып.

—Монын ни икәнен беләсенме сон әле син? «Һеннеси» коньягы! Кайчан да булса...—дигәч тотлыккандай булды Хәнәфи.—Безгә дә бер тиештер бит инде!—дип җөмләсен тәмамлады аннары.

«Безгә» урынына анын «сина» диясе килгән иде анын. Үзе, мөгаен, мондыйларны эчкәли торгандыр.

—Әйдәле, очрашу хөрмәтенә күтәреп куйыйк берне!

Ул янә кашын сикертеп, хәйләкәр елмайды да, чынаяктагы эчемлекне тамчылап кына имә башлады.

Мозаффар ике йотуда чынаякнын төбенә төшеп, балык телеме алып чәйнәде. Коньяк тамакны кыздырып узды, ләкин тәме, затлылыгы сизелмәде. Чөнки уйлар башкада иде. Ничек болай юмартланган әле бу «буяудаш»? Бер-бер сере булырга тиеш иде монын.

Хәнәфи исә җитди сүз башларга ашыкмады. Ипи телеменә уылдык ягып капты да, рәхәт чиккәнлеген күрсәтеп, күзләрен йомып, озаклап чәйнәде.

—Әйтәсе сүзен булса, тәмам изелеп беткәнче әйтеп кал,—диде Мозаффар.

—Әйдә, синен ин бөек әсәрен өчен күтәрик әле.

—Кайсы ул?

—Әнә тегесе...

Хәнәфи йөзен ишек ягына борган иде, сүзе өзелеп, чырае кинәт җитдиләнеп китте. Анда, диварда «Киенгән маха» белән янәшә эленгән, герцогиня Альба кебек үк чалкан яткан кызнын портреты телсез калдырды аны. Менә ул, чынаягын тоткан килеш, салмак кына торып басты да, киндер белән капланган мольбертны әйләнеп узып, ишек ягына атлады.

—Күрми дә торам... Кайчан ясадын син моны?

Анын карлыгып киткән тавышыннан, тырпайган чәчле башыннан, ак күлмәк астында салыныбрак торган инбашларыннан—бөтен кыяфәтеннән дулкынланганы сизелде. Берничә мизгелгә бүлмәдә тынлык урнашты. Менә ул, ниһаять, үзен кулга алды булса кирәк, борылып, авызын ерып елмайды:

—Шәп яткыргансын син моны! Тик шунысы кызганыч: моны күргәзмәгә куймаячаклар, сата да алмаячаксын. Чөнки ни күчермә түгел, ни яна әсәр дип булмый. Вакытынны бушка уздырып, буяуларны суга салгансын. Юк белән азаплангансын.

—Нишләп юк белән булсын? Кул күнектерер өчен әйбәт ул. Әгъләм абыйнын кинәшләрен онытмагансындыр бит?

—Ул чактагы кинәшләр хәзергә ярый димени!

Хәнәфи кире өстәл янына утырып, чынаягын ана таба сузды.

—Бушка эшләү кешенен абруена ифрат каты суга бит ул, —диде Мозаффарнын күзенә туры карап.—Бигрәк тә хәзерге заманда. Үтмәс товар эшлиләр, димени. Ә бит син товарнын үтемлесен эшли аласын. Кулыннан килә.

Хәнәфи янә каршы як диварга карап куйды.

—Әле күптән түгел генә телевизордан атаклы картиналарнын күчермәләрен ясап сата торган берәүне күрсәттеләр. Бәлки, күргәнсендер?

—Телевизорны сирәк ачам шул мин.

—Парижда, Венада, тагын әллә кайларда хан сарае кебек йортлары бар икән. Син анын остаханәсен күрсә-ән!..

Хәнәфи чыраена мыскыллау галәмәте чыгарып, керле түшәмне, обойлары каралган диварларны, бизәге сыдырылгын, анда-санда кыршылып тишелгән линолеумны күздән кичерде.

—Чын иҗат кешесе мондый урында эшләргә тиеш түгел. Әнә, бер атаклы язучы әйтә бит, әсәренне кухняда язсаң, аннан кәбестә шулпасының исе аңкып торачак, ди. Рәссамның картинасына да остаханәсенең төсмерләре күчми калмый!

Ул бераз тынып торды, әмма Мозаффар дәшмәде, эче пошкан кыяфәт белән, карашын почмакка төбәп, ялкау гына ипи чәйнәде.

—Сизә торгансыңдыр, бездә дә мөмкинлекләр ачылып килә,—дип дәвам итте Хәнәфи сүзен.—Сәнгать әсәрләренә ихтыяҗ арта. Элекке елларда көчле кешеләр акчага гына кызыктылар, чөнки кемнен миллионнары күбрәк, шул абруйлы саналды. Хәзер инде банклардагы миллион-миллиард долларлар белән генә бер-берсен шаккатыра алмыйлар. Күзләре сәнгатькә ачылып килә. Үзләренен шәп йортларын бик тә затлы картиналар белән бизәргә телиләр. Әнә, Самаркинны гына ал. Нинди ихата җиткерде, ә?

—Күрәбез...—диде Мозаффар йөзен тагын да ныграк сытып.

—Аның бит ул гына түгел! Төрле шәһәрләрдә әллә ничәшәр бүлмәле фатирлары бар! Мәскәү үзәгендә ике янәшә фатир сатып алып берләштерде, картиналар галереясы ясарга ниятләп йөри.

—Шунда, чын шедеврлар дигән булып, күчермәләр элеп куярмы?—дип мыскыллап сорады Мозаффар һәм чынаягыннан бер йотым кабып куйды.

—Ә кем аны аера? Бар шундый осталар, күчермәне оригиналыннан аергысыз итеп ясыйлар. Ә бит, уйлап карасаң, алар бик изге эш башкаралар. «Джоконда» да бөтен дөньяда күтәреп мактыйлар да бит, аны күрер өчен Парижга барып, Лувр музеена керергә кирәк. Кемнең генә андый мөмкинлеге бар? Ә күчермәсен—рәхим ит! Телгән һәр кешегә иң гүзәл картиналарны күреп сокланырга мөмкинлек биргәнг затлар өчен күтәрәм мин бу бокалымны!

Шулай дип үрә басты да чынаягыннан төбенәчә бушатты ул.

—Мин иртәгә Мәскәүгә китәм,—диде кире урынына утыргач.—Андагы реставрация остаханәсендә танышлар бар. Бер очтан кирәк-яракны алып кайтырга булыр иде. Борынгыча эшләнгән буяуларын, киндерен... Әйдә, бергә барабыз!

—Мәрхүмнәр хисабына тамак туйдырырга тәкъдим итәсең инде алайса,—диде Мозаффар. Хәнәфи, тончыгып, иреннәренә китергән чынаягын кире куйды.

—Шедеврлар үлгән кешенеке түгел, бөтен дөнья халкыныкы,—диде ул.—Кем теләсә шул карый, сатып ала яки күчермәсен ясый. Аның бер гаебе дә юк.

—Бу хакта сөйләшү булган иде бит инде,—диде Мозаффар.—Нәрсәгә кабатлап торырга?

—Кайчан?

—Моннан ун ел элек. Ант биргән көнне.

Хәнәфинең йөзе кызарынып китте.

—Онытмагансың икән...—дип куйды ул.

—Дүртәү идек без анда. Хәзер өчәү генә калдык, дип уфтанырга кала.

—Нишләп өчәү?

—Зөфәр шагыйрьлеген ташламады. Ансар —җырлавын. Мине үзең күрәсең.

—Мине сызып ташламыйсыңдыр бит?

—Син, минем белүемчә, башка сукмакларны таптыйсың . Әле, күрәм, мине дә үзенә ияртмәкче икәнсең...

—Җитмәгән икән әле сина,—диде Хәнәфи теш арасыннан сыгып.

—Нәрсә җитмәгән?

—Нужа калачын аз кимергәнсең икән әле. Прагага барып, бер әйбереңне сатып кайтсаң, шуның белән мантырмын, дип уйлыйсыңмы әллә? Нәрсә белән тамак туйдырмакчы буласың? Шушының беләнме?

Мозаффар анышмый да калды, Хәнәфи урыныннан кузгалды да, бүлмә уртасына атлады, мольбертны каплаган киндерне сыдырып алды. Һәм, андагы сурәтне күреп, тораташ булып катып калды. Моны һич көтмәгән Мозаффар бермәл тынсыз булып утырды, аннары сикереп торды да Хәнәфине этеп җибәрде, кулыннан киндерне тартып алып, мольберт өстенә ташлады.

—Нишләп син рөхсәтсез кеше әйберенә кагыласың?

—Синекеме?.. Зифа синең әйбереңмени?—дигән сүзләр хырылдап чыкты Хәнәфинең күгәргән иреннәре аша.—Син аны чишендердең дәмени инде?

—Синең ни эшең бар анда? Ни телибез, шуны эшлибез!

—Теләгәнеңне эшләденме? Ә ул мондый гамәлләрнең ни белән бетәсен беләме? Күнеле суынгач, Гойя үзенең сөяркәсен ни төсле итеп ясаган, ә? Урам себеркесенә атланган пәри карчыгы итеп, шулай бит? Син дә бу кызны себерке итәрсеңме?

—Житте...—диде Мозаффар тыны кысылып.

Хәнәфи аның йомарланган йодрыкларына күз салып алды да, читләшеп, урындыктагы портфеленә үрелде. Аннары ишеккә таба чигенде. Бусагага баскач:

—Шлюха ясагансың син аннан!—дип кычкырды.—Фахишә иткәнсең!

—Во-он!

Мозаффар өстәлдән «Һеннеси» шешәсен алып томырды. Тегесе читкә тайпылып өлгерде, шешә ишек борысына бәрелеп челпәрәмә килде, идәнгә пыяла кыйпылчыклары сибелде, коньяк тамчылары чәчрәде.

Баскыч ягыннан аяк тавышларына кушылып, Хәнәфинең каты кычкырынганы ишетелде:

—Күрсәтермен әле мин сиңа! Аяк астымда аунап ятачаксың әле!.. Белмисең әле син мине!

Мозаффар аның артыннан көлеп карап калды. Буяудашының нәрсәләргә сәләтле икәнен белеп житкермәгән иде шул әле ул.

## Үч алуның ысуллары мең төрле

Баскычтан ничек төшкәнен, аскы ишектән ничек атылып чыкканын сизми дә калды Хәнәфи. Тротуарга баскач, бер тын акылын җыя алмыйча торды, чалбар кесәсеннән кульяулык алып, битен сөрткәләде, күлмәк түшендәге коңгырт тапларны сыпыргалады. Үзе һаман авыз эченнән янау сүзләре мыгырданды.

Сак кына сызгырган тавыш ишетелде. Почмактагы күксел «Дэу Нексия»нең тәрәзәсеннән берәү башын сузган иде.

Хәнәфи исенә килеп, аңа таба атлады. Машинаның алгы ишеген ачып, портфелен арткы утыргычка томырды да, лап итеп алга кереп утырды, үзе дә сизмәстән тешләрен шыгырдатып куйды.

—Кем болай итте сине?—дип сорады шофер.

—Кретин! Ничтожество!—дип, теш арасыннан ысылдады Хәнәфи карашы белән йортның өске катына төбәлеп. —Мин сине сындырмасаммы?

Шофер рульдән кулын алып, ишекне ачты да машинадан чыгарга омтылыш ясады:

—Әйдә, кереп чыгыйк әле.

—Тукта!—дип аның ала-кола күлмәгеннән тартты Хәнәфи.—Нишләмәкче буласың анда?

—Хәзер игә китерәбез без аны. Ефәк кебек булачак, күзгә генә карап торачак!

—Йодрык белән хәл ителә торган мәсьәлә түгел бу сина!

Шофер кире урынына утырды.

—Ә ничек хәл итәргә?

—Уйларга кирәк.

Шофер кашларын җыерды, әмма каршы әйтмәде. Моторын кабызып, газга басты да, машинаны салмак кына борып, олы урамга чыкты. Алар Казансу аша салынган күпергә таба киттеләр.

Халыкның эштән кайткан чагы, урамда машина күп, светофорларда озак-озак торырга туры килде. Бераздан Хәнәфинең сулышы тигезләнгән кебек булды.

Рульдә утырган Кырыс кушаматлы, утыз бишләр тирәсендәге кеше Самаркинның ихатасын саклый торган биш егетнең башында тора, үзенә күрә командир иде.

Барыбызның да күз алдында: үзгәреш елларында ишек-капка төпләрендә каравыл торучыларга ихтыяҗ бик нык артты. Элеккеге конторларның ишеген пенсионер Мишә дәдәй яки Сәхәп бабай саклап утыра торган иде. Хәзер андыйларны күрмәссең. Тышында алтактасы булган һәр ишекне ачып керүгә будка куелган, аннан сиңа форма кигән егетнең тук чырае күренеп, үткен күзләре текәлә.

Сакта торучы бу кавем халыкның шактый күп һәм, әйтергә кирәк, куәтле өлешен тәшкил итә. Бер карчыкның шундый каравылчыны күргәч:

—И ходаем, бу ир заты да эштән кайткач хатынына, ардым, ашарга бир, дип әйтә микән?—дигәнен ишеткән бар. Күпләр шулай гаҗәпләнәдер, дип беләм.

Күксел «Дэу-Нексия»ның рулен боргалап барган Кырыс та шул кавемнән иде. Тик менә кайткач ардым дип зарланырга һәм ашарга сорарга хатыны гына юк—буйдак иде ул. Әфган сугышыннан исән кайткач, бер укытучыга өйләнгән булган да, озак яши алмаганнар. Утлар-сулар кичкән егетнең какшаган, тузган холкы сәбәп булганмы моңа, һәркемне тәрбияләргә, һәр кешегә акыл өйрәтергә күнеккән укытучының бәйләнчеклегеме, анысын төгәл генә әйтеп булмый. Һәрхәлдә алар берничә ел әле килешеп, әле пыр тузып талашып яшәгәннәр дә, ахыр чиктә хатыны, үзара сугышып борынын сындырганнан соң, Кырысны үзенә якын китермәс, малаен күзенә чалындырмас булган.

Хәзер менә Самаркин ихатасындагы төзелеп бетмәгән кечерәк бинаның бер бүлмәсендә яши егет.

...Шактый вакыт эндәшми барганнан соң, ул, сугышта алган җәрәхәтләрдән шадраланган, шакмаклы чыраен юлдашына таба бормыйча гына:

—Нинди бәндә инде ул?—дип сорап куйды.

—Художник... Мазила несчастный...

—Аның ишене сындыру авыр булмас, —диде Кырыс.

—Нишләп?

—Художник единоличник бит ул. Командасы юк. Кесәсе дә такырдыр әле. Шулаймы?

—Бүре улый кесәсендә!—Хәнәфинең эченнән янә ялкын теле ургып

чыккандай булды.—Ә кыланмышлары кырга сыймый! Олигархмы әллә диярсең!

—Фәкыйрь, димәк, яклаучысы юк,—дип үз уйларын йомгаклап куйды Кырыс.—Андыйны нишләтсәң дә була. Үч алуның мең төре бар аның. Теләсә кайсын сайла.

—Мәсәлән?

—Мәсәлән, машина астына керүчеләр күпме. Үз гаебе белән. Элементарно!

Хәнәфи фыр-р итеп куйды.

—Сезнең шул булыр инде. Таптау да изү, үтерү дә бетерү. Сүз урам хулиганы турында түгел, рәссам турында бара! Сәнгать кешесе турында!

—Нәрсә, сәнгать кешесе башка камырдан әвәләнгәнме әллә?

—Әйе шул, башка камырдан.

—Андыйдан үчне дә башкача алалармы?

—Әйе шул, башкача! Гәүдәсеннән котлет ясап түгел! Хәер, сәнгатьне, матурлыкны аңлыйсызмыни соң сез...

—Курыкма, дүрт саны төгәл калыр. Бернинди криминал булмаячак. Син аны миңа күрсәт кенә. Ни төслерәк... Калганына катышмассың.

—Сурәтен күрсәтсәм дә ярыйдыр бит? Студент чакта шаярып безнең портретларны ясаган иде. Кеше таный беләсеңдер?

—Обижаете, шеф!

—Ну, сурәтен бирермен. Адресын беләсең...

—Өй адресынмы?

—Сиңа аның өй адресы нәрсәгә? Остаханә мин кереп чыккан йортның бишенче катында.

Бераз уйлап торгач, Хәнәфи:

—Син анда кереп йөри күрмә тагын,—дип куйды.

—Керсәм ни була?

—Атаң башы була. Сиңа түгел, миңа! Шау-шу купса, иң беренче минем якага килеп ябышачаклар... Ашыгыч түгел, иртәгә мин Мәскәүгә китәм әле. Хужа чакыра.

—Озаккамы?

—Бәлки, өч-дүрт көн торырга туры килер, ә бәлки, бер көннән кайтып булыр...

—Алайса, вакыт бар икән...

—Ут капмаган...

Хәнәфи бераз уйланып торды, аннары Мозаффарның кызарынып чыккан чыраен, аннан да бигрәк мольберттагы сурәтне күз алдына китерде дә:

—Ничек кенә булса да, мин моны болай гына калдырмаячакмын! —дип куйды.—Тик белеп тор: милиция килеп кысылырлык итмәскә!

—Әйттем ич, бөтенесе о-кей булачак! Элементарно, эшлибез аны!

## Кан адреналинга сусаса

Утлар-сулар кичкән, жиз торбалар аша үткән Кырысның шактыйдан инде эче поша иде. Андый егетләр ипле-жайлы гына көн итә белми, вакыт-вакыт канга адреналин чыгару кирәк аларга. Башбирмәс рәссамны тезләндерү менә шул адреналин дигән нәрсәне суына башлаган канга мул итеп чыгарачак иде. Интеллигент кыйпылчыгын баш идерү ул сиңа урамда болганып йөргән бомжны тотып изү түгел! Аның ләззәте бөтенләй икенче. Мин рәссам, мин шагыйрь, мин жырчы дип борын чөеп йөрүчеләр белеп торсын: алар Кырыс кебекләрдән өстен түгел!

Тимерне кызуында сук, дигәннәр, эшне озакка сузуда мәгънә юк иде. Хәнәфи Мәскәү белән Казан арасында болганып йөргәндә, юл җилләре аның башын суытып, ачуын басып куймагае. Ул чакта кызык ясап булмаячак.

Тик менә ничек итеп ясарга ул кызыкны? Остаханәгә кермәскә кушылды. Бер уйласаң, анысы дөрес тә. Эт оясында көчле дигәннәр. Димәк, иң беренче итеп, оясыннан тартып чыгарырга кирәк аны. Һәм берәр ят җиргә илтеп тыгарга. Андый хәлгә тарыган бәндәнең, ничек кенә кәперәергә тырышса да, кикриге шиңми калмый. Башын идерү, тезләндерү җинеләя. Әлегә һичкемне тукмыйсы да, «чылатасы» да юк. Бер җилкенеп аласы гына. Көне дә бик уңай: син урыныңдамы, ни эш майтарасың, дип баш өстендә торучы «шеф» Мәскәүдә.

Үзең генә башкарып чыга торган түгел, булышчы кирәк иде. Кырыс иң элек Кармак белән киңәште. Кечкенә башы озын муенында алгарак салынып торган, чырае көньяк кешесенә тартым, тар җилкәле бу адәм беренче карашка гына сыек күренә, кешене боргычлап алып бәйләп салуның ысулларын бик яхшы белә иде. Өченчегә үзләре белән бер төркемнән таза гәүдәле, сөзгәк маңгайлы Абрекны алдылар.

Кызык ясау һәрчакта да җиңел генә бирелми. Монда да нык әзерлек, сабырлык таләп ителде. Алар көткән көнне рәссамның остаханәсенә килмәве дә ихтимал иде бит әле!

Ярый, кичкә таба ул килде. Тар урамның чатында торган «Дэу-Нексия» янынннан бик эшлекле адымнар белән узып китте. Машинаның корымланган тәрәзәләреннән өч пар күзнең үзенә текәлгәнен сизмәде, билгеле. Хәзер инде сәгатьләр буе, дикъкатьне киметмичә, аның кире чыкканын көтеп утырырга кирәк иде...

...Бу көннәрдә Мозаффарга җәяү йөрергә туры килде шул—шактый искергән «восьмерка»сының техосмотр вакыты узган иде.

Прагага ул комиссия сайлап алганнан тыш (кайсыларын сайлыйлар бит әле!) үзе белән тагын бер-ике картинасын алып барырга тели иде. Таныш музей директорына бүләк итәргә, мөмкинлек чыкса, сатарга... Шуларны әзерләп, төреп куярга иде исәбе.

Уйлана-сайлана торгач, вакыт узганын сизми калган—кесә телефонына күз салса, уникенче киткән иде инде. Болары шулай торып торсын, калганын иртәгә хәл итәрмен, дигән карарга килде ул.

Караңгы ишегалдында кеше-кара күренми, аулак урамга төннәрен машина сирәк керә. Андый-мондый хәвеф-хәтәр булыр, дип шикләнерлек түгел иде. Ләкин ул урам ягына борылуга, хәтәр кинофильмнарда була торган хәлләр башланды. Почмактан каршыга өчәү йөгереп килеп чыкты... Мозаффар юл биреп читкә тайпылмакчы булды, ә алар аның өстенә ыргылдылар. Ул бәргәләнде, чапаланды. Тик өчәүгә каршы берүзең нишли аласың? Бигрәк тә бу рәвешле көтмәгәндә һөҗүм итсәләр. Берсе биткә сасы чүпрәк каплап, сулышны кысты, икенчесе кулларны артка каерды.. Аны каядыр сөйрәделәр, башын аска идереп, типкәләп, төрткәләп, машинага илтеп тыктылар. Мозаффарның аңы чуалды...

Һәммәбезнең дә телевизор каршында, ала-кола киемле, башларына тишек кара оек кигән егетләрнең ничек итеп кемнәргәдер һөҗүм иткәнен карап утырганыбыз бар. Нинди гайрәт, төгәллек, оешканлык аларда!

Ярты сәгать үткәндерме-юкмы, шундый оешкан өч егет кызык «операция»не уңышлы башкарып чыкканнан соң, ике шешә, колбаса, ипи куелган табын артында кәеф-сафа корып утыралар иде инде. Канга адреналин җитәрлек сеңгән, күңелләр күктә иде.

Алай да Кармак бер урында канәгатьсезлеген белдереп куйды:

—Бигрәк әйбәт урнаштырдык инде,—диде. —Олы кунакмыни! Баз да

ярап торган булыр иде.

—Алай түгел ул!—дип каршы төште ана Абрек.—Аны моннан эт тә эзләмәячәк.

—Анысы шулай инде. Кемнен башына килсен.

—Эш анда түгел ул,—диде Кырыс.—Шеф обижать итмәскә кушты. Бәллүр савыт кебек саклап кына йөртергә наказ бирде.

—Белмәссен шефны да... Үзенен үче бар дисен, үзе кадерләргә кушкан. Үчен ничек кайтармакчыдыр?

—Интеллигент халкы синең ише түгел ул! Үчен башкача ала—хәнҗәрен йөрәккә түгел, бәгырьгә кадый!—диде Кырыс.

—Ә ничек була икән ул?

—Карарбыз, күрербез. Әйдәгез, бусын шеф өчен күтәрик әле. Морадына ирешергә язсын!

—Без—команда, бездә көч!—дип кружкаларын чәкештерделәр алар.

## Яшерен остаханәдә

...Анына килгәч Мозаффар шактый вакыт зиһенен туплый алмады. Бу нинди урын? Ул монда ничек килеп эләкте?

Ниһаять, остаханәсеннән чыккач булган хәлләр исенә төште. Әйе, анын кулларын каерып машинага тыктылар. Димәк, монда китереп ташлаганнар.

Ул авырлык белән торып утырды да чалбар кесәләрен капшады. Ачкычлары да, телефоны да урынында. Шылтыратырга була... Әмма телефонның тәрәзәсе тонган иде, Мозаффар анын төймәләренә төрткәләде, аннары тырнак очы белән эчен ачып карады. Сим-картаны алганнар—шылтыратып булмый.

Мозаффар торып ишеккә таба атлады. Башта сак кына, аннары жилкәсен терәп, көч белән этте, әмма ача алмады. Ишек бикле иде.

Ничек чыгарга? Һич булмаса, урам ягындагы узгынчыларның дикъкатен җәлеп итәргә?

Мозаффар бүлмәне күздән кичерде. Затлы кунакханәнең «люкс» бүлмәсе төсле иде ул. Яктылык түшәмдәге түгәрәк тишекләрдән сирпелә. Диварлар идәннән түшәмгәчә тар такта белән капланган. Сул якта зур күн диван, аның янындагы тәбәнәк пыяла өстәлдә сулы шешә, стакан. Уртада түгәрәк өстәл, анын янында сырлап ясалган дүрт урындык. Бер почмакта телевизор, икенчесендә суыткыч.

Ишеккә каршы як идәннән түшәмгә кадәр саргылт жалюзи белән капланган, аның тар тасмалары арасыннан көн яктысы саркый. Анда зур тәрәзәдер, күрәсең. Хәзерге вакытта банкларда дисеңме, башка бай оешмаларда дисеңме, шундый мода китте бит: яна биналарның тәрәзәләрен тоташ итеп диярлек уялар, әмма эчтән жалюзи белән каплап куялар да бүлмәләрне электр белән яктырталар. Тәрәзәләр эчтәгеләр өчен түгел, тыштан ялтырасын өчен генә куела шикелле. Монда да шулайдыр, күрәсең. Ачарга кирәк... Мозаффар тәрәзә борысы кырыннан салынып торган нечкә ак бауны тарткан иде, жалюзи шыгырдап күтәрелде, ә күз алдында тоташ дивар пәйда булды. Яктылык түшәм астыннан, тар уемнардагы озынча лампалардан бөркелә икән.

Мозаффарның тәне эсселәнеп китте, тыны кысылгандай булды. Сулыш алырга иркенлек эзләп, тагын бер тапкыр як-ягына караган иде, ян диварда тотка күреп алды. Ишекме әллә? Чыннан да, анда юыну бүлмәсе икән. Һәммә нәрсә—зәңгәрсу пәрдә артындагы ванна, юынгыч, краннар—затлы, яңа, чиста. Ян дивардагы элгечтә зур ак йөнтәс сөлгеләр, халат, каршы

якта зур көзге, аның астындагы киштәдә сабын, теш пастасы, кырыну өчен кирәк-ярак, эреле-ваклы шешәләр. Барысы да куллануда булган—шешәләр яртылаш, тюбиклар сытылган. Мозаффар ялтыравык краннарның үрдәк борынын күтәреп карады: суның салкыны да, кайнары да шаулап ага. Ул битенә салкын су сипте дә, сөртеп тә тормыйча кире чыкты.

Әгәр дә жалюзи артында бетон дивар булмаса һәм тышкы ишек ачылса, үзенне ерак бер шәһәргә килеп, кыйммәтле кунакханәгә урнашкан кебек хис итәр идең. Мондый командировкада атналап рәхәт кенә яшәп булыр иде. Ләкин менә мәҗбүри ябылып ятарга кем риза икән?

Нинди урын соң бу?

Соңгы елларда кинәт баеп китеп, бик югарыга үрмәләгән кешеләрнең бәгъзеләрен кулга алып ябып куялар бит. Төрмәләрдә алар өчен камераларны махсус җиһазлыйлар, дигәнне гәзитләрдә укыганы бар иде. Шундыйларның берәрсе микән әллә бу? Алай дияр идең, милицияне ничек кенә хурлама, алар ордерсыз-нисез, берни аңлатмыйча гына берәүне дә ябып куймый. Кеше урлап, акча сыгучылар дисәң, рәссамның байлыгы ташка үлчим икәнлеген һәркем белә.

Кем китереп бикләде аны монда? Ни кирәк аңа?

Ул, башын күтәреп, түшәм-диварларны тагын бер тапкыр күздән кичерде. Бүлмәдә, мөгаен, видеокамера бардыр. Аны кая яшерделәр икән?

Каршыдагы диварның тар такталары арасындагы эз бер төштә кинрәк түгелме? Әйе шул, кинрәк, башкалардан аерылып тора. Мозаффар тактаны эткән иде, ул ачылып китте. Эчтә караңгы иде. Ул кулы белән капшап, электр кабызгычын тапты. Ялт итеп ут кабынды. Биек түшәмдәге люстра остаханәне яктырта иде. Әйе-әйе остаханә иде бу! Мозаффарныкыннан тәбәнәгрәк, кысанрак, әмма бер кеше өчен менә дигән! Һәм, ни гаҗәп, һәммә нәрсә аның остаханәсендәге тәртиптә урнаштырылган иде. Алюмин кювет та бар хәтта. Эчендәге суда кылкаләмнәр... Ун як диварга киндер тарттырылган нечкә агач рамнар сөялгән.

Мозаффар уртада торган мольберт өстеннән киндерне йолкып алды. Аның күз алдында артык мул, кызыл янбашлы хатын, бу якка артын куеп, башын борган да янтаеп ята иде. Таныш сурәт! Ләкин тукта, чырае таныш түгел, башкача бит монын! Әйе-әйе, Нурзифа чалымнары ярылып ята анда!

Бернинди шик юк: Хәнәфи Рәҗәповның кылкаләме сылаган иде монын буяуларын. Мозаффар диварга сөялгән рамнарны берәм-берәм сурәтле ягы белән яктыга борып карый башлады. Менә җәйге кыр күренеше, менә каенга сөялгән кыз... Нурзифа ич бу! Тагын портрет—анда да Нурзифа. Тагын, тагын... Төрле урында, төрле кыяфәттә... Һәммәсе таныш кул, таныш төсләр белән ясалган. Бәй, Хәнәфинең остаханәсе ич бу! Рәҗәпов кылкаләмен ташлады, башын акча эшләүгә салды, дигәннәре юк сүз икән ләбаса! Ул биредә җан-фәрман тырмашып ята икән бит! Менә нилектән уртак остаханәдән бизде!

Ник соң әле ул бер генә картинасын булса да күргәзмәгә куймаган? Хәер, куярлыгы бармыни соң боларның? Үзе һаман Нурзифаны сурәтли, гел аны гына уйлый, күрәсең. Шунда Мозаффарның зиһене ачылып киткән кебек булды: карасана, Хәнәфи аны ярата икән бит! Үлеп гашыйк, өзелеп сөя икән! Нурзифа үзе моны белә микән соң? Ә бәлки, ул бирегә килеп, өлге булып та утыргандыр әле? Әллә ятып та торды микән?

Мозаффар янә мольберт каршына килде. Тынычланып китте: янтаеп яткан гәүдә—училищедагы натурщицаныкы иде. Хәнәфи аның муенына Нурзифаның башын утыртырга маташкан.

Ул, мөгаен, аны чакырырга кыймагандыр да. Чөнки сурәтләрен күрсәтергә ояла. Аларны Мозаффарныкылар белән чагыштырып карар да,

тәмам гайрәте чигәр, дип шүрли...

Менә нинди кисәүләр көйри икән анын янында! Җәһәннәм уты диярсең! Еллар буе янүга ничек чыдый икән? Түзә алмас хәлгә килгәндер, шуна Мозаффарны бирегә китереп япкандыр да. Үзе түгел, билгеле, ниндидер бандитлар яллап эшләгән ул бу хәтәр эшне. Ни төсле итеп үч алырга ниятли икән инде?!

Үзе кая соң әле?

Мозаффар алгы бүлмәгә чыкты да имән ишекне дөбердәтергә кереште.

—Ни кирәк?—дигән тавыш ишетелде тышкы яктан.

—Хәнәфи кирәк! Рәҗәпов!

—Бераз көтәргә туры килер.

—Күпме ул «бераз»?

—Бер-ике көн.

—Ике көн?! Ике көн нишләп ятыйм мин монда?

—Ял ит бераз.

Мозаффар ярсудан сулышына буыла башлады.

—Әй син! Чакыр монда Рәҗәповны!—дип кычкырды ишеккә аягы белән тибеп.

—Акырма! Ул юк әле. Ә әйтәсе сүзеңне селектордан әйт әнә.

—Селектордан? Кайда ул?

—Кирәк булса, табарсың.

Селектор остаханәдәге озын өстәлдә, буяу савытлары янында икән. Мозаффар анын төймәләренә төрткәләде—җавап булмады. Барысын бергә йодрык белән төя башлагач кына, карлыккан тавыш:

—Ватсаң, үзеңә начар булыр,—дип куйды.

—Рәҗәпов белән тоташтыр мине!

—Вакыт житкәч, үзе тоташыр. Әйттеләр бит инде сиңа: ул монда түгел.

—Килсен!

—Килер. Вакыты житкәч.

Селектор челт итте дә тынды. Мозаффар кызышкан иреннәрен ялады, тамагы кипкәнен тойды. Түр почмакка барып, суыткычны ачты. Анда эреле-ваклы шешәләр, казылык, сыйр, уылдык, телемләп туралган ак һәм кызыл балык, ипи бар иде.

Ул «Киндзмараули» дип язылган юан корсаклы шешәне алды. Саргылт шәрабне бәллүр бокалга тутырып салып эчеп җибәрде, аннары утырып ашарга кереште. Кызган башы бераз тынычланып киткәндәй, уйлары бер эзгә төшкәндәй булды.

Аннары остаханәгә керде. Биек өстәлдәге буяулар арасыннан күмер таякчыклары , кәгазь табып алды, утырып сызгаларга кереште. Анын кулы астында башы Хәнәфинекенә охшаган кырыгаяк пәйда булды.

## Башны ташка орырлык хәлләр

Хәнәфи Мәскәүдә бер генә көн торды, ике төнен поездда йоклап, төш турында кайтып та төште. Вокзалда аны Кырыс каршы алды. Вагонга кереп, «шеф»ынын кулыннан авыр юл сумкасын һәм зур, озынча төргәк алганда анын шадра чырае серле, юка иреннәрендә мәгънәле елмаю уйный иде. «Ни кылдылар икән инде тагын?»—дип уйлады Хәнәфи. Әмма сорашырга ашыкмады, чөнки эшнең никадәр хәтәр икәнен белми иде әле. Кара «Гранд-Чероки» кузгалып, урамга чыккач, Кырыс руль өстеннән алга караган килеш:

—Булды бит,—дип куйды. Аның бик тә канәгать кыяфәтендә тизрәк «шеф»ын куандырасы килгәне ярылып ята иде.

—Нәрсә булды?

—Тәпиеннән эләктердек без теге асыл кошны.

—Нинди асыл кош? Анлатыбрак сөйлә!

Мәскәүдә Хәнәфинең башын катырган нәрсәләр күп булды, ул инде китәр алдыннан булган сөйләшүне онытыбрак җибәргән иде.

—Теге сез әйткән пачкунны,—диде Кырыс.

Шунда гына Хәнәфи Мозаффарны исенә төшерде.

—Әйттем бит мин сина, кагылмаска, дип!

—Ә без кагылмадык... Бармак белән дә орынмадык... Үзегез күрерсез... Әле генә агачыннан өзеп алган алма кебек томраеп тора. Сезне көтеп утыра.

—Кайда?

—Үзебездә.

—Кайда ул «үзегездә»?

—Теге сезнең аскы каттагы бүлмәгездә.

—Остаханәдәме әллә?!

—Шунда инде.

—Ник керттең син аны анда?!

Хәнәфинең чырае гына түгел, башы-муены мәрмәр бюст төсенә керде. Бу галәмәттән югалып калган Кырыс машина бамперы белән алда барган трамвайны сөзә язды. Тормозларның каты чинавы, Кырысның әшәке сүгенүе, кинәт алга сөрлегеп, мангае белән алгы пыяланы вата язган Хәнәфинең сулышын ачып җибәрде. Аның беренче омтылышы—Кырысның шадра чыраен йодрык белән төю иде. Әмма мона кул озайтып булмый!

—Ә син беләсеңме кеше урлаган өчен ничә ел биргәннәрен?

—Ә кем әле монда кеше урлаган?—диде Кырыс көлемсерәп.—Урланган кешене шундый затлы җиргә китереп ябалармыни? Әшне судка житкерсә, кунакка килгән җиреннән китә алмый ятты, дисең дә бетте китте. Аның бер дәлиле дә, бер шаһиты да юк. Ә бездә шаһитлар өчтән дә ким булмаячак. Бөтенесе уйланган, шеф! Элементарно!

Буласы булган, буявы сеңгән—башны ташка орудан файда юк, ни кызган булса да, Хәнәфи моны анлый иде. Ул күзләрен чытырдатып йомды да, фикерләрен бер эзгә салырга тырышты.

Димәк, Мозаффар остаханәдәге картиналарны, этюдларны, Зифаның портретларын күргән... Моны күз алдына китергәч, эчке сызланудан нишләргә белмичә, Хәнәфи авырттырып иреннәрен тешләде. Аңа күрсәтә торган нәрсәләр идемени алар? Аны кертә торган җирмени ул?

Моңарчы Хәнәфи анда һичкемне аяк бастырмады. Ялгызы бикләнеп эшләде дә эшләде. Этюдлар, натюрмортлар, портретлар ишәя торды, тик аларны берәүгә дә күрсәтмәде. Студент чакта аның сурәтләренә күз салган остазларның, курсташларның чырае ничек сытылганы хәтергә нык сеңеп калган иде шул. Бигрәк тә ул сурәтләр Мозаффарныкылар белән янәшә эленеп торганда! Кулга диплом алганнан соң, остаханәдә дүртәү очрашканнары гел искә төшеп тора. Мозаффарны ничек-ничек күккә чөеп мактадылар анда Ансар белән Зөфәр, Хәнәфине исә ничек чеметеп-чеметеп алдылар. Сүз белән генә түгел, карашлары, кыланмышлары белән. Бигрәк тә Зифа алдында түбәнсеттеләр...

Ул чакта Ансарның сәнгатькә генә хезмәт итәргә ант итик, дип котыртуы да Хәнәфине кимсетү өчен эшләнде кебек.

Ант эчкәнгә июльдә ун ел тула. Быткыч Зөфәр, очрашкан саен шуны искә төшереп, кайчан жыелышабыз инде, дип сорамый калмый. Шагыйрьләргә

кызык кына булсын! Чын сәнгатьне анлый белсәләр ни әйтер иден. Һәммәсе Мозаффар стиленә, анын манерасына мөкиббән. Хәнәфи исә беркемне дә кабатламый, бөтенләй башкача, үзенчә яза. Килер бер көн, аны бәяләрләр!...

Тик менә кайчан килә бит әле ул көн. Ван Гогка килгән сыман үзе үлеп туфрак булгач, бәлки. Хәнәфинен исә исән чакта, менә хәзер үзен раслыйсы килә иде.

Күргәзмә буласын белгәч, анын йокысы качты. Аһ, шунда бер генә картинанны булса да элеп куйсалар иде! Юк, эленеп тору гына житми, Прагага баручылар арасында булсаң иде!

Ятып калганчы атып кал, диләр, Хәнәфи күргәзмәгә эләгергә талпыныш ясап карады.

Мона бер генә кеше—мәдәният министры Илгизәр Фаязович Кәримов аша гына ирешеп була, дигән фикергә килде ул. Самаркин төрле концертлар кую, юбилейлар үткәрү өчен акчаны шактый еш бирә, зур сәхнәләрдән, затлы табын түрләреннән ана рәхмәт сүзләре еш ишетелә. Исеме янгырый, ә жисеме еракта йөри. Анын вәкиле буларак, рәхмәтләрне Рәжәпов кабул итә. Шунлыктан ул министр өчен күз күрмәгән кеше түгел иде, телефоннан шалтырату белән кабул итәргә ризалык бирде.

Хәнәфи күрсәтергә дип өч картинасын алып барды. «Казансу буе»н, «Татар бистә»сен һәм, әлбәттә инде, кырын яткан хатын-кызны.

Министр аны мондый йомыш белән килер дип башына да китермәгән иде. Күргәзмә хакында сүз кузгалуга, әле генә елмаеп каршыга килгән кеше кинәт үзгәрде дә куйды: какча чыраенда балкыган елмаюы сүрелде, нык чаларган, күперенке чәчләре астында, мангаенда ике тирән сыр хасил булды, күксел күзләренен карашы салкынайды.

—Кайсы картиналарны кую-куймау мәсьәләсен мин хәл итмим бит, комиссия карый,—диде ул урындык аркаларына сөяп куелган картиналарга керфек кенә сирпеп алгач.—Анда үз кешеләрегез бар—рәссамнар берлеге әгъзалары. Ник шулар белән кинәшмисен?

—Сезнен үз фикерегез ничек соң?

Хәнәфи мөлдерәп анын күзләренә карады. Билгеле бит инде, министр яклап сүз әйтсә, каршы килүче булмачак.

—Алар ни дисә, мин шуна риза,—диде Илгизәр Фаязович карашын тәрәзәгә төбәп.

Бүтәнгә баш орудан мәгънә юклыгы Хәнәфи өчен көн кебек ачык иде.

Күргәзмә ачылганда ниләр кичергәнен ул үзе генә белде. Башкаларны сөендергән, өметләндергән бу вакыйга анын күптәнге йөрәк ярасын гына тырнады.

Әгәр дә син кем дә булса берәү белән тигезләшергә теләп тә, анын югарылыгына күтәрелә алмыйсын икән, аны үз дәрәжәнә, ә ин яхшысы, тагын да түбәнрәк тартып төшерергә кирәк. Бу—күптәннән мәгълүм хакыйкать. Мозаффарны үз дәрәжәнә төшерүнен бердәнбер чарасы—аны акча өчен, фәкать табыш алу өчен генә эшләтү иде. Монын бер ысулы булырга тиеш иде, чөнки фәрештә түгел, адәм баласы бит ул, гап-гади бер бәндә!

Кызган башка килгән фикер, беренче карашка акыллы тоелса да, бик сирәк очракта гына дөрес булып чыга. Хәнәфи ун ел элек, ант биргән кичнe күчермәләр ясап сату турында кузгалган сөйләшүне, Мозаффарнын бу гамәлгә каршы ничек чәчрәп чыкканын исенә төшерде... Ах, әгәр дә аны бу эшкә тартып булса!

«Һеннеси» коньягы күтәреп остаханәгә барганда, Хәнәфи сабакташы

мондый тәкъдимгә берсүзсез риза булыр дип өметләнмәде, билгеле. Кылын тартып карау иде аның нияте. Эч серләрен ачтырсаң, нечкә җирен табып булыр, бәлки. Әле Прагага барыр юлын кисәр өчен жае да табылыр иде...

Кыскасы, сабакташы белән әрепләшү, ачуланышу Хәнәфинең уенда да юк иде. Ләкин сөйләшү һич тә ул күз алдына китергәнчә барып чыкмады. Барып керүгә үк Мозаффар аңа караңгы чырай күрсәтте. Ә инде мольбертыннан киндерне тартып алгач, бөтенләй котырды.

Бу мизгелне исенә төшергән саен Хәнәфинең жаны-тәне калтырана башлый. Мольберттагы сурәт аның бөтен вөҗүден эссе суга коендыргандай итте... Мозаффар Нурзифаны чишендереп, берничә көн дәвамында, сәгатьләр буе каршысында ялангач яткырган. Ул аны сөяркәсен көтеп яткан хатын рәвешендә тасвирлаган!

Көткән-көткәндер дә көтеп алгандыр, әлбәттә. Хәнәфине кулына да орындырмаган, фәрештәгә тиң күренгән кыз бала Мозаффарныкы!

Бу инде ижатынны бәяләмәү, рәссам буларак түбәнсетү генә түгел. Еллар буе яшерен сөю утында янган, Нурзифа аңламас, көләр генә дип куркып хисләрен белдерергә жөрьәт итми йөргән Хәнәфи өчен бу—аның ирлегенә китереп ору, шәхесен бетерү дигән сүз иде. Мозаффар монда да аны уздырды!

Ул көнне остаханәдән чыкканда Хәнәфинең хәле бик мөшкел иде. Кырыс кебек бәндәләр алдында, гомумән шоферлар янында артык ачылырга ярамаганлыкны яхшы белсә дә, бу юлы ул тыела алмады. Һәм менә нәтиҗә...

...Хәнәфи рульгә ябышкан Кырыска нәфрәт белән карап алды.

Алар Казансу күпереннән чыгып, каенлык белән капланган үргә менделәр дә, яшелгә буялган биек, киң тимер капка каршына килеп туктадылар. Капка шыгырдап ачылды, машина баганаларга кутәртеп куелган будка яныннан эчкә узып, зур бинаның ишеге каршында туктады.

—Әйберләрегезне кая кертим? Подвалгамы?—дип сорады Кырыс багажник ягына ымлап.

—Торсын шунда!

Хәнәфи арткы утыргычтан крокодил тиресенә охшаган портфелен алды да, имән ишектән кереп китте. Киң баскычтан икенче катка менеп, сулдагы бүлмәгә узды. Хәлсезләнеп, урындыкка утырды. Инде нишләргә?

Кайсы яктан гына карасаң да, иң элек Мозаффарны чыгарып жибәрергә кирәк иде. Бу эшне озакка сузу—ут белән уйнау дигән сүз. Мозаффар урынында бүтән кеше булса, Кырыс әйткәнчә, барсын да шома гына үткәреп жибәрергә мөмкин булыр да иде бит, әмма бу башка... Әлбәттә, иң элек янына кереп, гафу сорарга, үзеннең бу эшкә катнашын юклыкны аңлатырга кирәк. Ахыр чиктә теге көнне Хәнәфи түгел, Мозаффар кызды бит, ул буза куптарды... Шуны исенә төшерергә... Өстәл янына утыртып сыйларга. Алай да игә килмәсә, тәртәгә типсә, акча сонарга... Күпме сораса шулкадәр—мондый очракта санашып торып булмый... Соныннан машина белән озатып куярга.

Четерекле хәлдән бу рәвешле шома гына чыгу бик мөмкин эш кебек тоелды. Мозаффарның да монда ятасы килмидер. Бик жаваплы көннәре бит—Прагага барырга әзерләнгән чагы. Аннары милициягә әләкләп, гауга куптарып йөрергә сәләтле дә түгел ул.

Шуларны уйлагач, Хәнәфи бераз тынычланып киткәндәй булды. «Иң элек сискәндерергә кирәк аны,—дип уйлады ул.—Көтелмәгән хәлдән югалып калсын, зиһене чуалсын. Ул чакта сөйләшү дә жиңелрәк булыр». Шулай эшләргә Хәнәфинең мөмкинлеге дә бар иде.

Әмма бу юлы да ул ниятләгәнчә барып чыкмады. Бер абынган гел абына шул ул...

...Мозаффар алгы бүлмәдә, өстәл артында, остаханәгә аркасы белән, имән ишеккә яны белән утырган иде. Алдындагы кәгазьгә гасабиланып күмер белән сызгалый, аяк очында сурәтле кәгазь кисәкләре чәчелеп ята иде.

Кинәт кемдер:

—Саумы, буяудаш!—диде.

Мозаффар сискәнеп турайды да тышкы ишеккә карады. Ишек ябык, әгәр ачылып ябылган булса да күренми калмас иде. «Саташам инде әллә?»—дигән уй узды анын башыннан. Сикереп торып борылган иде, Хәнәфине күреп, имәнеп китте. Ишек ачылганы сизелмәде, аяк тавышлары ишетелмәде, каян пәйда булды бу!?

—Син... ничек кердең монда?

Хәнәфи жавап бирергә дип авызын ачкан иде, идәндәге, өстәлдәге кәгазьләргә күзе төште дә, әйтер сүзен онытып катып калды: аларда дөньядагы иң кабахәт хәшәрәтләр ясалган иде: кыргаяк, таракан, елан, канәчкеч яркanатлар... Һәммәсе адәм чырайлы, һәммәсендә Хәнәфинең чалымнары ярылып ята.

Ул арада Мозаффар аңына килеп, анын артына чыкты да, таза беләге белән муеныннан урап та алды.

—Әйдәле, чыгыйк әле моннан!

Һәм артыннан төрткәләп имән ишеккә китереп терәде.

—Ач!

—Миндә... ачкыч юк...—диде кызарынган-бүртенгән Хәнәфи хырылдап.

—Ачтыр!

—Жибәр...

—Чыккач жибәрермен!

Мозаффар ишеккә типкәләргә кереште:

—Ачыгыз, югыйсә үтерәм мин моны! Ачыгыз!

Тышкы яктан дөбердәгән аяк тавышлары, кемнеңдер кычкырынганы ишетелде. Ишек әчке якка ачылды, Мозаффар белән Хәнәфи егылып киттеләр. Атылып кергән шадра чырайлы ир заты Мозаффарны чәченнән умырып, Хәнәфидән аерып алды да, тибеп читкә этәрде. Үзе шундук кире чыгып, ишекне япты.

Мозаффар Хәнәфине янә эләктермәкче булып артына борылды. Бүлмә буш иде... Остаханә ягында да, юыну бүлмәсендә да беркем юк... Кая китте бу мөртәт? Ишектән чыгып шыларга өлгермәде, бүтән качар урын да юк! Таш диварлар аша үтә торган әкияти көче бармы әллә? Ә бәлки урыны сихерледер?

Мозаффар тәмам аптырашта иде. Нинди жир соң бу? Кай төштә, кайсы урамда, нинди бинада? Моны ничек белергә?

Анын күзе өстәлдәге селектор аппаратына төште. Ул кабаланып трубканы алды:

—Хәнәфи?.. Рәжәповны бир миңа!

—Заткнись!—дигән тавыш ишетелде аннан.

...Ә бу минутларда өске каттагы кунак бүлмәсендә Хәнәфи, зур көзге каршына басып, кызарып чыккан муенын сыйпый-сыйпый, күлмәк якасын төзәтә иде. Чырае качкан иде анын, чөнки хәзер инде вакыйгаларның хәтәр төс алганы аермачык иде.

Нишләргә?.. Шушы сорауга жавап эзләп миңгерәгән кичне шылтыратты да инде ана Нурзифа. Хәнәфи борчуларын сиздермәскә тырышты, шат тавыш белән сөйләште. Ә бәлки, бу четерекле хәлдән чыгуда кызның ярдәме тияр?

## Бормалы баскыч астында

...Нурзифаны озатып кире кергәндә, Хәнәфинең кәефе яхшырган иде. «Ай-һай кирәкле минутында шылтыратты теге!—дип уйлады ул.

Аннары почмактагы бормалы тар баскычның култыксасына таянып, аска үрелеп карады. Анда төшә башласаң, биш-алты борылыш ясаганнан соң, бикле ишеккә барып төртеләсең. Хикмәтле ишек ул: тыштан гына күренеп тора, эчке яктан исә барлыгы сизелми. Аның артында остаханә, анда Мозаффар... Әле генә Зифа белән аны ун-уникe адым гына аерып тора иде. Әгәр алар моны белгән булсалар, нишләрләр иде икән?.. Белмичәрәк торсыннар әле! Билгесезлек дигән нәрсә адәм баласының күңелен нык изә, ихтыярын йомшарта ул.

—Шәп иттемме үзеңне?—дип аска бармагы белән янады Хәнәфи. —Бәгыреңә утлы сөңге кададыммы?

Һәм кинәнеп көлеп куйды. Хәзер инде тынычлабрак, ашыкмыйча уйларга була иде. Ахыр чиктә, бер ябып куйган кешене чыгармыйча ике көн тоттыңмы, ике атнамы, аның аермасы, мөгаен, юктыр. Авылча әйтсәң, сыер кәлҗемәсенең кырыена бастың ни дә уртасына бастың ни...

Мозаффарны бу килеш кенә чыгарып җибәрергә һич тә ярамый иде. Шау-шу куптарса, Хәнәфинең бөтен язмышына кара тап төшәчәк. Андыйны Самаркин янында тотар микән әле? Байлар үзләре кырын юлларны күп таптасалар да, вак-төяк аркасында пычранып йөргәнне женнәре сөйми. Бәҗәсы дип тормас, куар да чыгарыр. Талканы коры!

Сабыр төбе сары алтын, дигәннәр, Хәнәфи ашыкмаска булды. Әнә, Мозаффар бәргәләнсен, ул чыгырыннан чыксын! Әгәр һаман шушылай чәбәләнсә, дуласа, Прагага барудан коры калмагае! Шуны уйласын!

Шул минутта Хәнәфинең теләге кабул булгандай, селектор зеңгелдәп куйды.

—Теге пачкун сине сорый,—диде Кырыс тавышы.

—Тоташтыр!.. Рәҗәпов тыңлый!

—Нурзифа белән сөйләшергә мөмкиндер бит?

Мозаффарның ачуын тыеп, тавышын йомшартырга тырышканы сизелде. «Әһә, сыгыла башладыңмыни?»—дип уйлады Хәнәфи.

—Ул китте инде,—диде ул трубкага.—Шул гынамы?

—Юк... Тукта... Сөйләшик әле... Сиңа миннән ни кирәк?

—Мин сиңа әйткән идем бит инде. Остаханәдә очрашкач...

—Нәрсә дип?

—Онытгыңмыни? Алайса исеңә төшкәч сөйләшербез.

—Күчермә ясау турындамы?..

—Ә син ничек җавап бирдең? Гомумән синең белән сөйләшеп булмый. Кичә дә янына яхшылык белән кергән идем. Әгәр тыңлаган булсаң, һәммәсе шундук хәл ителә иде. Ә син бугаздан тотып алдың.

—Соң син аңларга тиеш!

—Ә мине аңларга кирәкмиме?

—Аңлашыйк соң. Иң элек син миңа шуны гына әйт: Нурзифа кайда? Әллә аны да?..

—Әйдәле аның турында сөйләшмик!—диде Хәнәфи кинәт кызып.—Син үзең турында уйла!

Трубка бераз тынып торды, Мозаффар үзен кулга алырга тырышты булса кирәк.

—Нишләтмәкче инде син мине?—дип сорап куйды ул аннары.

—Китереп терәсәләр, кеше теләсә нәрсәгә бара. Монда мин генә түгел, башкалар да бар әле! Безгә гарантияләр кирәк.

—Нинди гарантияләр?

—Башым исән калсын дисәң, мин әйткәнне эшлисең.

—Күчермә ясаргамы?

—Шуннан башла. Аннары карарбыз.

—Кайчан карарсың?

—Тәртибең ничек булыр. Шуны бел: шартларны мин куям хәзер! Син мине ахыр чиккә китереп терәдең!—диде Хәнәфи кызып китеп.—Әгәр мине булдыра алмас, дип уйлыйсың икән, монда бөтенесенә сәләтле кешеләр бар!

Селектор тагын беразга тынып калды.

—Мин риза...—диде ниһаять Мозаффар.—Тик бер шартым бар: Нурзифага тимәгез!

—Ә анысын без аның белән икебез хәл кылырбыз, өченче кеше кирәкми!—диде Хәнәфи кинәнүле тавыш белән.—Сиңа кирәкле бөтен әйберне кертеп бирерләр. Беренче эшең әзер булгач, сөйләшербез.

—Миңа үземнең кылкаләмнәрем кирәк!—диде Мозаффар.—Үземнең палитрам!

—Булыр. Уңышлар телим!—дип Хәнәфи селекторның төймәсенә төртеп, араны өзде.

Ярый әле, Мәскәүдән борынгыга охшатып картиналар ясау өчен һәммә кирәк-яракны алып кайткан иде. Ул аскы катка төште дә ишек төбендә утырган Кырыстан:

—Теге сумка белән төргәк машинададыр бит әле?—дип сорады.

—Багажникта ята.

—Кертеп ыргыт, —дип ияге белән аска ымлады Хәнәфи.—Юк, соңрак. Кузгат машинаны. Бер җиргә барып килик әле.

...Машина таныш йорт янына барып туктар-туктамас, ул ашыгып төште, атылып бишенче катка менде, кабаланып рәшәткәле ишекнең йозагын ачты. Мольберт үз урынында, киндер белән капланган килеш тора иде. Өстен ачуга, таныш сурәт пәйда булып, сулышны кисәндәй итте. Менә бит ул—Зифа—чынында нинди! Хәнәфи янында гына бөрешеп китә, ниндидер кабык эченә кереп качкандай була. Әкәм-төкәм кебек. Ничек салдырырга аның кабыгын, ничек менә шушындый хәлдә каршында яткырырга? Һәм... аннары... үзең дә аның янәшәсендә булырга? Мөмкин эш бит бу! Юлы ачылган бит инде...

Хәнәфи Нурзифа янәшәсендә Мозаффарны күз алдына китерде дә, күзләрен йомып, аскы иренен чәйнәде. Аннары мольберттан сурәтне йолкып алды, дивардан икенчесен. Коридордан калын кәгазь алып кереп, икесен бергә төрде. Ян өстәлдән кюветны алып, суын чыгарып түкте дә кылкаләмнәре, палитрасы белән бергә киндергә чорнады. Аннары борылып чыгып китте.

## Аңла син бу сәнгать кешесен!

Ә кичен остаханәгә Нурзифа килде. Мозаффар белән очрашырга курка да ул, шул ук вакытта аның остаханәдә булуын да тели иде. Телефоннан шылтыратты, димәк исән. Әмма тавышы, сөйләшүе нинди бит! Бик тә хафаланган, хәтта ярсыган кебек. Ни булган? Ник рәтләп сөйләшмәде? Ник сораганга җавап бирмәде, кайдалыгын әйтмәде?

Остаханә буш иде. Бу юлы ул галәттәгедән дә тәртипсезрәк күренде. Мольбертны каплаган киндер, андагы сурәт юкка чыккан. Кювет та, аның

эчендәге кылкаләмнәр дә юк. Дивардагы картинаның да урыны гына беленеп тора.

Бу ни дигән сүз? Мозаффар алып китте микәнни? Ләкин кая? Бәлки, рәссамнар берлегендә беләләрдер?.. Чит илгә барасы бар, телефон аша гына булса да алар белән хәбәрләшми тормыйдыр!

...Иртәгесен эшкә килүгә Нурзифа иң элек рәссамнар берлегенең телефонын эзләп тапты.

Берлек рәисе Хангилдин көттереп кенә җавап бирде.

—Кем әле бу, Азалия ханым, сезме?—дип сорады ул Юлдашев хакында сүз кузгатуга.

—Юк, бу... Юлдашевның остаханәсеннән...

—Натурщицасымы?

Нурзифа куырылып куйды.

—Юк, мин аның дусты... Ул каядыр югалды... Без борчылабыз...

Хангилдинның тавышы катыланып киткәндәй булды.

—Без бу хакта Азалия ханым белән сөйләштек инде,—диде ул.—Прагага нинди әсәрләрне алып бару турында комиссия үз фикерен әйтте, калганын югарыда хәл итәләр. Бар мәдәният министрлыгы, бар президент аппараты... Азалия ханымга да шулай дип әйттек: югарыдагылар белән эш йөртегез, дидек. Әйтик, министрның үзе белән сөйләшергә була. Гафу итегез, бездә киңәшмә бара иде. Сау булыгыз!

Һәм трубканы куйды.

Димәк, комиссиянең утырышы булган. Юлдашевның кайсы картиналарын сайлап алдылар икән? Мозаффар үзе бу хакта белә микән?

Нурзифа кесә телефонының төймәләренә төрткәләде. Министр Кәримовның номеры сакланган булырга тиеш: бер ел элек аның яңа фатирына аш бүлмәсен нәкъ менә Нурзифаның сызымнары буенча ясатканнар иде.

Беренче шылтыратуда ук аның белән сөйләшеп булмады: «Анда киңәшмә бара»,—дип җавап бирде секретарь. Сонрак: «Чыгып китте»,—диде, аннары сораган саен: «Килмәде әле»,—дип кабатлап торды.

Ахыр чиктә Нурзифа аны иртәнге сәгать җидегә барып, министрлыкның ишек төбендә сагалап торырга булды. Тәҗрибәле кешеләрнең шулай итүләре хакында теге чакта колагына чалынып калган иде.

Ул килгәндә, ике ир кеше шул тирәдә болгана иде инде. Урам чатыннан министрның аксыл машинасы күренүгә, алар икесе дә ишеккә илтә торган киң баскыч янына килеп бастылар. Министр машинадан чыгуга, ирләрнең берсе аңа таба атлады. Ике минут үттеме-юкмы, аны икенчесе алыштырды. Нурзифа ун-унбиш адым читтәнрәк күзәтеп торды.

Илгизәр Фаязович шактый калку, күксел костюмы бик тә ятышып торган чандыр гәүдәле илле яшьләр тирәсендәге кеше иде. Сынын төз тота, озынча башын иебрәк сөйләшкәндә, нык чал кергән куе, көлсу чәче кабарып, башын тагын да озынчалатып күрсәтә иде. Күренеп тора: ул кешеләрне дикъкать белән тыңлый, ә бәлки кайбер мәсьәләләрне шушылай аягөсте генә хәл кылу аның үзенә дә ошыйдыр. Кабинетына кереп, йомшак кәнәфигә урнашкан кеше сүзне озынга сузучан... Әнә, бу ике ир-ат та аның белән җиңел аңлаштылар бугай—берсе артыннан берсе, бик канәгать кыяфәттә, мәйдан уртасындагы затлы бакчага таба китеп бардылар. Ә Нурзифа үзенең йомышын бер-ике авыз сүз белән ничек аңлатып бирер икән соң?

Менә министр карашын аңа төбәде.

—Нурзифамы соң бу? Хәерле иртә! Син дә минамы?

—Исәнмесез, Илгизәр Фаязович! Мин Юлдашев турында... Рәссам Мозаффар Юлдашев...

Министрның йөзе житдиләнеп китте.

—Әйдәле, эчкә кереп сөйләшик,—диде ул.

Алар ян-якларына гөл түтәлләре сузылган киң мәрмәр баскычтан имән ишекләргә таба менеп киттеләр. Эчкә кергәч, ялтырап торган лифтка утырып дүртенче катка менделәр. Секретарь килеп житмәгән иде әле, алгы бүлмә аша эчтәге иркен кабинетка уздылар.

—Рәхим ит,—дип, министр Нурзифага озын өстәл янынннан урындык тәкъдим итте. Үзе аның каршысына чыгып утырды.

—Портретларыннан күренеп тора: Юлдашев өчен син гади натурщица гына түгел, бик якын кеше...—дип башлады ул сүзен.—Әйт әле дөресен генә: кая югалды ул?

—Мин... белмим.

—Шулаймыни? Хатынының белмәвен ничектер аңлатырга була. Синнән ник кача, монысы аңлашылмый.

Нурзифа югалып калды.

—Рәссамнар алар... гади кешеләр кебек түгел бит...—дип быдырдады ул.

—Шулай дип уйлыйк. Ләкин аның мондый чакта болай шаяруы сәер бит. Син ничек уйлыйсың? Әле кайчан гына без аның белән шушы кабинетта очрашып сөйләштек. Болай ук кыланырга ярамый иде. Бигрәк тә минем белән.

Соңгы сүзләрдә, хатын-кыз белән төрлечә кыланырга була, әмма житәкчеләр белән үзеңне тәртиплерәк тотарга кирәк иде, дигән мәгънә яңгырады.

—Комиссия аның картиналарын кире какмагандыр бит?—дип сорады Нурзифа.

—Өч картинасын сайлап алдылар. Өчне! Ике атнадан алар Прагада булырга тиеш. Авторлары белән бергә. Аңлыйсыңмы? Андагы күргәзмәгә куелган әсәрләрне авторлар үзләре тәкъдим итәчәк—тегеләрнең шарты шундый. Әгәр дә Юлдашев һаман шушылай качып йөрсә, аның урынына башка берәүне алып барырга туры киләчәк.

—Әгәр ул кинәт авырып китсә, ә әсәре шедевр булса?—дип сорады Нурзифа кинәт батыраеп.

—Их, Нурзифа туташ, сәнгать әсәренең кайсы нинди икәнен без билгелибезмени? Анысын инде зур белгечләр карый. Күргәзмәнең үзендә. Ә безнең эш—бар булганын кешечә итеп озату. Вакытында барып житсен, янында авторы ялтырап торсын. Балкып, беләсезме? Аның әле кайсы мөһимрәктер: картинасымы, авторымы.

—Ничек инде, сәнгать өлкәсендә...

—Син үзең яшь булсаң да рәссамнар белән күптәннән аралашасың булса кирәк. Сәнгатьтән мәгълүматың бардыр. Картинаны ничек тәкъдим итәсең бит. Менә мәсәлән, Малевичның «Кара квадраты». Нәрсә тасвирланган анда? Минем карашымча, анда кара шакмактан башка берни юк. Ә кемнәрдер аны шундый итеп мактадылар, бөтен дөньяны, бу шедевр, дип ышандырдылар. Син беләсеңме, быел аны ничә миллион долларга сатып алдылар? Әгәр дә аның авторы безнең Хангилдин яисә шул ук Юлдашев булса, борылып карауччы булыр иде микән? Бу очракта да автор үзе тырышырга тиеш. Ижат иткән әсәре өчен янып йөрергә! Картина бит ул рәссам өчен мәгъшукасы кебек кадерле! Ташлап качалар, димени? Аңа аннан ни файда? Мин, әлбәттә, аның картиналарын жибәрер идем. Ахыр чиктә, моңа берәү дә каршы түгел. Үзеннән генә тора! Элемтәгә керә алсаң,

әйт: килсен, күренсен!

Нурзифага: »Ярый»,—диюдән башка чара калмады. Ул урыныннан торып, саубуллашты да ишеккә юнәлде.

Эш урынына килеп утырганда, аңа кояшлы күк йөзен болыт сарган кебек тоелды. Ичмасам бер киңәшер-сөйләшер кешең булса иде! Әнисе белән уртаклаша торган вакыт түгел—ул аңламаячак. Кеше ирендә синең ни эшең бар, диячәк. Дус кызлар арасында Мозаффарга бәйле серләрне сыйдырып, сакларлыгы юк...

...Күңел түрендә янә Рашатның елмаюлы йөзе калыкты. Теге чакта аның телефоныннан хатын-кыз чыркылдавы ишетелде ишетелүен. Тик кем булды икән соң ул? Ә бәлки, кардәшедер? Бәлки, машина эчендә алар икәү генә булмагандыр?

Нурзифа телефонын алып, Рашатның номерын чыгарган иде инде. Ләкин өлгермәде, телефон үзе җырлый башлады. Аның тәрәзәсендә ят номер каралып чыкты.

—Алло! Сезнең исемегез Нурзифамы?—дип сорады нечкә яшь тавыш.

—Әйе. Ә сез кем?

—Анысы мөһим түгел. Рашат белән күптәннән очрашып йөрисезме?

Бу сораудан йөрәк убылгандай булды.

—Ә нәрсәгә ул сезгә?

—Әһә, очрашасыз, димәк. Ә беләсезме, ул сезнең белән генә түгел, минем белән дә очрашып йөри. Дөресрәге йөри иде... Без ярәшкән идек инде. Шушы арада туебыз булырга тиеш иде. Ә ул сездән, миннән башка тагын берәүнең башын әйләндергән! Мин ул кызга... дөресрәге, ул хатынга шалтыраттым. Виолетта исемле. Һәммәсен ачыктан-ачык сөйләп бирде. Алар хәзергә кадәр гражданский брак белән яшәп яталар икән! Телисезме, үзегез сорагыз. Хәзер мин сезгә аның телефонын җибәрәм!

—Ә минем телефонны каян белдегез?

—Аның кесә телефоныннан.

—Теге... Виолеттаның номерын да шуннан алдыгызмы?

—Шуннан. Җибәримме соң сезгә дә?

—Кирәкми,—диде Нурзифа нык итеп.—Әйткәннәрегез дә бик җиткән.

Һәм кызыл төймәгә бармагы белән төртте.

Аһ, күңелнең дә шундый төймәсе булсын иде дә, шуңа төртеп кенә аннан Рашатның үзен дә, исемен дә сөртеп ала алсаң иде!

## Сер булып калсын

Яше утызга җитеп тә хатын-кыз тәмен татымаган егет заты нинди буладыр, әйтүе кыен, Рашат андыйлардан түгел иде. Моңарчы Нурзифа аннан үткәннәре хакында сорашмады, алай ачылып сөйләшергә җай чыкканы да юк иде әле. Җай чыкса, сорашыр иде микән? Егет аңа һәммәсен ихластан, ачыктан-ачык сөйләсә, нәтиҗәсе ниндирәк булыр иде икән?..

Ничек кенә яратса да, күпме генә тырышса да, егет хәлен кыз аңлап бетерә алмастыр... Ир затлары бөтенләй башка камырдан әвәләнгән бит. Аларның гамәлләрен хатын-кыз аршыны белән үлчәп: «Мин алай итмәс идем, болай эшләмәс идем»,—дип фикер йөртеп, хөкем итә башласаң, белмим, кая барып чыгарсың... Шуңа күрә егет күңелендә ургыган кичерешләрнең төбенә төшәм, кылган гамәлләрен беләм, дип тырышырга кирәкмидер дә, бәлки. Сина килеп җиткәнче ул узган сукмакларда нинди гөлләр тапталганын, нинди шайтан таяклары аякларын гына түгел, йөрәген дә тырнаганны белергә тырышып, казына башласаң, иске ярлар искә төшеп

үзәгеn өзәр, йөрәгендәге җөйләнгән яралар яңадан ачылып, сызландырыр. Шул уңайдан синең дә бәгыреңә ут кабар. Ә нигә кирәк болар? Шагыйрә Фирая Зиятдинова әйтмешли: «Кузгатмагыз иске яраларны, ясалырга тора яңалары!»

Шуңа күрә үткәннәрдә казынмаска, фәкать бүген яратырга һәм ышанырга гына кирәктер. Һәм, әлбәттә, кичерә белергә... Шушы хакыйкатьне аңлаган кызлар, кагыйдә буларак, нык гаилә кора, һәм тыныч гомер итә.

Рәшатка да Нурзифа янына килеп җиткәнче шактый юллар узып, күп кенә сукмакларны таптарга туры килгән иде шул инде.

Үсмер чагында классташ кызларның иң чибәренә «үлеп» гашыйк булулары, төннәрен аны уйлап борсаланып ятулары, кайчакта аның аркасында иптәш малай белән чәкәлешеп алулары турында сөйләп тормыйк. Аларың аерым бер матур хикәя итеп язып булыр иде, тик бу юлы безнең максат ул түгел. Егет булып җитлеккәч тә чибәрләр белән мавыгып, якынаеп киткән чаклары булды.

Тик тән өчен яраган һәркем җан өчен ярамый икән шул. Тәнгә—татлы, җанга якын кешеңне табу исә һич тә җиңел түгел.

Ә табарга кирәк иде. Әти-әнисе шактыйдан инде өйлән дә өйлән дип Рәшатның колак итен ашыйлар. «Әнә, Дениска кара. Укыганда синнән уздыра алмый иде, ә хәзер ул кайда да син кайда?» Чыннан да, Рәшат белән бергә уйнап үскән күрше малае, институтны тәмамлаганнан соң бер-ике ел нефтьчеләрдә программист булып эшләп йөрде дә, кредит алып, үзенең компьютер фирмасын ачып җибәрде. Хәзер ул фирма шәһәрдә иң зурысы, яхшысы булып санала. Үзе генә булдыра да алмас иде бәлки, кәләшнең үткенен, уңганын, таза гаиләдә үскәнен әләктерде. Аның кызыл «Нисан»ын күргән саен, Тимерҗанның күзе кыза. Улы кайткан саен колак итен ашый: «Күр әнә, үрнәк ал!—ди.—Өч бүлмәле фатиры бар, тезендә улы, кулында кызы... Неужели бер рәтле кызны да үзеңә карата алмыйсың инде?—дип каты гына чеметтереп алгалый.—Сау-сәламәт егет син, килмәгән җирең юк, берәрсе белән күрешми-очрашмый яшәмисеңдер. «Гражданский брак» белән тормыйсыңдыр бит?» Һәм улының ак чырае алланып, башы иелгәнен күргәч, ачуы чыгып, утырган урыныннан сикереп тора да, бүлмә буйлап йөренә башлый. Куллары белән түшәмгә кизәнгәндәй итеп: «Таптылар мода!—ди.—Никахлашмый, язылышмый-нитми генә, ата-анага әйтеп тормыйча кочаклашалар да яталар. Беләсең килсә, ул сезнең «гражданский брак» дигәнегез милиция телендә «сожительство» дип атала! Татарчага тәрҗемә иткәндә, бозыклык дигән сүз ул! Зина диләр аны! Нәтиҗәсен күр син аның, нәтиҗәсен! Башта әле тегесе, әле бусы белән яшәп карыйбыз, бер-беребезгә туры киләбезме, юкмы икәнен беләбез, аннары гына өйләнешәбез, шулай итсәң, гаилә нык була, диләр дә бит, рәтлеме соң гаиләләре? ЗАГСларның, әнә, бер ягында ничә пар язылышса, икенче ягында шулкадәр пар аерылыша».

Аннары катырак бәрелгәнен үзе дә аңлап, улының кунакка гына кайткан кеше икәнен исенә төшереп, прәннек каптыруны кирәк тапты: «Туйга фатир бүләк итәчәкбез»,—ди. Машинаны улларына унсигезе тулуга алып биргәннәр иде инде. Башта «Ока», анысы тузгач, «Жигули». Хәзер инде аны ак «Лада»га алыштырдылар.

Сүзе буш түгеллеген исбатлап, Казанда төзелә башлаган йорттагы бер бүлмәле фатир өчен акчасын да түләп куйды Тимерҗан. Инде йорт та өлгереп килә, кәләш исә һаман табылмады да табылмады!

Илдә кызлар егетләрдән күбрәк, диләр бит югыйсә, каян килә икән соң

ул кәләшләргә кытлык? Сайлый башласаң, рәтлесен табып булмый икән бит аның!

Әбе килсә, җәбе килми дигәндәй, чибәре томана булып чыга, чаясы—каты күңелле. Яратам дигәне дә, төптәнрәк карасаң, дөнья малын синнән артыграк сөя... Яшьлекнең беркатлы еллары узып, күзләр ныграк ачылгач, гомерлек пар табу ифрат кыенлаша икән шул.

...Ел ярым элек Рашат Виолетта белән танышты. Кыз әле генә Түбән Камадан Казанга килгән, бер оешмага бухгалтер булып урнашкан. Күп еллар инде фитнес, аэробика белән шөгыльләнә икән, түгәрәкләр дә алып барган. Мәдәният сараена ул шул шөгылен дәвам итәргә дип килгән иде.

Рашат белән алар шунда таныштылар. Танышлык дуслыкка илтте, әберәр ай үтүгә якынлык булып китте. Моңа шартлары да бар иде. Дөрес, Рашат үзенең торган җиренә хатын-кыз ияртеп кайта алмый, чөнки әтисенең кардәшендә—Гүзәлия карчыкның кече бүлмәсендә яши. Малай киртәдән чыкмасын, тәмам бозылып бетмәсен дип, Тимерҗан махсус шулай урнаштырды. Виолетта исә ирекле шәхес, әнисе итәгеннән дә, атасы кулыннан да күптән ычкынган. Түбән Камадан килүгә бер бүлмәле фатир яллаган. Бу бик уңайлы булып чыкты.

Шөгыленә хас булганча, искиткеч сылу, сыгылмалы сынлы, маңгаена төшеп торган салам чәчле, битенә бик килешле итеп кенә макияж салган кыз иде бу. Ачык йөзле, тәмле телле, кайнар тәнле—бер килмәгән җире дә юк. Рашат бер ялны әтиләре янына Виолеттаны алып кайтып, таныштырырга кирәк, дип ниятләгән иде инде. Һәм аларның шатланасына тамчы да шиге юк иде.

Әмма очрашкан саен телләр ныграк ачылып, сер капчыкларының бавы чишелә башлагач, мәсьәлә катлауланып китте. Бу заманда бер кызның да капчыгы буш түгел, күрәсең, төбеннән тотып селки башласаң, әллә ниләр коела... Баксаң, Түбән Камада Виолеттаның никахлы ире калган икән.

—Аерылдыгызмыни?—дигән сорауга:

—Ю-ук,—дип җавап бирде ул.

—Ничек җибәрде соң ул сине монда?

—Аннан кем сорап тора... Үзем киттем.

—Начар кешемени?

—Әйбәт ул, бик әйбәт. Тик анда түгел хикмәт.

—Ә нәрсәдә?

—Соң үзең уйлап кара: ул бәләкәй шәһәрдә бернинди перспектива юк бит! Кем булып калам мин бөтен гомеремне шул тишектә уздырсам?.. Житмәсә эштә бәйләнә башладылар.

—Нәрсә дип?

—Отчет вакытларында кичке тугызларга кадәр утырырга кушалар. Ә минем клубка түгәрәккә барасым бар. Мин бит әле һинд биюләре белән дә шөгыльләнәм... Өстәвенә фитнес буенча конкурста финалга да үткәрмәделәр.

—Ә монда үткәрерләр дисеңме?

—Казан зур ул, ярышлар гел булып тора, берсендә узмасам, икенчесендә үтәрмен. Көчем бар чакта нәрсәгә булса да ирешәсем, үз-үземне күрсәтәсем килә!

—Кемгә?!

—Иң элек үз-үземә!

—Күпме яшәдегез инде сез аның белән?—дип сорады Рашат бераз тынып торганнан соң.

—Күп инде, өч ел.

—Ә балагыз... булмадымыни?

Виолетта кеткелдәп анын башын сыйпады.

—Син үзен сабый! Йә, уйлап кара: кайда асрыйк ди без аны? Кеше почмагындамы? Анын эшләгәне үзеннән артмый. Мин өйдә утырсам, ни була инде ул! Бала кайгысы юк әле монда! Яшь чакта яшәп калырга кирәк,—дип Рашатның тезенә менеп утырды да, башын тыгыз күкрәгенә кысты, иелеп, колагына кайнар сулышын өрде... Ирләрне сары май урынына эретеп, башларын идерә торган сәләте бар шул чукынмышның...

Тик бу сөйләшүдән соң Рашатның теге яхшы нияте какшап китте. Ә бер какшаган баганаНы гел селкетеп торалар бит аны.

Августның җылы бер кичендә алар автобус тукталышында очрашырга вәгъдәләшкәнәр иде. Рашат машинасын урамның икенче ягында туктатты. Ерактан ук күреп алды—халык төркеменнән бераз читтәрәк торган Виолетта әллә каян күзгә ташланды: салам чәче иненә сибелгән, сары кофтасының изүе күкрәк ярыгыннан түбән, итәге кендектән югары, яшькелт кыска штаны ботларына сыланган. Ачык кендегендә күзләрне камаштырып алка елкылдый... Рашат килеп житәрәк, тротуар кырына күксел «Рено» килеп туктады, таза егет ачык тәрәзәдән башын сузып, Виолеттадан:

—Күпме?—дип сорады.

Кыз гажәпләнмәде, бик оста макияж салынган йөзе генә елмаюдан балкыды. Хәлбуки машинадагы егет аны фахишә дип белгән иде бит! Рашатның килеп туктаганын күргәч, кузгалды да китеп барды.

—Оят түгелме сина?! Нәрсәгә дип кендегенне шулхәтле тырпайттын?! Рәтлерәк киенеп булмыймы әллә?—диде Рашат исәнләшергә дә онытып. Виолетта аяк очларына күтәрелеп анын бит очыннан үбеп алды.

—Бозма йөзенне! Нәрсәсе рәтсез? Бөтенесе сонгы мода буенча! Кендеген каплаган кыз күренми әле монда,—дип көлде аннары. Чыннан да урамдагы кызларның күбесенен кендекләре ачык, чалбарлары ботларына сыланган иде. Әмма теге адәм нәкъ менә Виолетта янына туктады бит!

...Шик түбәсе бер тишелсә аннан тама да тама инде. Әмма араны кинәт кенә өзеп булмады. Ияләнү дигән нәрсә дә бар бит әле. Житмәсә, атнага өч-дүрт тапкыр мәдәният йортында бер-берсенә юлыгып торалар... Вакыт-вакыт гайрәт чиккән сыман тоелса да, йөзгә-йөз очрашкач, авызлар ерыла, күңел җылына иде.

Әмма кызны әти-әни янына алып кайту теләге сүрелгән иде инде. Виолетта үзе дә Рашатка гомерлеккә бирегергә бик ашкынып тормый шикелле, иремне Казанга алып килсәм, яхшырак булмас микән, дигән уе да бар бугай. Сайлана кызый! Тегендәгесе белән язылышмыйча гына никахланышып, монысы белән «гражданский брак» дип жинел генә кавышып яшәп карый...

Нишлисен, заманасы шундый, күп яшьләр шулай итә!

## Тылсым кичәсе

Әмма дә ләкин хәзерге яшьләрнен дә төрлесе бар.

...Октябрь башында мәдәният сараенда бик зурлап шагыйрь Зөфәр Назировның яна китабын тәкъдир итү кичәсен үткәрделәр. Жиде йөз кешелек зал шыгрым тулы булып, беренче карашка халык бик чуар: ак яулыклы әби-сәбиләр, түбәтәйле абзыйлар, мөселманча киенгән кызлар янында джинсы чалбары өстеннән кендеге күренеп торган яшь-жилкенчәк тә житәрлек иде. Ә бит рок-концертларның тамашачысы бер иш, бер-берсенә охшаш була. Татарча шигырь укучы аз, гомумән татар әдәбияты

бетүгә таба бара, дигән фикер киң таралган бу чорда, зур-зур китап кибетләрендә татар китапларына бер шкафлык та урын табылмаган бу заманда каян килә шигырь тынларга теләүче бу кадәр халык? Ни өчен татар җырчыларын тынларга ашкынган тамашачылар еш кына Казанның иң зур залларына сыймый?

Рашат өчен бу җинел генә аңлатып булмый торган бер күренеш.

Вазифасы буенча ул кичәдә музыка яңгырашын тәэмин итәргә тиеш иде. Урыны иң алгы рәттән дә алда, тавыш аппаратурасы белән шыплап тутырылган киң өстәл артында.

...Менә залда утлар сүнде, сәхнә исә көчле яктылыкка күмелде. Ян пәрдәләр артыннан салмак кына атлап җирәнсу бөдрә чәчле, бик ыспай, төз сынлы шагыйрь килеп чыкты да сәхнә уртасына куелган микрофон янына басты. Залда тыенкы гына кул чаптылар, әмма бу тыенкылыкта үзенә бер ярату, рәхәт мизгелләр көтү сизелде. Менә ул бөдрәләрен җилпеп, башын күтәрде, ияген чөя төшеп, карашын залдагыларның баш өстеннән каядыр еракка төбәп, дулкынланудан чак кына тибрәнгән, ягымлы тавыш белән сөйли башлады:

Илнең яме кимрәк булыр иде —
Ярый әле мин туганмын җиргә
Бик күпләрнең гади тормышына
Шатлык гөле булып үрелергә.
Ак биләүдә яткан чагымда ук
Минем гүләү күпме зарны юган,
Авыр чакта әти белән әни
Өмет күргән минем елмаюдан...

Иң алда утырган Рашатка сәхнә биеклегенә башын чөеп карарга туры килә, шунлыктан шагыйрь аңа гадәттәгедән буйлы булып, мәһабәт һәм затлы булып күренә иде. Гомумән сәхнәнең шундый кодрәте бар бит аның: ул кешене төркемнән аерып, күтәреп куя да, үзгәртеп, үстереп җибәргәндәй итә. Рашат борылып карамады, әмма аркасы белән дә сизеп торды: сәхнәдәге шагыйрь генә түгел, бөтен зал үзгәргән иде. Һәм ул яңадан-яңа шигырьләрен укыган саен, бу үзгәреш көчәя барды. Аның сүзләрендә шундый кодрәт бар иде ки, ул кешеләрне көнкүреш баткаклыгынннан тартып чыгарып, өскә күтәрә дә, хисләренең саф җиле белән күңелләрне кер-тузаннан арындыра, сафландыра, җаннарга канат куя иде шикелле. Алай гына да түгел, залны иркенәйтә, таш диварларны ерагайта бара, ниһаять күренмәс итә... Синең күз алдыңа дөньяның гүзәл манзараларын китереп бастыра... Залдагы чуар халыкның һәммәсе—абзый-апалар да, чәч бөртеге дә күренмәслек итеп башына шәл ураган мөслимәләр дә, бил турында шәрә тәне күренеп торган замана кызлары да—һәммәсе бер үк кичерешләр бишегендә тирбәлә иде.

Үләндәге тамчыларга кагылыр өченме әллә,
Каенның яшел чуклары җиргәчә иелгәннәр?
Җемелдәшеп каеннарның чуклары арасыннан
Яңгыр тамчылары кебек сагыну тама сыман,—

дип сөйли шагыйрь. Һәм залдагы һәркемнең йөрәге: «Минем хакта бит бу!—дип сулкылдый.—Минем дә каеннар арасында шулай адашып йөргән чакларым бар иде, җан сөйгәнемне сагынып, күзләремнән кайнар яшьләр чык булып тамган иде...»

Рашатта исә шул хискә үкенеч тә килеп үрелде: «Минем әле андый саф сөюне кичергәнем юк бит... Төннәрен йоклый алмыйча, иртәнге чыкларны ерып, каеннарга серләремне сөйләп йөргәнем юк... Ә бар бит андый мәхәббәт!»

Шагыйрьне озаткан алкышлар астында сәхнәгә, ике баянчы егетне ияртеп, ак күлмәк, кара костюм кигән, муенына кара күбәләк таккан егет солтаны—жырчы Ансар Гыймадиев чыгып басты. Зал колаклар чыңлардай тынып калды. Гармунчылар уйнап жибәрде, жырчы тагын да киңрәк урын алырга теләгәндәй, аякларын аерыбрак басты да, тирән сулыш алып, башлады:

Көймәмне чайкатып көчле жил
Рәхимсез талкыды, янады;
Тантана итте гел—мине ул
Бирештe бу, диеп санады...

Чын жырчының жырлавын сүз белән тасвирлап биреп була микән? Жыр сүзләргә генә сыймый шул ул. Чын жырчы шигырьне моңга төреп, тыңлаучыга шундый итеп ирештерә, аннан бөркелгән хисләр тәнне чымырдатып, тамырларга саркый һәм йөрәккә татлы да, ничектер бераз сыкрата да торган дәва булып тама.

Аермыйм уң яктан сул якны,
Өметем бөтенләй сүрелде:
Калдым бер чарасыз, дигәндә,
Еракта бер маяк күренде...

Мондый жырчыларны тыңлаганда күңелне узенә бер горурлык хисе дә биләп ала. Алар кебек дөньяда бүтән юк, аларны һичкем алыштыра алмый. Ансар Гыймадиев Мәскәүдә дә, Миланда да иң катлаулы опера партияләрен башкара ала. Ә менә татар сәхнәсендә безнең жырларны аның кебек һичкем жырлый алмый. Ул—бердәнбер.

...Жырчыны алкышларга күмделәр, берничә кыз йөгереп килеп, аңа чәчәк бәйләме сузды.

Моннан соң күңел нindидер могжиза көтә иде. Һәм гүяки шул теләкне тормышка ашырып, сәхнәгә фәрештә инде...

Ак, яшел, алсу, зәңгәр яктылык нурларыннан яралгандай булды да кауры болыттай жиңел күлмәк итәгенә төренгән аякларын идәнгә тигезер-тигезмәс атлап, киң жиңнәрен канат кебек жилпеп, караңгылыкка чумган зал каршына килеп басты ул. Өзелеп торган нечкә билен чак кына бөгеп, залга сәлам бирде—шома кара чәчләре иңнәреннән шуып узды. Шунда нидер булды Рашатка, берничә тын ул хәтта музыканы тоташтырырга онытып утырды. Кыз аңа керфекләрен сирпеп, әмер биргәндәй итеп карагач кына аңына килеп, тиешле клавишаларга төрткәли башлады. Музыка яңгырады, аңа нечкә, яңгыравык, саф тавыш үрелде:

Бик сагындым сине, бәгърем, өзелеп сагындым,
Сине уйлап мең кат сүндем, мең кат кабындым...
Сорыйм сине тулган айдан, сорыйм Чулпаннан,
Сөйгәнем, дим, кайда, нигә хәбәр юк аннан?

Бөтен торышыннан, ак йөзеннән, тавышыннан сафлык, сафлык бөркелә иде аның. Чисталыкның, гөнаһсызлыкның өлгесе булырга хаклы зат иде

бу. Чын-чынлап фәрештә. Әллә сон туй күлмәге кигән кәләшме?

Халык аягөсте торып кул чаба башлагач, Рашат анын жыярга тырышты. Туктале, бу Ләйсән Вәлидине күптәннән белә бит инде ул! Бүген көндез кичәнең репетициясен үткәргәндә дә күрде. Консерваториядә укып йөргән бу кызыкай монарчы башка жырчылардан берни белән дә аерылмый кебек иде бит. Ничек болай әвәрә итте сон әле ул бөтен тамашачыны? ...Ул арада сәхнәгә чәчәк бәйләмнәре күтәргән егетләр, кызлар сикереп менде, кайсы Ләйсәнне кочаклый, кайсы бит очыннан үбеп тә ала. Рашат алардан көнләшеп куйды. Чәчәк алып килсә, ул да кызнын битеннән үк булмаса да, кулын үбә алган булыр иде бит!

Концерт тәмамланып килгәндә, инде бөтен катнашучылар сәхнәгә чыгып, тезелеп баскач, залдан сәхнәгә җинел генә сикереп рәссам Юлдашев менде: Шагыйрьнең портретын ясаган икән, шуны бүләк итте. Зөфәр бер кулы белән аны, икенче кулы белән жырчы Гыймадиевны кочаклап, алгарак әйдәде.

—Без өчебез—күптәнге дуслар,—диде.—Моннан ун ел элек без гомеребез буе ходай биргән сәләтебезгә, шигърияткә, сәнгатькә тугры калырга, беркайчан да хыянәт итмәскә ант биргән идек...

—Ул чакта без, дүрт егет, матурлык яки үлем, дип ант иттек,—дип аның сүзен жөпләде Ансар.—Авыр еллар булды, әмма без сайлаган юлыбыздан тайпылмадык...

—Дүртенчегез кая?—дип кычкырды залдан бер егет.

—Ул да исән-сау, аллага шөкер. Бүгенге кичәгә генә килә алмады.

—Сез барыгыз да бик мәгълүм шәхесләр. Ә ул?—дип төпченүен дәвам итте теге.

—Сез сорамагыз, без әйтмибез!—диде Зөфәр, шаяртуга борып.

...Кичәдән таралганда халыкнын күнеле бик хуш иде. Ара-тирә генә булса да шушындый залларга килеп, чын шагыйрьнең сүзен ишетмәсәк, чын жырчыны тынлап монланмасак, без ни төсле булып бетәр идек икән? Үзебезне Адәм галәйһессәламнең сөекле балалары дип хис итә алыр идек микән?

Ә шулай да бу кичәдән ин көчле тәэсир алган тамашачы Рашат иде булса кирәк.

*Дәвамы киләсе санда*

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШКАН ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ

## Гариф Галиев *(1903–1985)*



1903 елның 10 маенда хәзерге Татарстанның Азнакай районы Урманай авылында туа.

Ул егерменче елларда беренче хикәяләрен яза. Гомумән, сугышка кадәр үк аның хикәя, повестьлардан торган унлап китабы дөнья күрә.

Гариф Галиев 1943 елның гыйнварыннан фронтның алгы сызыгында Мәскәү хәрби округы чыгарган татарча матбугат органы «Кызыл сугышчы» газетасында һәм аның дәвамы—Беренче Белоруссия фронты сәяси бүлеге карамагында чыккан «Кызыл Армия» газетасында җаваплы сәркатип булып хезмәт итә.

Сугыштан соңгы елларда Гариф Галиев, нигездә, балалар әдибе буларак киң танылу ала.

## Фәйзи Галиев



1925 елның 2 июлендә Татарстанның Әтнә районы Түбән Шашы авылында туа.

1942 елның декабрендә ул армиягә алына, Сарапулдагы пехота училищесында тизләтелгән курсларны тәмамлаганнан соң, фронтка озатыла. Смоленск шәһәре өчен барган сугышларның берсендә каты яраланып, дүрт ай Уфа госпиталендә дәвалана. Аннары исә, гаскәри хезмәттән бөтенләй азат ителеп, 1944 ел башында туган авылына кайта.

Фәйзи Галиев озак еллар дәвамында туган ягында колхоз рәисе булып эшли. Ул укучыларга документаль повестьлары белән танылды.

## Макс Гатау *(1913–1941)*



1913 елда хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән районы Тозау авылында туа.

Утызынчы елларда «Колхозчылар тавышы» дигән төбәк, «Коммунист» һәм «Социализм юлы» дигән Чиләбе һәм Свердловск шәһәре газеталарында беренче шигырьләре дөнья күрә.

1939 елда аның Казанда беренче китабы—«Урал мәхәббәте» басылып чыга. Шагыйрь икенче җыентыгын да басмага әзерли, ләкин сугыш башлану сәбәпле, китап чыкмый кала.

Макс Гатау 1941 елның июлендә фронтка китә һәм шул ук елның 20 ноябрендә Калинин (хәзерге Тверь) өлкәсендәге Гаврилово авылы янында барган сугышларның берсендә һәлак була.

## Мансур Гаяз *(1917–1943)*



1917 елның 5 октябрендә хәзерге Мари Элнең Бәрәнге районы Бәрәнге авылында туа.

Мансур Гаяз—сугыш алды елларында әдәбият мәйданына чыгып, кыска гына вакыт эчендә исемнәрен танытып өлгергән, ләкин, иҗади талантларын ахыргача ача алмыйча, Ватан сугышы фронтларында халыклар азатлыгы өчен гомерләрен биргән зур бер төркем татар әдипләренең берсе. Ул 1936 елда яза башлый. Шигырьләре һәм поэмалары күмәк җыентыкларда һәм альманахларда дөнья күрә.

Мансур Гаяз сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә. 1943 елның 19 ноябрендә Белоруссиянең Витебск өлкәсе Усково авылы өчен барган бәрелешләрнең берсендә шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була.

## Шамил Гәрәй *(1916–1946)*



1916 елның 31 декабрендә Казан шәһәрендә туа. Ул бик яшьли әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. 1932 елда аның беренче шигырьләр китабы (16 яшендә!) дөнья күрә. Шуннан соң, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә (1932-1941) аның янә дүрт китабы басылып чыга. Балалар шагыйре булып танылган Шамил Гәрәй әдәби тәрҗемә белән дә шөгыльләнә: А. Чехов хикәяләрен, М. Лермонтов һәм А. Барто шигырьләрен татарчага аудара.

Сугышның беренче көннәреннән үк Шамил Гәрәй—фронтта. Мәскәү янында барган каты сугышларның берсендә ул сугышчан иптәшләре белән чолганышта калып, әсир төшә. 1946 елның 22 мартында Польшаның Гливице шәһәрендә әсир тоткыннарны тикшерү лагеренда вафат була.

## Хатип Госман *(1908–1992)*



1908 елның 21 маенда хәзерге Пермь краеның Чернушка районы Сулмаш авылында туа. Бик яшьли шигырьләр яза башлый. Утызынчы елларда төрле татар газеталарында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1939 елда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, укытучылык һәм гыйльми эш белән шөгыльләнә башлый. Чәчмә әсәрләрдән торган ике китабын бастырып чыгара.

Сугыш башлангач, күпчелек татар зыялылары кебек, сугышның беренче көннәреннән үк фронтка озатыла, фронт газеталарының хәрби корреспонденты, саперлар бригадасы офицеры сыйфатында алгы сызыкта булып, сугышны Алманиянең Гюстроф шәһәрендә тәмамлый.

Сугыштан соң күренекле әдәбият галименә әверелә.

## Таһир Госман-Сулмаш *(1900–1983)*



1900 елның 16 мартында хәзерге Пермь краеның Чернушка районы Сулмаш авылында туа. Ул—Хатип Госманның бертуган абыйсы.

Таһир Госман-Сулмаш, язучы-прозаик буларак, 1928-1935 елларда «Атака», «Яңалиф», «Совет әдәбияты» (һәммәсе дә—«Казан утлары» журналының әүвәлге исемнәре) битләрендә басылган хикәяләре белән билгеле. Аерым китап рәвешендә аның роман, повестьлары да 1931, 1934 елларда дөнья күрә.

Таһир Госман-Сулмаш, сугыш башлангач, армиягә алынып, фронтның алгы сызыгында «Катюша»лар расчетында хезмәт итә. 1942 елда

авыр яраланып, госпитальгә эләгә. Анда озак кына дәваланганнан соң, гаскәри хезмәттән азат ителеп, туган авылына кайта һәм гомеренең соңгы елларын шунда яшәп уздыра.

### Гыйз-әл-Габид *(1918–1955)*



1918 елның 7 гыйнварында хәзерге Оренбург өлкәсенең Свердловск районы Хөсәен (Саиновка) авылында туа.

Сугышта әүвәл гади солдат була. Соныннан исә фронт газетасы хәбәрчесе—офицер сыйфатында Ленинградтан алып Финляндия һәм Төньяк Норвегиягә кадәр сугышчан юл уза; фашистлар җиңелгәч, Ерак Көнчыгышка җибәрелеп, Япониягә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, совет гаскәрләре белән бергә Манчъжурия һәм Төньяк Корея җирләренә кадәр барып җитә.

Гыйз-әл-Габидның зур булмаган әдәби мирасы (иллеләп шигырь) Ватан сугышы чоры солдат поэзиясенең бер сәхифәсе буларак зур әһәмияткә ия.

### Бәян Гыйззәт *(1918–1991)*



1918 елның 16 июлендә хәзерге Башкортстанның Кушнаренко (Кушнарат) районы Толбазы авылында туа.

Казан дәүләт педагогия институтының аспирантурасында укыганда сугыш башлана һәм ул 1941 елның декабрендә фронтка озатыла. Көнбатыш, Өченче Белоруссия фронтларында барган канлы бәрелешләрдә катнаша, яралана, госпитальдән соң, хәрби мәктәпне тәмамлап, офицер буларак янә фронтка җибәрелә. Ул Курск дугасы дип аталган мәгълүм канкоешларны исән имин кичеп, Кенигсбергка кадәр сугышчан юл уза.

Бәян Гыйззәтнең сугыштан соңгы әдәби-гыйльми эшчәнлеге тулысынча диярлек татар театр сәнгате һәм драматургиясе белән бәйле.

### Сафа Гыйльфан *(1902–1950)*

1902 елда Уфадагы Балкар прискасы бистәсендә туа.

Утызынчы елларда ул шигырьләр яза, рус һәм чит ил язучыларының аерым әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү белән шөгыльләнә.

Сугыш башлангач Сафа Гыйльфан фронтка китә, җиңү көннәренә кадәр алгы сызыкта була. Сугышны ул подполковник дәрәҗәсендә тәмамлый.

### Әхмәт Гыймадов *(1915–1943)*



1915 елда Казанда туа. Утызынчы елларда әдәби иҗат белән актив шөгыльләнә башлый, төрле басмаларда хикәя-повестьларын чыгара.

1943 елның башында Әхмәт Гыйматов фронтка җибәрелә һәм шул ук елның октябрь аенда сугыш кырында һәлак була.

### Әнвәр Давыдов *(1919–1968)*



1919 елның 21 мартында Самара өлкәсенең Камышлы авылында туа.

Унике яшендә чагында ук Камышлыдагы төбәк газетасында аның беренче шигырьләре басылып чыга.

1940 елны гаскәри хезмәткә алынып, сугышның башыннан азагына кадәр әүвәл гади солдат, аннары кече командир сыйфатында Волхов, Ленинград янында, Балтыйк буе республикалары территорияләрендә барган канлы бәрелешләрдә катнаша.

Сугыштан соң Әнвәр Давыдов фәлсәфи-лирик поэмалары белән танылa, күренекле шагыйрьгә әверелә.

## Нәби Дәүли *(1910–1989)*



1910 елның 1 июнендә Татарстанның хәзерге Әлки районы Иске Камка авылында туа.

Утызынчы елларда ул шагыйрь буларак таныла, 1937-1941 еллар арасында аның дүрт шигъри җыентыгы басылып чыга.

Сугышның беренче көннәрендә үк, 1941 елның 25 июнендә, Нәби Дәүли фронтка китә. Шул ук елның августында чолганышка эләгеп, әсир төшә. Бухенвальд, Баден-Баден, Магдебург шәһәрләре янындагы үлем лагерьларында газап чигә.

Нәби Дәүли Казанга 1945 елның декабрендә кайта, иҗат эшенә чума. Үзенең шигъри әсәрләре, роман-повестьлары белән укучылар күнелен яулап ала, күренекле әдипкә әверелә.

## Әмирхан Еники *(1909–2000)*



1909 елның 17 февралендә хәзерге Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында туа.

Яшьтән үк әдәбият, иҗат эше белән кызыксынган Ә. Еники 1925 елда Казанга килә һәм тиздән көндәлек матбугатта аның әдәби парчалары һәм хикәяләре күренә башлый.

1941-1945 елларда ул—Ватан сугышы фронтында: хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьларында рядовой солдат булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Әмирхан Еники, татар психологик прозасының матур үрнәкләре булып саналырга хаклы хикәяләр, повесть-романнар язып, күренекле әдипкә әверелә.

## Әхмәт Ерикәй *(1902–1967)*



1902 елның 16 декабрендә хәзерге Башкортстанның Дуван районы Өлкенде авылында туа.

Егерменче елларда шигырьләр яза башлый, Мәскәүнең татар телендә чыга торган «Эшче», аннары «Игенчеләр» газеталарында сәркәтип, мөхәррир урынбасары булып эшли.

Ватан сугышы елларында Әхмәт Ерикәй фронт газетасында хезмәт итә.

Сугыштан соң Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе була, күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесенә әверелә.

## Кәрим Җаманаклы *(1905–1965)*



1905 елның 21 гыйнварында хәзерге Украинаның Кырым ярымутравындагы Жаманак авылында туа.

Утызынчы елларда ул шагыйрь һәм фольклорчы галим буларак та таныла башлый.

1941-1942 елларда Кәрим Жаманаклы фронтта була.

Сугыштан соң галимлек һәм әдәби иҗат эшен дәвам иттерә.

## Муса Җәлил *(1906–1944)*



1906 елның 15 февралендә хәзерге Оренбург өлкәсенең Шарлык районы Мостафа авылында туа. Бик яшьли шигырьләр яза башлый. Утызынчы елларда ил күләмендә шагыйрь буларак танылу ала, сугыш алдыннан Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе була.

Муса Җәлил сугышка, өлкән политрук булып, 1942 елның декабрендә эләгә. Ул Төньяк-Көнбатыш фронтта чыга торган русча «Отвага» («Батырлык») газетасының алгы сызыктагы хәрби мөхбире итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә, Волхов юнәлешендә барган бәрелешләр вакытында ул, каты яраланган хәлендә, фашистлар кулына эләгә. Шул көннән аның тоткынлыктагы газаплы һәм каһарманнарча кыюлык белән узган кыска гомер этабы башлана.

1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезден шәһәрендә хөкем була. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә аларны җәзалап үтерәләр.

Тоткынлык шартларында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен Муса Җәлилгә вафатыннан соң (1956) «Советлар Союзы Герое» дигән исем бирелә, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты—бөтен дөньяга мәгълүм «Моабит дәфтәре» СССРның ул вакыттагы иң зур бүләге—Ленин премиясенә лаек була (1955).

## Исхак Закиров *(1911–1944)*



1911 елның 14 сентябрендә Казан шәһәрендә туа. Бик яшьли шигырьләр яза башлый. 1934-1941 елларда ул әүвәл Татарстан китап нәшриятында, соңыннан Татарстан Язучылар берлегендә бухгалтер булып эшли.

Сугыш башлану белән, Исхак Закиров фронтка җибәрелә, бик күп канлы бәрелешләрнең шаһиты була, Белоруссия җирләрен азат итүдә катнаша, шәхси батырлыклары өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә, шул сугыш шартларында партиягә алынып, үзе хезмәт иткән ротаның парторгы итеп сайлана. 1944 елның 14 июлендә Витебск өлкәсенең Гордилово авылы янында барган бәрелешләрнең берсендә Исхак Закиров, ротаны һөҗүмгә күтәреп, дошман ныгытмаларын атакалаганда каһарманнарча һәлак була.

Шагыйрьнең Ватан сугышы чорында иҗат иткән шигырь һәм очерклары шул елларда «Алга, дошман өстенә!» дигән фронт газетасында һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә басыла.

## Шаһиморат Зәйни *(1913–1980)*



1913 елның 7 мартында хәзерге Оренбург өлкәсе Тоцк районы Кондызлытамак авылында туа.

Сугыш башлану белән ул фронтка китә һәм отделение командиры, пулеметчылар взводы командиры ярдәмчесе, батальон парторгы сыйфатында Мәскәүне, Сталинградны саклауда катнаша, совет гаскәрләре белән бергә Польша, Чехословакия, Румыния, Венгрия, Австрия һәм Германия җирләренә кадәр барып җитә.

Сугыштан соң Шаһиморат Зәйни драматург һәм башка милләт драматургларының пьесаларын татарчага тәрҗемә итүче буларак танылу ала.

## Якуб Зәнкиев *(1917–2003)*



1917 елның 6 апрелендә Иркутск шәһәрендә дөньяга килә.

Бөек Ватан сугышыннан кайткач, ул 40 елдан артык үзе яшәгән Себер төбәгендә, Тубыл шәһәрендә балаларга татар әдәбияты укыта. Якуб Зәнкиев үзенен күләмле романнары белән укучыларга танылды.

## Рахман Ильяс *(1908–1943)*



1908 елның 15 мартында Татарстанның хәзерге Апас районы Карамасар авылында туа.

Утызынчы елларда ул газета редакцияләрендә, Татарстан радиокомитетында әдәби хезмәткәр, мөхәррир, Язучылар берлегендә әдәби консультант, аннары исә Главлит вәкиле булып эшли, повесть-хикәяләр, пьесалар иҗат итә.

Ватан сугышы башлангач, үзе теләп фронтка китә һәм рота командиры сыйфатында Украина җирләрендә барган канлы бәрелешләрдә катнаша. Харьков шәһәре тирәсендәге шундый бәрелешләрнең берсендә, 1943 елның 23 августында, Рахман Ильяс батырларча һәлак була.

## Рәмзи Илялов *(1923–2009)*



1923 елның 13 декабрендә Башкортстанның Баймак районы Темәс бистәсендә туа.

1940 елның декабрендә Янавыл урта мәктәбен тәмамлагач, Ташкенттагы укчы-бомбардировщик авиамәктәбенә укырга китә һәм 1942 елның 22 апрелендә авиазвено составында самолет штурманы итеп Көнбатыш фронтка җибәрелә. 18 хәрби очыш ясаганнан соң, төнге бомбардировка вакытында Смоленск өлкәсендә бәреп төшерелә. Контузия алганнан соң, ул авиациядән мотоукчылар бригадасына күчерелә. 1942 елда автоматчылар төркеме составында һөҗүм вакытында дошман уты астына эләгә һәм каты яралана. Егерме кешедән өч кенә кеше исән кала.

Сугыштан соң Рәмзи Илялов әдәби-документаль повестьлар авторы буларак таныла.

## Ихмәт Исхак *(1905–1991)*



1905 елның 1 мартында Казанда туа.

Беренче шигырьләре 1923 елда «Кызыл Шәрекъ яшьләре» журналында басыла. Утызынчы елларда ул төрле газета-журналларда бүлек мөхәррире һәм мөдире, җаваплы сәркәтип кебек вазифаларны башкара.

Сугышка 1942 елның язында алына, 1945 елның августына кадәр Украина шәһәрләрендә хезмәт итә.

Сугыштан соң Әхмәт Исхак юмор-сатира остасы, мәсәлче һәм тәрҗемәче буларак танылу ала.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Флера
Гыйззәтуллина

# ВАТАН КӨЗГЕСЕ

ШИГЪРИ ДАСТАН

## 1 фасыл. Кабатлана тарих

**...Ай—көзгесе җирнең...**
**Ай тулганда**
**Сүнгән хисләр кабат яңара.**
**Язмыш дәрьяларын чайкалдыра**
**Йөрәктәге айлы манара.**
**Ай юлыннан мин дә Илгә кайтам**
**Җирләр кире якка әйләнсә...**
**«Кичер?!»- диеп мин Зөһрәгә дәшәм,**
**Торгынлыкта телем бәйләнсә.**
**«Кичер?!»—диеп киләм Тукайга мин,**
**Читтә йөреп батсам гөнаһка.**
**Айдан—Зөһрә, Җирдән—Бөек Тукай**
**Якынайта безне Илаһка.**
**Берләштерә безне әһле Иман,**
**Шигърияткә, нурга омтылыш...**
**Безнең кулда, безнең юл өстендә—**
**Омтылыштан торган бу тормыш.**
**Әҗәле дә аның безнең кулда—**
**Гомер кичә безнең арада.**
**...Тынычлана Тәкъдир, җәсәдеңне**
**Җир куенына илтеп сала да.**
**Бөек Ханмы, бер дәрвишме—әмма,**
**Яшәешкә кайтмый бер үлгәч.**
**Күбәләк—җан, ләкин, канатлана—**
**Кара кабер гөлгә күмелгәч.**
**Кабатлана тарих, кабатлана—**
**Тармакланып йөзгә, меңгәчә...**

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА—*шагыйрә, уннан артык китап авторы; «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар Берлегенең С. Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Шуны раслап, әнә, Сөембикә
Җиргә түтәл-түтәл гөл чәчә.
Талбишеккә салып тибрәтә ул
Якты истәлеген Сафаның.
Казан яры буйлап күккә үрли
Таң сулышын ачкан саф агым.
Күккә үрли бөек Тукай моңы,
Тиңдәшлеген раслап—ал таңга!
Ләкин Тукай үзе тиңсез кала
Гел әрнештән торган Ватанда.

## II фасыл. Тукай моңы аша...

*...Гел әрнештән торган ятим җаны*
*Ай шикелле ялгыз, ялангач ул...*
*Алдан алып гөлгә салсалар да*
*Йөрәгенә тынгы табалмас ул!*

...Мин дә ятим идем... Әрнеп сөйдем
Саф җилләрен Арча ягының...
Арча халкының мин даһилыгын
Тукай моңы аша таныдым.
Ерак калган тарих ярасыннан
Танып алдым нәсел кыягым.
Шул кыякның исен сулый-сулый
Дәверләрне урый хыялым.
Чынбарлыгым исә гаҗизлектән
Яшеннәргә түгә күз-яшен:
Яшен-кылыч кабат кыннан чыгып
Үзәккәен Илнең өзмәсен!
Чорның гаделсезлек сөремендә
Тотылмасын аең, Кояшың...
Бар минем дә газиз башкаемны
Кояш иңнәренә куясым.
Бар әле, бар әйтер сүзләрем дә,
Төзәтәсе ялгышларым да...
Үкенече гомерлеккә җитә—
Бер ялгышсаң язмыш ярында...
Анда синең бер ялгышың өчен
Бар эшеңне юкка чыгарып,
Соңгы тәкатеңне корыталар
Тәре юган суда сугарып.
Анда сиңа:
—Чукын!..
—Чукын!..—диләр,—
Кояшың күр булыр, чукынсаң...
Изге айга урын калырмы соң
Түшең тәре белән тутырсаң?
Мөселманга әллә мәҗбүриме
Тотып карау—диннең яңасын?
...Яу кубарган денсез үзе белән
Йөртә һәрчак попын, монахын.
Суырылган, имгәтелгән тәкать
Күтеп тормый суның тонганын.
Тәре үбеп, вәгъдәләшә шунда
Буй җиткезгән кызың-улларың...
Шул форсаттан катнаш никах туа;
Нәсел китә, ятка кан китә!

Иманыннан китә-китә кавем
Тугрылыгын хаклап ант итә...—
Адым саен:
—Сөям... яратам...—ди,—
Бата-бата яңа хатага.
Мондый сөю, борын-борынгыдан:
«Милли хыянәт» дип атала.

## III фасыл. Имгәтелгән хисләр аһы..

*Айга карап Язмыш юрый татар—*
*Юнәлсә дә юлы кай табан...*
*Ай—кан-кызыл!.. Әйтерсең лә Зөһрә*
*Айны кан күлендә чайкаган!*
*Әйтерсең лә Сөембикә анда*
*Тарый канлы тарих ялларын,*
*Ил искәрсен өчен—Илбасарның*
*Йөзгә бәргән яла-ялганын.*

...Күктән җиргә баккан Ай көзгесе—
Милләтемнең рухи өлгесе!
Сүнгән рухым кабат җанланырмы
Күзгә бакса йөзнең керлесе?
Шул көзгедән калкып, тәре колы:
—Табын!
—Табын!—дисә, нишләрмен?
Җанны кыеп гел тәрегә куна
Аһы имгәтелгән хисләрнең.
Бу көзгеләр никтер безнең йөзне
Керле... чалыш итеп күрсәтә.
—О-о-о, господи!—дигән өн ишетелә
Үзебез кайда гына йөрсәк тә...
...Ул көзгедә—күзләр яшьле безнең—
Иңнәр кылыч белән чабылган
Чалыш җанны ташлап китмәс өчен
Аяк-кулга богау сарылган.
Биш йөз еллык чылбыр-богау сөйрәп
Ничек ирешик соң ирекка?..
Моның авырлыгын аңлап була
Көзгеләрдән генә күреп тә.
Көзгеләргә генә күз төшсә дә
Барлаганда еллар чамасын,
Сагыш баскан милли асылыңның
Чалымнарын танып аласың.
Таң каласың үз-үзеңне танып
Олы юлда, Казан юлында...
Юл кичкәндә алган җан газабым,
Тыпырчынып сәгать угында,
Минем дастан язганымны көтә,
Ашыктырып көтә өзлексез...
Ә мин исә кәгазь-каләмем дә
Эзләп таба алмыйм күзлексез.
Яза алмыйм хәтта нәселемне
Төсләү өчен шигъри сүрә дә...
Үкенечле югалтулар ахры
Дәвам итә шуңа күрә дә.
...Татыдык бит... Беләбез бит юкса—
Катнаш канның җанны чагасын...

**Чукынышның, милли омтылышның**
**Җуйды милләт чутын-чамасын.**
**Ана—кызны, ата—улын җуйды,**
**Дошман әверелде әшнәгә.**
**Кендегенә алтын тәре элеп,**
**Татар кызы менде сәхнәгә.**
**Атын аның: «Сөембикә!»- диде**
**Алып баручысы кичәнең.**
**Хур иттеләр шулай милләтемнең**
**Ханбикәсен—бәгырь кисәген.**
**...Җырлады кыз... Төрле телдә җырлап**
**Төрле төскә кереп балкыды.**
**Кап-караңгы залдан иңгән алкыш**
**Күкрәкләрен аның талкыды.**

***

**Алкышлардан яраланган кызын**
**Ак бәрхеткә милләт төрсенме?**
**Моны күреп бары Тукай гына**
**Йөрәк турын тотып көрсенде.**
**Ә башкалар, калып, күңел ачты,**
**Хәмер эчте банкет-кичәдә.**
**Иман ябылып калды—хәмереннән**
**Бушатылган затлы шешәдә.**
**Шешәдәшләр, шанлы сәхнәдәшләр:**
**Хәтирәләр, Хәтим, Хәкимнәр!**
**...Чүплек башындагы буш шешәне**
**Җыйды ятимәләр, ятимнәр...**
**Алкашлыкка чыккан яшьләр өчен**
**Каравылга басты карт буын.**
**...Күрми калды яшьләр өлкәннәрнең**
**Ватан йөген җигелеп тартуын.**
**Без дә сизми калдык шигърияткә**
**Телсез маңкорт кереп тулганны...**
**...Кысыр калган кендек тирәсендә**
**Әйләнде дә дөнья тулганды.**
**Хатабызның нәкъ тә шул төшендә**
**Җуйды милләт яшәү бәһасен.**
**Мыскылланган, котсызланган төшкә**
**Ничек итеп чәчәк чәчәсең?!**
**Хаклык сорап кемгә сүз кушасың**
**Ут йотканда матәм хисаплап?..**
**Җавап—тынлык!.. Мин дә тып-тын гына**
**Елыйм чалыш көзге кочаклап.**

## IV фасыл. Кереп киләм ханнар заманына

*Чал гасырлар безгә богау селти—*
*Урә тотып атлы гаскәрен.*
*Кан коелмый, җан кыелмый калмый,*
*Гаскәр булса җиргә чәчкәнең.*
*Сөйләгәнең кара гайбәт булса,*
*Дошман керми калмый арага.*
*Дошманлашып чорлар данга үрли,*
*Тарих каны дөрли ярада.*

**...Чал чорнаган газиз башкаемда**
**Булмаса да уйның яманы,**

Ут... Кан... Богау күрсәм, хәтеремдә
Гәүдәләнә ханнар заманы.
Гәүдәләнә гүзәл Сөембикә:
—Газап йөгем, Раббем, күтәреш?!—
Бар дөньясын аның тулгаклатып
Тумыш таләп итә Үтәмеш.
Тулгак гаме өйдән-өйгә китә:
«Улмы, кызмы, Раббем, кем туар?»—
Үсеп җитеп, ат өстенә менгәч,
Булмас микән берәр «Җилкуар»?
Айга кырын карап, йолдыз санап
Кырылмасмы акыл-зиһене?
Арабызда галәми нур йөртеп
Сәламләрме олы-кечене?...

***

Кичерсә дә татар Ил өстендә
Шик-шөбһәле уйның төрлесен,
Күрәчәген багар өчен һәрчак
Үзе белән йөрткән көзгесен.
Киләчәктән ак бәхетен көткән,
Көтеп күзкәйләре талса да.
Исемен ул вөҗданына чиккән,
Антын чиккән алтын парчага.
Откан даны саллы булмаса да
Җаны белән Җиргә камалган.
Ләкин учта көзге уйнаклату—
Олы гөнаһ булып саналган.
Гөнаһ булган нәсел-ыруыңны
Мәхрүм итү бәби туеннан...
Үтәмешнең бәллүр бишегенә
Пар фәрештә килеп сыенган.

***

Фәрештәгә тиңдәш кыз-киленчәк,
Сый вә нигъмәт белән түр тулы.
Ләкин никтер сабый күзләр моңсу,
Сөембикә үзе борчулы.
Шуңа карамастан туй үтүгә
Сафагәрәй ауга җыена.
Әҗәленә юлдаш булачагы
Килми хәтта аның уена.
Җиһан шатлык белән тулышканда
Ул яманлык көтми кемнәндер...
Илне тугры юлга алып чыгар
Йөз кыйбласы аның бердәнбер!
Йөз кыйбласы аның—изге Коръән,
Ризалыгы бөек Аллаһның!..
...Үз каныңны дәвам итеп, Җиргә
Туып килгән яңа алмашның
Киләчәген, бөтен күрәчәген
Үз өстенә йөкләп алгачтын—
Хакың бармы хата җибәрергә,
Читкә юнәлтергә ваемың?..
...Юк... Юк... Сафагәрәй сыен бозмас
Балкып килгән бәхет Аеның...
Иман шартын бозмас!.. Әнә ич ул:

Коръән тотып антын яңарта.
Уңышлы ау теләгәндәй аңа—
Нурларын таң Җиргә тарата.
Коръән сере хәтерләтә әмма
Таң алдыннан күргән төшләрен:
Акбүз аты белән ярымайлы
Манарадан егылып төшкәнен,
Ишеткәнен шунда шомлы хәбәр,
Казансуы ярга бәргәндә:
—Мәскәү падишаһы канга сусау,
Казан сусау ашыгыч ярдәмгә!
Сөембикә сусау... Сусавына
Дәва табар ләкин кем аша?
—Ник ярдәмгә килми атам?—ди ул,—
Хәлгә керми туган-тумача?...

Нинди кайгы ирен бимазалый—
Уйга батса йөзе карала...—
Ихлас мәхәббәте сүрелдеме,
Хәрам керде мәллә арага?
Түземлеге төкәндеме ханның,
Сыный-сыный дошман, дусларын?
Чын дус сине имин юлга кертә,
Дошман алдан йөртә куштанын.
Дошман Илгә әләк, гайбәт кертә—
Изге туфрагыңа кер селтәп...
«Кер генәме?...» димик,—ошбу кердән
Манаралар ава гөрселдәп.
Заманалар ава, заманалар—
Ватан күкрәгенә капланып...
...Һай, уйлансын иде Сафагәрәй—
Бикәсенең сүзен хак танып.

## V фасыл. Хан йөрәге җиңү таләп итә

*Белә татар: Ил башчысыз калса*
*Тарих гарасаты үрә басыр...*
*...Кыл өстендә—җилән итәкләрен*
*Ука белән каеп чиккән гасыр.*

...Сөембикә ир сүзенә күнде:
«Ау кәсебе лаек хөрмәткә...»—
Затлы аучы күл буена килсә—
Угын төбәп ата үрдәккә.
Ә затсызы «үрдәккә» дип китеп
Атып ала урман бүресен.
Андыйларны ләкин каргый милләт:
Билең сынсын, затың корысын...
Көне-төне каргый... җиде ятның
Юлын кисә-кисә ак бүре.
Ак бүре ул—төрки кавеменең
Яуда яраланган хәтере.
Ул ирекккә, күккә озатучы
Азан моңын, былбыл моңнарын.
Палач исә, изге бу моңнарга
Батырган да тутык тырнагын,
Берәүдән дә рөхсәт сорап тормый,
Үзлегеннән бирми хисап та...

Шуны уйлап күздән йокы кача
Ялкын сүнә яккан учакта.
Ә күрәчәк сыный, күз-керфеккә
Аллы-гөлле сихри сер элеп...
Хан булып хан кайчак хаталана,
Үз серенә үзе сөрлегеп.
Хан йөрәге тәвәккәллек йөртә
Чишелмәстәй серләр аша да...
...Бу арада серле тәэсирләрдән
Берчә иләсләнеп, Сафа да
Батып барган ай-көзгегә карап,
Онытылып торды чак кына.
Шул форсаттан дошман хәйлә корды
Ханга үлем яулау хакына.
Шул форсатны күреп куркып калган
Күрәзәче Айга фал бакты.
«Иван» атлы әҗәл карачкысы
Эт өстереп Айны талатты.
Татар Ватанының җирен-күген
Котырынган этләр ураткан...
...Фалдан сөйләттергән ишаpәләр
Шундук очып чыкты колактан.
Һәм шунда ук җырлы аһәң сузып,
Таң кошлары Ханга дәрт бирде.
Назлы кош каурые биреп кенә
Алдап булса икән Тәкъдирне...

## VI фасыл. Урсәләнү

*Ватан ава, милли бердәмлектә*
*Какшый калса иман, вөҗдан, ирек—*
*Онытты Хан данлы ау йоласын,*
*Дошманнары ирегенә биреп.*

...Онытты Хан бүре аучысының
Татарлардан тәхет даулавын,
Аю-бүреләрне үксетерлек
Кайгыларда Илнең кайнавын.
Онытты ул хәтәр төшләрен дә
Коелганда Җиргә таң чыгы...
Ау юлына ашыктырды аны
Җансакчылар—атлы, камчылы.
Ашыктырды шаулы карурманнар,
Гөлчәчәкле сихри болыннар...—
Һәр күренеш монда җырдагыча,
Һәр әйткән сүз—шигъри, легендар...
Бөтен байлык монда татарныкы!..
Татарныкы—Ай да, Кояш та...—
Бу киңлектә татар Ватанына
Нигә Кояш булып тумаска?!
Нигә балкымаска: сулар буйлап,
Уйлап алтын балык хакында...
Татар бит ул борын-борынгыдан
Акыл егәрләгән алтынга.
—Сөюем хак!..—
Кап-кап, алтыным!..—дип,—
Океан суларына ау салган.
Җәтмәсенә хәрам капмаганда

**Иман ае исән-сау калган.**
**Ай янында Зөһрә йолдыз калган,**
**Кандаш булып Сөембикәгә...**
**Үрсәләнә җаннар—ирегенең**
**Ачылганын көтә-көтә дә...**

***

*Тарих тегермәне әҗәл тарта,*
*Тарткан саен үкенечләр арта.*
*Кан тамырлар буйлап саркый-саркый*
*Бакыйлыктан кайтавазлар кайта...*

## Беренче кайтаваз

*Тәкъдир:*
**...Таң алды. Бала елый.**
**Исә җил ярсып-ярсып.**
**Тәресен шакый таңга**
**Мәскәү—мәкерле карчык.**
**Кан эчкән кара хөсет**
**Иделгә көри гайбәт:**
**—Чукынган милләт әйбәт!**
**—Буйсынган милләт әйбәт!**
**...Буйсынмас горур татар—**
**Тарихта тирән даны...**
**Бүредән күчкән, имеш,**
**Кодрәтле кайнар каны.**
**Иманын сатмас өчен**
**Сугыша бүре сыман!..**
**Татарның хозурлыгы—**
**Таңга нур уйган иман!**
**...Тәм табып кан исеннән,**
**Мир канын агызудан,**
**Татарның иманына**
**Ау кора явыз Иван.**
**Эт өрә, бүре улый;**
**«У-у-ууу!!! Уян, Казан!!!**
**Биленңне сындырырлык**
**Башыңа төшкән казаң!**
**Алдагы күрәчәгең—**
**Кыңгыр эш, кыңгыр болыт!..**
**Сынарлар иманыңны—**
**Утларда ургылдырып.**
**Кортырлар Ватаныңны—**
**Халкыңны асып-кисеп...**
**Һай, гүзәл Сөембикә,**
**Түзәрсең моңа ничек?**
**Ни белән бәхилләрсең**
**Балаңның кадер-санын?**
**Бала бит бәгырь каны—**
**Бәһасы чиксез аның!**

## Икенче кайтаваз

*Ак бүре:*
**...Сихерләп йоклаткан хәтердәй**
**Ул көнне тын иде урман да...**
**Гөнаһлы чор эзен тирәнгә яшереп**

Чумган җир чәчәкле юрганга.
Хыялда йомылган Сафа да
Ахрысы Җир хакын хаклады:
Ул сикереп иярдән төште дә
Болыннан җәяүләп атлады.
Ә дошман көнчеллек мәкерен
Кояшка шәл итеп элдерде:
Күз ачып йомганчы ук төбәп,
Җәясен тартырга өлгерде.
Сызгырып үтте ук берочтан
Кояшлы хыялга, йөрәккә...
Якында юк дус та, дошман да—
Йөрәкне бәйләргә кирәктә.
Йөрәк тик сулкылдый: «Каныма
Манып, хан, ярыңа хат озат.
Мөһерле һәм тере хат булып,
Казанга томрылды
Кан иснәп ярсыган Акбүз ат.
Һәм Ай да иярде аңарга—
Кайгыда бергәләп янарга,
Хаклыкның күзенә багарга...

## Өченче кайтаваз

*Иртәнге моң:*
Ау атларын кешнәп түли диләр
Күтелмәгән әҗәл ясагын.
Кешни-кешни кара төскә кергән
Акбүз аты мәгърур Сафаның.
Чал чәчләрен кара шәлгә төргән
Тол бикәсе—Сөембикәсе...
Аңлашылмас төсләр алмашында
Туып килә Казан иртәсе.
Туып килә меңәрләгән сорау:
—Кем ул—хаин?..
—Ханга кем аткан?..—
Ялгыш бозып милли ау йоласын
Хан үземе әллә сынаткан?
Җан сакчысы ялланганмы ятка
Булу өчен алтын-көмеше?..
...Еллар буе Ватан матәм кичте:
Кичереше белән җиңеште,
Көйгә салды Сафа иҗат иткән
Легенданы, Җырны, Хәтерне...
Алда нәрсә көтәчәген ләкин
Үтерүче сиңа әйтерме?!!
Әйтерме ул нигә чукынганын:
Динен сатып яттан отылганын,
Чиста канлы, шанлы нәселенең
Тәре юллыгына йотылганын...
Кертерме ул, югарыдан карап
Татар файдасына төзәтмәләр?
Һәрчак телсезлеккә дучар булган
Палачларга каршы сүз әйткәннәр.
Юкса палач та бит бәйрәм корып
Шигырь сөйләп, җырлап күңел ачкан,
Үз телендә «бисмилласын әйтеп»
Кан укмашкан хәтер күзен ачкан...

## Дүртенче кайтаваз

*Ятим ямансулык:*
Су өстендә—бала акчарлакмы,
Ханбикәме елый сулык-сулык?..
Юк... Ханбикә түгел, Ханбикәгә
Хәбәр юллый ятим ямансулык:
—Тәрәз аша күз салсаңчы, бикәч,—
Күзең яшь түгүдән бушаганда...—
Өтек чырай сытып, тәре тотып,
Явыз Иван тора бусагаңда!—
Сакчылары, палачлары тора,
Үткен балта—кылыч билләрендә!..—
Ил өстенә сасы агу чәчеп,
Елан боргалана телләрендә.
Шул кайгыдан дулкынлана Идел,
Ярларыннан ташып чыга-чыга...
Сабырлыкка өндәп Кол-Шәрифең
Манарадан азан моңы суза.
Әмер бирә Иван:
—Көймәгездә
Җитәрлек бит утлы сумалагыз!
Азаннарын, бөтен Казаннарын
Утлап, сумалалап томалагыз!
Буйсынмаган, чукынмаганнарны
Уздырыгыз балта... кылыч аша...
Шулай баш калкыта гасырларны
Кара гүрдән йөрткән бу тамаша.
Бу явызлык, бу кара көч җирне
Рухи төпсезлеккә тарта тора.
Явызлыкка хезмәт иткән бәндәләрдә
Шәфкатьсезлек, рәхимсезлек арта тора.
Чукынышып эчкә мәкер җыйнаганнар
Сөембикә каргышына эләгәләр:
Танымыйча берсен-берсе тотып ашый
Су төбендә җәяү йөргән күләгәләр...

## Бишенче кайтаваз

*Сөембикә манарасы:*
...Кемгә үлем!.. Кемгә сөрген яный.
Кемдер елый күрәчәген каргап.
...Ага Идел... Аның агымнары
Милләт хәтередәй тармак-тармак!
Шушы тармакларны барлау өчен
Теләктәшләр, йөрәктәшләр җитми.
Аксөякләр, әйдәмәннәр—уйда!—
Уйлар урау! Чырайлары җитди,
Һәр чырайдан ләкин укып була:
Һәр «аксөяк» үзен «хан» дип таный,
Сөембикә аша каш җыерып,
Нәни ханга—Үтәмешкә карый.
Астан сөзеп хан тәхетен капшый
Кан исеннән котырынган хөсет,
Бата бара милләт, бата бара
Хөсет, мәкер упкынына төшеп,
Һәр сунарчы атлы гаскәр туплый,
Яңа кын койдыра кылычына—

Кыз ярәшеп бүләк итәр өчен
Ун балалы Мәскәү урысына.
Мин дә авышамын Казансуга:
Хәрам форсат уңлы-сулы суга.
Нәфрәт сазлыгына чума-чума,
Иман баскычлары шартлап сына!

## Алтынчы кайтаваз

*Шигъри кодрәт:*
Яна Казан! Дөрли-дөрли яна.
Утта яна изге Коръән, әфтиякләр.
Җиргә чүгә-чүгә тәре үбә
Сатлык җанлы, зәгыйфь аңлы бәкләр.
Кыяматкә тоташ чал тарихның
Хыянәте хәтәр сабак бирде:
Ханбикәсен озатты да Казан,
«Ләхәүлә»сен баш очына сөрде.
... Баш очында—ата-баба анты
Гасырлардан күчкән изге мирас!—
Нәсел тибеп туган җирдә манты,
Хәләл иманыңа кыйбла уйгач.
Юнәл изге ханнар зиратына,
Көчләп чукындыру гасырына...—
Кем хатасы белән бу гасырлар
Муенга таш булып асылына?!.
Ни майтарган дәвер—ут эчендә
Татар башы белән тау-таш көрәп?—
Уйлан шунда... Уят хәтер моңын,
Кабер ташларына башың терәп...
Гүрдән-гүргә йөреп кайтар кире:
«Бөек татар» дигән исемеңне...
...Шигъри телдә язган изге Коръән
Әмма бу мәхшәрне кичерерме?
Безнең ханнар әллә шигъриятне
Аерым караганмы Коръәннән дә?..
Шул сораулар бездән җавап көтә
Аллаһ рәхмәтенә теркәлгәндә.

## Җиденче кайтаваз

*Тукай:*
...Сафагәрәй.. Олуг Мөхәммәтме—
Кайсы хан соң шагыйрь булмаган?
Безнең ханнар шигъри телдә хәтта
Ак бүрегә сәлам юллаган!
Шушы йола чордан-чорга китеп
Мәртәбәгә чөйгән Ил данын...
Мәхәббәте, шигърияте сүнсә,
Яме калыр микән дөньяның?
Гашыйк итеп булыр иде микән
Бер ваемсыз, хиссез бәндәне?
Шагыйрь бит ул ваем чыганагы,
Шигырь бит ул йөрәк шәмдәле!
Шигырь бит ул очар канатына
Оялаган Кояш—Пегасның.
Татар йөрәгендә бәргәләнә
Җиһан киңлегенә сыймас моң.

**Йөрәк белән ләкин хисаплашмый**
**Халык дөнья көткән чагында.**
**Халкы көйсезләнсә, йөкли шагыйрь**
**Нахагын да сүзнең, хагын да.**
**Акчасызлыгын да, ачлыгын да**
**Саклый шагыйрь шигъри биштәрдә,**
**Биштәр асып әмма үлгәндә дә**
**Чыкмас үзе хәер эстәргә.**
**Авызы тулы кара кан булса да**
**Мир алдында җиргә төкермәс...**
**Йотылыр ул бары йөрәгенә—**
**Тиешлесен язып бетергәч.**

## Сигезенче кайтаваз

*Милләт аһы:*
**Тукай һәм Ай—рухи рифмадашлар,**
**Имандашлар туа-тумыштан.**
**Аларның да алган яралары**
**Ятимлектән. Тәре. Кылычтан...**
**Ай сагышы, Тукай ятимлеге**
**Уза бит ул безнең аша да...**
**Адым саен:**
**—Аһ!—дип, сыкрый Язмыш,—**
**Кылыч йөзләренә баса да.**
**Изә, сыта сагыш тәгермәне**
**Азатлыгын шигъри азанның...**
**Азан өннәрендә Тукай үкси,**
**Нигез ташы үкси Казанның.**
**Берөзлексез үкси Сөембикә**
**Ай-күзгедән карап туп-туры:**
**Ярдәм көткән чакта нәсел-затта**
**Какшадымы иман ныклыгы?**
**Ясадыммы берәр ялгыш адым—**
**Афәт ябырылганда Ил-көнгә?..**
**Ватаныңа басып кергән дошман**
**Җыр тергезми синең иркеңдә.**
**Күкләр җавап бирми:**
**—Кичер?!—диеп,—**
**Илерүләр, тилмерүләргә...**
**Мондый чакта һәр сулышың өчен**
**Кирәк каның белән түләргә.**
**Көрәшергә, берләшергә кирәк,**
**Тайпылмаска кирәк хак юлдан—**
**Имансыз да, Ватансыз да калып**
**Язмас өчен һуштан, акылдан.**

## Тугызынчы кайтаваз

*Изге Аксакалы Казанның:*
**Җан азыгым биш вакытлы намаз иде,**
**Йөз кыйбламда илаһилык вә наз иде.**
**Ярты юлда намазымның өнен өзеп,**
**Ил өстенә афәт килгәнлеген сизеп,**
**Кулыма мин кылыч алдым...**
**—Ватаным!—дип уттан-утка ташландым мин:**
**Ут үрләде сакалыма, чапаныма...**
**Кылыч белән сакалымны кисеп алып**
**Ут ыргыттым шулчак мәхшәр шакалына.**

Ил өстендә шакал тоташ улап торды,
Илгә әҗәл юрап торды кылыч чары...
Шул чарларга бәхиллегең сала күрмә,
Һай, Ватаным!
Һай, татарым!
Һай, Җир шары!
Һай, тулган ай!..
Кояш белән тотылган Ай!..
Җирнең кайгы-хәсрәтенә йотылган Ай!
Сине баккан гашыйкларның сөю хисе
Мәхәббәткә, мәрхәмәткә, хыялга бай...
Ватан өчен син сабырлык символы да,
Син илче дә—көн белән төн арасында.
Алданиләр күрәчәген алдан белеп
Яктырасың милләтнең күз карасында.
Һәр инсанны кисәтәсең, үгетлисең:
—Тугры бул!..—дип, иманыңа, намусыңа,
Намуссызның «сатлык» дигән даны чыга,
Базар ачып, сатулашып җаны чыга.
Базарларда базлар төпсез, стенасыз:
Пычагы да, бомбасы да анда сыя...
...«Дан әһеле» маен, балын алга куя.
Һәм... теләсә—пычаксыз да сине суя..
Һәм шунда ук бар дөньяга разбой сала:
—Мин гаепсез! Ул бит үзе суелды—дип,—
Ялангачлык, ачлыгына ачу итеп
Әҗәл кочагына килеп сыенды,—дип...

## Унынчы кайтаваз

*Ак бүре:*
Күрәсезме, кыр казлары китә
Чиксез билгесезлек тарафына?—
Көмеш каурыйлары коелып кала
Айлы манаралар арасына.
Борынгыдан килгән изге йола:
Кыр казына хәерле юл багыш...
Әүвәл шагыйрьләргә куна бит ул
Кыр казларын гаҗиз иткән сагыш.

***

Толлык, хурлык, коллык сагышын да
Читләп үтеп булмый бу җиһанда.
Сагышларга ничек сабышканын
Кол Гали дә язды, Кол Туфан да.
Мусалар да «Җырларым»ны җырлап
Атлап керде палач бусагасын.
Күкрәгеңнән җыру бөркелгәндә
Үләреңә ничек ышанасың?!
Җырлавыңнан ничек тукталасың
Кан дошманың анда сөендереп,
Кыр казына яфрак изәп калган
Каеннарның башын иелдереп.

***

...Җәлилчеләр җырлап туктамады,
Балта әңгәмәсе хупланмады,

Алар җырлый-җырлый еладылар,
Ак каеннан кичерү сорадылар.
Һәр батырлык, әйе, җыру сорый,
Ватанына үлемсезлек юрый.
Сорый саф мәхәббәт чыганагын,—
Сагышлардан сынмый чыдаганын...

***

Күкрәп үскән серле урман сыман
Көрәш җыры тирәнәя бара...
Һәр шагыйрьнең күкрәк кагышында
Тамбов урманнары яфрак яра.
Һәр яфрактан бер поэма саркый
Кавем сулышына ашлам булып,
Җирне күккә тоташтырып торган
Сөю тугрылыгын сафландырып.
Шул сафлыктан син баш тартып кара—
Сылтап Илгә заман авырлыгын—
Калыр микән кеше арасында
Үз-үзеңне күреп танырлыгың?..

***

...Шагыйрь—былбыл...—кылыч тагып йөрми,—
Томшыгын ул мәхәббәткә кайрый.
Җирнең иминлеген яклап сайрый,
Хак Тәгалә хакын хаклап сайрый
Шагыйрь базар ачып корал сатмый,
Сугыш ачмый җир һәм мал даулап.
Бер басмач та үлем үзәненә
Кертә алмый аны богаулап.
Тукай да бит, Һади Такташ та бит—
Милләт хәтерендә—үлмәгән...
Безнең кавем: «Туган тел»не көйләп,
«Мокамай»ны көйләп дөрләгән!
Безнең кавем көрәш дәверендә
Чабата да кигән, галуш та...—
Дөньякүләм хәтер күрке итеп
Сагышларын чөйгән камышка.
Камыш шаулый җилсез көнне дә,
Уйга салып кара төнне дә...

## Унберенче кайтаваз

*Колшәриф:*
Иман антым кочып күккә ашкач,
Мин дә серем Айга сөйләдем.
Дошман аткан таштан таулар өйдем,
Әмма башым түбән имәдем.
Ай бүген дә сөйли шушы хакта:
—Уяныгыз!—диеп, чаң суга.
Айдан битәр бер җисем дә әле
Юлыкмаган мондый ярсуга.
Илне басып алган тәре явы
Шәфкать күрсәтмәгән һичкемгә.
...Татар гаме уҗым булып шыта,
Җәсәденең көле өстендә.
Татар халкын «кол» дип түбәнсетү

Ут йөгертә билгә, тезләрдән...
...Без бәхиллек сорап тезләнсәк тә
Бер Аллаһка кайтып тезләнгән.
Рухыбызны ятка мескен итеп
Күрсәтергә безгә кирәкмәс!
Казансуга карап уйга талган
Һәр тал-тирәк безгә йөрәктәш.
Талга кунып сайрар һәр сандугач
Туып килгән таңнан моң утлый...
Хак Тәгалә сандугачка тиңдәш
Моңдаш имандашын онытмый.
Онытылмый йөрәк каны белән
Ташка уеп язган исемнәр.
Аллаһ хозурында калучылар
Шул ташларга рәхмәт дисеннәр.
Безнең хакта бәет көйләсеннәр,
Көйләсеннәр «Ихлас» сүрәсен...
Ачыклыкта тотып рухи көчең,
Ихласлыкка күтәрелү өчен
Шәһит китү кирәк, күрәмсең...

## Уникенче кайтаваз

*Сөембикә:*
Елап табындырган Ай-көзгемне
Куя алмам инде кулымнан.
Узган гомеремнең һәр мизгеле
Тамып тора хәтер чугыннан.
Кайнар күз-яшьләрем юып тора
Гөлгә кушып чәчкән сер эзен...
Ватан хакын, иман хакын хаклап
Мин сөргенгә киттем берүзем.
Үзем китү белән вәхши җаннар
Күтәргәннәр Илне кылычка...
Чабылдымы—оча уңлы-суңлы
Адәм башы—канлы йомычка!
Мәхәббәт тә каннан яратылган:
Саркыла кан—сөю антымнан.
Татар Иле һәлак булган турда
Күкләр җәя булып тартылган.
Шунлыктанмы, җиде катлы күкләр
Ирештерми миңа бер сүз дә...
Мин Ханбикә идем... инде менә
Ватансыз да калдым, гүрсез дә...
Үлгәч баш очыма—билге өчен
Куймадылар таш та, гөләп тә...
Кара кан эчендә җәйрәп калган
Ил зираты—минем йөрәктә!
Минем йөрәгемдә туксан тәмуг—
Чыганагы туксан хатамдыр?.
Таянычсыз калган аянычым—
Хаталарга баткан Ватандыр...
Илдән теләп сөрелгәннәр өчен
Михнәтледер айсыз кара төн...
Мин күкләрдән йолдыз җилпер идем—
Әгәр булса очар канатым.
Җир шарларын йөз кат урар идем—
Уч төбемдә тотып айны мин...

**Башым җиргә игән көннән башлап**
**Коллык кайгысыннан айнымыйм.**

## VII фасыл. Үчле җилләр, хәтәр җилләр исә

### I

*Без дә гомер кичтек, антлар эчтек:*
*Ата-баба хакын хакларбыз...—дип.*
*Сөю хисен, йөрәк кичерешен*
*Хәтер сандыгында сакларбыз...—дип.*

**...Хәтер көне җитсә, тарих калка,**
**Дәрья шартларыннан урап кайтып,**
**Төнлә юл адашкан мосафирдай**
**Гасыр капкаларын шакый вакыт.**
**Барлый вакыт Ватан сакчыларын:**
**—Уяулармы, аек, исәннәрме?**
**Ил эченә сыйдырамы илат—**
**Иләмсезне, гамьсез, үшәннәрне.**
**Илдә базар ачып баеганнар,**
**Алданганнар, таланганнар нишли?..**
**...Сакчы рапорт бирә:**
**—Байгуралар**
**Айга менеп айгыр булып кешни!**
**Бай кайгырта фани дөнья эшен**
**Хәерчеләр, коллар эшләсен, дип,**
**Океан артларына олактырган**
**Долларларның хакы төшмәсен,—дип.**

### II

**«Доллар» дигәч, кисәк айнып хистән**
**Мин дә ачам хәтер сандыгымны.**
**Аннан ыслап кара елан чыга**
**Яулап алу өчен җан җылымны.**
**Аннан чыга сугыш аждаһасы,**
**Ачлык, ялангачлык, көрәш, үлем...**
**Шушы хакта сакчыга сүз катсам,**
**Ни өчендер көрмәкләнә телем.**
**Томалана кинәт ике күзем,**
**Каный башлый елан чаккан йөзем...**
**Чагылудан исән калыр өчен**
**Еланнарга телим сабыр... Түзем...**
**Һәм яудырам үз-үземә сорау:**
**—Нинди гөнаһ кылдым, нинди хата?**
**Сугыш талап алган язларыммы—**
**Алларыма елан булып ята...**
**Хакланмаган ата-баба хакы**
**Бездән шулай әллә үч аламы?**
**Шомлы кара елан заманасы**
**Үчләшүдән әллә көч аламы?**

### III

**...Үчле җилләр, хәтәр җилләр әле дә**
**Мир хатасын Ил өстенә ишә...**
**Бу хәтәрлек әйе, иң әвәле**
**Иҗатчылар җилкәсенә төшә.**
**Шушы хакта язсаң—ак җирлектә**

Пәйда була кара полосалар.
...Байлар аңлар иде, йөрәкләрен
Палас итеп селкеп карасалар—
Аңлар иде... Кара полосада
Тартышканнар белән бергә атлап...
Каралыкны кая яшерсәң дә
Булмый аны сер иттереп саклап.
Антларны да баш очында гына
Булмас иде саклап тотып һәр ләм[1]...
Икейөзле, азгын бу дөньяда
Һәр тарафка кирәк ашыгыч ярдәм.
Һәр инсанга тәвәккәллек кирәк
Саклап калу өчен йөз аклыгын
Хәтерләргә, фасылларга йөкләп
Кайтарганда җырга үз хаклыгың.

## VIII фасыл. Явызлыкның авызлыгы кемдә

*Фасыл санап язмыш багучылар:*
*«Айга кырын карамагыз!»—диләр,*
*Мәхәббәтне, хисне, миһербанны*
*Явызлыктан аралагыз!»—диләр.*
*Явыз белән тау кичмәгез,—диләр—*
*Булса да ул таудаш, ызандашың...*
*Зурлык, муллык хакын бүлешкәндә*
*Нәфесеннән ары узалмас ул!..*

Явызлыкның дине, милләте юк,
Ул үлемсез, тотанаксыз, кыргый.
Сөюен ул тауга тиңләп зурлый,
Тауга күтәрелсә—Айга ыргый.
Явыз үзен—Аллаһ күреп таный,
Гөнаһсыз дип таный—тулысынча...
Ватандашын чагар шикаятен
Аяк белән яза, кулы сынса...
Кылычын да кында сакламый ул—
Баш очында, югарыда тота.
Дус йөрәген яралаган өчен
Куштаныңнан мактау сүзе ота.

***

...Явызлыкка авызлыклар юктыр...
Юктыр ахры дәва яманаттан...
Чөнки без бит—түзем!—эндәшмибез,
Көн күрсәк тә ярык тагарактан.
«Байбыз...»—дибез, исән-саубыз...—дибез,
Ярчыклы җан әрнеп сызланса да,
Хәтер дулкыннары аргы ярга
Үрә каткан килеш бозланса да.
Әйе... Әйе... Без яшибез әле дә—
Явызлыкка юл ачылган мәлдә.
Үз-үзеннән йөз чөергән заман
Өстерәлә аңлашылмас хәлдә.
Яхшылыгын, яманлыгын да ул
Кертеп тора төрле кыяфәткә.
Кайбер акыл ияләре хәтта
Сөеп карый кебек бу афәткә!..

[1] һәр ләм—һәр сүз саен.

Тарихчылары да чуар тавык!—
Бер үк чүпне тибенеп «җырлай» сыман.
...Тарих—ялкау!—яткан җирдән генә
Үләксәгә баккан—бурзай сыман.
Авызлыксыз хәтәр авырлыкны
Һәр тарафта тарих сынландыра,
Мондый халәт иҗат әһелләрен
Шомландыра бит ул, шомландыра.
Эт хөкеме шик астына куя
Халыкларның милли дәрәҗәсен.
Шулай булгач ничек Ил каршында
Шәҗәрәләр санап шәбәрәсең?!.
Байрак итеп ничек күтәрәсең
Кара янган сугыш гарасатын?
Синә төкереп баккан мәнсезләрне
Ничек итеп күзгә каратасың?!
Кан косудан ничек аралыйсың
Гамилләрең... Тукай... Туфаннарың?
...Юк, мин шигърияттән тулган Айга
Ал байраклар кочып очалмадым.
Ир көйләгән, бала баккан өчен
Алтын медаль миңа бирмәделәр.
Шәҗәрәсез ирдән ул баланы
Нигә таптың?—диеп тиргәделәр.
...Үстерсәм дә аны бик кадерләп,
Тиңләп күзләремнең карасына—
Бүгенгәчә күкләр күз-яшь коя
Шул баламның йөрәк ярасына.
Өермәле давыл кубып тора
Үзем нәсел типкән тыныч ярдан.
Минем шәҗәрәмнең дәрәҗәсе
Тып-тын тамып тора кылычлардан.
...Ватан башын кискән шушы кылыч—
Гел исбатлап тора кискенлеген,
Явыз затлар салган хыянәтнең
Җирдә бар нәрсәдән өстенлеген.

## IX фасыл. Сагыш

*...Бүре күзләрендә—сары сагыш!—*
*Ай фасылы аша иңәдер...*
*Бала чактан таныш бу фасыллар*
*Алгысыта мине нигәдер?!*
*Шуңа күрә тыныч тормыш теләп*
*Укыйм Айга «Сабыр» сүрәсен.*
*...Бүреләр дә Айга карап улый:*
*Сагышлары уртак, күрәмсең.*

...Сагыш тулы риваятьләр, дастаннар
Борынгыдан Айга сукмак сабалар.
Саргаюдан йола торган дәвалар
Калдырмаган безгә ата-бабалар.
Залим патша кылган гөнаһларының
Калдырмаган санап чутын-чамасын.
Гаепсездән гаеплегә чыгарып
Казаматка яткан побын, монахын.
Үз баласы, үз Алласы өстенә
Көтү-көтү явыз этләр өстергән.

Чиный-чиный шул этләрме шуыша
Сөембикә чәчәкләре өстеннән?
Әллә теге сагыш эчкән бүреме—
Парын эзли гөлчәчәкле бакчадан?
Әҗәленә дәва көтеп кансырый
Кылыч белән туракланган барча җан.
Ничә гасыр ачыш көткән хакыйкать
Тарих күзәнәкләрендә мөлдери.
...Юк... эт түгел, эт хәтерен уятып
Дошман якка әсир төшкән тел йөри.
Айдан төшкән яктылыкка ияреп
Эзәрлекли безне бүре сагышы.
Ешайганга микән йөрәк кагышы,
Тармаклана гомерләрнең агышы.
Югыйсә бит гомер юлым—тулаем
Агымнарга каршы йөзеп узылган...
Шигъриятькә яккан учакларымның
Ялкыннары офыкларга сузылган.
Ваем сала дошманга да, дуска да
Азатлыкка юл күрсәткән учаклар...
Бакыйлашкан гүр салкынын искәртә
Учак утын татымаган кочаклар.
Ирек өчен көрәшмәгән милләтләр
Коллык хурлыгыннан айный алмыйлар,
Баласының, ата-бабасының да
Кем булуын инде аңлый алмыйлар.
Алар инде Алладан да ваз кичкән:
Шигырь нуры качкан гамьсез йөзләрдән.
Сүзсез генә шул йөзләрне күзәтәм
Сөйләнмичә һәлак булган сүзләрдән.

## X фасыл. Язмыш

*...Моңсулансаң, агымсуларыңны*
*Шигъриятең белән ишләрсең...*
*Шагыйрьләрең бүре булып улар*
*Чиккә җитсә, Ватан, нишләрсең?*
*Нишләрсең син, татар, ятимнәрең*
*Ычкындырса җирне кучәрдән?*
*Ятим моңындагы хисси зиндан*
*Тере ут өстенә түшәлгән.*

Илаһият, Илһамият ае...
Тукай ае диләр бу айны.
Моңга талган утлы минутлардан
Күзләп киләм бөек Тукайны.
Ил язмышын көйлим бертоташтан:
Язмый торсаң—зиһен таркала
Язмыш бит ул—бала! Үсеш ала—
Кочып йөрткән чакта аркаңа.
Илаһилык иңә, кысыр калып
Буш тотмасаң җырлы бишекне...
Хәмер түгел... Газиз башкаемны
Бөек Тукай моңы исертте.
Хәтеремә, керсез вөҗданыма
Ак бүресе Илнең баш сапты.
Хәтерен һәм Ил йоласын җую
Ләкин бик күпләрне аксатты.

**Горур башын, Ай-Кояшын алып**
**Андыйлардан качты иман да...**
**Алларыма чәчәк сипсәләр дә**
**Тик кан гына күрдем мин анда.**
**Шигъри телдә бүре каны ялап**
**Тарих белән килдем күзгә-күз...**
**Тик бүрегә:**
**-Тү-үз!—диюдән битәр—**
**Әйтәлмадым мин дә үзгә сүз.**
**Шуңа микән җирне шомга сала**
**Ай-күзгедән төшкән сагыш-моң?..**
**Ак каеннар әнә яфрак коя**
**Уртасына җитеп августның.**
**Бездән рәхим-шәфкать көтә-көтә**
**Ауганнары бардыр—ничә төп!..**
**Карадагынай урман, караңгы төн**
**Кала арттан күкиш күрсәтеп,**
**Татарларга кисек тел күрсәтеп**
**Җир ычкынып бара кучәрдән...**
**—Кот-ка-ры-ыгыз!!—диеп, оран сала**
**Тиздән исебезгә төшәр гамь...**

## XI фасыл. Мин кол түгел...

*Мәхәббәттән, шигърияттән бизгән*
*Кара йөрәкләрдә—җан кысан!..*
*Шигъриятькә милли аһәң эзләп*
*Кара полосада тартышам.*

**Җир-су өчен, әзер мөлкәт өчен**
**Ашамаган кемнәр кем башын?**
**Эт улавы, бүре дулаулары**
**Баскан әнә, бөтен дөньясын.**
**Үксезлек һәм затсыз имансызлык**
**Кунган байракларның алына...**
**...Үлеп киләм...**
**Җаным—сөюемнең**
**Дөрес чагылышын сагына.**
**Чалышлыкка дәва табалмасам—**
**Куркам: «күзгемне,—дип, ватармын»...**
**Мин тумыштан дөреслеккә мохтаҗ,**
**Ятим шагыйрәсе татарның,**
**«Теләп сөрген киткән» шахтер кызы—**
**Баш чөереп яшьлек гомердән.**
**Бер чеметем хәләл бәхет эзләп**
**Таулар өйдем кара күмердән.**
**Себер буйлап тимер юллар салдым,**
**Шпал ташып иңдә—туң шпал...**
**Узгынчыга уң юл теләп калдым,**
**Теләп калдым чиксез уңышлар.**
**Теләкләрем кабул булмадымы,**
**Юлыгыпмы дәһри затларга—**
**Күпме татар шул юллардан китеп,**
**Кайталмады туган якларга.**
**Ә күпмесе телсез, өнсез калды,**
**Мәхәббәтсез калды, чырайсыз?**
**Чырайсызга хәзер эш хакында**
**Сүз кату да хәтта уңайсыз.**

Чырайсыз кол чалышны да «төз» ди!
«Чалыш» шулай әйт дип өйрәтсә...
Җаныңны да, тапкан малыңны да
Тартып ала, әгәр кирәксә...
Шул исәптән шигъриятеңне дә
Басып ала «кара полоса...»
Кара полосадан чыгып булмый,
Илең сиңа кырын караса.
Язган шигырьләрең укылмаса,
Җимерелә өмет-хыялың...
Нәфрәтемнән аңым җуймас өчен
Хыялыма башым куямын.
Язып куям акка кара белән:
Мин кол түгел, гадел көрәшче!
Шушы сүзне сызып ыргытырга
Дәрман тапмас микән берәрсе?!

## XII фасыл. Чарасызлык

*Башкаемны иеп басып торам*
*Колак салып хәтер чаңыма.*
*Әйтерсең мин муенга таш асып*
*Кайтып киләм бала чагыма.*
*Әйтерсең лә шәфкать сорап миңа*
*Бөтен сугыш аһы иргән...*
*Илдә ташландыкка чыккан шагыйрь*
*Бирә алсын кемгә, ни ярдәм?!!*

...Айга хисап бирер көнем җитте:
Ватылмачы, көзгем—түз инде.
Хакыйкатьтән, шигърияттән килеп
Акъәбиләр булдык без инде...
Милли чарасызлык шаукымында
Яра салдык нәсел канына.
Кылыч кайрагыдай кара еллар
Әҗәл булып өстә кагына.
Төркем-төркем шагыйрьләрең, Ватан,
Кагынадыр:
—Кыйгак!!!
—Кыйгак!!!—дип.
Кыр казына әверелү өчен
Килеп җитте безгә чират, дип—
Әмма безнең каурый-каләм хакын
Бәяләүче Илдә булмады.
Без өлешсез калсак, безне яклап
Ташлар телгә килер—юлдагы...
Үч алырга җирдә гомер буе
Милләт кичкән золым-җәбердән
Колгалиләр, әйе, Кол Шәрифләр
Кубарылып чыгар кабердән.
Зөһрә сылу сузар «Туган тел»не—
Хәтерләтеп былбыл сайравын,
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын.
Үсмер еллар сәлам юллар безгә
Мокамайдан, Һади Такташтан...
...Без үстергән язмыш агачының
Һәр яфрагын канлы тап баскан.

Татар халкы телдән язсын өчен
Агач саен безне асканнар.
Шушы хакта сөйли, мәңгеләшеп
Безнең аңга сеңгән дастаннар,
Һәм хәзер дә дастан язган шагыйрь
Асыл пәйгамбәр дип санала.
Ләкин кем дип кенә саналса да,
Айга өргән эттән талана.
...Шагыйрьләргә, пәйгамбәрләргә дә
Кадер-хөрмәт бездә тыелган!
Шуңа күрә банда йөри—элек
Кол Шәрифләр йөргән бу юлдан.

## XIII фасыл. Дөреслек

*«Игән башны кылыч кисми»—диеп,*
*Башкисәрләр сыйпый башлардан.*
*Баскынчыга Ил баш имәсен,—дип,*
*Шагыйрьләре хак сүз сөйләсен,—дип,*
*Кол Шәрифләр шигъри сүрә укып,*
*Кылыч диңгезенә ташланган.*

Үтәлмәгән антлар, әманәтләр
Аңын, һушын алды күпләрнең.
Мин дә аңсыз калган булыр идем,
Ярый әле башым күтәрдем.
«Кылычлы»дан, ярый, акча даулап
Котын качырмадым пакъ җирнең...
...Буйсынмаган өчен гафу сорыйм
Чал сакалын үбеп Тәкъдирнең,
Гафу сорыйм Айдан, узганымның
Һәр фасылын тотып исәптә.
Исәпне без читкә сөрә алмыйбыз,
Йөзгә нинди битлек кисәк тә.
Исәбенә хисап бирсә генә
Алга бара гомер сөреше...
Җирдән без эзләгән хаклыкның да
Шул бит инде иң-иң дөресе.
Шул дөреслек—илһам чыганагы
Гади халыкның да, Ханның да...
Киләчәккә имин көннәр теләп,
Хөрлек теләп тибри җан монда.
Шул дөреслек сугыш чорында да
Крематорийларда тотәгән.
Дөреслектән тайпылмаган палач—
Үз бурычын тәгәл үтәгән.
«Дө-өр-рес!!!»—диеп искән тарих җиле—
Чорның иман көлен туздырып,—
«Батырларча... шагыйрьләрчә» диган
Матәм җырын алдан уздырып...



Рәмзия
Габделхакова

# ТАУ АРТЫНДА КОЯШ БАР

РОМАН

*Көннәр төнгә кереп күмелаләр,*
*Мизгелләрдән учак якмасаң.*
*Артта кала кара күләгәләр,*
*Гел кояшка карап атласаң...*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Мин балачактан ук тауларга карарга яраттым. Тик менә таулар гына безнең авылдан ерак иде. Әтием җимеш бакчасына таган ясап куйды, шунда атынганда мин гел Бараҗ тауларына карый идем. Бәлки еракта булганга, ә бәлки болытларга, күксел томаннарга күмелеп утырганга, алар миңа зәңгәр һәм биниһая серле булып тоела иде. Чынлап та зәңгәр идеме ул таулар, белмим, чөнки беркайчан да аларга барып җитә алмадым. Үзләренә таба барган саен ул тылсымлы таулар никтер ерагая, алар артында гүя төпсез бушлык кына, гүя җирнең чите, анда тормыш юк та шикелле сыман. Җиргә яктылык, җылылык биреп, баш очында балкыган кояшның да нәкъ менә шул таулар артына китеп югалуы аларның серлелеген тагы да арттыра иде. Әйтерсең лә, ул таулар күренмәс җепләр белән кояшны үзләренә тартып китерәләр дә, куеннарына яшерәләр.

Офыктагы зәңгәр таулар киләчәгем кебек ерак, серле һәм ымсындыргыч иде.

Балачак иленнән аерылгач та, тауларга соклануым, аларның бөеклегенә, серлелегенә ышануым кимемәде. Җир өстеннән күкләргә ашкынып күтәрелгән, карашларын кояшка, йолдызларга төбәгән ул тауларның колач җитмәс куеннарына әллә нинди серләр яшеренгән, караңгы мәгарәләрендә без белмәгән үзгә, ят тормыш кайный, ә биек таулар артындагы төпсез упкыннарда әллә ничә кояш алтын нурлар сибеп, ял итеп ятадыр кебек тоела...

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА — *шагыйрә, прозаик; «Күзгә яшен», «Көмеш тун» һәм башка китаплар авторы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

Тянь-Шань тауларын мин төннәрен күзәтергә яратам. Бакчадагы эскәмиягә чыгып утырам да, мөселман кешесе Мәккәгә төбәлеп намазга оеган сыман, тауларга карап онытылам.

Кызык та, хәйләкәр дә бу таулар. Әкияттәге матур кыз кебек. Хәтерлисезме, шундый әкият бар: көчле, батыр бер ярлы егете ифрат чибәр кызга өйләнә дә, бу гүзәлгә юньсез патшаның да күзе төшә. Аны үзенеке итәр өчен, патша төрледән-төрле мәкер-хәйләләр кора: кызның сөйгәненә башкарып чыкмаслык авыр-авыр эшләр йөкли, әллә кайларга, җиде тау, җиде диңгез артларына, ерып чыкмаслык карурманнарга җибәрә, егетне ничек тә харап итмәкче була. Ләкин ни гаҗәп, сөйгәне патша йомышы белән китеп баруга, кыз иләмсез карчыкка әйләнә дә куя. Комсыз, азгын патша гүзәлкәйне үзенеке итәргә теләп, бу йортка күпме килсә дә, коты очып, буш кул белән чыгып китә. Бары тик кадерлесе янында гына кызга кабат яшьлеге, чибәрлеге кайта...

Таулар да шул хәйләкәр кыз сыман үз матурлыкларын кояшка түгел, бары айга, йолдызларга гына ачалар бугай. Көндезләрен алар артык гади, хәтта бик кыюсыз, күндәм күренәләр, әйтерсең матур йөзләрен чадра белән каплап куялар. Кояш офык артына югалып, күктә якты йолдызлар кабынгач та, ул чадра гүя каядыр югала, һәм тауларның нурлы йөзе ачыла. Төннәрен алар шундый якты, бөтен дөньяга нур сибеп, балкып утыралар, карап-сокланып туймалы түгел. Бу илаһи матурлыктан бар күңел-калъбем кытыклана, йөгереп барып шул мәгърур тауларга сыенасым, аларның бөек серләренә кушыласым килә. Монда ни өчендер йолдызлар да якынрак кебек. Якынрак та, яктырак та, хәтта күбрәк тә кебек. Бөтен күк йөзе йолдыз белән тулы, үрел дә ал гына. Әллә аларның таулар белән уртак сере бармы? Шуңа күрә кешеләр йокыга талгач та серләшер өчен үзләре тауларга төшәме икән?

Әйдә, меник әле шул тауларга дип, мин Әнәскә әллә ничә әйттем инде. Ә ул көлә генә: «Нәрсәң калган анда? Тауда куйлар гына йөри.» Әнәс шул таулар итәгендә туган, гомере буе шунда яшәгән, минем өчен яңа-ят, серле булган бу матурлыкка күзе-күңеле күптән күнгән. Аның бар кайгысы—акча эшләү. Мондагы чая, әрсез халык хөкүмәт биргәнне генә көтеп утырмый, табыш алуның, җиңел баюның әллә нинди яшерен юл-ысулларын белә.

Майлысуда төрле халык яши: кыргыз, үзбәк, урыс, татар, немец, украин, эстон... Немецлар, Кырым татарлары бергә көчләп китерелгән, диләр. Безнең халыкны беркем чакырмаган-кумаган бугай, үз теләкләре белән акча эшләргә килгәннәр, чөнки монда уран рудасы чыгарыла торган шахта булган. Минем җизнәм дә гомере буе шунда эшләгән. Хәзер, сәламәтлеге какшау сәбәпле вакытыннан алда ялга чыгып өйдә утыра, куяннар, куйлар үстерә. Фатыйма апа хастаханәдә шәфкать туташы булып эшли. Аларның олы кызлары Рамилә гаиләсе белән Ташкентта, быел егерме җиде яшен тутырган Әнәс әти-әнисе янында яши. Җизни дә, апа да аны башлы-күзле итмәкче булып мәш киләләр, тик Әнәснең өйләнергә исәбендә дә юк: «Хәзер менә! Хатын ашатып ятам ди, кирәге бер тиен!»—дип гел кирегә сукалый. Үзе бер дә тик ятмый әле, кача-поса ике балалы марҗа янына йөри. Тегесенең ирен анаша саткан өчен төрмәгә утыртканнар икән. Авылыбызның «җирле радиосы» Мәмдүдә апа кебек күп күрәм, күп беләм мин, чөнки йокламыйм.

Их, йокламыйм шул мин... Йоклар өчен күңел тыныч булу кирәк. Ә ул юк... Һич тә тыныч түгел күңел. Минем хәлләрне белсәгез, аңласагыз икән! Әнием эче пошканда гел әйтә иде, җанымны корт кимерә, дия иде. Корт кимерү дигәннәре шулай була икән...

Мин бу якларга эз югалтыр өчен аптыраганнан гына килеп чыктым бит.

Кайдалыгымны беркем белми. Алай гына түгел, исәнме, юкмы икәнемне дә белмиләр... Энем әле бәләкәй, ул анламас, ә әтием кайгырадыр. Әбием дә борчыладыр. Чит кеше түгел ләбаса, киребеткән булса да үз оныгы. Ә үги анам эчтән генә сөенеп йөридер... Ә бәлки, сөенмидәдер. Аңлый алмадым инде мин аны. Аңламагач, ничек теләдем—шулай уйладым... Дөресен әйткәндә, минем аны начар итеп күрәсем килә иде. Чөнки үги ана берничек тә яхшы була алмый. Хәтта яхшы булса да, ана яхшы диясе килми. Минә шул гына.

Мин бу жирдә егерме ел йөрим инде. Һәр елда унике ай бар. Димәк, мин ике йөз дә кырык ай яшим икән. Әгәр инде көннәрен дә исәпли башласаң... Ай-һай гына инде... башың житмәле түгел.

Вакыт дигән нәрсә мине гомумән бик аптырата әле. Вакыт үтә, гомер үтә, диләр. Ничек үтә соң ул? Кояш чыккан-батканга карап кына вакыт билгеләү һич тә дөрес түгелдер ул. Барысы да чагыштырмача гына бит. Вакыйгалар белән янәшә куеп уйлый башласаң, минут, сәгать, көн дигән төшенчәләр үз көчен, мәгънәсен югалта да куя. Гажәп түгелмени, Майлысуга килүем әле кичә генә кебек. Ә Мәскәү-Ташкент поездына утырып, туган яктан чыгып китүемә гүя айлар гына түгел, еллар, гасырлар үткән. Бик-бик күптән булган кебек анысы. Югыйсә шул ук вакыт арасы, Майлысуга килүемә дә, туган яктан китүемә дә әле ярты ел да юк ...

Уйлыйм, уйлыйм да аптырыйм, чынлап та минем белән булдымы соң бу хәлләр?! Беренче мәхәббәт... Сәлим белән очрашып йөрүләрем... Юлда машина көтеп торганда Женяны очратуым, больницага килеп эләгүем, дөм караңгы төндә тәрәзәдән чыгып качуым... Бу вакыйгалар бик-бик күптән булган гына түгел, хәтта аларда минем бер катнашым да юк кебек. Әйтерсең, әллә ничә серияле бер мажаралы кино гына караганмын...

## 1

Мин—яңа сигезенче сыйныфны тәмамлаган унбиш яшьлек кыз. Кирәкле документлар кирәкле жиргә илтеп тапшырылган. Аттестатым «кызыл» булгач, имтиһан биреп йөрисе юк. Сентябрь житү белән, култык астына китап-дәфтәрләрне кыстырып, туп-туры укырга гына китеп барасы. Шуңа күрә борчу-дәртсез йөрим, вакытны юкка-бушка уздырмас өчен әбиемә булышам. Ул кунак йортында эшли. Һәр жәйне безнең колхозга ярдәм итәргә дип шәһәрдән шоферлар, төзүчеләр килә. Менә шундый килгән-киткән халык өчен авыл уртасында махсус йорт тора. Безнең авылда аны ни өчендер урысчалап «Дом приезжих» дип йөртәләр. Әмма беркем дә авыз тутырып дөресләп әйтеп тормый, әлбәттә. Ике сүзне бер итеп «домприжи» дип кенә жибәрәләр.

Без әбием белән шунда эшлибез. Һәр жәйне шулай. Әби эшчеләргә ашарга пешерә, керләрен юа. Ә мин жыештырам, савыт-саба юам, су ташыйм...

Ул көнне дә гадәтенчә жыештырынып йөри идем. Болын хәтле мәйданны һич тә иелеп, кул белән юып интегәсе килми. Шул хәтле пычрак! Шофер агайлар аяк киемнәрен алмаштырып мәшәкатьләнмиләр, урам тузанын рәхәтләнеп ташыйлар, юып кына өлгер. Артларыннан үзләре жыеп йөрсәләр, алай итмәсләр иде дә бит... Тик ирләр, әби әйтмешли, хатын-кыз хезмәтен бәяли беләмени?!

Әй, барыбер шул була дип, мин дә алай бик тырышмыйм. «Яшәсен ялкаулар таягы!»—димен дә, шуның белән әрле-бирле майлыйм гына, юылганы юылыр, юылмаганы калыр. Ярамаган тагын бу килмешәк халыкка, монда туй мәҗлесе үткәрәсе юк әле.

Эшләргә күңеллерәк булсын өчен радиоалгычны бар көченә кабызып

куям, ә аннан вальс тапшыралар. Күнелне айкап ташларлык шундый матур көй яңгыраганда япь-яшь кызның идән юасы киләме?! Түзмәдем, ялкаулар таягын үземә «кавалер» иттем дә, тотындым бөлмә буйлап әйләнергә: «ла-лай ла-ла—ла—лай-ла...» Имеш, мин тәрсәгенә хәтле ап-ак перчаткалар кигән, ап-ак күлмәкле гүзәл кәләш, әйтерсең кин күкрәкле, ифрат чибәр киявемнең иңнәренә сарылып, мәрмәр идәнле зиннәтле бер сарайда биим...

—Сударыня! Вальс со шваброй не танцуют!

Көтелмәгән тавыштан сискәнеп туктап калам. Бу вакытта монда беркем булырга тиеш түгел, барысы да эштә, басуда ләбаса. Кем бу? Мин ни дә булса аңларга, әйтергә өлгергәнче егет ялкаулар таягын читкә алып ата да, бер кулын билемә сала, икенчесе белән кулдан тота һәм мине көй агымына бөлмә буйлап очырта башлый. Ул миңа шундый якын, сулышы йөземә бәрә, алсуланып торган чиста йөзен, озын сары керфекләр арасында нурлар чәчеп балкыган зәңгәр күзләрен, күпереп торган дымлы иреннәрен шул иреннәр өстендә борын төрткән алтын төк бөртекләренә хәтле ап-ачык күрәм. Егетнең өстендә затлы смокинг түгел, әлбәттә, юа-юа әүвәлге төс-сыйфатын югалткан соры футболка гына, һәм анардан һич тә хушбуй түгел, тозлы кыяр, тәмәке исләре килә. Мин партнерымның иңеннән генә, зур учларындагы кулым кайнар ком эченә эләккәндәй кызыша, билемнең аның бармаклары кагылган турысы утлы күмер тигәндәй пешә. Әни!—дөрләп янам бит мин хәзер! Ә ул үртәгән шикелле көлемсерәп миңа карый. Без әйләнәбез, бөлмә әйләнә, тәрәзәдән сузылган алтын кояш нурлары тәнгә генә түгел, җанга, күңелгә урала...

Ах, бу тылсымлы музыка мәңге туктамасын иде!

Әмма ул туктый. Егет кинодагы көяз джентельменнар сыман миңа баш ия, елмаеп:

—Ә сез бик җиңел биисез. Күбәләк кебек очасыз,—ди.

—Мәктәптә бию түгәрәгенә йөргән идем,—дигән булам мин.

—Бу вальс соңгысы булмас бит, ә, Золушка?

—Мин Золушка түгел. Минем исемем бар: Наргизә.

—Нагиза? Юк, истә калдырып булмастыр, татар исемнәре бик катлаулы, тел әйләнми әйтергә. Ярыймы мин сиңа Настя гына дисәм? Настя, Настенька... Матур исем бит?

Матурын матур да... Тик бер дә безнеңчә түгел, колакка да, күңелгә дә ятмый. Татарча юньләп белмәүче туганнан-туган сеңлем Венера «нәрсә» сүзен бозып-имгәтеп шулай «настя» дия иде. Хәзер анысын да әйтми инде, гел урысча гына сөйләшә. Ә үз исемемне бик яратам мин. Аны миңа әбием кушкан, ут-ялкын кебек тере булсын, балкып торсын дигән.

Шулай да егетнең теләге белән ризалашырга туры килер, мөгаен. Әйдә, эндәшсен инде үзенчә, түзәрбез. Безнеңчә әйтә алмагач, нишлисең...

—Ярый соң, Настя диегез.

—Ә миңа таныш-белеш халык Евгений дип дәшә. Женя дисәң дә ярый. Сезгә яңа клуб төзибез. Николай Борисович үз бригадасына чакырган иде. Бераз акча эшләргә исәп бар.

Женя тәрәзә буендагы карават янына килеп юл сумкасын актара башлый, аннан бер кап тәмәке тартып чыгара:

—Егетләр сорады. Әлмәт кучтәнәче алып килдем үзләренә. Сезнең кибет бигрәк хәерче, берни юк. Ничек яши мондагы халык?

—Ачтан үлгән кеше юк әле! Тәмәке генә бардыр анысы, беткән чагы гынадыр,—дип акланам мин. Әлмәт егете каршында үз авылымны бер дә хәерче итеп күрсәтәсе килми.

—Шулай дип өметләник,—дип елмая Женя.

Чыгып киткәндә яныма килеп колагыма серле генә пышылдый:

—Настенька... Бүген кичке уенда кабат очрашырбыз дип ышанам.

Ул чыгып киткәч тә, сихерләнгән кешедәй байтак иськә килә алмый торам әле. Идәнне ничек юып бетергәнемне дә хәтерләмим хәтта...

Иске клуб сүтелеп, яңасы әле төзелеп бетмәү сәбәпле авыл яшьләре мәктәп бакчасына җыела. Кино карап булмый инде анысы. Аның каравы рәхәтләнеп биибез. Оялып, тартынып тору юк, чөнки бакчаны урам баганаларыннан төшкән саран ут кына яктырта. Гашыйклар агач ышыгына кереп рәхәтләнеп серләшә, үбешә, аулак урын эзләп ерак йөрисе түгел. Җәй көне авыл җанлана, кичләр дә күңелле. Чөнки җәен төрле тарафлардан кунаклар, әби-бабай янына шәһәр оныклары кайта. Авылга шәһәр рухы өстәлә, урамнарда урыс сүзләре, урыс җырлары яңгырый башлый. Кала исе исңәп кайткан мактанчык студент халкы кичке уенда бар көченә магнитофон кабызып куя да, шуннан агылган дәртле көйләр агымына кушылып, әби әйтмешли, корт чаккандай и боргалана, и сикерә... Аларга карап без дә маймылланабыз. Анысы туйдыргач, әти-әниләрдән калган уен-биюләр башлана.

Мин килгәндә кырык яшенә җитсә дә һаман кияү егете булып йөргән Халит абый такыр башын гармун өстенә кыңгыр салып, һәрвакыттагыча үзенең «Чыгарсыңмы каршы алырга»сын уйный, ә уртада берничә пар иренеп кенә селкенә, каен төбендәге эскәмиядә тезелешеп утырган олырак кызлар гармунга кушылып моңлана иде:

Кырык эшең ташлап кырык якка,
Чыгарсыңмы каршы алырга?

Уенда кеше аз, чөнки әле иртә. Көтү кайтып, сыерлар савылгач, кояш офыктагы зәңгәр таулар артына кереп югалгач кына мәктәп бакчасындагы мәйдан гөрли башлый.

Сабырсыз карашым Женяны эзли, тик ул күренми әле. Аның каравы каршымда әллә кайдан Сәлим пәйда була:

—Ай-яй, Наргизә, бигрәк матур син бүген! Әйдә биибез,—дип кулымны кыса.

Мин бүген чынлап та бик матур булырга тырыштым шул. Кием сайлый-сайлый башым катып бетте. Шәһәр егетенә ни ошаганын авыл кызы каян белсен? Сайлана торгач, чыгарылыш кичәсенә дип тектергән, кара җирлеккә вак-вак ак борчаклар сибелгән ефәк күлмәгемне киярга булдым. Бик килешә дигәннәр иде аны. Күлмәгем дә кара, чәчем дә. Сары булса яхшырактыр да... Сары чәчле кызлар курчак кебек матур була бит. Безнең класста бар иде бер сары баш. Чәче кояш учындагы алтын кебек җемелдәп тора, артист кына буласы бит үзенә, ә ул җүләр сатучылыкка укымакчы. И-и, үз кадерен үзе белми йөри.

Мин көзге янында бик озак бөтерелэм. Чибәрлегемә сокланып түгел, нәкъ менә матур булмавыма аптырап. Озаграк карагач, күз ияләшәме шунда, мең кат күргән, аркылыга-буйга мең кат өйрәнеп-тикшереп чыккан йөзең ул кадәр ямьсез булып тоелмый башлый. Тик шунысы гаҗәп, иптәш кызларым мине матур ди, әллә көләләр, әллә үртиләр. Кайсы җирем матур икән соң минем? Кашларым нечкәрәк, күзләрем әнинеке кебек зәңгәр, борыным бераз турырак, буем әтинеке сыман озынрак булса, ярыйсы гына да бит... Юк шул, барысы да киресенчә. Бу чәчләрне әйтер идем, һич җыеп бетерә торган түгел, алкаланып-алкаланып маңгаема, иңнәремә тәралалар да төшәләр. Якты дөньяга шул тузган бөдрә чәчләр арасыннан бүкәй кебек карап йөрим аннары. Чәчби! Аның каравы иреңем менә дигән, анысына инде бер үпкәм юк. Шофер абыйлар машинага ябыштыра торган рәсемнәрдәге матур кызларныкы кебек күпереп тора, буямасам да пешкән чия кебек кып-кызыл!

Әй, белмим инде... Шәһәрнең көяз кызларын күреп үскән Женяны чия ирен белән генә шаккатырып булмастыр. Кая инде безләргә мондый асыл егетне карату...

—Әйдә инде, ялындырма,—дип бәйләнә Сәлим.

Белеп торам, ул минем яннан кич буе китмәячәк, озатып та кайтачак. Ә мин аның аша үрелеп, башымны боргалый-боргалый һаман бакча капкасын күзәтәм, дүрт күз белән урыс егетен көтәм. Сәлим аның дөньяда барлыгын белми әле. Шуңа күрә минем хуҗам да, җан-тән сакчым да булып кырымда эре генә басып тора.

Сәлим үзенең мәхәббәтен миңа алты яшендә үк аңлаткан иде. Нишләптер истә дә калган бит. Кыш иде, көне буе чана шудык. Эре-эре карлар ява иде, шуңа күрә икебез дә кар бабайның үзе кебек ап-ак булдык. Тирләп-пешеп, арып-талып урам буйлап кайтып киләбез шулай.

—Чин утыл, мин чине талтып кайтам,—ди Сәлим.

«С» белән «р» хәрефләрен байтак әйтә алмый йөрде әле ул. Мин ялындырып тормадым, мендем дә утырдым моның чанасына. Тик Сәлимнең тартырга көче җитмәде, көчәнде-көчәнде дә, хурланудан башын якасына яшереп карга тезләнде. Мин аны кызганып:

—Ярар, җәяү генә кайтырмын,—дидем.

Шулчак ул еларга җитешеп:

—Мин чине ялатам бит, чин мина өйлән, яме,—дигән иде.

Бер урамда яшәгәч, күршеләр дә булгач, безнең балачак бергә үтте. Сәлим минем тормышымда гел бар, гел янәшәмдә иде. Мин моңа ияләшкән, шулай булырга тиеш дип кабул итә идем.

Ләкин бүген ул миңа кирәк түгел, янымда булуы ачуымны гына китерә. Бүген мин Евгенийны көтәм.

—Китәм дисең инде, Наргизә... Мин Югары авылда бергә укырбыз дигән идем. Синнән башка ни кызык, ни ямь...

Кайда соң бу урыс малае? Кичен очрашырбыз, дип әллә шаярып-алдап кына әйттеме?

Ә Сәлим һаман ыңгыраша:

—Син китәрсең дә югалырсың... Казан егетләре безнең ише генә булмас. Алып та калырлар үзеңне. Авылның бөтен матур кызын шулар эләктерә...

—Әй, йөдәтмәле, Сәлим! Казан егетләре кайгысы түгел әле миндә!

—Нәрсә кайгысы соң?

—Нәрсә, нәрсә... Баш кайгысы! Бәлки, йөрәк кайгысыдыр.

—Баш ватарлык ни булды?

—Бәйләнмә инде, Сәлим! Башка эшең юкмы? Нәрсә кирәк соң сиңа?

—Ник ачуланасың, Наргизә? Мин бит сиңа бернинди авыр сүз әйтмәдем...

—Юк-юк, Сәлим, ачуланмыйм. Ачуланаммы соң?!—Йөземә шатлык куна.—Әнә килә бит ул! Ул килә, Сәлим!

—Кем? Кем килә?

Мин телемне тешлим. Җүләр бит, әй, күңел серемне, үземә генә тиешле шатлыкны бөтен дөньяга кычкырмасам ни була?

Бакчаның тар сукмагы буйлап, үз бәясен бик белеп, килешле һәм горур атлап Евгений килә. Аны күрми мөмкин дә түгел. Ак костюм-чалбары белән, әйтерсең лә, караңгылыкны ертып, мәктәп бакчасына яктылык ияртеп алып килә. Әйтерсең, алсу офыклар, зәңгәр таулар артына качкан кояшны тартып алып, бакча түренә элеп куйды. Мин сихерләнгән карашымны аңа төбим, битемә ут каба, аяк астында гүя җир тетри, дулкынлануымнан чак егылмыйм.

Женя килә!

Аны күргәч, шатланам да, көенәм дә. Ник шатланам—сөйләп тору кирәкмәс, болай да аңлашыла. Көенәм, чөнки бар күңелем белән тоям: татлы хыялларым, якты өметләрем акланмаячак... Минамы соң инде шундый егетнең мәхәббәтен яуларга?! Минамы соң... И беркатлы авыл кызы, кемгә үреләсең син?

Мондый төшенке уйлардан соң буем тагы да кечерәеп киткәндәй була. Мин унайсызланып, кимсенеп Сәлим артына посам. Өзелеп көткәнемне, сөю-соклану тулы карашымны сизмәсен берүк, болай да тәкәбберлеге йөзеннән генә түгел, бөтен килеш-килбәтеннән ташып-түгелеп тора.

—Дусларым! Егетләр, кызлар! Игътибар!

Бу—Женя тавышы. Таләпчән, боеручан, кырыс-горур тавыш.

—Игътибар! Музыка!

Женя кулындагы магнитофон төймәсенә баса. Аннан күңелләрне айкап ташларлык ягымлы көй, вальс яңгырый.

Ә Женя...

Юк, булмас... Мондый хәл әкияттә генә буладыр. Ул бит... Ул бит миңа таба атлый! Минә каршыма килеп баса, башын иеп, кулларын суза...

... Ул мине озата кайтты.

—Мин сине арытмадыммы? Тын алырга да ирек бирмәдем үзеңә.

—Юк... Мин биергә бик яратам. Төне буе биергә дә риза,—дим мин. «Синең белән» дип уйлап куям эчемнән.

Капка турына житкәч, ул кул биреп, тыйнак кына хушлаша:

—Тыныч йокы, матур төшләр, Настенька,—дип китеп бара.

Тик матур төшләр күрергә насыйп булмый. Чөнки ул төнне бөтенләй йоклый алмыйм. Бар күңелемне биләп алган хисләр давылы тәнемә дә, жаныма да тынгы бирми. Минем урамга чыгып йөгерәсем, очар кошка әйләнеп йолдызларга күтәреләсем, һинд киноларындагы матур кызлар кебек очып-очып биисем, хәтта, ни гажәп, йомшак чирәмдә тәгәри-тәгәри елыйсым килә! Бәхет-мәхәббәт хисе әкәмәт сәер тойгы икән ул, кешене тәмам акылдан яздыра икән! Күрәсең, ул кеше жанын шул тиклем зурайтадыр, һәм ул бичара жан, тәнгә генә сыя алмыйча, әллә кайларга ашкына башлыйдыр. Хисләнеп-хыялланып ятам-ятам да, яктыра башлау белән су буена кер чайкарга төшеп китәм. Күкрәгемә кереп тулган, гомердә татымаган бу кыргый, ят көч тауларны актарып ташларлык иде.

Мин идән юарга ояла башладым. Женялар бүлмәсенә кергәч, гәрчә үзе анда булмаса да, кемдер мине күреп-күзәтеп торгандай дулкынланам-каушыйм. Караватына утырам да, башымны мендәренә салам. Аннан Женя исе килә. Мин сөйгәнемне сагынып-хисләнеп мендәрне үбеп алам. Бәлки нәкъ шул турыда аның дымлы, кайнар иреннәре булгандыр, менә шулай бер-беребезне үбәбездер... Ә бит ничә көн очрашып та, аның мине кочканы, үпкәне юк... Чынлап та, нигә үпми икән ул мине? Әллә ошатмый, яратмыйммы икән? Алайса, нигә минем белән генә бии, нигә гел озата кайта? Киноларда күрсәтәләр бит, егетләр үзләренең яраткан кызларын гел иркәләп, үбеп кенә торалар. Әнә, Сәлим дә бит яраткач, кочакларга гына тора, тик мин аны якын да китермим.

Ничек жаен табадыр, аның шулай эш ташлап йөрүенә ничек түзәләрдер, Женя әледән-әле бүлмәсенә кереп-чыгып йөри. Сиздерми генә, әкрен генә басып керә дә, кинәт билемнән йә беләгемнән тотып ала. Мин куркудан чырайлап кычкырам. Ул икәнен белгәч, тәнемә ут каба, битем кызыша, йөрәгем дулый башлый.

Дөресен әйткәндә, мин аннан бераз шүрлим дә әле. Чөнки урысча яхшылап сөйләшә алмыйм. Күбрәк ул сөйли. Мин тыңлап кына утырам.

Ләкин ул сораулар биреп аптырата. Сәлимнең миңа битараф түгеллеген сизеп алган икән очлы күз, аның турында сораша. Ә минем сөйлисем килми. Ни дисән дә, Сәлим—балачак дустым, минем аркада шулай газапланып йөрүе бер дә рәхәт түгел, үземне гаепле сизәм. Ләкин нишлим, ни хәл итим соң, бар күңелем, йөрәгем бары берәүгә—Женяга гына тартыла бит. Хисләрне төйнәп-яшереп бетерә торган түгел, мәхәббәтем күзләремнән түгелә. Кем өчен ут йотканны дөм сукыр кеше генә сизмәс.

Кызлар безгә көнләшеп карый, егетләрнең ачуы килә. Беләм-сизәм инде, Сәлим дә үртәлеп, эчтән кайнап йөри. Беркөнне әйтте:

—Әгәр бу урысыңны ташламасаң, бөтен авыл белән жыелып измәсен изәбез!

—Тиеп кенә карагыз, әтигә әйтеп, төрмәгә утыртам үзегезне,—дидем мин.

Миндә тәкәбберлек бар инде. Мин бит «түрә кызы». Әти колхозның парторгы. Эчеп, эшкә чыкмый йөрүчеләрне утлы табада биетә ул. Безнең әтине гадел кеше диләр. Әбине дә шулай диләр. Усал, ләкин дөрес карчык, имеш... Усал булуы хак, анысына тамчы да шик юк, ә менә гадел диюләре белән килешмим. Әби әниемне бер юкка рәнжетә, гел аны хурлап, гаепләп тора. Әни каршы дәшми, бөтен үпкә-рәнжүләрен эченә жыя да, аннары кача-поса елый. Күз яшьләрен миңа күрсәтәсе, борчылуын сиздерәсе килми. Бик йомшак күңелле кеше шул әнием. Шул йомшаклыгы аркасында бухгалтер булып эшли алмыйча, китапханәгә күчкән дә инде. Бухгалтер булу өчен усаллык, катылык кирәк, ди.

Женя белән очрашып йөрүемне әнигә житкергәннәр. Беркөнне чәй янында икәүдән икәү калгач, әйтте:

—Килгән кеше чит кеше инде ул, бүген—монда, иртәгә—тегендә. Аларга тырнак очы кадәр дә ышаныч юк. Бу урысны ияләштермә, кызым, сак була күр. Үз авылың кешесенә житми барыбер, Сәлимең белән генә очраш. Ана бер сүзем юк, акыллы, ышанычлы егет.

Их, әни... Эш акыллы булудамыни?! Дуслык белән мәхәббәт бер түгел ич. Мин Женяның карашыннан да исерәм, тәнемне-жанымны гүя ялкын ялмап ала. Бу бөтенләй башка хис, башка халәт! Сәлим хәзер күземә дә күренми, бармы ул дөньяда, юкмы—миңа барыбер. Ә Женяны уйламаган минут-секунд юк, йөрәгем аның исемен әйтеп тибә, күз алдымда—аның көләч йөзе, колагымда—ягымлы тавышы, күңелемдә—назлы сүзләре... Өнемдә дә, төшемдә дә ул, бары ул! Аерылышу турында уйласам да, үләргә житешәм, жанымны тау хәтле сагыш биләп ала. Мин Женяны югалтудан бик куркам, аннан башка дөньяның бер яме калмас төсле. Үз ихтыярым белән ничек аннан ваз кичим дә, баш тартыйм ди?!

Әниемне тынычландырырга теләп:

—Кайгырма, әни. Женя тәртипле, яхшы егет ул,—дим.

Ләкин әни үгетләвен, акыл өйрәтүен дәвам итә:

—Ике-өч көндә кешенең кемлеген каян белеп-аңлап бетерәсең ди?! Кыз баланың намусы—кыл өстендә аның. Башыңны югалтып йөрмә, кызым. Андый-мондый хәл була калса, Алла сакласын, ул урыстан жилләр исәр, ә хурлыгы безгә калыр.

Әнинең сүзе мине гүя шыр-ялангач калдырып, авыл уртасына, халык каршына чыгарып бастыра, оятымнан жир тишегенә кереп китәрдәй булып, акланганлай итенәм:

—Юк инде, әни... Мин бит... Без бит матур гына, дусларча гына йөрибез.

—Ай-һай, кызым... Егет халкына ышансаң... Иделгә таянма, иргә ышанма, дип әйтмәсләр иде аны. Аларның югалтыр нәрсәсе юк, чалбарын

каптыра да китеп бара,—дип баш чайкый әни.—Бер ана да баласын саклап, итәгенә тагылып йөри алмый. Берүк уяу бул, кызым.

Уяу булам дип нишлим соң инде?!

Женядан баш тарту турында сүз дә юк. Башка кызларга карап елмайса да көнләшүдән шартларга җитешәм. Югыйсә бар бездә чая, әрсез кызлар. Әнә, Казанда укып йөрүче Кычыткан Саниясенең карашы гел Женяга кунган, оялмый да! Беркөнне күзен майландырып биергә чакырмасынмы. Кызлар чакыргач, ничек баш тартсын, биеде инде егеткәем шул әрсез Кычыткан белән. Ачу-үртәлүдән тәмам кайнап чыктым, боларның бер-берсенә сарылып биюе мәңге туктамас сыман тоелды. Сабырым төкәнеп чак кына Саниянең Казаннан көдрәләтеп кайткан мунчала чәченә барып ябышмадым.

—Үпкәләмә, миңа синнән башка беркем кирәкми,—ди Женя.

Үзе көлә. Ана кызык: көнләшәләр, яраталар бит берәүне! Чибәр егетнең кадер-дәрәҗәсе арта!

Ә мин:

—Тавыштан туйдым, башым авырта. Әйдә, су буенда йөрибез!—дип хәйләләп, сөйгәнемне «куркыныч зона»дан тизрәк алып китү ягын карадым.

Ул төнне ай бик матур иде. Тулы да түгел үзе, ярты да түгел, елмаюлы иреннәрне хәтерләтә. Әйтерсең, күктәге ниндидер алып зат, күз-борыннарын бездән яшергән дә, алтын иннек сөрткән тулы иреннәре белән елмаеп җирне күзәтә. Югарыдан карасаң, ниләр генә күренмидер, картаеп беткән бу җирдә еларлык та, көлеп үләрлек тә хәлләр буладыр. Менә без дә, кеше күзләреннән кача-кача, кулга-кул тотынып, су буена төшеп барабыз. Икебез дә дәшмибез. Гармун тавышлары ерагая, су буенда тынлык, бу тынлыкны бары бакалар гына боза. Шул хәтле шаулашып, нәрсә сөйләшеп бетәләрдер.

Бөдрә башын иеп тын калган карт тал янында тукталабыз. Бу—минем агачым. Әле беренчедә укып йөргәндә үк иптәш кызлар белән су буендагы биш талны бүлешкән идек. Мин шунысын сайладым. Чөнки ул, бердән, туп-турыга үсмәгән, инешкә иелә төшеп утыра. Шуңа күрә аңа үрмәләп менү җиңел. Икенчедән, аның өч ботакка аерылган урынында яшерен оя бар. Анда утыру гына түгел, рәхәтләнеп ятып торырга да була. Женя белән килеп туктагач та, аны-моны исәпләп тормый, шунда үрмәләдем. Моннан елга өсте дә, ярлар да ап-ачык күренә, күк тә, көләч ай да якынрак кебек. Аста калган Женя көлә:

—Әй, кызый, кая киттең, күккә очмакчы буласыңмы әллә?

—Әйдә, курыкма, мен син дә.

—Ни калган анда?

Шулай дисә дә, минем арттан үрмәли үзе. Кечкенә кызга иркен булган оя ике кеше өчен кысанрак икән шул, без бер-беребезгә сыенып утырабыз. Женяның кайнар иреннәре колагыма, яңакларыма кагыла, тәнемә ут каба. Мин үзем дә сизми аңа ныграк сыенам.

—Син бик матур, Настенька, шундый сөйкемле...

—Женя...

—Сөеклем...

Безнең иреннәр кушыла. Үбешү шундый була икән... Мина әйтеп бетергесез рәхәт, Женяның кайнар кочагында эреп югалырмын төсле. Аңлыйм югыйсә, болай ярамый. Тик аның назларына каршы торырлык көч тә табалмыйм. Женяның уттай бармаклары кулларымны, беләкләремне иркәли, әкрен генә капмаланып, күкрәгемә кагыла... Шулчак мин айнып киткәндәй булам. Юк-юк... Күңелдә әни сүзләре яңгырый: «Уяу бул, кызым!

Кыз баланың намусы—кыл өстендә!» Мин кисәк кенә егетемнән аерылам, кулын күкрәк турыннан алып ташлыйм. Тик Женя тынычланырга теләми, һаман миңа сарыла.

—Бигрәк назлы син, сөеп туймалы түгел. Бер күрүдә гашыйк булдым мин сиңа, Настенька. Минеке бул, әйдә, минеке бул... Мин сиңа өйләнәчәкмен.

—Алдамыйсынмы?

—Юк, сөеклем, юк. Яратам сине, бик яратам. Син шундый яшь, чиста. Син минеке генә булырсың. Бары минеке!

Женя бөтен тәне белән калтырана, кабаланып минем кофта төймәләрен ычкындыра...

Моның теләк-ниятен чамалап, карыша башлыйм. Мизгел эчендә күнелдә хәйлә туа:

—Монда жайсыз, төшик...

—Син каршы түгелме?

—Юк...—дим мин. Һәм мәче житезлеге белән тал башыннан төшәм дә, аягым жиргә тиюгә, бар көчемә тыкрыкка таба йөгерәм...

...Икенче көнне Женялар бүлмәсен жыештырып йөргәндә, Николай Борисович килеп керде. Миңа кырыс кына карап куйды да, өстәл янына утырып нидер яза башлады. Бу кешене өнәп бетермим, каранғы чырайлы, тупас йөзле ул. Ачуы бар кешедәй гел каш жыерып, болай да бияләй хәтле иренен бүлтәйтеп йөри.

Шулчак башын күтәреп миңа карап торды да:

—Син Мидхәт Бариевичның кызымы?—дип сорады.

—Әйе.

—Безнең Дон-Жуан синең белән чуаламы?

—Кем?

—Женяны әйтәм, синең арттан чабамы?

Чуала, имеш... Шул да булдымы сүз?! Мин үртәлүдән кызарам, бу абзыйга жавап та бирәсем килми. Тик ул миңа бәйләнүдән туктамый, сорау алуын дәвам итә:

—Сиңа ничә яшь соң әле?

Мин дәшмим, башым игән килеш тузан сөртеп йөрим.

—Булса, унбиш-уналтыдыр инде, шулаймы?

—Әйе.

—Салага гына бит син. Наивная дура!

—Ә сезнең ни эшегез бар? Мин сезгә тимим, сез дә минем тормышыма кысылмагыз!

—Сиңа яхшы булсынга сөйлим бит, дивана! Ул бабникның синең кебек ачык авызлары авыл саен. Кызганып кына әйтүем, сез бит күбәләкләр кебек күзегезне тондырып утка очасыз. Сак бул, кызый, битең пешмәсен!

—Нишләргә икәнен үзем беләм!

Сер бирмәс өчен генә шулай дидем. Абзыйның сүзләре яңагыма китереп суккандай булды. Күзәмә яшьләр тәелде. Ничек инде алай? Шулай буламыни? Хисләр белән шулай шаяралармы? Юк, ышанмыйм. Ышанмыйм! Женя андый түгел, ул мине ярата! Өйләнәм, диде бит. Башка кызлар белән дә йөргәндер, тик аларга өйләнмәгән ич. Димәк, яратмаган. Мин үземне шулай юатам. Әмма эчемә корт төште, кимерепме кимерә. Минем тизрәк Женяны күрәсем, аңлашасым килә.

Ә абзый үч иткәндәй туп-туры күземә карап тора, янәсе, әйткәнен сеңдерделәрме, аңладымы аны бу кызый?

—Мидхәт Бариевичның кызы булмасаң, вакланып та тормас идем. Әтиең яхшы кеше, бик хөрмәт итәм үзен. Кызын рисвай итеп, ташлап китсәләр,

парторг кешегә һич тә күңелле булмас. Безгә дә рәхмәт әйтмәсләр. Әтиәниенә хәсрәт китермә, кызый, ташла бу майлы күзне!

—Ярар,—дидем мин күндәм генә. Бу эчпошыргыч сөйләшүгә тизрәк нокта куясым килде.

Шуннан соң абзый акыл сатудан туктап, кабат кәгазьләре өстенә иелде. Мин дә җиңел сулап куйдым.

Төшке ашны таратканда Женяга күтәрелеп тә карамадым. Сиздем югыйсә, ул әллә ничә тапкыр аптырап-гаҗәпләнеп миңа карап-карап алды, савытларын юарга китергәндә, кулымнан тотмакчы булды. Мин фырт итеп моның яныннан китеп бардым. Яратам да үзен, ләкин үртәләм дә, эчемне кара мәчеләр тырный. Яман хәбәргә ышанасы килмичә исем китмәгән булып кыланcам да, теге абзыйның сүзләре агулы ук булып йөрәгемә кадалды бит. Шулай итеп, без ул көнне сөйләшә-аңлаша алмадык. Бар сабырлыгымны җыеп, кичен яшьләр уенына да чыкмадым. Магнитофонны кабыздым да, кат-кат әйләндереп, Боярскийның «Всё пройдет» җырын тыңлап, үз-үземне кызганып яттым. Төн йокысыз үтте.

Икенче көнне эшкә баргач, күрәм: Женя бүлмәдә утыра. Керү белән каршыма килеп басты да иңнәремнән кочып алды:

—Матурым, ни булды?

—Син...

—Нәрсә мин? Миңа ни булган?

Ничек башларга соң сүзне? Теге абзый синең турында шулай-шулай сөйләде дисәң, болар арасында низаг чыгуы мөмкин. Ә болай тиктомалга, бернинди сәбәп-дәлилсез гаепли дә алмыйм... Женяга бәйләнергә, үпкәләргә әлегә бер нигез юк! Шулай да аңлашу кирәк. Йөземә үпкәләгән кыяфәт чыгарып, юаш-мескен тавыш белән сүз башлыйм:

—Син минем белән вакыт үткәрер өчен генә очрашасың икән... Шәһәрдә яратып йөргән кызың бар икән...

—Карашыңны яшермә, күземә туры карап сөйләш!—ди Женя.—Кем әйтте сиңа моны?

Моның тавышы харап кырыс.

—Шулай ишеттем... Сүз иясе белән йөрми.

—Дөрес ишеткәнсең, бар иде. Хәзер юк инде, мине ташлап, кияүгә чыкты. Хәзерге вакытта минем бер генә сөйгән кызым бар, ул—син! Настенька, житте инде, юкка көнләшмә.

—Көнләшмим дә әле.

—Алайса, ник үпкәлисең?

—Минем сиңа ышанасым килә.

—Яратмаган кешегә тәкъдим ясамыйлар, кадерлем. Хисләремнең чынлыгын тагын ничек исбатлыйм соң?! Йөрәкне яндырып та куясың син! Ашым—аш, йокым йокы түгел, төне буе борчылып чыктым. Синнән башка беркем кирәк түгел, Настенька, бары сине генә яратам! Кызган, ярлыка бу мескен гашыйкны, газап утларында яндырма, сөеклем!

Аның җылы-назлы сүзләреннән соң бөтен шик-борчуларым җилгә очкандай булды. Шулай да эреп төшмәдем, матур сайравына исем китмәгәндәй коры гына:

—Ә син ник эштә түгел соң әле?—дип сорадым.

—Сине күтеп калдым. Аңлашасы килә бит. Эчең тулы ут булганда эш кайгысымы?

—Николай дәдәй ачуланыр, ул шундый усал.

—Син елмайсаң, Николайдан түгел, аю-бүредән дә курыйкмыйбыз. Йә, матурым, бер елмай әле, күңелем тынычлансын. Югыйсә кулдан эш китте. Йә, дуслыкмы?

—Дуслык.

—Алайса, менә монда мөһер сук.—Женя миңа таба иелеп, бармагы белән яңагына төртеп күрсәтте. Мин ашыгып кына үбеп алган идем, иренен бүлтәйтеп:

—Бу үбү түгел, әтәч кебек чукып кына алдың ич!—диде.—Ансат котылмакчы буласың син, ә?!

Женя мине иркен кочагына кысып, иренемә үрелде. Нәкъ шул мизгелдә бүлмәгә әби килеп керде...

Шуннан соң инде минем иректә тыныч көннәргә нокта куелды, капкынның иң каттәсенә эләктем. Шул ук көнне әби мине кунаклар йортыннан куып кайтарып җибәрде. Кич белән уенга чыгулар бетте. Күңел кояшымны күрүдән бөтенләй мәхрүм калдым. Әни дә, әти дә ул кадәр кырыс түгел әле, тик әби күзне дә ачырмый:

—Урыс егетләре белән генә сөйрәләсең калган, чукынчык кыз. Кычытуына чыдый алмыйсыңмы әллә? Итәгеңне җыеп, өйдә генә утыр!

Утырам инде, нишлим соң? Тик Женяны сагынуга һич чама юк, үземне кызганып әче яшьләр түгәм. Тәмам ашау-эчүдән калдым, сагышлы җырлар тыңлый-тыңлый өйдә аптырап утырам. Күңелдә тынычлыкның әсәре дә юк, җанны авыр уйлар каезлый: Женя минем сыман елап-моңаеп ятмыйдыр әле, рәхәтләнеп уеннарга йөридер, кызлар белән биидер, аларны озата да кайтадыр... Ә мин, бәхетсез бала, бичара татар кызы, өйдә бикләнеп утырам...

Шулай да без очраштык. Су буена кер чайкарга төшкән идем, күрәм, чыр-чу килеп өч ир-ат буада су кереп ята. Игътибарлап карасам, минем танышлар—клуб төзүче егетләр. Берсе—Женя! Су күреп кинәнгән үрдәк-казлар сыман рәхәтләнәләр болар, йөгереп барып, ярдан сикерәләр дә, чумып-чумып йөзәләр. Урысча акырышкан тавыштан бөтен су буе гөрләп тора. Көянтә-чиләкләрне күтәргән килеш, мин аларны яр башыннан байтак күзәтеп тордым. Аларны дигәч тә, үземнекен инде. Әй, матур да соң минем Женечкам: җилкәләр киң, гәүдә төз, тәннәре кояш нурында елык-елык килә. Ә мин, тиле, әбидән куркып өйдә бикләнеп утырам. Нидер эшләргә кирәк, Наргизә-җанкисәк, язмышыңа күнеп болай йоклап йөрсәң, сөйгәнеңнән колак кагуың да бар.

Керләрне улак янында калдырдым да, тегеләр коенган якка киттем. Әрсезлек булса булыр, ятып калганчы атып калыйм әле. Су кырына килеп әрле-бирле йөргән булам. Күрерме Женя, дәшәрме?

Дәште бит! Алай гына да түгел, «Настюша!» дип кычкырып янымә йөзеп тә килде!

Мин аның кояш нурлары тулган зәңгәр күзләренә төбәлеп, йотылып-йотылып карыйм. Ике көн эчендә үләргә җитеп сагынганмын икән үзен! Кочагына атылмый чак түзеп торам. Ул да сагынган, ул да миңа төбәлгән. Юеш куллары белән беләгемнән кысып, үзенә тартып китерә дә колагыма пышылдый:

—Матурым, без бит дуслашкан идек. Кайда югалдың? Ник миннән качасың?

Мин Женяга дөресен әйтергә булдым.

—Качмыйм... Безнекеләр синең белән очрашырга рөхсәт итми. Урыс егете белән йөрмә, диләр...

Женя никтер бик тупас-ясалма итеп көлеп җибәрә:

—Ха-ха! Бигрәк иске карашлы кешеләр икән. Шул кеше парторг булып йөри тагын!

—Әтиемә сүз әйтмә, аның гаебе юк. Теге көнне безне бергә күргәннән бирле әби күземне дә ачырмый.

—Да-а... усал карчык ул.

—Ничек кенә әле!

—Неужели чыгып таярга берәр җай табалмыйсын, сөеклем? Бәйләп куймыйлардыр ич үзенне. Бигрәк куркак, кыюсыз кыз икәнсен. Әбиенне тыңлап утыргач, мәхәббәтең шул чама гынадыр. Ну-ка, күземә карап турысын әйт: яратасынмы син мине?

Женя мина үпкәләп һәм гаепләп карый. Яратуым хакында ана бер сүз әйткәнем юк әле. Бу юлы да тыйнак, оялчан кызлардай карашым яшереп, соравын җавапсыз калдырдым.

Женя үгетләвен дәвам итә:

—Настенька, вакытны бушка уздырмыйк, очрашу җаен табыйк.

—Ничек? Әби мине күзәтеп кенә тора.

—Капка турына да чыгарга ярамыймы?

—Синең янга ярамый. Икебезне бергә күрсә, асып куя.

—Тәки дошман күрәсез сез русларны. Бу—национализм хикмәте була түгелме сон? Алай ярамый! Бездә интернационализм булырга тиеш, иптәш парторг кызы. Болай булгач, жалоба язмый булмас.

—Шаярма инде, Женя.

—Менә хәзер тотам да урлыйм үзенне.

Минем Женяны үпкәләтәсем килми. Ничек булса да аның белән очрашу җаен табарга, әбинең күзәтүе астыннан чыгып качарга кирәк!

—Кичен, уннар тирәсендә безнең турыга кил әле. Бәлки...

Мин сүземне әйтергә өлгермим, Женя мине кочаклап күтәреп ала да, «Ур-ра!» дип кычкыра-кычкыра әйләндерә башлый...

—Син кая болай?—дип сорый әби, өстемә җылы кофтамны элеп чыгып барганда.

—Йомышларга чыгам, анда да ярамыймыни хәзер?!—дип телләшәм мин.

Әби ышанырга теләмичә шикләнеп карый, сынаулы-үткен карашы өс-башымны тикшереп чыга. Минем өстә кыска җиңле ситсы халат, аякта—кара оекбашлар. Бу кыяфәт белән ерак китеп булмасы тилегә дә аңлашыла. Ләкин Наргизәгә ышаныч юк, сак-зирәк әбиебез барыбер шикләнә: «Анда җылы, шул арада катмассың әле, кофтаңны калдыр,»—ди. Аны тыңламыйча булмый, югыйсә бәдрәфкә дә ияреп чыгар. Ләкин төнен салкынча, шуна да чыгып барышлый, сиздерми генә әнинең сыер сауганда кия торган иске җиләнен эләктерәм...

Женя турыбызда көтә иде, капканы ябарга өлгермәдем, мине кочагына җыеп та алды. Мин дә ана сеңдем, борыныма тәмәке исе килеп ягылды.

—Кая барабыз?—дип сорады Женя.

—Мин бу килеш ерак китә алмыйм. Әйдә, бакчага кереп утырабыз.

Бәрәңге бакчасында быел гына кайтарып өйгән печән өеме бар иде, көлешә-көлешә хуш исләр аңкып торган шул «яшел түшәк»кә аудык. Женя, сагынуына чыдый алмаган кешедәй, мине шашып-шашып кочарга, үбәргә тотынды. Аның назларыннан башым әйләнеп китте, үзем «кирәкми, юк, тимә» дип пышылдыйм, үзем һаман ана сарылам... Бөтен тәнем буйлап, барча күзәнәкләрне иркәли-кытыклый кайнар дулкын йөгерде. Ләкин әрсез куллар түбәнгәрәк шуыша башлагач, күңелгә шом үрмәләде, курку хисе сөйгәнем белән очрашу шатлыгыннан, аның назларыннан күпкә көчлерәк иде. Канга-җанга сеңгән бу хис, кызлык намусын саклау инстинкты «эңәләрне тырпайтып» карышырга мәҗбүр итте. Безнең арада мәхәббәт уены түгел, чын көрәш башланды. Тик Женяның көчле кулларыннан ычкынырга теләп күпме талпынсам да, урынымнан кузгала алмадым. Дәрт ташып

торган нык, таза гәүдә коточкыч авыр таш сыман мине изә-сыта, ә йөземә ишелеп төшкән печән суларга комачаулый иде. Куркудан-чарасызлыктан бөтен тәнем оеп, гүя мамыкка әйләнде...

Белмим, бу эшләр ни булып бетәр иде, шулчак өстебезгә кайдандыр ут көлтәсе төште. Көтелмәгән хәлдән егетем аптырап-югалып калды бугай, кочагы бераз бушады. Мин тизрәк аның астыннан шуып чыгып, өстемдәге чүп-үләннәрне кага-кага, бакча буйлап өйгә таба сыпырттым. Оятымнан җир тишегенә кереп олагырга әзер идем. Эчем тулы ут, күнел тулы сорау: кем безне күзәтеп йөрде, кем өстебезгә фонарь яктыртты? Кемнәр алдында оят-хурлыкка калдым? Иртәгә үк бөтен авылга яман хәбәр таралачак бит. Бу мәсхәрәне ничекләр күтәрермен?!

Атыла-бәрелә өйгә кердем.

—Нишләп озак булдың, убырный тишегенә төшеп олактыңмы әллә?

Әбинең соравы ачуымны китерде:

—Алай бик курыккач, саклап торырга иде!

—Син дә анаң кебек озын телле, теленне кыскартасы бар,—дип мыгырданды әби.

Мин исә, озын-озак сөйләшеп тормый, урын җәеп, тизрәк юрган астына чумдым. Йоклау юк инде, бер сүтеп, бер ишеп, булган хәлләрне уйлап баш ватам: кем безне күзәтеп йөргән, кем өстебезгә килеп чыккан? Женя белән иркәләшеп ятуыбызны кем күрде?

Курку-шикләнүләрем юкка булды, безнең хакта бернинди яман хәбәр таралмады. Иртән булмаса төштә, төштә булмаса кичен өйдә бомба шартлар дип куркып йөргән идем, ни гаҗәп, андый-мондый тавыш ишетелмәде. Моңа бераз тынычлап иркен сулыш алсам да, җавапсыз сораулар барыбер күңелгә кадалып калды: кемдер безне күрде, кемдер серебезне белә...

Икенче көнне әти яна хәбәр алып кайтты:

—Төзүчеләрнең берсен бик каты кыйнаганнар, чак исән калган. Район больницасына озаттык.

Минем колаклар үрә торды: кем ул, Женя түгелдер бит?

Шикләнүем рас булды: авыл егетләре нәкъ менә аны кыйнап ташлаганнар... Болай да җаным тыныч түгел иде, инде яна хәсрәт өстәлде, йөрәгемә урын тапмый өзгәләнепме-өзгәләнәм: ничек итеп Женяны күрергә дә, ничек хәлен белергә?

Авыл советы рәисе Ногман абый белән әтине районга чакырганнар. Имеш, кыйнаучыларны хөкем итәчәкләр икән. Төркем белән һөҗүм иткән өчен дүрт-биш елга кадәр утыртулары мөмкин ди. Бу хәбәрләрне әти миңа сөйләми, әлбәттә. Мин аларның әни белән сөйләшкәннәрен колакларым тырпайтып тыңлап торам, әби дә урамнан итәк тутырып хәбәр җыеп кайта. Женяның иптәшләре безнең авыл егетләренә бик ачулы ди, үч алырга җыеналар икән...

Иртәнге чәй янында әтинең әнигә сөйләп торганын ишеттем:

—Монда сугыш башланырга тора әле. Расчет ясап, бу бригаданы озатырбыз, мөгаен. Яңа кешеләр яллыйсы булыр.

Алар мине йоклый дип уйлады, ахры, чөнки әле бик иртә иде. Ә мин, тын алырга да куркып, мыштым гына тыңлап ятам.

—Сикаевны кыйнауларында безнең Наргизәнең катнашы юктыр бит? Шул малай белән чуала дип ишеттем,—диде әти.— Гадәттә мондый әтәчләнүләр кызлар аркасында килеп чыга.

Әнием-бәгырькәем, рәхмәт төшкере, минем өскә шик-шөбхәләрнең бөртеге дә төшмәслек итеп җавап бирде:

—Наргизәнең беркая чыкканы юк! Соңгы арада гел өйдә генә утыра.

Әниләр балаларын һәрчак яклый, беркемнән яман сүз әйттермиләр. Тик

шулчак «контр» әби сүзгә кушылды:

—Наргизәгезгә өч тиенлек тә ышаныч юк! Борынында манкасы кипмәгән, егетләр артыннан азып-тузып чаба. Үзебезнең күз алдында шулай кылана да, Казанга киткәч нишләр?!

И бу әбинең теле! Пычаксыз суя түлке, һәр сүзе елан агуына тиң. Шул усал карчыктан гомере буе куркып яшәгән мескен әнием кыюсыз гына әйтеп куйды:

—Әни, үз оныгыңны ул хәтле мыскыл итмә инде. Бала гына бит әле ул.

—Бала ди! Күрдем инде мин ул баланы! Суган башлы урыс малаена асылынды чисти. Шул кәнтәй аркасында кыйнап ташлаганнар да инде аны.

—Ярар, буласы булган. Хәзер сүз куертудан файда юк. Яшь чакта акыл түгел, күңел хуҗа була. Күрешми торсалар, онытыр,—диде әти, бу сүзләргә нокта куеп.

Ишеткән кадәресе дә житте, әгәр хәзер күрешү җаен тапмасам, Женя белән безнең юллар мәңгегә аерылачак. Нидер эшләргә, ничек тә район больницасына эләгергә, Женяны күреп-сөйләшеп калырга кирәк.

Халык эшкә киткәч, мин дә юлга җыена башладым. Машиналар йөри торган олы юлга чыксам, кем дә булса очрап, ниятемне җимерүе бар иде. Әтине райүзәккә бармас дип кем әйтә ала? Аларны көн саен диярлек җыелыш-киңәшмәгә чакырып кына торалар. Ә бу вакыйгадан соң бигрәк тә тынгы бирмәсләр. Кеше күзенә чалынмас өчен мин турыдан, борчак басуы, каенлык аша Иншар ягына сыпырттым. Иншар яныннан да олы юл үтә, шунда берәр машина туры килер әле.

Юлым уңды, төш житкәнче больница янына килеп баскан идем инде. Тик кабул итү вакыты үткән, якын да китермиләр, имеш, кичен килегез. Кичкә хәтле нишләп йөрим мин монда, кайтасы да бар бит әле. Больница янында әрле-бирле аптырап йөргәндә каршыма ак халатларын җилфердәтеп авылдашым Гөлия килеп чыкты. Әнисенә операция ясаганнар икән, шуны карап ята, йомыш белән кибеткә чыгып баруы. Ялына-ялвара, биш кенә минутка дия-дия, халатын салдырып алып, больницага кереп киттем.

Женя хирургия бүлегендә ята иде. Бәгырькәемне танырлык та түгел, йөзе өреп кабартылган кебек зәңгәрләнеп шешенгән, уң кулы гипста. Мин ишек төбенә басып ана дәшәргә кыймый торам. Ул башын бормый гына мина сөзеп карады, тик бер сүз дәшмәде. Палатада таныш-белешләр булмаганга кыюланып, янына килеп тезләндем, кулым белән кадерлемнең шешенгән-күгәргән кытыршы яңакларын сыйпый-сыйпый:

—Женечка, нык авыртынасыңмы? Сызлыймы?—дидем.

Ләкин кайгыртуыма, йомшак сүземә сөенүче юк.

—Ник килдең? Мина кызганучылар кирәкми. Бар, кит моннан!

—Женя, ачуланма инде! Минем ни гаебем бар?

—Кит дим бит, аңламыйсыңмыни?! Берегезне дә күрәсем килми!

Шуның белән сүз бeткәнен, сөйләшергә теләмәвен белдереп, Женя, чытык йөзен стенага таба борды. Карашында котып салкыннары, иреннәре ачу-нәфрәт белән кысылган иде. Мин әле һаман нидер көтеп, өметләнеп аның каршында таптанып торам. Тик Женя борылып та карамады, әйтерсең мин монда бөтенләй юк идем. Ник килгәнемә үкенеп, бик нык хәтерем калып чыгып киттем...

Ул җәйне аны башка күрергә насыйп булмады. Женя да, аның белән эшләүчеләр дә Әлмәтләренә кайтып китте. Алар урынына кәкре аяклы, кара мыеклы ят халык килде. Шуннан соң инде мина эшкә чыгарга да, яшьләр уенына йөрергә дә рөхсәт ителде. Ләкин анда барудан мина инде

бернинди шатлык-ямь юк, Женя киткәннән соң бөтен дөнья шыксызланып, бушап калган иде. Көнелем тулы мөлдерәмә сагыш килеш мин Казанга китеп бардым.

## 2

Казан безне өскә ишелеп төшкән авыр болытлары, коеп яуган яңгырлары, рельслар буйлап иренеп кенә шуышкан трамвайлары, биек, горур биналары белән каршы алды. Казан миңа ничек кенә битараф булмасын, ул минем өчен ят түгел. Әнием дә, әтием дә шунда укыган, бер-берсен тапкан, шул матур чал кала аларның язмышын бергә бәйләгән. Хәтта үзем дә шунда яралганмын, әниемнең йөрәге астында, җылы куенында йомарланып алар белән авылга кайтканмын.

Училищеның үз тулай торагы юк, әти алдан килеп миңа торыр фатир белешеп-сөйләшеп куйган иде. Авыр сумкаларны күтәреп, туп-туры шунда юнәлдек. Ишеп яуган яңгырга рәхмәт, югыйсә фатир хуҗабыз бакчасына китеп барасы булган. Кочак җәеп каршыламаса да, ачык сөйләште. Юантык гәүдәле, ике иякле, сары чәчле Катерина апай сабын заводында эшләп пенсиягә чыккан, ире үлгәнннән соң ике бүлмәле иркен квартирда ялгызы яшәргә куркып, ел саен студентлар кертә икән.

Ул миңа бүлмәмне күрсәтте дә, кухняга табын корырга чыгып китте. Үзебез алып килгән күчтәнәчләр белән чәй эчәргә утырдык.

Катерина апай әтидән тегесен-бусын сорашкач, үз зарын түгәргә кереште:

—Сашенькам исән булса, кеше кертеп болай азапланмас та идем. Бик игелекле, әйбәт кеше иде мәрхүм. Бер авырлык күрсәтмәде, көйләп кенә яшәде. Иркәләүчесе булса хатын-кыз иркәләнә инде ул. Ир кадерен ялгыз калгач кына аңлыйсың икән. Ичмасам бала да бирмәде Ходай, бу кадәр үк авыр булмас иде. Бичаракаемны искә алмаган, еламаган көнем юк...

Ул сүзенең чынлыгына ышандырырга теләгәндәй, алъяпкыч итәге белән күзләренә тулган яшьләрне сөртеп алды.

—Бигрәк яшьли китте шул мескенкәем, әле җитмеше дә тулмаган иде бит...

Аның бу сүзләре мине үтә дә гаҗәпләндерде: «Ничек яшьли булсын ди, җитмеш яшьлек кеше бик карт була бит инде ул!» Әти исә Катерина апайның сүзләрен җөпләп, «шулай-шулай» дип баш кагып утырды. Табыннан торуга ук китәргә дә ашыга башлады:

—Минем әле керәсе җирләрем, йомышларым бар.

Шунда гына үз хәлемнең авырлыгын чамалап алдым. Әти китсә, җиде-ят кеше янында берьялгызым утырып калам ич! Бу зур шәһәрдә башка сыеныр почмагым, көнел юатырдай бер якын кешем юк ләбаса! Миңа шундый авыр, куркыныч булып китте. Хәлем карурманда адашып калган үги кызныкыннан һич ким түгел иде. Ләкин әтине тоткарлый да алмыйм, аның үз эше, үз юлы. Кызыма көнелсез булмасын, боекмасын дип, мине саклап утырмас.

—Апаңны тыңла, тәртипле бул,—дип үгет-нәсихәтләрен бирде дә, әти хушлашып чыгып китте...

Аны озаткач, мин бүлмәмә кереп бикләндем. Хәлем еламыйча һич түзә торган түгел иде. Урамда яңгыр койды, ә бүлмәдә мин рәхәтләнеп яшь түктем... Ул көнне оясыннан очкан кош түгел, күккә күтәрелә алмыйча, җиргә егылып төшкән, шунда берьялгызы бәргәләнеп ятучы яралы кошчык хәлендә идем мин...

Башта нык сагындырды. Күз алдымда гел авылым, туган йортым булды. Бу зур калада, биек таш йортлар арасында адашкан бәрән сыманрак хис итәм

үземне. Шәһәр кызлары чәчрәп тора, ә минем авылдан икәнем мангаема язылган. Ярый әле, группада минем ишеләр күбрәк. Казан, Чаллыдан берничә кыз бар барын, тик алар харап тәкәббер, яннарына якын килмәле түгел. Мин Әлфирә исемле бер кыз белән дуслаштым. Ул да минем кебек авыл кызы, серләребез килешә. Иптәш тапкач, жинелрәк булып китте, сагыш хисе бераз басылды кебек. Әлфирә үзләренен туганнарында яши иде. Ләкин тегеләре тора-бара авырсынып, аңа башка фатир эзләргә кушканнар. Бәхетебезгә, Катерина апай дустымны кертергә ризалашты, бер бүлмәдә икәү яши башладык.

Беркөнне икәүләп циркка барырга ниятләдек. Минем гомердә анда булган юк иде. Ә Әлфирә классташлары белән Казанга экскурсиягә килгәч, цирктагы тамашаны барып күргән дә, тәмам гашыйк булган. Шул турыда сөйли-сөйли башымны катырып бетерде. Әйдә, барыйк та барыйк кына, ди. Ахыр чиге мин ризалаштым.

Башкаларга һич охшамаган, тәлинкә сыман түгәрәк бу бина серле-тылсымлы әкият иле булып тоелды мина. Ерактан балкып-жемелдәп торган нурлы утлар, бәйрәмчә киенгән шат күнелле кешеләр, урамга ук ишетелеп торган ягымлы, матур көйләр анын эченә үткәнче үк кәефне күтәрә, гүя сине могжизалар белән очрашуга әзерли. Ифрат биек түшәмле якты залга килеп кергәч, башта югалып та калдым, әйтерсең очсыз-кырыйсыз бинһая зур шар эчендә йөри идек. Кай тарафка урнашсан да, урталагы сәхнә уч төбендәге кебек күренеп тора.

Менә кара пәрдәле мәгарә авызыннан, дәртле музыка белән бер агым булып, жем-жем итеп торган купшы киемле артистлар чыга башлады: клоуннар, жайдакчылар, фокусчылар... Аларга да әлләни исем китмәде, түземсезләнеп һава гимнастларын көттем. Чөнки беләм, телевизордан күргәнем бар, чыгышлары балет биючеләренеке кебек нәфис, нәзакәтле. Ниһаять, аренада көмеш костюмлы егет белән нәни калфаклы, ап-ак күлмәкле кыз пәйдә булды. Икесе дә төз, сылу-зифалар. Менә талгын гына йомшак-иркә музыка агыла. Прожектордан төшкән көмеш ут божрасы эчендә калып, гимнастлар әкрен генә өскә күтәрелә... Пәрәвез жепләренә уралып аккош булып йөзәләр, бөркет булып очалар, ике дулкын сыман ашкынып кушылалар да, бер тән, бер жан булып назлашалар... Ике фәрештә ай нурына күмелеп гүя мәхәббәт анлаша. Бөтен зал тып-тын калып бәхетле гашыйкларны күзәтә.

Ә мин парлашып очкан бу ике матурга сокланып кына түгел, көнләшеп тә утырам. Хыялым белән күкләрне инлим. Их, алар урынында Женя белән без булсак икән!

Беркөнне училищеда беренче курслар өчен көзге бал үткәрделәр. Адәм хурлыгы, рәхәтләнеп биергә юньле егет тә юк. Кайбер кызлар танышларын алып килгән иде. Алар биеде, ә без, «ялгыз аккошлар», почмакта бөрешеп моңаеп тордык. Вальс уйный башлагач, Женяны юксынудан елыйсылар килде. Ул монда булсамы?! Бөтен залны бер итеп төне буе биер, мәнге армас идек! Жанкисәгемне һич истән чыгарган юк, ә ул мине уйлыймы икән? Һай, юктыр, һич тә моңаеп утырмыйдыр. Николай дәдәй әйтте ич, Женя кебек чибәр егетләр тик ятамы сон?! Их, болай килеп чыгасын белсәм, укырга Казанга түгел, Әлмәткә генә китеп барган булыр идем.

Беркөнне төштә күрдем әле үзен. Имеш, бик затлы зур бүлмә, зал тулы халык. Барысы да матур-купшы киемнән, ә минем өстә алама күлмәк икән. Мин бу хәлгә бик уңайсызланам, күрмәсәләр ярар иде дип, бер почмакта сыенып басып торам. Үзем уйлыйм: «Кеше күзенә чалынмый гына тизрәк чыгып китәсе иде...» Карашым белән ишек эзлим, тик таба алмыйм. Ни тәрәзә, ни ишек күренми, бар тарафка сары пәрдәләр эленгән.

Ә кешеләр миңа карап мыскыллы елмаялар. Шул чак күрәм, миңа таба Женя килә. Минем аңа мондый ямьсез кыяфәттә күренәсем килми, шундый оят, гарьлек. Ә ул елмая. Яныма килеп житә дә, үпмәкче булып, йөземә иелә... «Ул барыбер мине ярата! Мин әкияттәге Золушка. Без хәзер бергә биибез,»—дип сөенәм икән. Үч иткәндәй, нәкъ шул вакытта, төшемнең иң татлы-матур жирендә уянып киттем. Төштә дә рәхәтләнеп күрешергә язмаган икән! Гел өнемдә күргән кебек булды, тиз генә айный алмыйча, Женяны кочарга теләп, кулымны да суздым әле. Тәмам уянып беткәч, шундый ямансу булып китте, үксеп-үксеп елыйсылар килде.

Женядан хәбәр булмаса да, Сәлимнән бар. Ничек тапкандыр мине. Хатын укыгач аңладым, бу хәйләкәр иптәш, майлап-жайлап, минем адресны, энемнән алган икән. Хәер, Илнарны озын-озак үгетләп торасы да юк, яраткан абыйсына адресымны гына түгел, үземне дә сатарга әзер.

Дустым авыл хәлләрен язган да, синнән башка монда бер ямь калмады, дигән. Шулай инде бу дөнья, Сәлим минем өчен ут йота, ә мин Женяны сагынып өзгәләнәм. Юлымда шул урыс егете очрамаса, күңелемдә биниһая тынычлык булыр һәм без Сәлим белән рәхәтләнеп хат алышып ятар идек тә бит... Их, бу мәхәббәтне... Аңа кеше газапларга, интектерергә булсын.

Октябрь бәйрәмендә авылга кайттым. Беркайчан да болай ерак китеп, озак аерылып торган юк иде. Авылымны, туганнарымны, әйтерсең, йөз ел күрмәгәнмен, шул хәтле сагындым! Машинадан төшеп калгач, биш чакрым юлны очып диярлек үттем. Иннәремә канат үстемени, эчем тулы шатлык, көләсе-жырлыйсы килә.

Тик мин кайтканда өйдә беркем юк, әби белән энем каядыр чыгып киткән, әниләр эштә иде. Күңелдәге шатлык бераз кимеде, бикле йортка кайтып керү һич тә кызык түгел. Аның каравы кичен бәйрәм булды. Әни сорау арты сорау яудырды: «Казанга ияләшеп буламы, укырга авыр түгелме, иптәшләрең яхшымы, фатир хужасы рәнжетмиме?» Илнар исә үзенекен такылдый, нindидер штаб турында, каенлыкта качып ятучы шпион турында үзе уйлап чыгарган әкиятен сөйли. Әти дә басынкы гына ара-тирә безнең сүзгә кушыла. Әби генә әлләни ачылып китә алмыйча, иреннәрен бөрештереп утырды-утырды да: «Укып йөрисеңме соң син анда, жил куасыңмы?»—дип сорап куйды.

—Укып йөрим, әби. Дәрес калдыру түгел, биш минутка да соңга калырга ярамый. Бездә тәртипләр кырыс,—дип олыларча житди итеп жавап бирдем.

Әби жавабымнан канәгать калды кебек:

—Амин, шулай булсын, тәртип кирәк. Сабагыңны калдырма, тырыш, дин дә укырга куша,—дип хуплап куйды.

Икенче көнне иптәш кызым Римма белән клубка чыктык. Клуб дигәннән, аның түбәсен япканнар, тик эчке яклары әзер түгел, шуңа күрә кино-мазар күрсәтмиләр икән. Шулай да яшьләр жыела, тагы кайда очрашсыннар соң. Римма Югары авыл хәлләрен сөйли, моның йөрәгенә дә мәхәббәт кошы кунган икән, теленнән Госман исеме төшми. Юл буе шул егет турында тынлый-тынлый колаклар тынып бетте. Мин дә сүз кыстырмакчы булам, тик кая ул! «Кызый, туктап тор, сүзеңне онытма»,—ди дә, тагын үзенекен сөйли башлый. Әй, тел бистәсе дә инде үзе, ничек арымыйдыр. Клубка килеп кергәч, классташ кызлар уратып алды. Бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә сөйләштек-гөрләштек. Аннары Сәлим килеп исәнләште. Никтер уңайсызланып, оялып кына исәнләште. Ул үсеп-ныгып киткән сыман. Баштарак ике арада киеренкелек булып, сүз ялганмый торды. Мәңгелек егетебез Халит абый, кулына гармун алып, үзенең яраткан көен уйный башлагач кына, күземә туры карап: «Биибезме?»—диде. Мин каршы

килмәдем. Бер-беребезгә сыенып әкрен генә әйләнә башладык.

—Сагындырдың. Хатыма җавап та язмадың,—диде Сәлим.

—Үзем кайтасы булгач, язып тормадым инде.

—Һаман аны уйлыйсыңмы?

—Кемне?

—Теге урысны.

—Юк...—дигән булдым мин. Хәзер, барысын да сөйләп торам ди!

—Алайса, өмет бар икән.

—Авылда кызлар беткәнме әллә?!

—Бар инде алар... Күңел башкага ятмый бит. Күз алдымда син генә.

Мин Сәлимгә ни дип җавап бирергә дә белмим. Аны алдыйсым, өметләндерәсем килми. Нигә үзе аңламый, сизми соң ул: бернинди хис, тартылу юк ләбаса. Йөрәк «кирәк» белән исәпләшәмени?!

—Сәлим... Син башканы яратырга тырыш әле. Без бит дуслар гына... Бу бөтенләй башка нәрсә бит...

—Дуслар?! Минем сине кочасым, иркәлисем килә! Шул дуслык буламы?!

Юк, бу дуслык кына булмый. Кем-кем, ә мин моны яхшы аңлыйм. Үземнең дә Женяга сыенасым-сарыласым гына килеп тора иде. Әгәр Сәлимгә карата да шундый назлы хисләр кичерсәм икән! Икебезгә дә җиңел, рәхәт булыр иде. Ә болай ике бәхетсез гашыйк без.

Шулай да аның озата кайтуына каршы килмәдем. Чөнки хәлен яхшы аңлыйм, кызганам да. Шуңа күрә кочып үбәргә маташкач та, карышмадым, йөзем яшермәдем. Минем аркада газапланып йөрмәсен, бәлки бераз күңеле басылыр.

—Наргизә...—дип пышылдый Сәлим.—Төшләремә кереп беттең.

Мин Сәлимнең сүзләренә дә, назларына да битараф булып, шул ук вакытта бернинди каршылык та күрсәтмичә, таш сын шикелле басып торам. Их, бу мизгелдә аның урынында Женя булса икән, эреп төшәр идем!

—Әллә мина да Казанга китәргә инде? Сине югалтудан куркам.

—Унны бетергәч, килерсең.

—У-у-у! Тагы ике ел синнән башка яшисеме?!

—Аннары тагы ике ел.

—Ник алай дисең?

—Армиягә китәсең бар.

—Син мине көтмисең инде.

—Сәлим... Өметләнмә миңа. Үзеңә дә, миңа да җиңелрәк булыр.

—Тырыштым инде, булмый бит. Йөрәккә кереп утыргансың.

—Себерке белән куып чыгар.

—Көлмә, Наргизә! Үз башыңа төшмәсә, кешегә акыл өйрәтергә җиңел ул.

Җиңел! Белсә икән хәлемне. Сәлим әле бәхетле: ятратканын—мине күрә, очраша ала, бер авылда яшибез. Ә мин Женяны кайдан, ничек эзләп табыйм?!

...Әмма вакыт үзенекен итте. Женяның саргылт бөдрә чәчләре, күк төсендәге якты күзләре, ягымлы елмаюлары әкрен-әкрен генә кышның салкын карларына, язның яшенле яңгырларына, көзнең куе томаннарына уралып, үткәннәргә китеп югалды. Җәйге ялым Сәлим белән үтте. Өйдә тик ятмас өчен, бераз акча да булыр дип, колхоз эшенә чыктым. Башта печән әйләндерергә, тәяргә, аннары икмәк ташучы машиналарда йөкче булып йөрдем. Үз эшләрең белән саф һавада эшләү кызык кына ул. Сәлим дә әтисе янында ярдәмче булып эшләде. Көндезләрен ничек кенә арытмасын, кичен клубка чыгабыз, төне буе җитәкләшеп авыл урамнарын, су буйларын

инлибез. Женяга татыган сыман назлы, кайнар хисләр булмаса да, күнел Сәлимне якын итә, ялгыз да күнелсез ич.

Беркөнне клубтан кайтышлый минем тал янына килдек. Бу юлы өскә үрмәләмәдем, кинодагы акыллы кызлар кебек агач төбендә тыйнак кына басып тордым. Сәлим кулымны учларына алып күкрәгенә кысты:

—Безнең су буе бигрәк матур, әйеме, Наргизә? Мин үзебезнең авылдан беркая китмәс идем.

Шундый назлы ишарәдән соң «җылы янгыр тамчылары булып» күнелемә назлы сүзләр, мәхәббәт хисләре явар дип көткәндә—вәт сина мә!—Сәлим авылны өзелеп яратуын сөйли башлады...

Кулымны анын учларыннан тартып алып, коры гына:

—Китмичә барыбер булмый, сина укырга кирәк,—дидем.

Сөйләшү житди төс алды.

—Бер караганда ниемә кирәк сон ул диплом? Колхоз эшен белмимме?

—Алай димә, Сәлим, комбайн йөртер өчен дә документ кирәк.

—Анысын гына алырбыз ла...

—Ә минем авылда яшисем килми.

—Ник?

—Күнелсез. Җәй көне генә ямьле бит монда. Кышларын саргаеп үләрсен.

—Үлмиләр бит әле. Яшиләр.

—Алар иялэшкән, башканы күрмәгән.

—Наргизә, менә синенчә, бәхет өчен нәрсә кирәк?

—Мәхәббәт.

—Тагын?

—Бу азмыни?

—Аз түгел. Әгәр бәхет өчен мәхәббәт кирәк икән, ник шәһәргә китәргә?

Сәлимнең сүзе мине уйга салды. Күрәсен, мин ялгышамдыр, бәхет өчен мәхәббәт кенә житмидер...

—Тагын беләсенме, нәрсә кирәк: яраткан эш! Ансыз булмый. Яраткан эш кирәк!

—Канкритны нинди эш? Менә син укытучы булырга укыйсын, авылда да мәктәп бар. Ни аерма?

Үз сүземне аста калдырасым килми, киреләнеп:

—Юк, хет нәрсә дин, авылда күнелсез. Минем авылда яшисем килми!—дим.

—Шәһәрдә сине кем көтә сон, Наргизә? Анда синен белән миннән башка да халык житәрлек. Чаллыда өч кенә көн торып кайттым, шул да житте, башка әйләнеп тә карыйсым килми. Шәһәр кешесе жирсез, тамырсыз бит ул. Йортлары таш, урамнары таш... Минемчә, кеше туган жирдән аерылырга тиеш түгел. Менә сина, Наргизә, ни ошамый авылда? Әйт, ни житми?

—Сәлим! Ник юк белән баш катырасын син? Башта укып бетерәсе бар бит әле!

—Сон, уйламыйча яшәп булмый лабаса. Киләчәк уйландыра инде ул.

—Уйлап интекмә дә, барыбер безненчә булмый.

—Нишләп?

—Әбием шулай ди. Ходай ни язган шул була, ди.

—Ходай мина сине язсын иде, калганын үзем дә табармын,—ди Сәлим.—Әй, Наргизә... Янымнан беркая да жибәрмәс идем үзенне!

Ул мине кочагына ала. Шулчак тавышлар ишетеп икебез дә тын калабыз. Ай яктысында теге як яр буйлап килүче ике күләгә шәйләнә.

—Безгә моннан кайтмаска иде, карангыда басманы күреп булмый,—ди

ят хатын-кыз тавышы.

—Ияләшмәгәнгә генә ул, без өйрәндек инде, сукыр килеш тә күрәбез.— Бусы әти тавышы. Шулай сонарып кайдан кайта ул, кем белән?

—Ун елга бер кайтсаң, үз авылында адашырсың, валлаһи.

Икесе дә көлешәләр.

—Әллә күтәреп чыгыйммы үзенне?

—Күтәр, мин каршы түгел,—дип хихылдый хатын.

Аннары безнең тарафка:

—Кит, җүләрләнмә! Шаярттым гына, егыласың бит,—дигән сүзләре килеп ирешә.

—Ә мин шаяртмыйм, гомер буе күтәреп йөрергә дә риза,—ди әти.

Башыма китереп сугалармыни, гаҗәпләнүемнән катып калам. Кемгә шундый матур сүзләр сөйли ул? Шәүләләр бездән ерагаеп, ярга менеп китәләр. Сүзләре өзек-өзек кенә ишетелә.

—Бәлки... Ничек булыр... Тырыш инде... Мин көтәм... Сак бул...

Ин башта Сәлим телгә килә:

—Таныдыңмы?

—Әйе... Әти иде...

—Икенчесен, хатынны таныдыңмы?

—Юк.

—Кифая апа ул.

—Мин аны белмим.

—Мин дә белми идем. Кайтуына күптән түгел генә әле. Авариягә очраганнар, ире белән олы кызы шундук үлгән. Кифая апа кечкенәсен ияртеп әнисе янына кайткан. Анда яши алмыйм ди икән. Кичә генә безгә Рабига апа килгән иде, ул сөйләде. Безгә туган тиеш алар.

Миңа димәгәе, хет кем булсын, тик әтинең монда ни катнашы бар? Ник төн уртасында унсигез яшьлек егет кебек ят хатын белән көлешеп, уйнашып йөри ул? Минем кәеф төшә, борын салына: «Әйдә, кайтыйк»,—дим.

—Наргизә... Күргәненне әтиеңә сиздермә, яме... Әниеңә дә...—ди Сәлим. Юатырга теләгәндәй йомшак итеп, юаш-гаепле тавыш белән әйтә. Ләкин мин ачулы:

—Өйрәтми генә тор! Нишләргә икәнен синнән башка да бик яхшы беләм!

Сәлимнең дә тавышы кырыслана:

—Белмисең! Үзләреннән башка беркем белми! Син кысылма, аңладыңмы?

Аның үгетләве мине ярсыта гына:

—Кысылам әле! Бу безнең гаилә, хакым бар!

—Тукта, Наргизә, кызма син, бераз суын башта. Ярсыган чакта әлләни әйтүең бар, йә артыгын кыланып ташларсың.

—Син бигрәк инде... Житмеш яшьлек бабайлар кебек... Акыл сатып торасың монда! Синең әтиең түгел шул. Минем урында булсаң, үзең нишләр идең икән?!

—Соң шуна күрә, нишләргә икәнен белмәгәнгә, сабыр ит, ашыкма дим бит. Тыңла сүземне, Наргизә!

Ләкин үрталгән күңелнең сабыр итәр чамасы юк. Сәлимгә фырылдап, «җеннәремне ияртеп» өйгә ашыгам. Сулышыма кабып кайтып керсәм дә, берни кыла алмыйм. Иренең кайда, кем белән йөрүендә бер хәбәре булмаган бичара әнием изрәп йоклый, ә әти һаман кайтмаган...

Әтине икенче көнне кичен генә күрә алдым. Һәр сүзен, һәр хәрәкәтен тикшереп-күзәтеп торсам да, аңарда андый-мондый үзгәреш, шикле нәрсә сизелмәде. Барысы да элеккечә иде: кайтты, ашады-эчте, яна

килгән газетларны караштырып чыкты, малларны ашатып керде, аннары көндәгечә «Вакыт» тапшыруын карады. Ләкин күнелгә шик кереп утырган, бу хәлләрнең ахырын белми торып күзәтүдән туктамаска булдым. Ул кичне клубка чыкмый, өйдә генә утырдым. «Башым авырта, хәлем юк,»—дигән булып, кояш баемас борын верандага чыгып яттым. Әмма йокларга җыенган кеше юк. Шыпырт кына тыңланып, күзәтеп ятам. Менә өйдә ут сүнде, тынлык урнашты. Минем дә күзгә йокы эленде. Тыңланып ята-ята йокыга киткәнемне сизми дә калганмын...

Иртән, икәүдән-икәү чәй эчеп утырганда түзмәдем, әбидән сорыйсы иттем:

—Әби, син Кифая апаны беләсенме?

Ул гадәттәгечә коры гына җавап бирде:

—Сиңа ниемә?

—Авылга бөтенләйгә кайтканмы әллә ул?

—Синең ни эшең бар?

—Беләсем килә.

—Күп белсәң, тиз картаерсын,—диде әби кисәк кенә тәрәзәгә капланып. Пыялага төя-төя, кыяр түтәлендә тибенеп йөрүче тавыкларны сүгәргә кереште:

—Көш-ш, көш-ш! Кара син бу ангыраларга, күзләрен тондырып бакчага кермәсәләр, башка урын беткәнме? Көш-ш, көш-ш дим, чукынчыклар! Бар, тизрәк куып чыгар әле шул имгәкләрне!

Шулай итеп, әбинең Кифая апа турында сөйләшәсе килмәде. Димәк, әти белән бу хатын хакында ул ни дә булса белә, шуна күрә, мәче үз гаебен тизрәк туфракка күмеп куйгандай, сер яшерә дә инде. Безнең әби шундый ул: кешенекен җилгә сипсә сибә, әмма үзенеке—җиде кат йозак астында...

Ләкин әтинең серен мин барыбер белдем. Аны эзләп йөрисе дә булмады, кулыма китереп тоттырдылар. Ул көнне Мәмдүдә апа белән көзге чәчүдә идек. Орлык китергәннәрен көтеп басу читендә моңаеп утырганда күземә сынап карый-карый: «Әтиеннең яшьлек мәхәббәте кайтты бит. Ничә ел күрешмәгәннәр иде,»—димәсенме бу! Моңа исем дә китмәгәндәй тыныч кына: «Кифая апамы?»- дип сорадым.

Мәмдүдә апаның мут күзләрендә үртәлү-ризасызлык чагылды:

—Бәракалла, беләсеңмени?!

—Беләм шул!

Авызына лимон каптырдыммыни, апайның ирене бөреште, йөзе җимерелде. Ис китәрлек хәбәр әйтеп, мине шаккатырасы килгән иде дә, татлы өметләре акланмады. Ул яна дип сөйләгән хәбәр төмен югалткан икән... Бәлки шуңа да бар белгәнен минем алда берьюлы селкеп салырга уйлагандыр:

—Очрашканнарын да беләсеңме?

Сер бирәсем килмичә:

—Бер авылда булгач, очрашырлар инде,—дидем.

Мәмдүдә апа, тырма тешләрен күрсәтеп, авызын ерды:

—Барысы белән шулай очраша башласа, җыеп бетерә алмас.

Тел төбен бик яхшы аңласам да, башны тилегә салдым:

—Җыючылар табылыр әле.

Мәмдүдә апаның сүзе йөрәккә утлы күмер булып төште. Мин бит болай да сизә идем, әти әнигә карата һәрвакыт суык, коры. Җитмәсә әби дә әнигә каршы гел котыртып тора. «И кызым, ичмасам, сезнең бәхетегез булсын,»—дип әнием юкка гына әйтмидер. Аны нindидер борчу-сагыш кимергәне күзеннән күренеп тора, үзе көлгән чакта да күзләре гел моңлы.

Бик сирәк көлә шул әнием. Инде бу хәлне дә белсә, нишләр?! Ә бәлки беләдер дә инде? Авыл кешесенен тормышы уч төбендәге кебек бит. Карга Мәмдүдәсе белгәнне башкалар да беләдер, әниемә дә килеп ишетелгәндер. Ничә ел буе читтә йөреп, ни туган авылын, ни әтине исенә төшермәгән бу Кифая ни өметләнеп кайткан монда?! Аварияга очрагач, ире түгел, үзе үлгән булса, яхшырак буласы да бит... Кеше ирен аздырып йөрмәс иде. Әти дә бигрәк инде... гомер буе күтәреп йөрер идем, имеш... Чит хатынны күтәргәнче әнине күтәрсен иде! Әллә әнием кадерләүгә, мәхәббәткә лаек түгелме?!

Әти турында бу хәбәрне ишеткәч, кичләрен өйдә утыра башладым. Сәлим белән көндез эштә генә күрешәбез. Ул, кичен турыгызга чык, дип ялвара. Болай да санаулы көннәр, кадерен белик, ди. Ә минем кәеф юк. Әнинең дә кәефе юк. Әти белән сөйләшмиләр диярлек, аралашулары «ашыйсынмы», «чәй эчәсеңме», «мин киттем» кебек гадәти сүзләрдән узмый. Әни гел боек, уйчан. Анын каравы әти кояштай балкый, үзалдына елмаеп йөри. Бу арада эштән бик соң кайта башлады. Әни аңардан берни сорамаса да, акланып маташа: урып-җыю вакыты, эш күп, басуларны тикшереп йөрибез, фәлән-төгән... Ә мин беркөнне әйттем ана, әни өйдә юк иде, маңгаена бәреп әйттем: «Кифая апа беләнме?» Шул чакта әтинең йөзен күрсәгез, карашы белән сытып үтерде. Чак сугып очырмады. «Сүзенне үлчәп сөйлә, кызым! Гайбәт җыеп йөрмә!»—дип кычкырды. Әйтеп ни файда инде, аны кем саклап бетерсен? Бу мәсьәләдә мин көчсез шул, әниемә берничек ярдәм итә алмыйм. Житмәсә, ялым тәмамланып килә, китәр вакыт якынлаша. Әнине ике ут арасында калдырып, үземнен дә эчем тулы ялкын килеш китеп барачакмын инде.

Башка вакытта әти мине озату жаен таба, һәрхәлдә олы юлга жәяү чыгарып жибәрми иде. Бу юлы: «Үзегез карагыз, берәрсе очрар әле,»—дип, тыныч кына эшенә китте дә барды. Анарда хәзер безнен кайгы түгел шул...

Әни мине озата чыкты. Аны кызганып:

—Интегеп йөрмә инде, әни, ерак ара түгел бит. Юлны беләм, үзем дә китәрмен,—дисәм дә, кире борылмады.

—Каеннарга хәтле булса да озатам әле, кызым, сумкаларың авыр. Бәлки берәр машина да туры килер. Бигрәк тиз үтте ялын, иркенләп сөйләшә дә алмадык. Күрми дә калдым кебек үзенне. Казаны да ерак шул, сирәк кайтасың.

Әнинең өстендә зәңгәр чәчәкле жинел күлмәк, башында да зәңгәрсу яулык. Күзләре зәңгәр булгангамы, шул төсне бигрәк ярата инде. Мина бу дөньяда әниемнән дә матур, сөйкемле кеше юк сыман. Яше кырыкка житсә дә кызлар кебек җыйнак, жинел гәүдәле, житез ул. Әтием нигә кимсетәдер аны, ник башкага алмаштырмакчы буладыр? Күрдем бит инде Кифаясын, әниемнән бер артык жире юк. Шәһәр хатыннары кебек фырт киенеп, ясанып-бизәнеп йөри. Чәче матур инде, сумала кебек кап-кара, үзе озын, биленә хәтле төшеп тора. Соклансыннар дипме, аларны толымга үрмичә, яшь кызлар сыман туздырып йөргән була. Анысы, озын чәчлеләр авылда аннан башка да житәрлек, берсе дә мактанмый әле, баш түбәсенә җыеп куялар да, яулык бәйләп, тыйнак кына йөриләр...

—Кызым, авыр уйлар белән китмә, яме. Безнен өчен борчылма.

Сәерсенеп, әниемә күтәрелеп карыйм:

—Син беләсенмени?—дип сорыйм.

—Ничек белмисен инде, йөрәк сизә бит...

—Йөрер-йөрер дә туктар әле. Син борчылма, әни.

—Үзем гаепле, кызым, белә торып чыктым бит. Артык яраттым шул

әтиенне. Ә ул Кифаясын гомер буе онытмады...

Бусы минем өчен яналык иде. Ничек инде алай, гомер буе Кифаяны яраткан да, үзе башкага өйләнгән? Шулай була димени?!

—Аны Кифая үзе ташлаган, читтән кайткан бер егеткә кияүгә чыгып, авылдан китеп барган. Ире үлгәч, исенә төшергән менә... Ялгыз яшисе килми, ир кирәк.

Әнинең тавышына, сүзләренә әйтеп бетергесез әрнү-үртәлү сеңгән. Минем дә күңелгә шом үрмәли:

—Әни... Әти безне ташлармы инде хәзер?

—Ташлавын ташламас анысы... Тик безнең белән дә булмас. Шулай йөрер инде ике арада...

—Әбием бу хакта беләдер бит, ачулансын иде әтине!

—И-и, кызым... Әбиең мине гомер буе чит күрде, кай җирем ярамагандыр инде. Әтиеңне ачулану түгел, мине яклап сынар сүз дә әйтәсе юк. Бигрәк каты бәгырьле шул...

Моңарчы әни авызыннан ни әби, ни әти хакында начар сүз ишеткән юк иде. Хурлаганы да, зарланганы да булмады. Гаиләбез хәлләрен уртага салып, олыларча җитди итеп тәүге тапкыр сөйләшәбез бугай. Димәк, мин бала яшеннән чыгып барам... Әнине юатырга, күңелен күтәрергә теләп, алдашып маташам:

—Әбием безне ярата! Үзе шулай диде. Сине дә якын итә ул, сиздерми генә.

Әни монсу елмаеп баш чайкый. Минем матур ялганыма ышанмый, әлбәттә. Ләкин аны-моны әйтми. Үз уйларыбызга чумып, шактый сөйләшми барабыз. Ә уйларның очына чыгышлы түгел. Менә сиңа башваткыч диген... Нишлиләр икән соң мондый очракта? Әнием кебек тешне кысып түзәргә каладыр инде. Тик сабырлыкның төбе алтын булуына гына өметем аз. Кайсы акыллысы уйлап чыгаргандыр ул мәкальне, сабырлык төбендәге сары алтынны кайсы бәхетлесе күргәндер?!

Барган җиреннән кинәт туктап, әни юл кырындагы каен агачына ишарәли:

—Әйдә, бераз утырыйк әле шунда, машинабыз көтеп тормый.

Август аеның җылы, кояшлы көннәре. Быел табигать авыл кешесенә мәрхәмәтле булды, урып-җыю вакытында нәкъ шундый аяз көннәр кирәк тә инде. Тик бар дөнья тузанга чумган, коры, эссе һава тынга каплана. Юл буендагы бу бичара каен да тоташ тузанга күмелеп утыра. Арыган, әлсерәгәндер инде мескенкәем.

—Эш-эш дип чабабыз, бер-беребезне күрергә, иркенләп сөйләшергә вакыт та юк,—ди әни.—Синнән күпме сорарга талпындым, кызым, тик һаман җай чыкмады.

—Ни турында, әни?

Сүзен нидән башларга аптырагандай, ул бераз уйланып тора, аннары күземә карамый гына сорый:

—Кызым, син теге урыс малаен һаман яратасыңмы, әллә оныттыңмы инде?

Мин оялып башымны иям. Ни диим, әлегә үзем дә кистереп әйтә алмыйм. Оныттым да кебек, тик кабат күрсәм, хисләр дөрләп кабынмас, дип ышандырып әйтә дә алмыйм. Озак күрми торганга гына басылганмындыр бәлки. Әтиебез, әнә, тәүге мәхәббәтен ничә елдан соң да онытмаган, яшьлегенә кире кайткандай кыланып Кифаясы артыннан чаба бит әле...

—Минем сиңа әйтәсе килгәнем шул, кызым: читләргә кызыкма син. Үз авылың кешесенә җитми барыбер. Чөнки аның бөтен нәсел-тамыры, тормышы күз алдында. Мине дә бер авылдаш егет яратып йөргән иде,

шундый тәртипле гаиләдән. Янында бөтерелүченең кадерен беләсеңмени? Аны куып җибәреп, әтиеңә ягылдым. Яратмаганын да белә идем югыйсә. Авырга узгач, өйләнергә мәҗбүр булды. Шулай, кызым, үзем дә гаепле, тагылып чыктым мин әтиеңә... Башканы яратканын белә торып. Менә хәзер шуның әче җимешен татыйм инде...

—Яратмаса, сиңа өйләнмәс иде.

—Кифаядан өмете өзелгәнгә өйләнгәндер. Тегесе кияүдә иде бит... Кызым, әтиеңне гаепләмә син. Ни язган шул булыр инде. Барысы да Ходай кулында. Минем ике зур шатлыгым—сез бар, яраткан кешемнән тапкан сабыйларым. Шунысына да рәхмәт.

Мин дәшмим. Карашым таш өстенә кызынырга чыгып баскан кырмыскага төшә дә күңелгә сәер уй килә. Болар да яши, үрчи бит, шул кечкенә бөҗәкләрдә дә мәхәббәт, хыянәт дигән нәрсә бармы икән? Алар да кавыша-аерылышамы икән? Булмастыр ла, кеп-кечкенә башларында ми дә юктыр әле. Ләкин акылсыз ничек җан асрамак кирәк? Үзләренә җитәрлек булса да бардыр инде ул...

—Кызым, күреп-белеп торам: Сәлим сине ярата. Акыллы, игелекле бала ул. Сиңа сүзем-киңәшем шул: үзеңне яраткан кешегә чык. Бергә тора башлагач, шуннан да кадерлесе булмый. Ятларга кызыкма, яшьли белгән, йөргән кешегә җитми ул. Сәлимне ташлама, ямe, кызым.

Әнинең сүзләре миңа сәер тоела. Кияүгә чыгарга җыенган кеше юк ла! Миңа әле унсигез дә тулмаган, бәлки тормыш юлымда тагы әллә кемнәрне очратырмын. Миннән җавап ишетмәгәч, әни тагын сорап куя:

—Сәлимне ташламыйсыңмы?

—Белмим, әни, каян белим инде...

—Сәлим Илнарны да бик якын итә. Ташлама син аны,—дип кабатлый әнием.

Ул мине чатка хәтле озата. Мин Чистайга баручы бер җиңел машинага кереп утыргач кына, артына каерылып, кул болгый-болгый, авылга илтүче юлга таба борыла...

... Кыш иде. Җиргә Яңа ел килде. Аны Әлфирә белән икәү генә каршыладык. Миңа яңасы ни дә, искесе ни, дип Катерина апай кичтән үк ятып йоклады. Без шәмнәр яндырып, тыйнак кына табын корып, иске елны озатып утырдык. Югыйсә озатсаң-озатмасаң да, вакыты җиткәч китә инде ул. Көлешә-көлешә, шампан шәрабы эчтек, икебезнең дә бу нәрсәне беренче тапкыр татып карау иде. Шуңа да бик тиз башка китте, тиктомалдан көлдерә башлады. Пырхылдаша-пырхылдаша, Әлфирә белән бер-беребезгә теләк теләргә керештек. Мин әйтәм:

—Киләсе елда кәкре аяклы, кылый күзле бер егет белән танышырга язсын,—дим.

Әлфирә өсти:

—Ник алай гына, аксак та булсын!

—Һәм пеләш! Пеләшләр янында гел якты була. Утка экономия.

—Ха-ха-ха... чукрак булса, тагы да яхшы. Кирәкмәгәнне ишетми.

—Юк, чукрак булмасын, ишетсен. Лутчы телсез булсын диң. Тып-тыныч, эррәхәт!

Үзебезнең дә рәт юк, сүзебезнең дә рәте юк... Башта шырык-шырык көлдем, аннары кинәт сагыш басты, тиктомалга елыйсы килә башлады. Үләргә җитеп Женяны сагындым. Янымда булса икән ул! Шәраб эчкәннән соң күңел иләсләнә башлады, тәнемә әллә нинди кыргый дәрт тулды, кемгәдер сыенасым, назланасым, иркәләнәсем килеп китте. Юк, кемгәдер түгел, нәкъ менә Женяга... И-и, тотындым Әлфирәгә мәхәббәтем турында илһамланып-илһамланып сөйләргә. Дус кызым мине тын да алмый,

авызыма кереп китәрдәй булып тынлый, шомырт күзләрендә мут очкыннар бии. Анын әле беркем белән очрашканы, үбешкәне юк икән, көнләшүдән еларга җитеште.

—Үбешергә өйрәт әле мине,—диМәсенме.

—Мин сине ничек өйрәтим ди?! Кызлар үпми, егетләр үбә ләбаса,—дим.

—Ә син ул үпкәндә нишлисен?

—Иренне бөреп торам.

—Үләм! Минем дә үбешәсем килә.

—Әйдә киттек урамга, берәр егетне тотабыз да үбешәбез.

Вәт акылсызлар, тәки чыгып киттек бит. Йөри торгач, эзләгәнебезне таптык. Тукталышта бер егет кисәге бөрешеп басып тора иде. Ике яклап эләктереп алдык моны. Куркып-сискәнеп китте мескенкәй. Аны да айныклар исәбенә кертеп булмый иде. Шуна күрә безнен тәкъдимгә авыз ерып ризалашты.

—Кайсыбызны башта үбәсең?—диештек без.

Егет аптырап калмады, озындыр куллары белән икебезне берьюлы кочагына җыйды да, башта мине, аннары Әлфирәне үбеп алды. Биттән генә. Без моңа риза булмадык: «Иреннән, иреннән!»—диештек.

Ләкин шул чак тукталышка, озын мөгезләрен тырпайтып, бер ялкау троллейбус килеп туктады һәм егетебезне үз куенына тартып алып, ыңгыраша-ыңгыраша күздән югалды. Тик моңа әлләни борчылмадык. Саф салкын һава безне айнытып җибәргән, карлы җил баштагы иләс-миләс уйларны таратып-тузгытып ташлаган иде. Айныгач, мажара эзләү теләге дә сүрелде, үз кыланышыбызга үзебез үк аптырап кире фатирыбызга кайтып киттек.

—Кара, ни кыланабыз... Кеше көлдереп... Бездән нинди тәрбияче чыга инде?—дип баш чайкады Әлфирә.

Ул бу минутта әлеге егеттән, миннән генә түгел, үзеннән дә ояла иде бугай.

—Аптырама, яшь чак—тиле чак,—дип юаткан булдым мин аны. Гәрчә үземне дә үкенү корты кимерә иде.—Бу егетне башка мәнге күрәсебез юк!

Эчү яхшыга илтә димени?! Исерек башка шайтан оялый, ди минем әбием. Хактыр, шулайдыр, шайтан ояламаса, төн уртасында шулай кыланып, исәрләнеп йөрер идекмени?! Үз башыңа үзен хуҗа була алмасаң, гомер юлында искә дә төшерәсе килмәгән күңелсез мизгелләр шактый җыела икән шул. Әни әйтмешли, кызлар намусы—кыл өстендә, кылдан төшсә—ил өстендә... Әле дә троллейбус бик вакытлы килде, рәхмәт төшкере!

Бәйрәмнән соң имтиханнар башланды. Баш та күтәрми әзерләнәбез. Алда кышкы каникуллар ымсындырып тора. Авылга, әни янына кайтасы килә. Андагы хәлләрне азмы-күпме белеп торам. Әти һаман беренче мәхәббәте белән чуала икән. Бичара әнием ничекләр түзәдер. Житмәсә, Кифаяны идарәгә эшкә урнаштырганнар. Кичләрен дә, көндезләрен дә алар әти белән бергә. Райүзәккә дә бергә йөриләрдер... И-и, теләгән кешегә ничек тә очрашып була инде. Әнинен генә түгел, минем дә йөрәк яна. Әгәр әби безнең янда тормаса... әгәр төп нигездә яшәмәсәк... әтине Кифаясы янына гына җибәрер идек... Алай бик яраткач, торсын шунда... кадерле сөяркәсе янында... Әниемнең күз алдында җан көеге булып йөрмәсен. Юк икән юк. Ә болай... бар да ул, юк та...

Гыйнвар аенын буранлы көне иде. Уйламаган-көтмәгәндә безгә Самат абый килеп керде. Колхозның баш механигы ул, Казанга сирәк булса да килгәли. Минем торган фатирны да белә, кергәне бар, көзен бәрәңге китергән иде. Бу юлы да, бәлки, ни дә булса алып килгәндер.

Мин авылдаш абыйны шатланып каршы алдым:

—Әйдәгез, Самат абый, үтегез, чәй эчәрсез, җылынырсыз.

—Юк, сенлем, үтеп тормыйм, ашыгам.

Ул бераз таптанып торды да:

—Син жыен әле, сенлем... Әтиең сине кереп алырга кушкан ие...

—Ник?! Безнең каникул башланмады бит әле, Самат абый. Тагын ике имтихан бирәсе бар. Мин кайта алмыйм.

Самат абый гаепле карашын мина төби:

—Кайтырга кирәк бит, сенлем. Кайтырга кирәк...

Күнелемә салкын дулкын булып шом тула, кабаланып-куркып сорыйм:

—Нәрсә булды, Самат абый? Әйтегез, ни булды?

Тик соравым жавапсыз калды.

—Син жыен, сенел, югыйсә карангыга калабыз.

—Урамда буран котыра ич. Ничек кайтырбыз соң?

—Ничава, йөрмәгән юл түгел. Чаллы юлына кар төшәргә дә өлгерми анда, машиналар тыз-быз йөреп кенә тора.

Мин тиз-тиз жыенып, Самат абыйга ияръм. Жанымны билгесезлек, сораулар телә: ни булган? Сизәм, хәерлегә түгел. Ләкин дөреслекне белергә куркам.

Казанны чыккач, түзмим, тагы бер кат сорыйм:

—Самат абый, газапламагыз, әйтегез инде: ни булды соң?

Самат абый көттереп кенә жавап бирә:

—Әниең авырый,—ди.

Мин жинел сулап куям. Югыйсә күнелгә әллә нинди начар, шикле уйлар килгән иде. Авырый—ул әле үлгән диган сүз түгел, димәк, өмет бар.

—Анда одеял бар, сенлем, төренеп ят. Йокласан, юл кыска була,—ди Самат абый.

...Мин уянганда район үзәген үткән идек. Авылга керәсе юлны кар күмгән, ике адым үтәбез дә, кар көрибез. Мин түгел, әлбәттә. Мин одеал астында, жылыда ятам. Авылга төнге уннарда гына кайтып життек.

Машинадан төшүгә әти каршы алды. Аны шундук сорауларга күмеп ташладым:

—Әнигә ни булды? Нинди чир диделәр? Хәзер кайда ул, өйдәме, балнистамы?

—Өйдә...—диде әти кулымнан сумканы алып.

Ул, жилкәсенә дөньяның бар йөге төялгән кебек, башын иеп, сөйрәлеп кенә атлый. Капкага житкәч, туктап, тирән итеп сулыш алганнан сон, карашын мина төбәде:

—Сабыр бул, кызым, сабыр бул. Дөреслектән качып булмый... Әниең үлде...

Шуннан ни булганын яхшылап хәтерләмим. Барысы да томан эчендә, әллә төш булды ул, әллә өн.

Без өйгә кердек. Алгы якта төнге ут кына яна. Шул сүрән яктылыкта бүлмә уртасында ак жәймә белән капланган әнинең гәүдәсен, анын кырында дисбе тартып утырган күрше әбиләрен күрәм. Өзгәләнеп кычкырып, әнием өстенә капланам: «Әнием! Мин кайттым, тор инде, әнием! Әнием, мин бит бу, ач инде күзенне. Тор инде, зинһар! Әнием, бәгърем!» Карчыклар мине күтәреп торгызалар:

—Кызым, алай ярамый. Әниенне борчыма. Ул барсын да күреп, ишетеп тора. Мәет янында тавышланырга ярамый.

Икенче көнне өебез хушлашырга килүчеләр белән тула. Барысы да кайгыбызны уртаклаша. Барысы да:«Ахыры хәерле булсын, Ходай сабырлык бирсен»,—ди. Сәлим дә күземә чалына, карашында—әрнү-кызгану, янымa килеп ниндидер юату сүзләре әйтә. Мин таш кебек катып йөрим. Канлы

яшьләрем бәгыремә оешкан. Акырып еласам, алар бәлки түгелер иде, тик елый алмыйм. Ә әти елый, күз яшьләре белән елый. Мин җансыз робот кебек кушкан бер эшне үтәп йөрим: «су җылыт, комганны әзерлә, энә бир, ак җеп бир, суны түк»... Калтыранган кулларым белән әниемә ахирәт күлмәге тегәм. Кеше үлгәннән соң да җирдә өч көнлек эше кала диюләре шул икән... Ярый әле бар ул эш, ярый әле бар. Әнине алып китәләр. Без, хатын-кызлар, каберлек кырында басып торабыз. Мин таш йөз белән әниемне кабергә иңдергәннәрен күзәтәм. Үзем уйлыйм: «Тизрәк бу төш бетсен иде. Тизрәк уянасы иде дә, тере әнине күрәсе иде!» Ә төш дәвам итә. Әнисез йортка кайтабыз да, күрше апалар белән өйне, керләрне юа башлыйбыз. Хәтта чип-чиста керләрне дә юарга кирәк. Имеш, җан чыкканда бөтен җиргә кан чәчри, тик без аны күрмибез икән.

—Әниеннең киемнәрен ташлама, туганнарга, күрше-тирәгә өләш,—ди Фәрдия апа.—Истәлеге итеп киярләр.

—Иске-москыларын тастымалга тура. Ләкин берүк идән юарга тотма, аяк астына салма, әниең рәнҗеп ятар,—дип өсти Нурсинә апа.

Керләр күп, алар белән бакчадагы баулар тула. Кышкы салкында әниемнең күлмәкләре бозланып ката. Әни салкын җир астында ята... Мескен әнием салкын җир астында ята... Үзе дә, күлмәкләре дә өши... Шуны уйлыйм да, кинәт кычкырып елап җибәрәм...

Әнием бу авылда чит кеше иде, әби әйткәнчә, килмешәк. Аның монда бер туганы да юк. Бердәнбер апасын сөйгән егете үзе белән Кыргызстанга ияртеп киткән. Кыргызстан күрше авыл түгел, сагынган саен йөгереп кайта алмыйсың. Кайнаналы йортта кунак булуның әлләни яме дә булмагандыр, Фатыйма апа якты йөзен безгә бик сирәк күрсәтте. Аның каравы әтинең туганнары бусагага тузан кундырмады инде. Әни ялгыз иде, аның рәхәтләнеп сөйләшер, сер түгәр кешесе булмады. Сер бүлешер, күңелен бушатыр кеше булмаса, бар хәсрәт-әрнүең йөрәгеңә кара кан булып оеша, диләр. Әнине шул алып киткән. Аны су буеннан, кер чайкарга төшеп киткән җиреннән алып кайтканнар. Кулына әтинең күлмәген тотып җан биргән мескенкәем. Нинди уй-сагышлар алып киткән аны бу дөньядан? Бәлки кулына әтинең күлмәген алгач та, мин юам, башкалар коча-назлана, дип уйлап куйгандыр. И әнием...

Мин әтине күралмас булдым. Ул үзе дә миннән ким газапланмый бугай. Бу көннәрдә гел өйдә монаеп утыра. Тота да гаилә альбомын актара, әниемнең рәсемнәренә карап уйга бата. Йә кисәк кенә киенә дә, каберлеккә менеп китә. Әнине вакытсыз гүргә кертүен үзе дә аңлый бугай ул, тик үкенүдән ни файда. Юк әни, юк... Бу юклыкка, бушлыкка ияләшү авыр, әле һаман ышанасы килми. Әни каядыр чыгып кына киткән кебек... Менә-менә ишек ачылыр да, башын ия төшеп, әкрен генә басып кайтып керер кебек...

Ни усал әби дә басылып калды, сөйләшмәс-дәшмәс булды. «И-и, дөньялар...»—дип авыр сулап куя да, шуның белән сүзем бетте дигәндәй, карашын читкә бора. Илнар балалыгы белән фаҗиганең тирәнлеген аңлап та бетерми бугай. Бәлки янында мин булганга җиңелрәк кичерәдер. Апа апа инде ул, апалар әни урынына кала.

Ә бит миңа китәргә кирәк, тапшырылмаган имтиханнарым өстә тора. Әни юк. Ләкин яшәргә кирәк. Тормыш дәвам итә.

*Дәвамы киләсе санда*

*Татарстан АССР төзелүгә 90 ел*



Индүс
Таһиров

# ТАТАРЛАР ДӘҮЛӘТ ТӨЗҮ ЮЛЫНДА

*Мәңгелек дан Сиңа татар—*
*Әкияти батыр—Алып,*
*Кайгыны да, үлемне дә*
*Җыр белән җиңгән халык!*
Ибраһим Биектаулы

## 1. Тирән тамырлар

Сүз татар тамырлары турында бара, хөрмәтле укучыларым. Җир йөзендә бер генә дә сыңар тамырлы халык юк. Татарлар да бер тамырлы гына түгел. Аларны тик болгарлардан гына яки Алтын Урдадан гына барлыкка килгән дигән фикерләр белән килешеп булмый.

Әйе, без болгарлар да, койрыгыбыз Алтын Урдага да нык берекккән. Шуның өстәвенә без әле кыпчаклар да. Хәтта хазарлар да. Угрофин, күпмедер славян каны да бардыр бездә. Һәрвакыт бертуктаусыз хәрәкәттә булган, дөньяның бер читеннән икенче читенә йөреп торган халыкта ник башкаларның да тамгасы калмасын икән? Алар бар, әлбәттә. Ләкин, ничек кенә булмасын, без—төркиләр. Алай гына да түгел, төркиләрнең юл башында торган татарлар без.

Безгә мәгълүм булган юл башыбыз, хөрмәтле укучыларым, моннан 25 гасыр элек яшәгән бабаларыбызга килеп тоташа. Кытай хроникалары тамырларыбызның хәтта үткән дәвернең 3нче меңьеллыгына кадәр үк җиткерәләр. Шушы дәвердә алар берничә, хәтта кытайларны буйсындырырдай дәүләтләр төзегәннәр.

Ни гаҗәп, без инглиз галиме Эдуард Паркерның 1895 елда ук чыккан «Татарлар тарихыннан мең ел» исемле китабына тиешле игътибар бирми яшәгәнбез. Бу кеше күп еллар буе Кытайда дипломатик хезмәттә булып, борынгы кытай чыганакларын өйрәнгән һәм татарның тирән тамырларын ныклап ачыклаган. Заманында китап шулкадәр дә зур резонанс алган ки, аны 1937 елда кытай галиме Шан Да, яңа чыганаклар белән Паркерның мәгълүматларын тагын да баетып, үз телләренә тәрҗемә иткән.

Бу соңгы мәгълүматны мин бүгенге көнне Алматы шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Мөнир ага Ерзинның миңа язган хатыннан белдем. Мөнир абый үзе дә бик кызыклы шәхес. Ул заманында Кытайда кытай телендә университет

бетергән. Алматыда да университет тәмамлаган. Ул да кытай чыганаклары белән таныш. Мөнир ага ул чыганакларның кайсы китапханәләрдә ятканлыгы турында да язган. Аңа моның өчен генә түгел, Кытайга күчеп килгән татарлар язмышына багышланган «Тропою предков» исемле китабы өчен дә зур рәхмәт. Озын-озак шатлыклы вә бәхетле гомер кичерә күр, Мөнир ага!

Китапның инглиз теленнән русчага тәрҗемәсен бүгенге көнне АКШта яшәүче милләттәшебез Вил Мирзаянов башкарган. Аңа да рәхмәтле булу кирәк.[1]

Татар тарихы һәм аның бүгенге язмышы өчен янып-көеп йөрүче милләттәшебез, дипломат һәм галим Йолдыз Хәлиуллин «Независимая газета» ның 2009 елның 6 октябрендә Эдурд Паркерга багышлап чыгарган мәкалә шулай ук бик кызыклы һәм зур әһәмияткә ия.



*Без—Кол Галиле, «Йосыф-Зөләйха»лы халык. Шагыйрьнең Т. Хаҗиәхмәтов иҗат иткән рәсеме.*

Сез, хөрмәтле укучыларым, минем шушы борынгы тамырыбызга тукталуыма гаҗәпләнмисездер дип уйлыйм. Алар аркылы безгә бүгенге атамабыз гына түгел, милли моңыбыз да, кайбер гореф-гадәтләребез дә, телебезнең нигезләре дә килеп ирешкән.

Татарларның дәүләти тәҗрибәсе монголларга да күчеп, аларга да дөньякүләм империя тудыруга юл ачкан. Татарның бөеклеге монголлар барлыкка китергән Алтын Урда дәүләтен татарлаштыруда да чагылыш тапкан. Моны бернинди шик шөбһәсез татар феномены дип атарга була. Болгар иленә, кыпчак далаларына килгән монголлар, хәтта Чыңгызның үз токымы да төркиләшкән, татарлашкан.

Икенче бер нык төпле болгар тамырыбыз аларны Ислам диненә дүндергән, Алтын Урда дәүләтен Ислам дөньясына алып кергән. Алай гына да түгел, ханнар Мәскәү дәүләтенә нигез салганнар. Дөрес, рус тарихчыларының күбесе, Ричард Пайпс әйтмешли, бу турыда сөйләргә ояла. Ә бит без капчыкта ятмый, ул кайчан да булса капчыкны тишеп чыга. Моның шулай икәнлеген аңлау өчен Владимир Белинскийның Интернетка куелган «Моксель или Открытие Великороссии» исемле китабын карап чыгу гына да җитә. Бу китапның безе капчыкны бик тә ныклап тишкән.

Тамыры тирән булган халыкны тарихтан йолкып алу мөмкин түгел, мөхтәрәм җәмәгать. Татар язмышы—авыр язмыш. Бөеклекнең иң биек ноктасыннан коллык ноктасының иң төбенә төшү җиңел була алмый, әлбәттә. Дөньяның гөрләп торган ничәмә-ничә дәүләтен юктан бар иткән халыкка кискен рәвештә коллыкка күчү—ул фаҗиганең дә фаҗигасе. Рус коллыгында калу афәтен Габделбари Баттал урыс җәһәннәме дип тә бәяләгән. Һәм дөреслектән әллә ни ерак та булмагандыр диярга кирәк.

Чыннан да, кыска гына вакыт эчендә Казан җир белән тигезләнә диярлек. Татарлар башкалаларыннан, яшәү өчен уңайлы булган урыннарыннан сөреләләр. Гасырлар буе җыелган рухи байлыгыбыз бөтенләе белән диярлек юкка чыга. Бәлки башка бер халык шушы сынаулар аша үтә дә алмаган, инде күптән үләнбеткән булыр иде. Ләкин татар үлемне дә, кайгыны да җиңәргә өйрәнгән, тарих тарафыннан нык чарланган халык. Аңа яшәү көчен әнә шул тамырлары биреп торган.

Татарлыкның иң зур дошманнарыннан булган атаклы миссионер Ильминский юкка гына татарларны дәүләти халык дип атамагандыр. Аны шул Ильминскийлар чукындырырга никадәр тырышмасын, ул чукынмады, руслаштырырга тырышсалар да—руслашмады. Ул дәүләтләреннән мәхрүм булганнан соң да, кайгы белән үлем арасында бөек булып кала алды. Миссионерларның, татарлар өч йөз буена руслар белән бергә яшәүләренә дә карамастан, руслашмыйлар, киресенчә, башкаларны татарлаштыралар, диган сүзендә дөреслек юк түгел. Галим-миссионер Ефимий Маловның 1904 елның 30 сентябрь—14 октябрь чорындагы көндәлек язмалары арасында уфтанып язылган мондый юллар бар: «Без, руслар, ун гына түгел, йөзләгән еллар дәверендә татарлар өстеннән хаким сыйныф рәвешендә яшибез.

[1] Китап 2003 елны «Идел-пресс» нәшриятында дөнья күрде.

Инде Казан алынганнан соң да өч йөз елдан артык вакыт үтте, тик менә без аларны күпме дәрәҗәдә генә руслаштыра алдык икән соң? Тагын да өч-дүрт йөз ел көтәрбезме икәнни?».

Бу сүзләргә: «Көтегез, көт, бәлки, көткәнегезнең киресенә тап булырсыз!»— дип өстисе генә кала. Татар беркайчан да үлмәячәк, чөнки аның тамырлары тирән. Ә алар исә вакыты җиткәч уяналар, дәүләтчелегебезгә юл ачалар.

## 2. Милли тамырлар уяна

Әйе, хөрмәтле укучыларым, күпмедер йоклап яткан тамырлар уяна, аларны, вакыты җиткәч, тарих үзе уята. «Без Бишенче елны беркөнне уяндык таң белән», дип язган Тукаебыз. Россия капкасын революция шакый башлау белән татар да уяна.

Татарлар XIX һәм XX гасыр чикләрендә яңарыш кичереп, үз мәгариф системаларын булдырып, Россиянең иң укымышлы халкына әвереләләр, 20дән артык газет-журнал, миллионлаган тираж белән китаплар чыгарып, аларны барлык төрки халыкларга да җиткерә алуга ирешәләр. Дистәләгән язучы, шагыйре үсеп чыга, театрлары барлыкка килә, музыкаль сәнгатьләре туа. Халыклар төрмәсе дип аталган Россиядә шушы гүзәл үзгәрешләрне булдыра алу могҗиза түгелме? Һичшиксез, могҗизаның да могҗизасы бу! Кыскасы, Рәсәй күгендә татар йолдызы балкый башлый.



Сулдан уңга: Г. Исхакый, С. Максуди.

1911 елны «Вакыт» газетасында басылып чыккан бер хатта мондый сүзләр бар: «Үзенең китап теле һәм әдәбияты, үзенең тарихы, менә дигән үткәне булган халык беркайчан да юкка чыкмас... Менә безнең халык уяна, өстендәге кабер туфрагын кагып төшерә һәм озаклап яткан кабереннән чыга. Татарның киләчәге томанлы түгел, ул бик тә ышанычлы».

Казан җандарм идарәсе башлыгы, 1909 елның 9 августында Эчке эшләр министрлыгының полиция департаментына юнәлтелгән депешасында, татарлар арасында милли идеянең ныгуына борчылып, болай дип язган: «Бу идеянең максаты барлык мөселманнарны бер дәүләткә җыюдан гыйбарәт. Аның тактик алымнары татарларда һәм мөселманнарда милли хис уятуга, автономия, милли мәктәп, милли бердәмлек булдыру, рус йогынтысына һәм хөкүмәтнең руслаштыру сәясәтенә каршы торуга юнәлтелгән... Ә киләчәктә Төркестан һәм Кавказ белән союзга кереп, эшне гомум төрки республика төзүгә кадәр җиткерү күздә тотыла.»[2]



Й. Акчура

1911 елда төзелгән бер җандарм справкасында» Казан губернасында һәм кайчандыр куәтле булган тарихи татар патшалыгының үзәге Казанда алдынгы татар элементлары җыела»[3], диелгән. Әйе, беренче рус революциясеннән соң Россия татарлары дәүләтчелекләрен аякка бастыруны максат итеп куялар. Шул елларны Петербург шәһәрендәге татар студентлары «Татар учагы» исемле оешма булдырып, анда шулай ук татарлар өчен махсус республика булдыруны үзләренең бурычлары итеп билгелиләр.

Ә инде 1917 елгы революцион өермәләр дәверендәге берничә мөселман съездында дәүләтчелек мәсьәләсе ныклап тикшерелә. Шул елның маенда булып үткән

[2] НАРТ,ф.1,оп. 6,д. 636,л. 3.
[3] ДПОО,д.74,ч.27,л.12.

I Мөселман съездында, Россия федератив рәвештәге дәүләткә әверелергә тиеш, дигән карар кабул ителә. Ә Нижгар мулласы Габдулла Сөләймани Россиядә татарлар өчен бер штат төзергә кирәклеген алга сөрә.

Штат төшенчәсе беренче мәртәбә шунда яңгырый һәм акрынлап көчкә дә керә башлый.

## 3. Идел–Урал штаты

Бу башлангыч Милләт мәҗлесе тарихына бәйле. Мәҗлескә сайлаулар үткәрү турындагы карар 1917 елның июлендә булып үткән мөселман съездында кабул ителә. Һәм аңа яшерен рәвештә тавыш бирү принцибы нигезендә гомум сайлаулар да үткәрелә.

Шул ук елның 20 ноябрендә Уфада Милли мәҗлес җыелып, күренекле шәхесебез Садри Максуди җитәкчелегендә эшен башлап та җибәрә. Ул 1918 елның 11 февраленә кадәр дәвам итә. Бу уңайдан «Известия Всероссийского Мусульманского Военного Шуро» болай дип яза: «Хәзерге заманда һәр милләт үзенең эчке тормышын төзү белән мәшгуль. Инде ниндидер съездлар, кәгазъ резолюцияләрнең вакыты үтте—иске җимерекләкләр нигезендә Россия халыкларының яңа, якты киләчәкләрен төзергә кирәк. Милләт мәҗлесе нәкъ менә шул практик эш белән шөгыльләнә».

Мәҗлестә Ильяс Алкин күтәреп чыккан татарлык рухы хөкем сөрә. Безнең, ди ул үз чыгышында, тарихи хәтеребез көчле һәм без аңа таянып, нинди генә юллар белән булмасын, Татарстанны барлыкка китерергә тиешбез.

Әйе, шушы Бөтенроссия мөселман хәрбиләрнең Шурасын барлыкка китергән данлыклы морзалар токымының дәвамчысы, 22 яшьлек прапорщикның милли тамырлары кузгалып, каны кайнаган көннәр бу. Әлбәттә, аныкы гына түгел, шушы мәртәбәле җыенга килгән һәрбер кешене милли хис һәм тойгы чорнап алган була.

Мәҗлес Урал-Идел штатын төзүнең Коллегиясен сайлый. Аның составына И. Алкин, С. Янгалычев, Г. Шәрәф, Ф. Мөхәммәдъяров, Ф. Сәйфи, С. Атнагулов, Г. Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин кертеләләр. Җитәкчелек вазифалары Бөтенроссия Мөселман Хәрби Шурасы рәисе Ильяс Алкинга йөкләнә. Ә аның рәистәше итеп күренекле галим Галимҗан Шәрәф сайлана. Монда тагын руслардан 5, чуашлардан 2 һәм чирмешләрдән 1 кеше кертү тиешле табыла. Коллегиянең Казанда эшләргә тиешлеге фаразлана.



*Милләт Мәҗлесе депутатларыннан бер төркем.*

Хәрби Шура 1918 елның 17-18 гыйнварында бу эшкә кичекмәстән тотынырга кирәклеге турында һәм Штатның Учредительный җыелышына сайлаулар үткәрү турында карар кабул итә. Һәм Казан Советы белән шушы турыда сөйләшүләр дә башлап җибәрә. Ләкин бу сөйләшүләр уңай нәтиҗә бирми. Чөнки халыклар дуслыгының дошманнары шәһәр халкы арасында әллә нинди коткылар таратალар: имештер, Шура шәһәрне үз кулына ала һәм татар идарәсен оештыра, хан заманнары кайта. Тагын әллә нәрсәләр...

Шушы уйдырмаларга җавап итеп, Хәрби Шура, Мөселман хәрби округ комитеты, мөселман хәрби комитеты, инде татарлаштырылган 95нче полк

вәкилләре 31 гыйнвар көнне Казан халкына мөрәҗәгать кабул итәләр. Анда мондый сүзләр дә бар: «Рус туганнар—Солдатлар, Крестьяннар, Эшчеләр! Инде ике ай буе шәһәрдә әшәке провокацион имеш-мимешләр таратыла. Имештер, мөселман оешмалары җирле совет хөкүмәтен кулга алырга телиләр». Мөрәҗәгатьтә тагын мондый сүзләр бар: «Безме соң инде гасырлар буе иске режим тарафыннан изелгән, сезнең белән янәшә тынычлык, яхшы күршелек мөнсәбәтләрендә яшәгән революцион демократия, инде менә азатлыкның якты кояшы чыккан көннәрдә бозылышырга тиешбез? Юк, юк һәм кабат юк!»



И. Алкин

Хәрби Шураның шулкадәр дә ачык позициясен Казан Советы җитәкчеләре күрмәмешкә салыша киләләр һәм шул ук вакытта съезд делегатлары арасына чөй кагып, аларны бер-берсенә каршы куярга маташалар. Һәм максатларына ирешәләр дә. Шушы шартларда, ни кызганыч, милли әһелләребез арасында аңлашмаучылык арта. Милләт мәҗлесе һәм Хәрби Шура арасында да ниндидер каршылыклар килеп чыга.

II Бөтенроссия мөселман хәрби съездында Шура штат игълан итүне кирәк таба. Тиз арада тыл һәм фронттагы хәрби частьлардан 200 делегат сайлана һәм 1918 елның 8 гыйнварында съезд үзенең эшен башлап та җибәрә. Аны Ильяс Алкин ача. Йосыф Мозаффаров, кулына Штат картасын тотып, аның асылы турында доклад ясый. Картаны Галимҗан Шәрәф төзегән була. Шул ук көнне съезд Совет властен яклап, III Бөтенроссия Советлар съездының карарларын тулысы белән таныганлыгын белдерә. Тик менә Казан Советы аларны таныргa теләми. Аның җитәкчеләре Брест солыхына да, III Бөтенроссия съездының Россияне федерация итеп игълан иткән карарына да каршы чыгалар. Һәм инде, әлбәттә, Урал-Идел штатына да каршы булалар. Теш-тырнаклары белән аны игълан итүне булдырмаска тырышалар. Һәм, татар сулларына таянып, аларның кулы белән съездны җитәкчеләрсез калдыралар. Татарлар үзләре төнлә килеп, съезд җитәкчелеген кулга алалар. 1918 елның 28 февралендә игълан ителергә тиешле Штат игълан ителмичә кала. Ни кызганыч, бу эшкә Мирсәет Солтангалиев белән Шамил Усманов җитәкчелек итәләр. Соңрак алар хаталарын таныйлар, эшләгән гамәлләренә үкенәләр. Тик инде соң була. Терсәкне тешләп булмый шул!

Съезд эшен Болак артына күчерергә мәҗбүр була. Аны таркату өчен Мәскәүдән Бөтенроссия мөселман Комиссариаты җитәкчесе Мулланур Вахитов 300 кешелек матрослар отряды җибәрә. Шуның белән Идел-Урал штаты идеясе юкка чыга.

Нәтиҗәдә большевиклар дәүләтчелек төзү хокукын үз кулларына төшерәләр. 1918 елның 22 мартында И. Сталин һәм М. Вахитов тарафыннан имзаланган Татар-Башкорт республикасы турындагы положение хасил була. Тик ул гамәлгә ашыру өчен түгел, Идел-Урал проектын мәтәлдерү өчен дөнья күргән бер уен гына булып чыга.



М. Вахитов

Шул ук елның июль ахырында Мулланур Вахитов Мәскәүдән Казанга килә һәм, шәһәр аклар кулына күчкәч, алар тарафыннан атып үтерелә. Бу каһарманның үлеме милли азатлык юлындагы беренче иң зур корбан була. Ләкин соңгысы булмый. Революция татар җанын тарта, яңа корбаннар сорый... Революция үз балаларын үзе ашый дип юкка гына әйтелмәгәндер, күрәсең.

Большевикларга исә Идел-Урал штаты да, Татар-Башкорт республикасы да кирәкми. 1922 елда Ленинга җибәргән бер хатында Сталин мондый уеннарны туктатыр вакыт җитте, чөнки моңа миллиләр /националлар / үзләре дә ышана башладылар, дип яза.

Уен, әйе, Татар-Башкорт республикасы да бер максатчыл, Гражданнар сугышы вакытында татар-башкорт потенциалын тулысы белән файдалануга юнәлтелгән уен гына була. Һәм 1919 елның 13 декабре көнне РКП(б) Политбюросы Милли Эшләр буенча Халык Комиссариатының проектын юкка чыгара һәм бу республиканы төзү өчен агитация алып баруны тыя.

Бервакыт республиканы Казансыз һәм Уфасыз төзү идеясе пәйда була. Бу кемгә кирәк булган икән? Тик моңа инде барлык күренекле зыялылар бердәм рәвештә каршы чыгалар.

Искиткеч авыр еллар бу. Совет хөкүмәтенең халыкны, бигрәк тә крестьян халкын, продразверстка белән талап, чишендергән Гражданнар сугышы еллары. Шушы талауларга, рәнҗетүләргә җавап буларак сәнәкчеләр фетнәсе күтәрелә. Ул 1920 елның 7 февралендә башланып, 35 көн дәвам итә. Аны регуляр гаскәр көче белән канга батырып бастыралар. Күрәсең, бу—республика төзүнең кереш сүзе була .

## 4. Республика туа

1920 елның 27 маенда Татарстан автономияле республикасын төзү турындагы декрет барлыкка килә. Татарлар республика төзүгә тулысынча әзер булалар. Тиешле рәвештәге кадрлар, бөтен яктан камил язма, дәүләти фикер—болар барысы да була. Моны хәтта татарларны әллә ни өнәмәгән, егерменче елларда РСФСР Халык Комиссарлары Советы рәисенең урынбасары булып торган казакъ Т. Рыскулов та таныган. Ул Татарстанны бердәнбер дәүләти дәрәҗәдә өлгергән, житлеккән республика дип бәяләгән. Башка республикалар исә, аның әйтүенә караганда, Совет хөкүмәтенең мәрхәмәте аркасында гына гомер кичергәннәр.

Республиканы оештыру өчен Сәхибгәрәй Сәетгалиев җитәкчелегендә революцион комитет төзелә. Аның чикләрен билгеләү эшләре Галимҗан Шәрәф җитәкчелегендә башкарыла. Бу,әлбәттә, җиңел эш булмый, чөнки ул төрле губерналарның татарлар күпчелек тәшкил иткән өязләреннән барлыкка килергә тиеш була. Самара губернасының Бөгелмә, Сембер губернасының Буа, Уфа губернасының Минзәлә, Вятка губернасының Алабуга һәм Әгерҗе өязләре шушы республиканың төп җирлеген тәшкил итәләр.

Татарстанны төзү декретында искәрмә рәвешендә Уфа губернасының Бәре һәм Бәләбәй өязләренең бу республикага керү мәсьәләсе халык фикере нигезендә хәл ителергә тиеш, диелгән. Әмма берәү дә халык фикере белән кызыксынмый. Бернинди плебисцит та үткәрелми. Күрәсең, монысы да уен гына була. Бу өязләр республикага кертелмиләр. 1922 елда исә алар Башкортстанга бирелә.


К. Мохтаров

Шул рәвешле Татарстан 67.126 квадрат километр мәйданда җирлектәге һәм баштарак 10, соңрак 13 кантоннан тора торган республика буларак барлыкка килә. 1929-30 елларны кантоннар урынына 43 район төзелә.

Республикада 2892 мең кеше булып, аның 51,6 процентын татарлар, 40,4 процентын руслар, калганнарын чуашлар, марилар һәм башка халык вәкилләре тәшкил итә.

1920 елның 26-27 сентябрендә ТАССР ның I учредительный съезды булып үтә. Анда республиканың 7 кешедән торган Үзәк Башкарма комитеты төзелеп, аның председателе итеп Борһан Мансуров сайлана. Шулай ук 15 кешедән торган Халык Комиссарлары Советы сайлана. Аның председателе итеп Сәхибгәрәй Сәетгалиевне куялар.

Дөрес, республика шулвакыттагы милләтпәрвәрләребез теләгән рәвештә төзелми. Ул территориясе дә, хокуклары да кысылган, зәгыйфь рәвештә барлыкка килә. Шулай булса да, аның автономия төшенчәсенә туры килердәй хокуклары була. 15 комиссариатның кайберләре мөстәкыйльь була, Федерация комиссариатларына буйсынмый. Бу—Мәгариф, Сәламәтлек саклау, Юстиция, Эчке эшләр комиссариатлары. Суд, Прокуратура шулай ук мөстәкыйльь булалар. Суд карарлары Татарстан республикасы исеменнән кабул ителә торган була. Ләкин бу комиссариатларның РСФСРның тиешле комиссариатлары аркылы гына финанслануы нәтиҗәсендә аларның мөстәкыйльлекләре шактый чикләнә.

Дәүләт органнарының хокукларын партия Өлкә комитеты да ныклап чикләргә һәм идарә эшләрен үз карамагына алырга тырыша. Ул Үзәк Башкарма комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы рәисләрен бик еш алыштырып тора.

Республика оешуга бер ел да үтми, Сәетгаливне Кашаф Мохтаров алмаштыра. Ул зур тормыш мәктәбен үткән, зирәк акыллы, тәҗрибәле кыю шәхес, җаны-тәне белән Татарстанны тулы хокуклы чын республикага әверелдерү өчен көрәшә,

хөкүмәт һәм партия органнарының вазифасын ачык итеп билгеләүне алга сөрә. Мохтаров хөкүмәте җиң сызганып 1921 елның 25 июнендә кабул ителгән декрет нигезендә татар телен гамәлгә ашыру эшенә керешә. Хөкүмәт документлары ике телдә төзелә башлый. Татарлар гына яшәгән авылларда дәүләти эшне бары татар телендә генә алып бару көйгә салына.

Мохтаров белән кулга кул тотынышып эшләүчеләр арасында җир эшләре халык комиссары Юныс Вәлиди исемен махсус атау урынлы булыр. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә заманында су, юл буйларыннан куылып, җирсез һәм сузыз калган татар крестьяннары өчен Идел буйларында, башка уңайлы урыннарда махсус поселоклар барлыкка килә. Ул 1921-22 еллардагы ачлык афәтен җиңеләйтү өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Тик менә шул вакыттагы партия өлкә комитеты җитәкчелегенә аның бу эшләре һич кенә дә ошамый. Аны партия оешмасының эшендә катнашмауда, кадрларны дөрес сайламауда, чәчү кампаниясен өзүдә гаеплиләр. Хәтта 1922 елның 18-19 апреле көнне партия өлкә комитеты бюросында аның персональ эше дә карала. Вәлидине принципиаль рәвештә, тулы катгыйлык белән Халык Комиссарлары Советы рәисе Кашаф Мохтаров яклап чыга. Ул үзенең чыгышында Вәлидовның Комиссариат белән җитәкчелегенең дөрес юнәлештә икәнлеген, аның максатчыл эшчәнлеген ассызыклый һәм, чәчү кампаниясен өзү турында сүз булырга мөмкин түгел, ди.



*Ю. Вәлиди*

1924 елда Мохтаров хөкүмәте хакимияттән читләштерелә.

Гомумән, 20нче елларда үзара бәрелешүләр гадәти хәлгә әверелә. Монда махсус рәвештә ачлык афәтенә кагылмый булмас. Аның башлангычы республикага салынган 10120 мең пот икмәк разверсткасы була.

1920 елның 30 сентябрендә, Татарстан хөкүмәтенең беренче утырышында продразверстканы үтәү, халыкны аны үтәргә өндәп мөрәҗәгать кабул итү мәсьәләсе карала. Республиканың Үзәк Башкарма Комитеты секретаре Шамил Усманов, «халкымны таларга теләмим», дип, аны имзалаудан баш тарта. Юныс Вәлиди мөрәҗәгатьне кабул итәргә өндәүчеләрне «милләтне сатучылар, Мәскәү холуйлары» дип атый.

Тик шулай да мөрәҗәгать кабул ителә. Продразверстка хәтта арттырып та үтәлә.

Шушы күтәрә алмаслык йөккә күптән күрелмәгән корылык афәте өстәлә. Документларда күренгәчә, бу елның апреле кызу июнь аен хәтерләткән. Язын чәчкән җирләр кибеп ярыла башлаган.

Татар иленә ачлык килгән. Ул шулкадәр дә көчле була ки, күп авылларда мал заты, хәтта эт-мәчеләр дә калмый. Кайбер урыннарда кеше ашау очраклары да була.

Нәтиҗәдә республикада 400 мең кеше ачтан үлә. 1920-26 еллар арасында татарларның саны 300 мең кешегә кими.

Болар барысы да партия өлкә комитеты һәм хөкүмәт арасындагы мөнәсәбәтләрне тагын да кискенләштерә.

1927 елны вәзгыять шуңа җитә ки, хәтта Шаһимәрдән Шәймәрдәнов җитәкчелегендәге хөкүмәт—Халык Комиссарлары Советы—тулы составы белән Мәскәүгә, партия Үзәк комитетына дәгъва белән бара. Вакыйга тарихка наркомнар стачкасы исеме белән кереп урнаша. Бу турыдагы хәбәр бөтен Казанны биләп ала, халык шаулый. Татарлар хөкүмәтне яклыйлар. Тик менә Мәскәү аны якларга теләми. Халык комиссарлары җиңелә. Дөрес, өлкә комитетның җаваплы секретаре Хатаевич та урыныннан алына. Тик бу хәл вәзгыятьне үзгәртми. Чөнки бу вакытта илдә инде партия диктатурасы урнашкан була. Сталин культы гамәлгә аша. Шушы милләтебезне аерым яратмаган кешеТатарстан өчен суверенлык капкасын яба.



*Ш. Усманов*

1922 елдан башлап Татарстан берничә мәртәбә үзен СССРга суверен дәүләт буларак кабул итүне дәгъвалый. Шулай булуга да карамастан, ул СССР төзү

шартнамәсен мөстакыйль рәвештә имзалау хокукыннан мәхрүм ителә. Бу очракта Мирсәет Солтангалиевне искә төшермичә булмый. Бу кеше РСФСРның Милләтләр эшләре буенча Халык Комиссариатының Кече коллегиясе әгъзасы, Федераль җир комитеты рәисе, кыскасы, Совет хөкүмәтенең җаваплы хезмәткәре була. Төньяк Кавказ республикаларын төзү комиссияләренең дә башында ул тора. Солтангалиев СССРдагы барлык республикаларның да тигез хокуклы булуын алга сөрә. Фикерен исбатлап партия съездларында чыгышлар ясый.

Бу вакыт инде Ленин хәлсезләнгән, үлем түшәгендә ята, Сталин исә, киресенчә, тулы көчкә кереп килә. Ул, Ленин сүзләре белән әйткәндә, үз кулына иксез-чиксез власть туплаган була. Аның өчен берәү дә авторитет түгел. Ул хәтта Ленинның үзен дә, аның «К вопросу о национальностях или об автономизации» исемле хатындагы Солтангалиев фикерләренә авазадаш булган тәкъдимнәрен дә РКП(б)ның XII съезды делегатлары алдында мыскыллап тәнкыйтьли. Әлбәттә инде, Солтангалиевнең тәкъдимен катгый рәвештә кире кага. Аның җене котыра. Алай гына да түгел, шушы гаделлек сакчысы вазифаларын башкаручы шәхесне эзәрлекләү юлына баса һәм үзенең иң беренче сәяси корбанына әверелдерә.

Республиканың хокуклары елдан ел кими. Ә 1936 елгы СССР, 1937 елдагы РСФСР һәм Татарстан Конституцияләре нигезендә моңа кадәр автоном хокукта дип саналган наркоматлар турыдан туры РСФСР наркоматларына буйсындырылалар. Шуның белән, хөрмәтле укучылар, автономия бөтенләе белән бетә. Автономия исеме республиканың икенче сортлылыгын яшерү өчен тегелгән тишек юрган рәвешендә генә кала.

Бу урынга житкәч кайбер укучылар, шушы рәвештәге республика кирәк булдымы икән, дигән сорау куярлар. Һәм хаклы да булырлар. Чыннан да, төзелгән елларында ук республиканы фикция дип атаучылар, аны авырдан-авыр продразверстка бәрабәренә генә оештырылды диючеләр була. Ләкин ничек кенә булмасын, автономиябезнең тарихи әһәмияте бик зур. Чөнки бу инде күптән югалган дәүләтчелегебезне кайтаруның юл башы. Яңа дәүләтчелегебезнең яралгысы. Әгәр дә шул вакытларда ук республика төзелмәсә, бүгенге шартларда аны суверен дәүләткә әверелдерү мөмкин булмас иде.

## 5. Татарстан суверенлык юлына чыга

Үткән гасырның 80нче еллары уртасында илдә үзгәртеп кору башлангач, республикалар дәррәү рәвештә хокукларын киңәйтү мәсьәләсен күтәреп чыгалар. Алар чын суверенлык даулыйлар. Ә Балтыйк буе республикалары, алар артыннан Украина һәм Грузия дә, СССРдан чыгу мәсьәләсен кабыргасы белән куялар. Менә шушы вәзгыять яңа союз договоры төзү ихтыяҗын тудыра. Чөнки СССРның киләчәге кыл өстендә кала. Дөресрәге, исән калу мөмкинлеге инде юк дәрәҗәсендә була. СССРны саклау хакындагы референдумда Татарстан аның исән калуын яклап чыкты.

Республика шушы дулкында үз статусын союздаш республикаларныкы белән тигезләштереп, яңа шартнамә нигезендә барлыкка килергә тиешле Союзга тулы хокуклы мәмләкәт буларак керүне дәгъвалый башлады. Алай гына да түгел, хәттә бәйсез дәүләт булдыру таләбе дә ныклап яңгырады. Моны Марат Мөлеков житәкләгән Татар Иҗтимагый үзәге күтәреп чыга. КПССның Татарстан өлкә комитеты суверенлык идеясен хупламый. Республиканың Югары Советы президиумы суверенлык Декларациясенең проектын төзү өчен махсус комиссия булдыра. Һәм тиз арада Декларациянең рәсми проекты барлыкка килә. Республика газеталарында моннан тыш Декларациянең тагын берничә варианты басылып чыга. Республикабызның статусы хакындагы бәхәсләр нәкъ менә матбугат битләрендә башланып, Югары Совет залына да бәреп керә. Шул мәсьәләгә багышланган сессия 1990 елның 27 августында башланып, зур киеренкелек һәм кайнар бәхәсләр белән 3 көн дәвам итә.

Бу көннәрне Югары Совет кына түгел, Казан һәм башка шәһәрләр дә гөрли. Мәйданнар тулы халык. Югары Совет бинасы каршындагы Ирек мәйданында казанлылар белән бергә төрле җирләрдән килгән меңләгән кеше гөж килә. Транспарантлар күтәргән яшьләрнең «Азатлык, азатлык!» дигән ораны бөтен көчкә яңгырап тора. Ерак-ерактагы, хәтта АКШта яшәүче татарлар да төн йокыларын калдырып Казаннан хәбәр көтәләр, хат-телеграммалар яудырып мәйдандагыларга һәм сессияләр залындагы милләтпәрвәрләргә көч-куәт, дәрт һәм дәрман өстәп торалар. Бу көннәрне Югары Совет исеменә 685 документ ирешә, шуларның 612се—илнең 137 төбәгеннән килгән, бәйсезлек игълан итүне таләп иткән хатлар, мөрәҗәгатьләр.

1990 елның 30 августы. Югары Советта бәхәсләр дәвам итә. Мәйдандагы халык түземсезлек белән уңай нәтиҗә көтә. Шул ук вакытта күрше бүлмәдә 30 кешедән торган килештерү комиссиясе яңгыраган төрле фикерләрне, тәкъдимнәрне тәңгәлләштерү эше белән мәшгуль. Монда да бәхәсләр тынмый. Ниһаять, «Народовластие» төркеме вәкилләре республикада бер татар телен генә түгел, рус телен дә дәүләт теле дип игълан итү бәрабәренә Татарстанны Россия составында күрсәтмәүгә ризалашалар.. Шулай итеп, килешү барлыкка килә.

Һәм кичке сәгать 10 белән 11 арасында килештерү комиссиясе әзерләгән Декларация депутатларга тәкъдим ителә. Аны иң абруйлы депутларның берсе Фәндәс Сафиуллин укый. Кайбер төзәтмәләр кертелгәннән соң проект тавышка куела һәм кабул ителә. Шушы тарихи әһәмияткә ия документ, хөрмәтле укучыларым, халкыбызның һәм җитәкчелегебезнең бер тән һәм бер җан булып хәрәкәт итү нәтиҗәсе.

Менә шушы тарихи вакыйгадән соң нәкъ бер ел үткәч, Б. Н. Ельцин һәм М. Ш. Шәймиев ике ара мөнәсәбәтләрне билгеләү өчен делегацияләр төзиләр. РСФСР делегациясенең башлыгы—Дәүләт секретаре Г. Э. Бурбулис, безнең делегациянең җитәкчесе вице-президент В. Н. Лихачев, аның урынбасары—шушы юлларның авторы иде.

1991 елның 12 августында Россиянең Ак йортында делегацияләр очрашып, сөйләшүләрне башлап җибәрделәр. Әлбәттә, монда да зур бәхәсләр булды. Тик алар тыныч, бер-береңне аңларга тырышу рәвешендә барды. Монда эчендәгене тышка чыгарырга ярамый. Дипломатия уены бит бу! Эчеңдә утлар янса да, йөзеңдә кояш балкырга тиеш.



*Азатлык мәйданы азатлык даулый. 1991 ел.*

Сөйләшүләрнең асылы түбәндәге бер сорау тирәсендә булды: Татарстан Россиядән китәме? Җавап: юк, уланың белән шартнамәле махсус мөнәсәбәттә яшәячәк. Һәм инде яңартылган Союз договорын Россия делегациясе составында түгел, мөстәкыйль рәвештә имзаларга тиеш.

Россия делегациясен шушы җавапка күндерү өчен тарихны иңләп-буйлап чыгып, татарларның тарихи хәтерләрендә дәүләтчелек фикеренең беркайчан сүнмәгәнлеген исбатларга туры килде. Шул ук вакытта кайбер юридик документлардан да өзекләр китерелде. Гомумән, безнең делегация сөйләшүләргә, Россия делегациясеннән аермалы буларак, ныклы әзерлек белән килгәнлеген исбатлый алды. Моны безнең оппонентларыбыз да таныды.

Сөйләшүләр 15 август көнне уртак беркетмә кабул итү белән тәмамланды. 19 август көнне ике Президент очрашып, сөйләшүләр нәтиҗәсенә нокта куярга тиеш иделәр.

Ләкин! Әйе, мин бу сүзне ачынып әйтәм. Чөнки бу очрашу булмый калды. Кызганычка каршы, безгә яңартылган Союз договорын тигез хокуклы республика рәвешендә имзалау өчен өч көн җитми калды.

19 августта яңартылган Союз договорын имзалау процессы башланырга тиеш иде. Тик менә делегация Мәскәүдән кайтып өч көн үтү белән үк ГКЧП фетнәсе купты. Аны СССР Президенты М.С. Горбачевның иң якын яраннары башлады. Горбачев исә, ил белән идарә итү дилбегәсен куллары калтырап торган Янаевларга тапшырып, Кырымга, Форостагы дачасына ялга китеп барды. Гекачепистлар җиңелеп, кулга алынганнан соң Горбачевның базары төште. Ул хәлсезләнгән, көчсез, мескен бер бәндәне хәтерләтә иде.. Аның болай да бик ныклы булмаган сәяси ихтыяры бөтенләй юкка чыккан. Шуннан файдаланып Россия, Украина,

Белоруссия җитәкчеләре Ельцин, Кучма һәм Шушкевич Беловежск урманына җыелып, СССРны таркату турында карар кабул итәләр.

Менә нинди аянычлы өч көн турында сүз бара, туганнар.

ГКЧП фетнәсе сәясәтне тагын да катлауландырды. Бу көннәрдә бәйсезлегебез дошманнары тагын да канатлана төштеләр. Мәскәү җитәкчелеге Минтимер Шәймиевне, КПССның республика комитетының беренче секретаре Рево Идиятулинны, Югары Совет рәисе Фәрит Мөхәммәтшинне ГКЧПны яклауда гаепләп, суверенлык Декларациябезне юкка чыгарырга маташтылар. Шушы вакыйгаларны тикшерергә җыелган Югары Совет сессиясенә Ельцинның киңәшчесе Сергей Шахрай килде. Аның кесәсендә Россия президентының Шәймиевне урыныннан алу турындагы карары да булган диләр.

Ләкин Шахрайны үз президентын якларга җыелган, шаулап-гөрләп торган мәйдан каршы алды. Халык үз президентына кул тидертмәде. Аның иминлегенә гарант булды. Һәм Татарстан үзе сайлаган юлдан тайпылмады. Аның җитәкчелеге артка чигенмәде. Халкыбыз бу көннәрдә дә бер җан, бер тән булып хәрәкәт итте.

Менә шушы шартларда халкыбызның республикабызның суверенлык статусына «әйе» дигән ныклы фикере кирәк булды. Референдум сәяси ихтыяҗга әверелде. Һәм аны үткәрү көне итеп 1992 елның 21 мартты билгеләнде.

Референдумга каршы эшкә Россия президенты Б. Н. Ельцин турыдан-туры үзе катнашты. Ул телевидение аша сайлаучыларга мөрәҗәгать белән чыкты. Рус сайлаучыларын ул, әгәр дә сез референдум соравына «әйе» дип җавап бирәсез икән, иртәгесен икенче сортлы гражданнар булып уяначаксыз, дип куркытты. Ельциннан соң Татарстан халкына Шәймиев мөрәҗәгать итте. Ул телевизор карачыларга Татарстан позициясенең асылын һәм референдумның максатын аңлатты. Аларны референдумда актив катнашырга һәм аның соравына уңай җавап бирергә чакырды. Бу, һичшиксез, аның тарафыннан ясалган батыр адым иде. Чөнки картага Президентның үз язмышы куелган иде. Референдум алдыннан Мари республикасының Татарстанга терәлеп торган Волжск шәһәренә Хасбулатов килә. Референдум тискәре нәтиҗә бирсә, ул Шәймиевне кулга алып Мәскәүгә алып китәргә тиеш була. Һәрхәлдә, безгә шундый сүз килеп ирешге.

Референдумның нәтиҗәләре һәркемгә мәгълүм: сайлаучыларның 61,4 проценты Татарстанның суверенлыгын яклап чыкты. Бу тарихи җиңү иде. Чөнки Россия Конституция судының рәисе В. Д. Зорькин референдум алдыннан, РСФСР Югары Советы утырышында: Әгәр дә референдум соравына «әйе» дигән җавап алынса, бу бәйсезлек игълан итү өчен юридик нигез булачак. Моны һәрбер юрист шулай дип санар, һәм хаклы да булыр, дигән иде.

Бәлки, соңрак ул бу сүзләрнне әйтүенә үкенгәндер дә. Тик бит менә, халык әйтмешли, «әйткән сүз—аткан ук». Аны кире кайтарып алып булмый.

Референдум алды көннәрендә дә халкыбыз үз фикерен әйтә алды. Россия конституция суды референдумны законсыз дип тапса да, Россия генераль прокуроры Татарстан прокурорларына барлык сайлау участокларын ябарга кушкан булса да, РСФСР Югары Советы рәисе Руслан Хасбулатов Шәймиевне Мәскәүгә тимер читлектә алып китү белән янаса да, халкыбыз мәйданнарда, йөзләгән телеграмма һәм хатларында Минтимерне тимер булырга өндәп, җитәкчеләребезгә көч һәм куәт биреп торды.

Сайлаучыларның күпчелегенең фикерен Россия президентының телевидение аша референдумга каршы мөрәҗәгать итүе дә үзгәртә алмады. Аның каравы Шәймиевнең Ельциннан соң Татарстан халкына мөрәҗәгате аларның күңелләренә хуш килде. Татарлар курыкмады. Алар Татарстан җитәкчеләренә көч-куәт, дәрт һәм дәрман өстәп тордылар.

Референдум татар халкының дәүләти халык икәнлеген тагын бер кат раслады. Декларациябез аның фикере белән ныгытылды.

1994 елның 6 ноябре көнне республикабызның яңа Конституциясе кабул ителде. Шуның нәтиҗәсендә Татарстан юридик рәвештә суверен дәүләткә әверелде. Бу иң зур җиңүләребезнең берсе булды.

## 6. Татарстан шартнамәле республикага әверелә

Инде язганымча, Россия белән шартнамәле мөнәсәбәтләр булдыру турындагы сөйләшүләр ГКЧП фетнәсе алдыннан ук башланган иде. Тик аларның дәвамына әнә шул сәяси өермәләр тоткарлык ясады. Ләкин сөйләшүләр дәвам итте һәм

нәтиҗәдә 1994 елның 15 февралендә Россия белән Татарстан арасында ике яклы дәүләтара Шартнамә барлыкка килде. Ул 1552 елдан соң төзелгән беренче Шартнамә булды.

Аның тагын бер зур әһәмияте бар. Республикабызга ияреп, Россиянең 40тан артык төбәге Үзәк белән төрле рәвештәге шартнамәләр төзи алдылар. Шуның белән без республикабыз Россияне унитар рельслардан федератив рельсларга күчерә алды дип әйтә алабыз.

Ә республикабыз үзе, хөрмәтле укучыларым, шушы шартнамәдәге вәкаләтләргә таянып, социаль-икътисади үсешнең иң алгы сафларына чыкты, алга киткән авыл хуҗалыгы, зур тизлек белән үсә торган промышленностька ия булды. Республика тулысы белән газлаштырылды. Шәһәрләрдә һәм авылларда зур төзелеш эшләре бара. Тузган торак программасын үтәү нәтиҗәсендә меңләгән гаилә яңа фатирларга күчте. Республикада дистәләгән спорт һәм культура объектлары үсеп чыкты, Кама аша күпер салынды. Башкалабызда метро барлыкка килде. Якын киләчәктә нефть эшкәртү нык артыр. Шушы елларда барлыкка киләчәк заводлар 14 миллион тонна чимал эшкәртә алачаклар. Республика нефть белән генә түгел, күбесенчә аның продуктлары белән сәүдә итәчәк. Бу исә табышның бермә-бер артуына ишарә. Чаллыда ФИАТ белән Камаз 2016 елдан башлап елына 500 мең машина җитештерүче яңа бер автомобиль заводы төзеләчәк...



*Шартнамәгә кул кую вакыты.*

2007 елның июнь-июлендә төзелгән яңа Шартнамә республикабызга, элеккесенә караганда шактый чигенүләр булса да, башка өлкәләр-республикаларга караганда кайбер өстенлекләр бирә, ягъни Татарстанны махсус статуслы бердәнбер республика итә. Аның махсус маддәсендә Татарстан үзеннән читтә яшәгән татарларга да тиешле ярдәм итәргә хаклы икәнлеге язылган. Моны без милләтебезне туплау коралына әверелдерергә тиешбез...

Илебез карабының капитаны Минтимер Шәймиев постыннан китте. Бу шәхес һәрвакыт халкыбызның иминлек сагында булды. Аның кинәт кенә шушы нияткә килүенә ниләр сәбәп икән, дигән сорау туа. Күрәсең, моңа бер төрле генә җавап юктыр. Шулай да, Мәскәү ягына күз салырга туры килә. Чөнки Шәймиев, Кремль яки Ак йорттагыларга охшаса-охшамаса да, үз фикерен әйтә торган кеше. Мәскәүгә исә күндәмнәр кирәк. Мәсәлән, Шәймиев чит ил журналистлары алдында Федерация субъектларының башлыкларын сайлау принцибын юкка чыгаруны законсыз дип белдерде. Бу исә метрополиядәге күпләрнең һич кенә дә күңеленә хуш килмәде. Моны «Эхо Москвы» радиостанциясе аша (2008 елның 25 июне, кичке сәгать 7 дән соң) язучы Александр Проханов Мәскәү Кремленә пирчәткә ташлау дип бәяләде. Ул Шәймивне генә түгел, Мортаза Рәхимовны да, Эдуард Россельне дә шушы гамәлдәгеләр рәтенә кертеп, сепаратистлар дип бәяләде һәм аларны урыннарыннан җибәрүне таләп итте.

Бу исемлек кайда һәм кемнәр тарафыннан төзелде һәм аны кемнәр төзеде икән, дигән сорау туа? Әгәр дә, нәкъ менә Проханов билгеләгән рәвештә берсе артыннан берсе Россель һәм Шәймиев китмәгән булсалар, бу сорау, бәлки, тумас та иде. Чират, бәлки, Мортаза Рәхимовка җиткәндер?

Республикабызның руле бүген Рөстәм Миннеханнов кулында. Ул моңарчы да күп җаваплы урыннарда эшләп, үзен тәҗрибәле һәм зирәк акыллы шәхес итеп танытты. Аңарга көч-куәт, дәрт вә дәрман биреп торыйк, туганнар!



*Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулган көндә төшерелгән фото. Игътибар белән карaганда бу рәсемдә дистәләгән мәшһүр шәхесләрне танып була. Кырлай авылындагы Тукай музее эргәсендә. 1986 ел.*




*Габдулла Тукайның 100 еллык юбилее Мәскәүнең Колонналар Залында үтте. Трибунада—галим Мансур Хәсәнов. 1986 ел.*



*Кыргыз һәм татар халыкларының бөек улы Чыңгыз Айтматов Казанда еш була иде. 2001 ел.*



*Шагыйрь, прозаик, драматург Әхмәт Фәйзи. Үткән гасырның 30нчы еллары.*

Әхәт
Мушинский

# «СҮЗДӘН ОЛЫ БЕРНИ ЮК!»

*Бөек Шекспирның әлеге сүзләре Австриянең Линц шәһәрендә узган—Халыкара ПЕН клубы оештырган—75 нче Бөтендөнья язучылары конгрессының девизы булды. Әлеге конгресста ПЕН клубының яңа президенты итеп Джон Рэлстон Сэйул сайланды. Форумның пленар (гомуми) утырышында халыкара әдәбиятчылар берлеген Татар ПЕН үзәгенең яңа президенты—язучы Разил Вәлиев белән таныштырдылар. Халыкара ПЕН клубына яңа әгъзалар—Албан һәм Монгол ПЕН үзәкләре кабул ителде. ПЕН клубы китапханәсенә татар авторларның инглиз телендәге китаплары тапшырылды.*

**Вена**

ЮНЕСКО тарафыннан 2009 елда Европа мәдәни башкаласы дип игълан ителгән Австриянең Линц шәһәрендә узган елның октябрь ахырында Бөтендөнья язучылары конгрессына 107 илдән зыялылары җыелган иде. Татарстаннан Линцка язучылар Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев һәм мин фәкыйрегез барды. Мәскәүдә безгә Татар ПЕН үзәгенең башкаладагы юридик киңәшчесе Борис Пантелеев кушылды. Рус ПЕН үзәге конгресска Андрей Битов белән Екатерина Турчаниновàны җибәрде.

Алар белән без элекке көчле империя башкаласы Венага бару хәстәренең «рәхәтлекләрен», ягъни визаларны рәсмиләштерүдә дөньядагы иң талымчан илчелек бимазаларын кичердек. Австриягә карата тискәре мөнәсәбәт туа язды. Тик ул Мәскәүдә генә шулай булды. Юлга чыккач, әлеге тойгылар таралды. Без Австрия Республикасына поездда бардык, Битов белән Турчанинова самолетта очтылар.

Бөтендөнья язучылары форумнары уза торган башкалаларда милләттәшләребезнең каршы алуына без инде күнегә башладык. Хельсинкида, Берлинда шулай булган иде... Венада да шулай ук булды. Иртән иртүк башкала вокзалында безне Австриядәге татар җәмгыяте җитәкчесе Рива Рюдиссер көтеп тора иде. Ул биредә күптән түгел генә яши әле, һәм, шәһәргә тамаша кылып йөргәндә, аңа еш кына кешеләрдән сораштырырга туры килде. Вена кешеләренең ихтирамлылыгы, теге яки бу тарихи урынга ничек барырга нечкәләп аңлатуы Мәскәүдән Көнчыгышка таба ераклаша барган саен, халык игелеклерәк,

дип инанган кагыйдәләрдән шикләнергә мәҗбүр итә башлады: Мәскәүдән көнбатышка ерагая барган саен да халык игелеклерәк икән бит.



*Разил Вәлиев, Борис Пантелеев, Туфан Миңнуллин, Әхәт Мушинский Австрия парламенты каршында.*

Вена күп, мәгърур скульптура, архитектура, мәдәни-тарихи һәйкәлләренең байлыгы белән таң калдыра. Европаның элекке эре империя башкаласы, сугышларга, күп санлы гео-сәяси үзгәрешләргә карамастан, үз йөзен саклап калган. Күккә ашкан бихисап соборлы һәм сарайлы борынгы шәһәрне үзәгендә саклап, Вена, божраларын күбәйтә барган агач кебек тармакланып үскән. Иркен мәйданнар һәм киң урамнар белән беррәттән, үзәктә упкындай тар урамнар да шактый. Тик алтын белән бизәлгән ак мәрмәр—меңьяшәр шәһәргә җиңеллек, якты, кояшлы төсмер бирә. Хәер, без Үзәк Европада чакта, атна буе күк аяз булды. Бер көннән гайре... Анысы турында—соңрак.

Венада без ике көнгә якын тордык—барып төшкән һәм китәсе көнне—поездларның расписаниесе безнең файдага булды. Беренче көнне Милли китапханәдә һәм Австрия Парламенты бинасында булдык. Европадагы иң борынгы китапханәләрнең берсе булган бу бина зиннәтлелеге һәм мәгърурлыгы белән таң калдыра. Каһарманнар мәйданы һәм Йозефс-плацта («Йозеф мәйданы») Австриянең бөек улларының атка атланган рәвештәге сыннары китапханәнең ике ягына тезелгән, ишеге алдында алтын бөркетләр һәм бюстлар куелган, бинаның алгы ягында күз колачлый алмастай колонналар рәте. Зиннәтле матур залга килеп керәсең. Ул Борынгы Дөньяның иң зур китапханә залы буларак танылган, анда ике миллионнан артык уникаль басма, кульязмалар җыентыгы, нота китаплары, географик карталар, глобуслар саклана—болар барысы да Китап Галиҗанәпләренә, әдәбиятка, белемгә никадәр зур ихтирам булу турында сөйли. Шушы зур мәйданы, сыннары, зиннәтле заллары, музейлары (сугыш һәм музыка кораллары) булган китапханә биналары тезмәсен дәүләт ирләре алдан планлаштырып төзегәннәр.



*Туфан Миңнуллин Австриянең татар җәмәгатьчелеге оешмасы җитәкчесе Рива ханым Рюдиссер белән.*

Австрия Республикасы Парламенты Рингштрассе («түгәрәк урам») божрасында университет, музейлар, театрлар белән беррәттән урнашкан... Аның яңа грек стилендә төзелгән (Борынгы Греция—демократиянең анасы бит) бинасы турында сөйләгәндә, шул ук мәһабәт, мәгърур, гаҗәеп дигән эпитетлардан башканы сайлап та булмый. Бары тик шуны өсти алам: Үзәк Европаның бүтән башкалаларындагы кебек үк Вена Парламенты да ачык һәм һәркем кереп йөри алырлык булуы белән гаҗәпләндерә. Безнең күз алдында экскурсия өчен мәктәп укучыларыннан төркем җыелды. Дүшәмбе көн иде. Ак мәрмәрдән ясалган Зирәклек алиһәсе Афина Паллада Дәүләт законнар чыгару Җыенының имән ишекләреннән кереп килүче балалар чыр-чуына гаҗәпләнеп карап торды.

Без китеп барышлый да Венада йөрдек. Көн шулай ук кояшлы иде. Җәяүләп урамнар һәм бакчалар аша император резиденциясенә—Австриядә легендар булган эрцгерцогиня Мария Тереза чорындагы Версаль үрнәгендә төзелгән Шенбрунн бакча-сарай ансамбленә киттек. Император сараендагы эчке бүлмәләр һәркем өчен ел буена ачык. Биредә бүлмәләрдәге зиннәтләрне һәм уникаль сәнгать әсәрләрен карап хозурланырга һәм Моцарт, Штраус көйләрен тыңларга мөмкин. Ә парктагы киң һәм буталчык аллеяләргә түләүсез генә кереп адашырга һәм, икесенә бергә исәпләгәндә, 160 яшьлек парларның каршыга җиңел генә йөгереп килүләрен күреп, мәңгелек турында уйланырга мөмкин.

Император сараеның төп бинасында Наполеон Бонапарт яшәп алган. Шенбрунны Версаль белән чагыштырып карагандыр ул, мөгаен. Ә без әлеге сарайны, аның парк һәм бакчаларын, сыннарын һәм фонтаннарын—чагыштырмача бер үк вакытта—18 гасыр башында Версаль үрнәгендә салынган Петергоф белән чагыштырдык. Мин шунда фонтаннары, төрле биеклеккә урнаштырылган—арыслан авызын каеручы Самсоннары белән башланган—сыннары уч төбендәгедәй күз карашына сыешкан Петергоф Шенбруннан баерак һәм эчтәлеклерәк дип куйдым. Татар әдәбияты аксакалы Туфан ага килешмәде. Иксез-чиксез Шенбрунн Кама Тамагы киңлекләрендә туып үскән бу кешенең күңеленә ныграк хуш килә. Шенбрунн Самсоны белән арысланы төп бина эченә урнаштырылган һәм алар алтын түгел, тоныклар. Кабатлап әйтәм: Шенбрунн ансамбле гаять зур гигант. Ә ул бит шәһәр читендә дә түгел—үзәк вокзалдан 40 минут кына җәяү барасы. Юл уңаенда без тагын бер йөзьяшәр имәнле һәм киң колачлы каштаннар үсә торган парк аша уздык. Австриядә тере табигатьнең таш шәһәр белән «килешеп» яшәве гаҗәеп!

Австрия шәһәрләрендә салкын таш белән яшел табигатьнең берләшеп яшәвен күрсәтә торган йортлар да бар. Биналар өстеннән салынып төшкән бакчалар ул. Хундертвассер-хауз—Венадагы әнә шундый йорт. Рәссам Ф. Хундертвассер проекты белән шәһәр үзидарәсе 1985 елда төзегән аны. Гайре табигый бу күп катлы йортта 50 фатир, 13 асылма бакча, ресторан, кафе бар. Ул бакчалар, билгеле, асылынып тормый, ә йортның яссы түбәсендә, дивар чыгынтыларында, террасаларында үсә, һәм аларның ботаклары иелеп-салынып тора. Шундый ук бакчалы йортларны без Линцта да күрдек. Көн саен «Goldener Adler» («Алтын бөркет») кунакханәсеннән конгресс утырышларына җәяүләп барганда үтә торган Дунай аша салынган Нибелунглар күпере янындагы әкияти бакча төзелеше бигрәк тә күңелгә уелып калды.

## «Дизайн-конгресс»

Линцта, форум узган «Дизайн-конгресс» дип атала торган ангар сыман бинада без тагын Битов һәм Турчанинова дусларыбыз белән очраштык. Алар белән генә түгел. Татар ПЕН үзәгенең иске дусты Жан Бло белән кочаклаштык—Халыкара ПЕН клубының генераль секретаре чагында Казанга килгән иде ул. Элизабет Нордгрен (Финляндия), Владимир Сергиенко (Украина-Германия), Далмира Тиленбергенова (Кыргызстан), Канат Кабдрахманов һәм бик күпләргә җылы сәлам бирдек. Бу конгресста без күп мәртәбә чын күңелдән Уйгур ПЕН үзәге



*Ә. Мушинский, Р. Вәлиев, Т. Миңнуллин Рус ПЕН үзәге президенты А. Битов һәм Монгол ПЕН үзәге президенты Я. Мухджаргол белән.*

президенты, иленнән куылып, Швециягә сыенган Кайсар Озгун һәм Төркиядән Тарик Гунерселем белән аралаштык. Конгрессның беренче эш көнендә үк Туфан ага Миңнуллин, ике дә уйлап тормыйча, ике ел элеккеге кебек үк, башына милли кәләпүш киеп куйды. Һәм шундук, пароль көтеп алгандай, аның янына Кайсар Озгун килеп җитте һәм үз телендә сөйли башлады. Бернинди тылмач кирәкми иде. Татар һәм уйгур телләре бик якын, бу мәсьәләдә башкортлар белән генә «Кем якынрак» дигән бәхәс туарга мөмкин. Кайсар—озын буйлы яшь, чибәр кеше, берничә Европа телен бик яхшы белә, ул—алтай телләре, ягъни төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләрендә яза торган әдипләрдән «Урал-Алтай» оешмасын төзүчеләрнең берсе. Урал-Алтайлыларның беренче халыкара конференцияләре Линцка кадәр ике ай элек Истанбулда узган иде. Аның исемлегендә төрек, уйгур, татар, кыргыз, казакъ, фин ПЕН үзәкләре бар иде. Линцта әлеге берләшмә үзенең эшен дәвам иттерде. Татар ПЕН үзәге җитәкчесе Разил Вәлиев «Урал-Алтай» берләшмәсе эшчәнлегендә катнашуыбыз зур дәрәҗә дип саный. Аның икенче конференциясе Бишкәктә булыр дип билгеләнде.

Әлеге конгресста безнең делегация ПЕН клубының ел саен уздырыла торган халыкара конгрессларында русча сөйләшүче әдипләр секциясе оештыру фикерен күтәреп чыкты. Конгресста күп еллар эшләү аңа ихтыяҗны күрсәтте. Русча сөйләшү—рус телле, ягъни русча язучы дигән сүз түгел. Рус теле бу очракта—әдипләрнең совет чорыннан соң һәм элекке социалистик лагеренең аралашу теле. Утырышта катнашучылар киләчәктә дә халыкара әңгәмәләр алып барырга, рус, татар, кыргыз, казакъ, украин һәм башка телләрне саклау һәм үстерү турында сөйләшергә, сүз иреге мәсьәләләрен күтәрергә, әлифбабыз һәм телебез нинди булуга карамастан, үзебезне күрсәтергә дигән фикерне алга куйдылар. Карарда шулай ук үзләренең ПЕН үзәкләре, милли тел, мәгариф, китап бастыру кыенлыкларын белдереп торырга карар кылынды.

Быел яңа секциядә рус, татар, казакъ, кыргыз, украин, шулай ук чех һәм словак үзәкләре катнашты. Бөтендөнья конгресслары арасында эш конференцияләрдә алып барылачак. Андрей Битов конгрессның беренче пленар утырышында яңа секция һәм аның бурычлары турында киң мәгълүматлы чыгыш ясады.

Конгресста әдипләр һәм журналистларның хокукы һәм сүз иреге чикләнгән—Кытай, Куба, Вьетнам, Венесуэла, Төркия, Венгрия, Грузия, Россия кебек илләр буенча карар кабул ителде. 2000 елдан башлап Россиядә 18 журналист үтерелде. Төркиядә җиде дистәләп журналист ирегеннән мәхрүм ителде. Венгриядә—этник кыенлыклар.

ПЕН клубы китапханәсендә без үзебез алып килгән әсәрләрне күргәзмәгә куйдык. Анда инглиз телендә басылган Г.Тукайның «Шүрәле»се һәм «Татар халык әкиятләре», татар, рус, инглиз телендә басылган өчтомлы «Татар акылы» (мәкальләр, әйтемнәр, афоризмнар, әдәби миниатюралар), шулай ук Туфан Миңнуллинның өч телдә басылган «Әлдермештән Әлмәндәр»е һәм башка китаплар бар иде.

## Линц

Австриядә саны буенча өченче шәһәр саналучы Линц Дунайның ике ярына җәелеп урнашкан. Аны «Линц» дип тә, «Дунайдагы Линц» дип тә язалар, йә австриялеләрчә кыска гына: «Linz a. d. D.» Линц—тарих ул һәм башкаланың борынгы өлешеннән аз гына читтәрәк урнашкан промышленность үзәге. «Башкала» дип язуым ялгыш түгел—ЮНЕСКО тарафыннан Линц 2009 елда Европаның мәдәни башкаласы дип игълан ителгәнен әйткән идем инде. Чыннан да, Гете, Шиллер, Кант, Моцарт исемнәрен йөртә торган урамнар буйлап барганда, Борынгы Дөньяның мәдәни башкаласында йөрүеңә шикләнмисең. Борынгы, таш түшәлгән урамнарның ике ягында мәһабәт готика стилендәге соборлары күккә үрелгән, тарихи биналар, скульптура һәйкәлләре—борынгы һәйкәлләр арасында хәзерге заманда ясалганнары да очрый: мәсәлән, Музеум-штрасседагы бер сарай янында «поп-арт» стилендә металл ватыкларыннан ясалганы. Бөтен җирдә 2009 елда Европаның мәдәни башкаласы билгесе—нокталы өтер. Нәрсә аңлата ул? Бер карасаң, 09 кыяфәтендә ул, икенче караганда, Линц—Европаның мәдәни башкаласы дигән карарның катгый түгеллеген—эстафетаның дәвамчанлыгын аңлата кебек.

Бередә, Линцта, бөтен Австриядәге кебек үк, Моцарт, рәссам Гюстав Климт һәм реформатор-эрцгерцогиня Мария Терезага табыналар. Сарайларда, бүлмәләр

кибетләрендә, рәсемнәрдә, альбом тышларында, тәлинкәләрдә, кружкаларда, брелокларда—бөтен җирдә алар. Моцарт, йә Мария Терезаны аңлап була әле. Ә минә «сецессион» («модерн»ның бер төре) стилендә иҗат иткән яраткан рәссамым Г. Климтка табынуларына бик сөенеп гаҗәпләндем. Аның күренекле «Үбешү» рәсеме—адым саен. Тагын бер яраткан рәссамым—Австриянең Сальвадор Далиен—Э.Фуксны искә алган кеше юк. Гаҗәп, күршедә генә, Венада, дөньяның иң эре рәсемнәр галереяләренең берсендә, Тициан, Рафаэль, Веласкес белән рәттән Питер Брейгель рәсемнәренең иң зур җыелмасы бар. Хәзерге заман Леопольд сәнгать музеенда—Эгон Шиленың дөньядагы иң зур җыелмасы. Тик аларның берсе дә, күренекле экспрессионист О. Кокошка кебек үк, Австриянең көндәлек тормышында күренми. Ярар инде, Линцта Гюстав Климт рәсемнәрен төрле сувенир рәвешләрендә күңелем булганчы сатып алдым. А минә Туфан ага Миңнуллин Линц базарында ташкабак, тагын ниндидер орлыклар сатып алды: «Интере-есно, Татарстан җирендә алар нинди уңыш бирер икән?»



*Әхәт Мушинский Линцның үзәк урамында «Моцарт белән».*

«Интере-есно!»—Туфан Миңнуллинның яраткан сүзе. Теге яки бу тарихи һәйкәлне һәм базарда таныш булмаган яшелчәне күреп алса: «Интере-есно!»—дип, русчалалап, сүз кыстырып куя ул. Аның төкәнмәс кызыксынучанлыгы бик тә гаҗәпләндерә. Бөтен нәрсә кызык аңа, бөтен әйберне әйләнеп йөреп карый, мөмкин булса, капшап йә кабып карый. Безнең сәяхәтләрдә аның чыдамлыгына таң калдым. Хәтта элекке альпинист буларак, минем өчен дә күп булган чакрымнарны тәпиләргә туры килде бит. Бөтен сәяхәтебез буена ул татар авылы халкы, шәһәр, язучылар, театр тормышыннан төрле вакыйгалар, Мәскәүдә укыган чорында тирәсендәге кешеләр турында, көлке хәлләр һәм мәзәкләр (җае чыккан саен) сөйләде. Тормышында очраган һәм ишеткән мәзәк хәлләр турында китабын да чыгарырга җыена әле ул.

Линцта без көн саен киселгән штукатуркалы йорт янынннан үтеп йөрдек. Ул, тере тире кебек, Икенче Бөтендөнья сугышы чорында барлык мәхшәрне кичергән. Шул штукатур кисәкләре йортның беренче катындагы тәрәзә төбендә бик кадерләп саклана һәм XX гасырның акылсызлык фаҗигасен искәртүгә хезмәт итәләр.

Адольф Гитлерның бөтен балачагы Линцта үткәнлегә турында да әйтми булмый. Линц янындагы бер авылда аның әти-әнисе күмелгән. Тик австриялеләр бу хакта сөйләргә яратмыйлар, ул темага сорау бирү дә әдәпсезлек санала.

## Австриялеләр

Австриялеләр туристлардан аерылып тора. Венага караганда Линцта бигрәк тә. Аларга, аеруча олы яшьтәгеләргә, арткы өлешендә вензельле эшләпә кию хас. Австриялеләр күбрәк баварлардан килеп чыккан. Австриянең көнбатыш өлеше—Линц, Зальцбург, Бавария—элекке Бавария җирләре. Австриялеләр телләре белән немецларга тугандаш, тик алар, баварлар кебек үк, аерым милләт, үзләрен немецлар дип исәпләми. Көнчыгыш якта славяннар яшәгән, тик алар немецлар колониясе булган. Булачак Австрия җирендә бар да буталып беткән. Австрия халыкларның Бөек күчеш чорын башка илләрдән ныграк кичергән. Австрия иле 10 гасырда баварларның Көнчыгыш маркасыннан башланган һәм беренче тапкыр Австрия, ягъни Көнчыгыш өлкә дип аталган. Нинди илнең Көнчыгышы булган соң ул—Баварияның ме, Германиянекеме, Үзәк Европаныңмы?

Австрия 18 гасырда зур тизлек белән үсә башлый. Венгрия, Трансильвания,

Хорватия, Көньяк Нидерландия, Италиянең бер өлеше, Словения, Чехия, Босния, Польша аның хакимлегенә күчә. Шулай итеп, Австрия Европада Россиядән кала зурлыгы белән икенче урында була һәм күп милләтле империягә әйләнә. Ләкин, билгеле булганча, бөтен империяләр дә кайчан да булса җимерелә... Австрия державасы белән дә шулай була. 1918 елда ул республика була. 1938-1945 елларда Австрия фашистлар Германиясе хакимлегендә кала. 1945 елда, каты җимергеч сугышлардан соң, Совет Армиясе Венаны ала. Ил дүрт оккупация зонасына—Совет, Америка, Англия һәм Франция зоналарына бүленә. 1955елның 25 октябрендә оккупация гаскәрләре Австриядән чыгарыла, һәм ул бәйсез республика була.

Венадан Линцка без электричкага утырып бардык. Безнең күз алдыннан кыргый, хәтта әкияти матур урманнар, кырлар, күлләр, җил тегерменнәре, дөресрәге—җил ярдәмендә хәрәкәтләнә торган двигательләр (аларның киң канатларын компьютерлар аша җилгә каршы борып куялар)—тезелгән калкулыклар йөгереп үтә. Еракта Альп таулары өстендәге кар таулары күренә.

Кызыл чирәп түбәле уенчыксыман өйләр тезелгән авыллар безгә каршы йөгерә. Алар тирәсендәге һәр кишәрлек җир эшкәртелгән, тәртипкә салынган, сыйпап-сыпырылган. Туган җиргә шундый мөнәсәбәт ничек калыпланды икән бөтен дөнья каннары катнашмасы булган бу халык өйрәсендә?

Шәһәрдә дә шундый ук тәртип. Шулай беркөнне Линц үзәгендә фонтан янындагы утыргычка урнаштык. Австрияле килә. Билгеле инде, башында вензельле эшләпә. Фонтан бассейныннан иелеп пластик бокал алды, яныбыздан сыра киоскысы янына узды. Бомж, шушы бокалга сыра салдырмакчы, дип уйлыйм. Юк шул. Киоск янында торган чүп савыты янына менде, фонтаннан алган теге бокалны чүплеккә салды да үз юлы белән китеп барды. Безнең илдә мондый хәлне күрмәссең. Менә сиңа мә! Нигә аларда шулай да бездә болай соң ул?

## Маутхаузен

Линцтан ерак түгел шәһәрчек шулай атала. Аны аз кеше генә беләдер. Әмма аннан ерак түгел урнашкан нацистлар концлагерен бөтен кеше белә. Язмыш шаяруымы бу? Концлагерь 1938-45 елларда булган. 1948 елда ул хәтер музее итеп үзгәртелгән.

Конгресста катнашучы һәр кешенең анда экскурсиягә баруы планлаштырылган иде. Автобуслар кузгалып китәр сәгать җиткәч, кояш көзге соры болытлар артына кереп посты. Безнең 10 көнлек сәяхәтебез дәвамына бу бердәнбер яңгырлы көн булды. Күнегелгән гадәт буенча без зонтларны алмаган идек. Кем ничек булгандыр, минем өстемдәге киемнәрдә коры җеп бөртеге калмады, һәм ул экскурсия тәэсирләрен көчәйтте генә.


*Маутхаузенда Д. Карбышев һәйкәле.*

Маутхаузен хәрби әсирләр өчен, соңрак «түбән» милләтләр өчен лагерь буларак калкулык өстендә төзелгән. Тоташ стена, чәнечкеле тимер чыбык, күзәтү манаралары, бараклар, биек торбалы крематорий... Күршесендә—ташлык. Таш ваттыру өчен, лагерьны менә шушында салганнар да инде. Тоткыннар шунда иртән 6 дан караңгыга кадәр эшләгән. Иртән аларга өйрә ашатканнар, төшкә шуңа ит кисәге салынган. Кайчакта көрпә кушып ясалган сосиска, бәйрәмнәрдә мармелад бирелгән... Крематорий торбасы озак тотенләп тормаган... Тирә-юньдә яшәүче халык сасы истән зарлана башлаган. Тик аңа карап кына үлем фабрикасының эше кимемәгән. Маутхаузенда 122 мең кеше җәзалап үтерелгән. Алар арасында ммилләттәшебез, инженерлык гаскәрләре генерал-лейтенанты Дмитрий Михайлович Карбышев та булган. Ул лагерьларда дошманга каршы яшерен эш

алып барган. Маутхаузенда кышын, өстенә салкын су сиптереп, аны боз сынга әйләндерәләр.

Баракларның берсенә керәбез. Ике катлы ятаклар тезелеп киткән. Бер ябынгычлы бер ятакта ике кеше йоклаган. Торак ягып җылытылмаган. Икенче бүлектә цемент идәндә юыну өчен зур таш су мичкәсе. Коридор буйлап арырак гомуми бәдрәф. Бу бaрактан 75 совет офицеры качкан. Тревога буенча эзәрлекләп, ау мылтыклары һәм балталар белән коралланган җирле халык аларны тотып бирә. Икесе генә качып котыла. Аларны Көнчыгыш фронтта ике улы һәлак булган фрау яшереп кала.

Безнең делегация генерал Карбышев һәйкәленә чәчәкләр салды. Лагерь уртасында митинг буллы, һәм шул урынга Маутхаузен корбаннары истәлегенә Халыкара ПЕН клубы исеменнән чәчәкләр куелды. Митингта төрле илләрдән килгән төрле милләт әдипләре чыгыш ясады. Алар шушындый музейларга финанс ярдәме булдыру турында фикер әйтте. Кем төзесә, шулар төзеклеген сакларга тиеш, дип, кайбер урыннарда аларны тотудан баш тарталар. Минемчә, аларны төзегән кешеләр күптән исән түгел инде. Гыйбрәт өчен исәннәр сакларга тиеш. Хәер, баракта чакта кайберәүләр шыпырт кына—андый музейлар неофашистларга хезмәт итмәгәе дигән шөбһә белдерде.

## Прага

Конгрессның соңгы көнендә—чех каләмдәшләр чакыруы буенча—без Прагага киттек. Алар безне алырга җиңел машина җибәрде, һәм без Чехия башкаласына юл тоттык. Рульдә бик кызыклы нәшир Зденек Варжечка иде. Ул берничә ел Россиядә эшләгән, һәм без бик җиңел аңлаштык.

Гүзәл Прага безне туристлар төркемнәре һәм урамнарда урнаштырылган сыра табыннары белән каршы алды. Бер өстәл янында халыкның һәм телевидение хезмәткәрләренең игътибарын төрек җырчысы Таркан җәлеп итте. Старомест мәйданында бөркетләр (курантлар) суга иде. Өстә, шәһәр ратушасы каланчасында курантлар көенә төрле персонажларны гәүдәләндерүче курчаклар хәрәкәтләнә. Сәгать сугып бетерүгә, собор янында җәяүле рыцарьлар орышы башланды—кылычлар ялтырап китә, калканнар, тимер киемнәр чыңлый. Урта гасырга барып чыкканбызмыни—әсәрләнеп басып тордык. Әмма безне каршы алган якташыбыз—хәзер ул Прагада яши—Эдуард Трескин бүгенгегә кайтарды: кунакларны Россия фән һәм мәдәният үзәгендә зарыгып көтәләр икән.

Әлеге үзәк Праганың уңайлы, тыныч бер почмагына Россия илчелеге янәшәсенә урнашкан. Россия фән һәм мәдәният үзәге директоры—Чехия Республикасындагы Россия Федерациясе илчелеге киңәшчесе Владимир Сбирунов, Чехиядә рус телендә иҗат итүче язучылар Союзы президенты шагыйрә Галина Свинцова, һәм билгеле инде, һәркайда өлгер якташларыбыз—«Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе хезмәткәрләре—редакция директоры Рим Гыйльфан, хәбәрчеләр Алсу Кормаш, Али Гыйльми, Дилбәр Исламова, Индира Биктимерова—ишек төбендә безне ачык йөз белән каршы алдылар.

Беренче эш итеп безне үзәкнең китапханәсенә алып керделәр, һәм без дусларыбызга иң кадерле «йөгебезне»—китаплар журналлар һәм «Казанский альманах» саннарын тапшырдык.

Билгеләнгән очрашу үзәкнең иркен бер залында узды, без анда язучыларның Линцта булып үткән 75 нче бөтендөнья конгрессы турында сөйләдек, күп санлы сорауларга җаваплар бирдек. Рус телле публиканың татарлар өчен латин әлифбасының әһәмияте турындагы соравы гаҗәпләндерде. «Гарәп язуына караганда латин язуы чыннан да татар теленә кулайракмы һәм тел үзенчәлекләрен яхшырак күрсәтәме?»—дигән сорау булды ул. Залдагыларны шулай ук татарча китап бастыру һәм милли мәгариф мәсьәләләре дә кызыксындыра иде. Туфан Миңнуллин белән Разил Вәлиев аларга тәфсилле җавап бирделәр. Әлеге мәкалә авторына—Рус ПЕН үзәге Халыкара ПЕН клубыннан кайтышрак эшли, дигән дәгъване кире кагарга туры килде. Сүз дә юк, Рус ПЕН клубы генераль директоры Александр Ткаченко вафат булгач, андагы хәл яхшырмады. Әмма, 100 дән артык милләт ПЕНнарын берләштергән Халыкара ПЕН клубының хәл итәсе мәсьәләләре бик күп. Россиядә хәзер ике ПЕН үзәге бар—русларныкы

һәм татарларныкы.

Татарстанда һәм Чехиядә танылган язучы Ярослав Гашек турында аерым сөйләшү булды. Гашекның Татарстандагы тормышы турында Чехиядә яхшы беләләр. 1918-19 елларда ул Бөгелмә шәһәре һәм өязенең хәрби коменданты ярдәмчесе булган. Хәзерге көндә анда бөтен дөньяга билгеле әлеге язучының музее бар. Күбрәк юмор жанрында иҗат иүче Сергей Левицкий «Елгыр солдат Швейкның дөнья сугышындагы маҗаралары»н ун тапкыр укыганын әйткән иде. Мин—бер мәртәбә укыдым, аннары аерым бүлекләрен, бигрәк тә «елгыр алдакчы», Швейк җибәрелгән Австрия-Венгрия армиясе госпитальләрендәге алдакчылар белән көрәш чаралары турындагы бүлекләрен кат-кат укыдым, дидем. Ә минем абыем, нәкъ менә Левицкий кебек, «Швейк»ны ун мәртәбәдән ким укымагандыр. Шушы китапны иң нык яратучы күбәүләрне беләм мин.

Прагадагы Россия үзәгендә «Казанский альманах» һәм «Прага графоманы» редколлегияләре очрашуы булды диярга кирәк. Туфан Миңнуллин белән Разил Вәлиев—«Казанский альманах»ның редколлегия әгъзалары. Борис Пантелеев басманың юридик ягын саклый, ә Татарстанның халык артисты, хәзер Прага Операсы солисты Эдуард Трескин берьлы ике редколлегиянең дә әгъзасы. Ике басма да, күп милләтле хәзерге заман әдәбиятын рус телендә тәкъдир итә. Мәсәлән, Разил Вәлиев очрашуда рус һәм татар телләрендә шигырьләр укыды... Баш мөхәррирләр Сергей Левицкий белән мин фәкыйрегезнең сәхифәләрнең мәкаләләр алмашып, Чехиядә һәм Татарстанда бергәләп әдәби чаралар уздыру рәвешендә хезмәттәшлеге турындагы меморандумга кул куюы ике басманың сөйләшүләре нәтиҗәсе булды. Шулай ук басмаларыбызның мөхтәрәм язучы Ярослав Гашек истәлегенә игътибар итәчәге дә билгеләп үтелде.

Очрашу якындагы ресторанннарның берсендә кичке табында төгәлләнде. Анда Европада берничә тапкыр кабатланганча, «татарча ит» тәкъдим иттеләр. Тозланган яшелчәләр белән бирелә торган чи ит фаршы ул. Татарларда мондый ризык юк, дип көлдек без һәм чех халык ашларыннан берәр ризык бирүләрен үтендек. Миңа кыздырылган үрдәк итен бәрәңге һәм яшелчәләр белән китерделәр. Тәмле дә соң!

Ул вакытта безне «Radio Liberty» татар-башкорт редакциясендә көтәләр иде инде.

## «Азатлык» радиосы


Бу Прага үзәгендә күптән түгел генә төзелгән мәһабәт бина. Аңа кадәр Чехия башкаласы үзәгендәге иске бер бинада урын биләп торган. Ә элегрәк—күпләр хәтерли—«Азатлык» радиосы Мюнхенда урнашкан иде.

Радиога керү өчен, без ике тикшерү пунктын уздык—ишегалдына һәм бинага керү өчен. Ишегалдына кергәндәге рөхсәт кәгазен, бинага кергәндә, яңасына алмаштыралар. Катгый, берни дә әйтеп булмый!

Монысы ни тагын? Үтә күренмәле пыяла кырмыска күчен күзаллап карагыз. Әбрәкәе генә үтә күренмәскә мөмкин. Калган бар җире дә үтә күренә. Бөтен җирдә тавышны баса торган келәм юллар салынган. Коридорларда кайчандыр радиода кунак булып киткән Джон Кеннеди, Мартин Лютер Кинг, Ангела Меркель һәм башкаларның портретлары. Барысын да санап бетерерлек түгел, фоторәсемнәр галереясе коридорлар буйлап үсә бара. Прагадагы Россия үзәгендә каршы алган яңа танышларыбыз—татар-башкорт редакциясе хезмәткәрләре безне озатып йөри. Кызу әңгәмә алып барабыз. Алар татар, рус һәм башка Европа телләрендә сөйләшә. Татарстан төбәкләрендә туып үскән яшь-яшь, чибәр кызлар, егетләр, күбесе Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Туган илне сагынмыйсызмы соң, дип сорыйбыз. Сагынабыз, диләр, тик эшләргә кирәк бит. Туган якларга еш кайтасызмы, дигән сорауга, авыр сулап, елга бер мәртәбә, дигән җавап алдык.

Вакыт инде соң булуга карамастан, кайбер студияләр әле эшли. Төрле редакцияләрнең хәбәрчеләре, кызыксынып, безгә карый, безнең нинди телдә сөйләшүебезне ишетергә теләгәндәй, колакчыннарын күчереп куялар. Күрәсең, бу пыяла бинада экскурсияләр алай еш булмыйдыр.

Безгә дә эшләргә вакыт җитте. Рим Гыйльфан Туфан Миңнуллин белән Разил Вәлиевне һәр яктан үтә күренмәле тавыш яздыру студиясенә чакыра. Төгәл-



*«Азатлык» радиосы бинасының эчке яктан күренеше.*

рәк итеп бу бүлмәне мин радио техникасы тутырылган «радиоаквариум» дип атар идем.

—Тынлык! Микрофон кабынган!..

Студиядәге почмаклы өстәл тирәсендә «түгәрәк өстәл» гөрләп китте. Татар-башкорт редакциясе директорының Татарстандагы иҗтимагый-сәяси хәлне яхшы аңлавы сизелеп тора. Әмма республикадагы әдәбият, мәдәният тормышында үзенчәлекләр бар, мәгариф һәм фән мәсьәләсе дә катлаулы... Студия кунаклары сорауларга сабыр гына, тәфсилле җаваплар бирә, Туган җирдән еракта гына түгел, Туган Йортта да аңлашылып җитмәгән хәлләргә ачыклык кертәләр. Бәлки, чыннан да, еракта яхшырак күренә торгандыр.

Саубуллашканда, Туфан ага Рим Гыйльфанга үзенең кәләпүшен бүләк итте. Рим үзенең шүрлеге янына йөгерде. Аннан бейсболка алып, аксакалга тоттырды.

Урамда инде караңгы. Прага өстендәге күктә көзге йолдызлар ап-ачык булып ялтырый. Безне җилдереп кенә Линцка илтеп куяр өчен, Зденек Варжечканың уңайлы «каретасы» көтеп тора иде.

*Казан—Вена—Линц—Прага—Казан*
*Октябрь, 2009*

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

Ленар
Шәех

# ШИГЪРИ ТРАГЕДИЯ ОСТАСЫ

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илдар Юзеевнын шигърияте автор үзе исән чагында ук югары дәрәҗәдә бәяләнде. Драматургиясенең иң яхшы үрнәкләре Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры һәм Яр Чаллы халык театры, Башкортстанның Мәҗит Гафури исемендәге драма академия театры һәм Туймазы татар театры сәхнәләрендә зур уныш белән барды. Ә менә шигъри трагедияләре бүгенге көнгә кадәр артык игътибарга алынмады, матбугатта һәм аерым җыентыкларда дөнья күргән кыскача күзәтүләрне санамаганда, алар тулысы белән тәфсилләп өйрәнелмәде, жанр үзенчәлекләре ягыннан тикшерелмәде.

Трагедия—борынгы жанр. Ул үзенең асылы белән үк шигъри калыпта булган. В.Е. Хализев үзенең «Теория литературы» дәреслегендә (Мәскәү, 2004): *«XIX гасырга кадәр трагедия—ул нигездә югары поэтик жанр. Безгә якын дәверләрдә (аеруча XX гасырда) трагедия сизелерлек дәрәҗәдә кысрыклана һәм трагизмның хикәяләү-проза формасына кучүенә юл куя. Кагыйдә буларак, бу вакытта трагик геройның үзенчәлек ореалы юкка чыга һәм ул, күп очракта әлеге сүзнең югары мәгънәсендә, гади кеше буларак кабул ителә башлый...»*,—дип яза. Әмма Илдар Юзеев трагедия жанрының күптән түгел барлыкка килгән чәчмә формасын кабул итми, ә борынгыдан килгән шигъри калыпны сайлый. Нәтиҗәдә «Соңгы төн» (1968—1972), «Очты дөнья читлегеннән» (1980—1991), «Мәңгелек белән очрашу» (1982), «Бәгырь» (1995—2001) кебек көчле лирик, төпле мәгънәле, тирән фәлсәфи, татар әдәбиятының йөзек кашы булырдай, дөнья әдәбияты дәрәҗәсендәге үлемсез әсәрләр туа. Аларның нигезендә, трагедиянең төп үзенчәлекләреннән саналган көчле трагик конфликт ята.

### «Соңгы төн»

Бу шигъри трагедиянең өч исеме бар: «Соңгы сынау», «Гомернең алты сәгате», «Соңгы төн». Автор аны язгач тиз арада беренче атамасы белән китап итеп бастырып чыгарган. Аннары, берничә ел дәвамында үзгәрешләр кертеп, аны тагын да камилләштергән. Бер дә гаҗәп күренеш түгел, чөнки әлеге әсәр—авторның бу жанрда иҗат иткән иң беренче «карлыгачы». *«Камиллекнең, фәлсәфәнең чиге юк. «Соңгы сынау»ны укыганда, укучы буларак, миндә поэманы* (И.Юзеев аны башта «драматик легенда» дип атый.—Л.Ш.) *тагын да яхшырак итеп күрәсе килү теләге дә тумады түгел»*,—дип яза Равил Фәйзуллин Илдар Юзеевнын 1969 елны аерым китап булып дөнья күргән «Соңгы сынау» әсәре турында *(Фәйзуллин Р. Сайланма әсәрләр. 5 т. Казан, 2001)*. Трагедияне камилләштерүгә олы этәргеч булып, узган гасырның икенче яртысында зур үсешкә ирешкән татар әдәби тәнкыйте торгандыр, минемчә. Нәтиҗәдә «Соңгы төн» исемле ахыргы вариант килеп чыккан. Ул инде

драматик легенда гына түгел, ә көчле янгырашлы трагедия-легенда.

Әсәр татар халкының күренекле шагыйре, батыр йөрәкле улы Муса Җәлилгә, аның гомеренең соңгы мизгелләренә багышлана. М.Җәлилнен үлем җәзасы алдыннан Гетенең «Фауст»ын кабат укыганлыгы әсәргә эпиграф итеп бирелә. Вакыйга XX гасырның 40 нчы елларында төнге сәгать уникедән иртәнге алтыга кадәр дәвам итә.

Шагыйрь сәгать фонындагы зинданда утыра. Сәгать телләре аның гомерен саный.

*Шагыйрь*
*Җирдә—сугыш. Бөтен җиһан тетри-күкри,*
*Дәһшәт, үлем—без барасы юл өстендә.*
*Узды Тиран шомга салып... Шулай укмы*
*Кешелекнең киләчәге кыл өстендә?*
*Корал белән көчле идем—аердылар,*
*Куллар белән көчле идем—каердылар.*
*Күкрәгемдә, пычракларда тапталса да,*
*Тапталмаган бары җырым-җаным калды,*
*Тип, йөрәгем, тип, йөрәгем, сана, сана:*
*Тагын ничә төнем калды, таңым калды?*

—дип уйлана, сызлана ул.

Тиран образында турыдан-туры Гитлер күз унаенда тотыла. Ул үзенең кабинетындагы глобус алдында сурәтләнә. Мәнге җинелмәс кебек тоелган күпме илләр аның алдында башын игән, ләкин ул һаман алга—көнчыгышка таба бармакчы. Төп максаты—бөтен Җир шарын үзенә буйсындыру. Ләкин, әсәрдән аңлашылганча, СССР дигән дәүләт бер дә җинелергә уйламаган, Тиранның гаскәрләре зур югалтулар кичергән.

*Тиран*
*Нинди ил бу? Нинди адәмнәр?*
*Төрмәдә дә буйсынмыйлар.*
*Әллә инде ул халыкта*
*Мин белмәгән серле көч бармы?*
*Ни булды соң миңа?*
*Әллә инде көчем кими бара?*

Димәк, Тиранның беркайчан да сыгылмас булып тоелган кыйбласы какшый башлаган. Ул сорау һәм шик астында яши. Зинданда утыручы әсирләр дә, менә-менә баш күтәрмәкче булып, фетнәнең башлыгын—Шагыйрьне алардан аергач кына тынганнар. Тиран, Төрмә хуҗасы, Баш җәллад Шагыйрьне өч төн буе газаплаганнар инде, ләкин аның рухы сынмаган, ул, ничек кенә авыр булмасын, барлык җәзаларны да күтәргән, аларга тешен кысып түзгән. Хәзер аны язмыш әзерләгән соңгы сынау көтә. Шагыйрь аны күтәрә алырмы?..

Дүртенче төнне дә Тиран Шагыйрьне үз янына китертә. Әллә нинди мәкерле юллар белән аның рухын сындырырга тырыша. Тиранның фәнни лабораторияләрендә аек акыллы әсирләрдән кол-бәндәләр әзерли башлаганнар. Шагыйрьне шуларның берсе—аның яшьтәше, дусты—белән очраштыралар, ләкин бу Бәндә туган илен оныткан, ул берни дә хәтерләми, фәкать үзенең «Бөек хуҗа»сына гына буйсына, ана мен ел гомер тели. Тиран Шагыйрьгә психологик басым ясый: дус-ишләрең минем якка күчте, әниең белән сөйгән кызың һәлак булды, туган илең юк, туган җирең минем кулда... Ләкин Шагыйрь бу сүзләргә ышанмый.

*Тиран (Аптырап.)*
*Әйе... Син—кол-әсир.*
*Язмышыңа—мин хуҗа!*

*Һәрбер минутыңа—мин хуҗа!*
*Бер хәрәкәт, бер сүзем...*

*Ш а г ы й р ь*
*Төрмәләргә, колларыңа хуҗа,*
*Ә җаныма хуҗа—мин үзем!*
*Шагыйрь беркайчан да кол булмас,*
*Кол шагыйрьдән моңлы җыр тумас.*

Бу урында Шагыйрь белән Тиран арасындагы конфликт кискен рәвештә тирәнәя һәм үткенәйтелә, алар арасындагы каршылык югары дәрәҗәгә җитә. Шагыйрьнен:

*Тираннар омтыла—тәхеткә,*
*Шагыйрьләр омтыла—бәхеткә.*
*Тиранның кулында—ак кылыч,*
*Шагыйрьнең кулында—хак кылыч.*
*Тиранның юлында—кан кала,*
*Шагыйрьнең юлында—җан кала.*
*Тиранның эзендә—җир яна,*
*Шагыйрьнең эзендә—җыр яна.*
*Тиранның кабердә—җил исәр,*
*Шагыйрьнең кабердә—гөл үсәр.*
*Шагыйрьнең сүзләре—ук булыр,*
*Тиранның эзләре—юк булыр!*

—дигән сүзләрен Тиранның горурлыгы моннан ары күтәрә алмый. Ул Шагыйрьне үлем җәзасына хөкем итә, аның башын гильотинада чабарга боера. Бу күренеш бөтен Җир шарын үз учына алырга теләгән кешенең көчсезлеген, куркаклыгын, ә утлы каләм иясенең батырлыгын, каһарманлыгын күрсәтә.

Дөрес, шушы урында әсәр тәмамлана да алыр иде, ләкин бу очракта ул трагедия булмас иде, чөнки аның өчен «соң чиккәчә үткенәйтелгән тирән конфликт» кирәк. Автор Муса Җәлилнең үлем җәзасы алдыннан Гетенең «Фауст»ын укыганлыгын да юкка гына эпиграф итеп күрсәтмәде бит инде. Әсәргә Мефистофель образы килеп керә.

*«Мефистофель—Фауст турында йөргән легендадагы шайтанның, ягъни иблиснең исеме Гетеда—тискәре, ләкин шулай ук рухи сыйфатлары булган күпкырлы фигура» (Neues grosses Lexikon in Farbe. Koeln, 2004).* Төгәлрәк итеп әйткәндә, алман әдәбияты буенча, табигатьне, яшәешне танып белә алмаудан өметсезлеккә бирелгән Фауст явызлык рухы Мефистофель белән килешү төзи, шунын нигезендә ул җирдәге барлык рәхәтне татыганчы яшәячәк һәм шунын бәрабәренә шайтанга җанын сатарга тиеш булачак.

Мефистофельне алман әдәбиятындагы борынгы әдәби, шул ук вакытта мифологик образ дип тә атарга мөмкин. Әгәр язучы үзенең әсәрендә алман тоткынлыгында әсир булып яткан татар шагыйрен тасвирлый икән, ул бу милләтнең әдәбиятына, тарихына, мәдәниятына мөрәҗәгать итмичә булдыра алмый. Ник дигәндә, әсәр шул очракта гына тулы була һәм төп персонаж укучы өчен бөтен яклап ачыла ала.

Мефистофель Тиранга булышырга уйлый.

*М е ф и с т о ф е л ь*
*Дошманыңны үтерүдән элек,*
*Акылын, җанын яулап ал аның*
*Һәм үзенә каршы юнәлтә бел,*

—ди, ә монын өчен ана вакыт кирәк.

*«Муса кеше тәне күтәрә алырлык бөтен газаплар аша сыгылмаган килеш үтә.*

*Хәзер аның алдында соңгы һәм иң катлаулы имтихан—җан сынавы тора...»*—дип яза Рафаэль Мостафин (Татар әдәбияты тарихы. 6 т. Казан, 2001). Шагыйрь кайсы якта калыр? Иреклелек иллюзиясенә төрелгән мизгеллек рәхәтлеккә алданырмы, әллә җан хөрлеген һәм үлемсезлеген беренче урынга куярмы? Әсәрнең интригасы, үзәге шушы ике сорауга килеп ялгана. Нәкъ бөек инглиз драматургы Уильям Шекспирның «Гамлет»ындагы кебек: «Булыргамы? Булмаскамы? Менә сорау нәрсәдә...»

*«Гаҗәп хәл: шагыйрь рухи ныклыгы, гуманизмга һәм үлемсезлеккә омтылышы белән иблистән куәтлерәк булып чыга. Мефистофель мәхбүскә мондый көчнең туган җирдән, Алып батырлардан, Алпамшалардан килүен анламый»*,—дип яза Тәлгат Галиуллин *(Шагыйрьләр һәм шигырьләр. Казан, 1985)*. Чыннан да, геннар үзенекен итә. Без, татарлар—хөр мәмләкәтләр, зур дәүләтләр тоткан Атилла, Кубрат, Чыңгыз, Батый һ.б.ка юлбашчыларның турыдан-туры варислары. Баш бирмәү, иманга, ватанга тугры калу—безнең канга гасырлар дәвамында сеңгән, җанда төпләнгән, күнелне какшамаслык итеп ныгыткан. Ә Мефистофельнең рухы явызлыктан гына тора һәм аның төп максаты—кешелек өчен тормыш мәгънәсен юкка чыгару. Кемнеңдер варисы булу, үткәннәрдән килгән амәнәтне үтәү дигән төшенчәләр иблискә бөтенләй ят, ул кешеләр күңеленә битарафлык, имансызлык орлыкларын гына чәчә. Мефистофельнең ватаны да, иманы да юк, чөнки ул әлеге төшенчәләр белән гомумән таныш түгел.

Бер яктан караганда, Мефистофель Шагыйрьгә шанс бирә. Ул аны Тиран коллыгыннан азат итә, аның гомерен теләгән кадәр озайтып, тормыш юлын гамьсез, рәхәт итә ала. Тик бер шарт белән. Моның өчен гомеренең ахырында Шагыйрь Мефистофельгә үзенең җанын бирергә тиеш.

*Шагыйрь*
*Җаның сатып йөз ел яшәгәнче,*
*Хөр җан белән үлү—мең артык!*

—дип җавап кайтара, шуның белән явыз шайтан каршында үз кыйбласының, иманының хаклыгын, дөреслеген кат-кат исбатлый. Шулвакыт Мефистофель хәйләгә күчә, төрле яклап Шагыйрьнең күңел кылларында уйный: чәчәк сатучы кызны үз ягына авыштырып, каләм иясенең җанын үзенә буйсындырмакчы була, аның каршында төрле иллюзияләр тудыра. Имеш, Шагыйрьнең милләте беткән, «Җир хуҗасы» хакимлек иткән дөньяда ул—«Үз халкының соңгы шагыйре»; имеш, Җир шарында кешеләр калмаган, анда фәкать адәм үз башына уйлап тапкан Робот идарә итә; Мефистофельнең кул хәрәкәте белән «Шагыйрьнең сөйгәне», «Шагыйрьнең дусты», «Ана»сы пәйда була һәм алар аны хыянәттә гаеплиләр, гөнаһсыз булуына ышанмыйлар... Мондый психологик басымны бар кеше дә күтәрә алмас иде, ә Шагыйрь күтәрә, күңеле әчтән сызса да, ул бөтенесенә түзә. Ахырда ана чәчәк сатучы кызның ихлас мәхәббәте ярдәмгә килә. Шагыйрь соңгы җырына үзенең җанын салып, шул Кызга тапшыра, ә үзе хәйләгә күчә. Мефистофель һәм Тиранның таләпләре белән килешкәндәй итеп, тоткыннар каршында соңгы, әмма үтемле, көчле, горур сүзләрен әйтә:

*...Җирне юк итәргә хыялланган*
*Тираннарның уен өзәргә,—*
*Тор, күтәрел, Кеше!*
*Җирне ирекләләр яши торган*
*Бәхет йорты итеп төзәргә,*
*Тор, күтәрел, Кеше!*
*Күп газаплар күргән Җиребезне*
*Көл итмичә, гөлләр итәргә,—*
*Тор, күтәрел, Кеше!*
*Тираннардан азат булып, Җирдә*
*Хуҗа булып көннәр итәргә,—*
*Тор, күтәрел, Кеше!*

Шагыйрь үлә, ләкин Кыз ярдәме белән, аның соңгы жыры—ярсу, ирекле жаны—әсирләр йөрәгендә көрәш чаткылары тудыра. Тиран да, Мефистофель дә жиңелә, аларның «гениаль» идеяләре чынга ашмый.

И.Юзеев әлеге әсәре белән Муса Җәлилнең якты образын күз житмәс биеклеккә күтәрә, аны чын хакыйкать һәм дөреслек ягыннан тасвирлый. *«Башка әдәбиятлар тәжрибәсенә мөрәҗәгать итү шагыйрьгә милли колорит тудырырга һич тә комачауламый, төссезлеккә һәм космополитик талымсызлыкка китерми, киресенчә, эрудиция киңлеге, максат тирәнлеге, проблемалар тирәнлеге миллилекне ачыклый гына, аны яңа югарырак баскычка күтәрә»*,—дип яза Р.Мостафин *(Күрсәтелгән хезмәт)*. «Соңгы төн» әсәре дөньяви масштабтагы тирән проблемаларны хәл иткәндә татар милләтенең ни дәрәҗәдә катнашы булуын күрсәтә. Татар халкы да тарихка тәэсир итеп кенә калмый, ә аның нигез ташларына зур хәрефләр белән үз исемен уя.

Автор, ярдәмче образларны кертеп, трагедиянең эчке халәтен киңәйтә. Мәсәлән, Мефистофель белән йөрүче ике мәзәкченең тозсыз мәзәкләре аша явызлыкның фәкать әшәке күңелле җаннар өчен генә көлке булып тоелуы аңлашыла. Баш җәллад, Төрмә хуҗасы, Гаскәр башлыгы—болар Тиран образын тулыландыру, аның ният-максатларын ачыклау өчен хезмәт итә.

Әсәрнең төп максаты—укучыда татар халкының сөекле улы Муса Җәлил шәхесе белән горурлык хисләре тудыру һәм аның якты образын еллар аша киләчәк буын укучысына алып бару. Трагедиянең актуальлеге дә нәкъ менә шунда.

Әсәр ахырында «соңгы төн» төшенчәсе «соңгы жыр» белән алышына һәм бу Шагыйрьгә үлемсезлек алып килә.

Ни өчен автор трагедиянең исемен үзгәрткән соң? «Соңгы сынау» варианты әсәрнең эчтәлеген тулаем ачып бетерми, артык гади кебек тоела, анда интрига, серлелек сизелми. Сынаулар күп була ала. Соңгысыннан соң, гомумән, сынауларсыз җиңел тормышка күчәргә мөмкин. «Гомернең алты сәгате» исеме, бер яктан, үзен аклый кебек, чөнки әсәрдәге вакыйга алты сәгать вакытны үз эченә ала, әмма барыбер эчтәлекне ачып бетерә алмый. Ул фәкать кеше гомеренең ниндидер бер өлеше генә булып күз алдына килеп баса, ә алар шулай ук күп. Ә менә трагедиянең иң ахыргы исеме—«Соңгы төн»—интрига тудыра, анда ниндидер серлелек һәм, иң беренче чиратта, чиклелек бар. Соңгы төн икән, димәк, башка төннәр булмаячак. Бу үзе үк вакытны, гомерне чикли. Димәк, бер төн генә калган, бары тик ул гына язмышны йә уңай якка, йә тискәре якка хәл итәчәк. Әсәр эчтәлеге белән бәйләп карасак, соңгы төн—бик кыска, ләкин андагы вакыйгаларның урнашуы гаять дәрәҗәдә тыгыз, гади тел белән әйтсәк, шыплап тутырылган. Соңгы төн—дөньяви халәттән (тән халәтеннән) рухи халәткә күчәр алдыннан җанның әзерлеге. Кешенең бу якты дөньядагы гомере чикле булса да, аның җаны, ягъни рухы—үлемсез. Димәк, әсәрнең исеме үк аның трагедия икәнлеген күрсәтеп тора.

## «Очты дөнья читлегеннән»

«Очты дөнья читлегеннән» шигъри трагедиясе татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган һәм аның егерме җиде еллык гомерен үзенә сыйдырган. Трагедиянең башында ук түбәннән әкренләп биеккә күтәрелгән юл сурәтләнә. Ул Кояшка илтә. «Тәфтиләү»нең, аннары «Бишек жыры»ның көе яңгырый. Шундый илаһи мизгелдә дөньяга шагыйрь туа. Ул—көрәшче, милләтне торгынлыктан чыгаручы, ил һәм халык язмышы өчен жан атучы изге жан. Алла аны озын юл белән берләттән күпме сынаулар—ятимлек, кагылу-сугылу, мыскыл ителүләр көтә.

Әсәр башында ук Тукайның халык улы икәнлеге кат-кат раслана, И.Юзеев моны һәр адым саен искәртеп тора: *«шагыйрьне халык тудыра сыман»*, шагыйрь яткан *«бишекне бөтен халык тирбәтә кебек»*, *«Апуш, куллан-кулга күчеп, халык эчендә югала»* һәм кинәт калкып чыга, чөнки халык аны көтә, ана өмет белән карый. Шәкертләр Тукайны милләткә юл күрсәтүче, хатын-кызлар үзләренең яклаучысы һәм саклаучысы дип кабул итәләр. XX йөз башында яшәгән дин әһелләренең образын үзенә җыйган Хәзрәт кенә:

*Без көттек синең килүне*
*Еллар, гасырлар аша,*
*Тик чыкма рухи кануннан,*
*Безнеңчә генә яшә!*

—дип аңа чик куймакчы, шагыйрьнең иреккә омтылган жанын кысага—читлеккә кертеп утыртмакчы була. Дөнья үзе дә читлек икән, ә милләт атлап барган юл—рухи коллык. Әмма Тукай монын белән килешергә теләми, чөнки йөз-мен ел буена килгән кануннар хәзер искергән, диннең үзе кебек кырыкка үзгәртелгән. Халык азатлыкка сусаган, аңа рухи юлбашчы, туры юлны күрсәтеп, алга әйдәүче кирәк.

Тукай үзе дә икеләнә кебек, анын уйлары төрлечә:

*Башта мең уй... Халкыбызга*
*Кайсы юлдан китәргә?*
*Ирекле җир бармы? Безгә*
*Кайдан бәхет көтәргә?*

Әйе, шагыйрь ялгыз түгел. Анын ягында шәкертләр, иттифакчылар, хатын-кызлар, «Урал»чылар, зыялылар һ.б. Алар аны рухландырып, хуплап торалар. Хөрриятка төп ачкыч—тәрәккыят, мәдрәсәне янарту, чит телләр белү, Көнчыгыш һәм Европа белән сәүдә итү һ.б.

Икенче якта торучы Хәзрәт, кадимчеләр, миссионер, карагруһчылар, хажи, ишаннар да бар бит әле. Алар белән нишләргә? Көрәшергә һәм бары тик көрәшергә генә!

Теләнче образы конфликт барган ике як арасындагы күпер кебек. Ул кемгә ышанырга да белми әле, чөнки чираттагы халык исәбен алу вакытында дин әһелләренең «кяфер итеп яздыралар икән» дигән сүзенә ышанып, «Изге» җиргә—Төркиягә—күчеп киткән һәм алданган. Андыйлар бер теләнче генә түгел:

*Кайсы—вафат, кайсы—эшсез,*
*Йортсыз-илсез аптырап,*
*Көн-төн йөри бичаралар*
*Бер кабым икмәк сорап...*

Теләнче кебекләрнең кесәләрендә бер тиен акча да юк. Аларга ярдәм итәргә атлыгып торучылар да күренми. Соңгы чара—туган җиргә башны салып үлү. Хәер, халык андыйларны ташламый, колач җәеп, үз арасына кабул итеп ала.

Милләтнең бер өлеше заманында христиан динен кабул итеп, керәшен булган, ләкин үз асылын, туган телен саклаган. Миссионер үзенең булдыклылыгы белән мактана тора, ә алар «Туган тел»не җырлыйлар. Татар белән русның аралашуы да коточкыч күренеш түгел. Ике халык борын-борынгыдан «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яши. Әмма...

*Тукай*
*Су кирәк—кое казыйбыз...*
*Руслар—машина белән.*
*Без казыйбыз шул ук җирне*
*Кулдагы инә белән.*

Димәк, иң беренче чиратта, милләткә мәгърифәт нуры чәчәргә, халыкны уятырга кирәк. Моның өчен башка милләтләрнең тәҗрибәсен өйрәнү, үзебезнең көйчеләрне, рәссамнарны, әдипләрне, шагыйрьләрне булдыру, халык өчен тырышкан ирләрне табу зарур.

Әсәрдәге Тукай һәм кадимчеләр арасындагы конфликт, ахырда, Тукай һәм Патша дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Татар халкының бер вәкиле булган шагыйрь үзләренең өч йөз ел тәхеттә утыруларын бәйрәм иткән Романовлар нәселенең патшасы белән

күзгә-күз әңгәмә кора. Әмма Русия хөкүмәтенен татарга карата алып барылган сәясәте үзгәрмәячәк икән:

*Иң дөресе—аны читлектә тоту,*
*Тончыктыру, куркыту, кысу, йоту!*
*Мәгърифәттән читләтү, аңсыз иту,*
*Хәмер белән агулап, җансыз иту...*

Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яна Кисекбаш» әсәрендәге Карәхмәт образын Илдар Юзеев гади халыкның көчле, ләкин томана, надан, белемсез катлавы итеп күрсәтә. Аны кадим фикерлеләр төркеме үзләренең максатларында куллана, эт шикелле өстерә, котырта. Карәхмәт, беркатлы сабый бала сыман, барысына да ышана. Ахыр чиктә, халык үзе дә Тукайны аңлап бетерми кебек, ул патшаларга дан җырлаучы, ялагай Иманкол мулланы шагыйрь дип таный, ә Тукай такмакчы булып кына кала. Ләкин чишелеш бу түгел әле.

Искелек калдыклары, куштаннар һаман саен Тукайны кысалар, аның авыруы көчәйгәннән-көчәя һәм әсәрнең кульминацион ноктасы житә—шагыйрь үлә.

*Т у к а й*
*Дөнья зинданында кылган*
*Иң соңгы догам шушы:*
*Очсын дөнья читлегеннән*
*Тарсынып күңелем кошы...*

Әсәр башында түбәннән, халыкның төбеннән күтәрелгән шагыйрь Кояшка кадәр менеп житә һәм шунда югала. Бер мәлгә Кояш сүнә, бөтен дөнья караңгылыкта кала. Кара көчләр җиңү яулады кебек, ләкин Кояш тагын да нурлырак булып кире кабына һәм күктән Тукайның илаһи тавышы ишетелә. Халык уяна, соңлап булса да аңына килә:

*Х а л ы к*
*Кемне югалттык без, кемне?*
*...«Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач».*

Тукай—җиңүче. Ул үз дигәненә ирешә, халыкны күтәрә, ул халыкның барыр юлын яктыртучы Кояш булып калка.

Илдар Юзеев үзенең «Очты дөнья читлегеннән» шигъри трагедиясендә бөек халык шагыйренең образын бербөтен итеп сурәтли. Автор аның фаҗигале тормышын, халыкчан иҗатын тирәнтен аңлый һәм тоя. Әсәрдә ул Г.Тукайның мәгълүм шигырьләреннән кайбер юлларны шагыйрьнең үз авызыннан сөйләтә. Ник дигәндә, башкача, Тукай образын бар тулылыгы белән күз алдына китереп булмас иде. Т.Галиуллин бу хакта: *«Әсәрнең нигез өлгеләре итеп, бер яктан, Тукайның реаль тормышы һәм биографиясе алынса, икенче яктан, поэманы (шигъри трагедияне.—Л.Ш.) ул иҗат иткән әсәрләр, образлар, ситуацияләр тулыландыра. Шул ике линияне укучыга сиздермичә органик кушып бара алган очракларда шагыйрь җитди уңышка ирешә»*,—дип яза (Дәвамлылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан, 1987).

Әсәрдә читлек образы берничә мәгънәдә кулланыла. Беренчедән, ул—кадимчеләрнең төп кануны, ягъни аерым бер кыса. Алар фикеренчә, аннан беркемгә дә, шул исәптән, Тукайга да чыгарга ярамый. Икенчедән, читлек—патша хөкүмәтенең татар милләтенә карата алып барган астыртын сәясәте. Ягъни, татарны билгеле бер кысалардан чыгарырга ярамый. Ул надан, хәерче һәм мескен хәлдә булырга тиеш. Өченчедән, читлек—фани дөнья, автор аны зиндан белән дә чагыштыра. Дүртенчедән, ул—тән. Җан тәннән аерылгач кына тулы иреккә ирешә ала, чөнки ул шушы юл белән мәңгелеккә күчә һәм үлемсезлек яулый.

## «Мәңгелек белән очрашу»

Бу шигъри трагедиясен Илдар Юзеев борынгы грек мифологиясе тудырган образларны файдаланып яза, аларны бүгенге заманга күчереп тасвирлый. Әсәрдәге вакыйгалар Бүгенге, Борынгы һәм Киләчәк заманнарда, Җир астында, Җирдә, Күктә бара. (Җир асты—Борынгы заман, Җир—Бүгенге заман, Күк—Киләчәк заман.)

Трагедиянең төп каһарманы—Атлант. Ул—археолог. Аның хыялы—киләчәкне һәм үткәнне бүгенге заманда очраштыру. Шушы өч заман мәңгелекне барлыкка китерә.

*А т л а н т*
*...Өч заманның уртаклыгын тапкан*
*Адәм тиңсез эшләр кыла ала!*

Атлантның әтисе гомере буе җир йөзеннән эзсез юкка чыккан утрауның—Атлантиданың—серен белергә омтылган, ләкин, сорауларына җавап таба алмыйча, яу кырында башын салган. Үз миссиясен улына тапшырган, аңа Атлантида халкы юлбашчысының—Атлантның—исемен кушып калдырган. Хәзер Атлант әлеге серле утрауны табу хыялы белән яна, җир астын айкый. Ә Атлантида, Платон язып калдырган борынгы грек риваяте буенча, кайчандыр Атлантик океанда булган гаять зур, ундырышлы, күп кеше яши торган утрау, имеш. Ул җир тетрәү нәтиҗәсендә су астына киткән.

Икар—Атлантның улы. Ул—космонавт, галәм киңлекләрен айкарга җыена. Аның исеме дә грек мифологиясеннән алынган.

Атлант—үткәннәрне ялгап торучы бер буын вәкиле. Әтисе, яуга киткән чакта, аңа җиде буын бабаларының исемнәре язылган нәсел шәҗәрәсен биреп калдырган. Хәзер ул аны Икарга тапшыра, ләкин малай бу ядкарьнең кыйммәтен аңлап бетерми, ул үткәннәр белән кызыксынмый, ә күккә—киләчәккә омтыла.

Атлант казу эшләре алып барганда каты шартлау була, ул яралана һәм саташа башлый. И.Юзеев Атлантның саташуын алты бүлеккә бүлә. Төп герой анда күккә менә, җир астына төшә һәм җир өстенә чыга. Вакыйгалар борынгы грек аллалары—Олимп тавы хуҗалары белән тыгыз бәйләнештә бара. Баш алла Зевс һәм аның балалары: Арей—Сугыш алласы, Афина—Акыл алиһәсе, Ананка—Язмыш алласы, Аид—Җир асты алласы.

Атлант, аллалар катына менеп, күккә сигнал җибәрә. Аңа җавап килә. Әмма андагы серләрне ачу, барысына да төшенү өчен, иң беренче чиратта, җир астына төшәргә һәм андагы серле төеннәрне чишәргә кирәк. Атлант шулай эшли дә. Җир астына төшә, сугыш корбаннары белән очраша. Аларның саны коточкыч һәм аларның барысы да ачулы.

Атлант алар арасында тораташ булып катып калган әтисен танып ала.

*Т о р а т а ш*
*Без ышанып киттек Җирдән*
*Соңгы бу сугыш диеп,*
*Балаларга яшәү биргән*
*Соңгы бу сулыш диеп...*
*(Тораташларның сүзсез авазы.)*
*Яңа сугыш гөрелтесе*
*Диңгездә, Җирдә, Күктә...*
*(Еракта атом бомбасы шартлаган авазлар.)*
*Ракеталар һәр кешене*
*Юк итәр йөкләр йөртә!*
*(Тораташларның ярсулы-нәфрәтле авазы.)*

Күк аллалары да Җир астына төшә. Әлбәттә, аларга гади генә бер затның, гомере чикле булган нииндидер адәмнең, мәңгелек серләрен аңларга теләп, үз яннарында

йөрүе ошамый, шуна аның язмышын һәлакәткә дучар итәләр.

Аллалар кешелектән риза түгел, бары тик Афина гына кешеләргә яхшылык тели, алар өчен чын күңелдән борчыла. Ул, аллалар биргән антны бозып, Атлантны тоткынлыктан азат итә. Нәтиҗәдә, Атлантиданың ничә гасырлар буе билгесезлектә яткан сере ачыла. Гаделлек, тынычлык, бәхет сөючән атлантлар яшәгән утрауны Зевс юкка чыгарган икән. Ләкин бу халык үз нәселен саклап калган. Интал һәм Зукар дигән атлантлар бәладән котылганнар. Аларның берсе күккә очкан, икенчесе җирдә калган.

И.Юзеев бу әсәре белән кешелекне бер мизгелгә булса да туктап уйланырга, Үткәннәрне, Бүгенгене һәм Киләчәкне анализларга чакыра. Барыр юлын үзгәртмәсә, кешелек һәлакәткә юлыгачак, чөнки Җир шарында һаман сугышлар дәвам итә, иң куркыныч корал—атом төш бомбалары тоткан илләрнең саны елдан-ел күбәя. Табигать пычрана, экология начарлана. Нәтиҗәдә, кешеләр меңнәрләп кырыла. Димәк, безгә бердәм булырга кирәк. Моның өчен Җир шарында барлык халыклар да тигез булган, гадел, сугыш-талашларсыз, аңлы җәмгыять төзү зарур.

Әлеге әсәр белән татар халкының тарихы арасында да параллель үткәрергә мөмкин. Татар, дәүләтчелеген югалткач ук, юкка чыгарылуга хөкем ителгән, гасырлар дәвамында изелгән, тапталган. Аның дәүләте, Атлантида кебек, су астына батырылган, бик тирәнгә, төпкә яшерелгән. Ләкин татар яши. Ул—Җирдә, ягъни туган җирендә, Россия Федерациясе территориясендә, ул—Күктә, ягъни чит илләрдә. Совет чорында татар тарихы, аның данлыклы үткәне никадәр генә яшерелмәсен, тулы бер буыннар аныннан сөртелмәсен, узган гасырның 90 нчы еллары алып килгән үзгәртеп корулар бу байлыкны безгә кире кайтара башлады.

Әсәрдә тагын бер мөһим фикер бар. Без, татарлар, үзебезнең үткәнебезне, меңьеллык тарихыбызны, җиде буынга кадәр нәсел-нәсәбебезне мәҗбүри рәвештә белергә, гореф-гадәтләребезне, асыл тамырларыбызны сакларга тиеш. Шул очракта гына милләтебез яшәячәк. Бүгенге көнгә кадәр яшәп килгән телебезне, әдәбиятыбызны, мәдәниятыбызны, тарихыбызны, фәнебезне лаеклы төстә киләчәк буыннарга тапшыру—безнең төп бурычыбыз, милли миссиябез.

## «Бәгырь»

«Бәгырь» шигъри трагедиясе татар профессиональ музыка сәнгатенең нигез ташларын салучы, милләтебезнең буыннан-буынга күчеп килгән тирән моңын җаны белән тоеп, аны Европа дәрәҗәсендәге биеклекләргә күтәрүче, халкыбызның бөек композиторы Салих Сәйдәшевкә багышлана. Әсәрдә аның татар булып туу бәхете дә, шул ук вакытта фаҗигасе дә ачык тасвирлана.

Салих Сәйдәшев ялгызы гына үзенең иҗат бүлмәсендә пианино янында утыра, репрессия тырнагына эләккән аерылмас дусты Кәрим Тинчуринны искә ала. Пианино—композиторның күңеле. Сәйдәшев анда Тинчурин белән бәйле иң якты хатирәләрен фотосурәт кыяфәтендә саклый. Анда аларның бергәләшеп халык күңелендә гасырларга калырдай әсәрләр иҗат итү вакыйгалары да, тынлык, ирек һәм илһам эзләп, карурманга барулары да сыйган.

Яшь сынчы Сәйярнең да язмышы фаҗигале рәвештә тәмамлана. Ул бөек композитор белән бөек драматургны үзенең «Җан дуслар» дип исемләнгән сынында җанландырмакчы була, ләкин, Тинчуринны төрмәгә япкач, яшь егеткә дә шик төшә. Сәйярне Төн кешеләре, ягъни НКВД вәкилләре Черек күлгә алып китәләр, аның проектын «сәяси хата» дип бәялиләр.

Кәримне дә, Сәйярне дә «Советка каршы җинаятьчел эшчәнлекләре өчен» атарга хөкем итәләр. Драматургның исемен телгә алу тыела, аның әсәрләре сәхнәдән алына. Сәйярнең сөйгәне Гөлнара да, яшь сынчыны коткарам дип фаҗигагә юлыга.

Салих Сәйдәшевнең әле күпләргә билгеле булмаган «Гөлнара» балеты бар. Замандашлары әйтүенчә, композитор бу әсәрен Болгар хәрабәләрен күреп кайткач иҗат иткән. Автор исә аны шигъри трагедиясендәге Гөлнара исемле яшь балерина образы белән бәйли. Композитор күңеле белән аңа гашыйк. Шул яшерен, серле мәхәббәт, кызның фаҗигале язмышы «Гөлнара» балетын язуга этәргән күрәсең.

Сәйяр тулаем татар милләте образын күз алдына китереп бастыра. Халык өчен—Сәйдәшев белән Тинчуринның шәхесләре дә, иҗатлары да аерылмас бербөтен. Алар халык күңеленә шулай кереп урнашкан. Тинчурин исеме телгә алынмаган заманда аны Сәйдәшев фамилиясе үзе белән янәшә алып бара.

И.Юзеев К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» пьесасындагы күренешләрне, җырларны җинел һәм оста итеп үз әсәре белән үреп җибәрә. «Булат җыры»н, трагедияне тагын да көчлерәк итү, репрессияләр чорын тирәнрәк чагылдыру максатында, бераз үзгәртә. Бу профессиональ дәрәҗәдә уңышлы килеп чыга. Әсәрнең үзендә үк ике вариант та бирелә:

*Булат*
*Анда юк урак, анда юк сабан.*
*Анда икмәкне алалар сатып,*
*Эшчеләр санын, номерлар тагып,*
*Меңәрләп кенә саныйлар анда.*

*Кәрим*
*Монда юк уен, монда юк сәхнә,*
*Салкын бүлмәдә тоталар ябып.*
*Тоткыннар санын, номерлар тагып,*
*Меңәрләп кенә саныйлар анда.*

Трагедиядә авторның Кәрим Тинчурин образы белән «Зәңгәр шәл»дәге Булат образы аша параллель үткәрүе дә отышлы. Тормышта К.Тинчурин— күпкырлы шәхес. Ул искиткеч драматург, шәп режиссер гына түгел, ә яхшы артист та була. Узган гасырның 20нче еллар ахыры—30нчы еллар башында үзенең «Зәңгәр шәл» пьесасында Булат ролен башкара. Димәк, И.Юзеев күренекле драматургның тормыш юлын яхшы белә һәм ул аның иҗаты белән дә якыннан таныш. Бу очракта К.Тинчуринның «Зар» шигъри трагедиясеннән алынган Дәҗҗал образы үзенчәлекле. И.Юзеев аны Яңа дус образына төреп бирә. Бу геройның мәкере әсәр ахырында гына билгеле була. Әмма шунысы ачык: Сәйдәшев Яңа дус—Дәҗҗал артыннан иярми, аның коткысына бирелеп, Тинчуринны гаепләү юлына басмый, җан дустыннан баш тартмый.

Әсәрдәге күренешләрнең динамикасы сокландыра. Алар тиз һәм җинел алышына. Димәк, автор—чын профессионал, югары дәрәҗәдәге драматург, сүз уйнату, аларны урынлы һәм төгәл итеп куллану ягыннан караганда, искиткеч оста шагыйрь.

Трагедиядә Урта гасыр татар әдәбиятындагыча халыкчан шигъри тезмәләр дә очрый. Алар күбрәк фәлсәфи гыйбарәләргә, мәкальләргә якын.

*Салих*
*Ирекле кош сына торган*
*Юан талга куналмас.*
*Нечкә талларда тирбәлер,*
*Карурманда югалмас.*

Димәк, автор татар әдәбиятының күп гасырлык мирасын җаны белән тоя, аның традицияләрен дәвам итә һәм, шушы юлларны Салих Сәйдәшев авызыннан әйттереп, укучы алдында композиторны халыкның үткәнен киләчәккә җиткерүче бөек зат итеп ача, аны күтәрә.

«Бәгырь» шигъри трагедиясе—мистик әсәр. Бу очракта аны «Соңгы төн» шигъри трагедиясе белән чагыштырып була. Икесендә дә мистик образлар бар: Мефистофель алман әдәбиятыннан алынган, Яңа дус кыяфәтендәге Дәҗҗал—мөселман дини әдәбиятыннан. Алар икесе дә тискәре геройлар. Димәк, әлеге әсәрләрне мистик шигъри трагедияләр дип атарга мөмкин.

«Бәгырь» әсәрендә дә, «Соңгы төн»дә дә үзәктә җыр тора. Җыр—халык хәтерен саклый, үзен иҗат итүчеләрнең исемнәрен киләчәк буыннарга илтеп ирештерә.

Димәк, бөекләрнен күнеле—моңлы җыр кебек.

Әсәр ни өчен «Бәгырь» дип атала соң? Салих Сәйдәшев үзенен сөйләмендә «бәгырь» дигән сүзне еш кулланган, димәк, кешеләрне яраткан, якын иткән. Башка яктан караганда, Тинчуринның бәгыре—сүз, Сәйдәшевнеке—көй... Сүзнен бәгыре көй, көйнеке—сүз... Кәримнен бәгыре Салих, Салихныкы—Кәрим.... Халыкның бәгыре—шушы ике бөек шәхес. Димәк без аларның якты рухын, сүрелмәс мирасын кадерләп сакларга тиеш. Шул очракта гына безнен бәгыребез исән-сау була ала. Икенче яктан, мона «Бәгырь» шигъри трагедиясен театрда куеп та ирешергә мөмкин. Әгәр дә олы сәхнәгә менсә, ул искиткеч зур янгыраш алачак, халык аны бик яратып кабул итәчәк, күпләр хәтерләрен янартачак, күнелендә йөргән сорауларына җавап таба алачак, милли анын уятачак!

Илдар Юзеев—шигъри трагедия өлкәсендә җиң сызганып эшләгән бердән-бер автор. Ул үз әсәрләрендә кин халык массалары өчен актуаль булган һәм кирәкле, милли дәрәҗәдәге, кешелек югарылыгындагы глобаль проблемалар күтәрә, аны чишү юлларын күрсәтә. Р.Мостафин: *«И.Юзеевнын драма һәм трагедияләрендә автор ремаркаларында күрсәтелмәгән, кеше күзенә күренмәгән тагын бер шартлы-романтик герой бар. Ул да булса—хәтер»*,—дип яза (Күрсәтелгән хезмәт). Димәк, хәтерле милләтнен генә киләчәге бар. Без халкыбызның Г.Тукай, М.Җәлил, С.Сәйдәшев кебек күренекле шәхесләре белән беррәттән, Җир-анабыз, анын киләчәге турында да онытмаска тиешбез. Авторның «Сонгы төн», «Очты дөнья читлегеннән», «Бәгырь» әсәрләре милли аңыбызны саклауны өстен куйса, «Мәнгелек белән очрашу» исә дөньядагы барлык милләтләрнен тигезлеген, үзара анлашып, ярдәмләшеп яшәвен алгы планга чыгара. *«И.Юзеев яшәү һәм үлем, иҗат гомере һәм тереклек итүнен мәгънәсе кебек олы фикерләрне, мәнгелек проблемаларны чагылдыруда, сәнгатьчә хәл итүдә трагедия жанры үзенчәлекләрен оста файдалана»*,—дип яза Азат Әхмәдуллин (Күнелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе: монография. Казан, 2007).

И.Юзеев иҗатта үзен шагыйрь буларак кына түгел, ә драматург-шагыйрь буларак та раслады. *«Әйе, ул—драматургиясендә дә шагыйрь булып кала алган, милли сәхнәбезне шигърият белән баета килгән үзенчәлекле каләм иясе иде. Шуның белән ул үзенчәлекле театр тууга нигез бирде»*,—ди А.Әхмәдуллин. Кызганычка каршы, без Илдар Юзеев театрын бөтен тулылыгы, бөтен матурлыгы белән ача алмадык әле. Анын шигъри трагедияләре бигрәк тә опера һәм балет театры өчен отышлы. Без, ул иҗатның бөеклеген анлаган хәлдә, аны әнә шул югары дәрәҗәгә күтәрергә тиешбез. Бу безнен изге бурычыбыз, чөнки Илдар Юзеев—Татар Шекспиры югарылыгына ирешкән олы шагыйрь һәм көчле драматург!

Фәридә
Хәсәнова

# ШИГЪРИЯТТӘ—ЯҢАЛЫК

*Все эти стихотворения очень коротки,*
*а между тем ни к одному из них*
*решительно нечего прибавить.*
Н.Некрасов.

Рус шагыйренең әлеге билгеләмәсе Ф. Тютчев шигырьләренә карата әйтелә. Тютчевның, үткен сүз остасы булып, тирән фәлсәфи фикерле шигырьләр язуы мәгълүм. Әдәбият белемендә хәтта «Тютчев сере» дигән тәкъбир дә яшәп килә. Тютчев поэзиясе ул—фикер поэзиясе. Аның шигырьләре үз заманы китереп чыгарган реаль фәлсәфи һәм сәяси сорауларга җавап булып янгыраган. Аның шигырьләренә «искиткеч уйдырма» дип караганнар. Иван Аксаков Тютчев фикри шигыренә операция ясарга кирәкми, аның шигырьләрен «уйлы шигърият» дип билгеләргә түгел, бәлки «шигъри фикер»нең үзе дип кабул итәргә кирәклеген яклап чыккан. Тютчев шигырьләренең сәнгати формасына *«фикер кулга киертелгән перчатка кебек киертеп куелмаган»*, бәлки тән белән тире кебек бер булган, ягъни бу шигъри форма түгел, ә шигъри фикернең үзе дигән билгеләмә яши. Фәлсәфи фикер бу очракта тема буларак аңлашыла.

Тема белән стиль, сүз юнәлеше берләшкәнче, билгеле бер вакыт аралыгы сорала. Ә аннан соң форма, жанр үзенчәлегенә күчеп, таныла. Фәлсәфи лирикада форма, жанр турындагы бәхәсләр тынып тормаган. Яңа материал, метафизика билгеләре булган яңа тел дигән терминнар фәлсәфи лирика өчен гадәти төшенчәләр. Жанр шигъри сүз белән тема берләшкән очракта гына туа ала.

Сүз сөрешеннән аңлашылганча, безнең сөйләшү кыска шигырь турында булачак. Ачыклабрак әйткәндә, хәзерге шигъриятта актив иҗат итү белән бергә, ачыктан-ачык үз сукмагын салган (Р. Фәйзуллиннан соң бу бер дә җинел эш түгел!) татар шагыйре Мөхәммәт Мирза иҗатын тикшерергә алынабыз.

Безгә кадәр дә ул тәнкыйтьче һәм шагыйрьләр игътибарыннан читтә калмады. Аның шигырьләренә Р. Мингалим, Л. Шагыйрьҗан, М. Әгъләм, Р. Мостафин, Г. Гыйльман, М. Вәли-Барҗылы, А. Юнысова, Н. Акмал, Р. Зәйдулла, Р. Шәрипов һ.б. үз фикерләрен аерым язмаларда белдерсә, Р. Батулла, Ә. Рәшит, З. Мансуров язучыларның ел йомгакларында телгә алып үтте. Әлеге язмаларда шагыйрьнең үзенчәлеге, аз сүз белән күп мәгънә бирә алуы, лирикасының кешегә тәэсире мәсьәләләренә басым ясала, М. Мирза шигырьләренең татар әдәбиятын баетуы ачыклана.

Галим Хәнәфи Бәдигый Мирза шигырьләрен «хикмәтле бишьюллыклар» дип атый һәм мәкаль-әйтемнәр белән табышмаклар арасында торган яңа бер жанр дип таный, әлеге жанр формасына «М. Мирза нәсыйхәтләре» дигән исем дә тәкъдим итеп, шигырьләрнең тематик ягына басым ясый. Х. Бәдигый Мирза бишьюллыкларын «үзгә яналык, поэтик табыш, ачыш», дип билгели. Безнеңчә,

галим, эчтәлек белән мавыгып (ә ул, дөрестән дә, онытылып укылырлык), форма ягын күздән ычкындыра. Дөрес, нәсыйхәтнен төгәл генә билгеләнгән формасы юк, шулай булгач, ул биш юлдан да төзелергә мөмкин дип фараз итәргә була. Әмма Мирза шигырьләре үгет-нәсихәт китабы да, дидактик туплам гына да түгел. Бәет рәвешендә дә язылмаган. Шулай булгач, бу жанрны нәсыйхәт дип атау өчен тулы жирлек юк, дигән нәтижә килеп чыга. Галимнен әлеге яна жанр формасын «яшәеш интернеты» метафорасы белән атавын заманча уңышлы килеп чыккан дип танырга гына кала. Ә менә шагыйрь Рәниф Шәрипов «Адәм баласы»н «фирменный стиль» дип исемләгән.

Әмма, безнеңчә, шагыйрь ижатына фәнни яктан бәя бирү, монографик планда тикшерү күләгәдәрәк калып бара. Болар өстенә әле яна гына дөнья күргән «Адәм баласы» дүрттелле шигырь жыентыгы, бигрәк тә андагы яна форма, жанр күренешләре, фәнни яктан (бигрәк тә поэтика өлкәсендә) тикшерелеп, гадел бәя бирүне сорап тора. Ә «Адәм баласы»ндагы шигырьләрнен үзенчәлекле фикер формасы буларак, хәтта яна жанр буларак тәкъдим ителүе, безнен шул әдәби новаторлык күренешен фәнни яктан исбатларга алынуыбыз әлеге эшебезнен фәнни яналыгын тәэмин итәр дип фаразларга мөмкинлек бирә. Билгеле, перспективада М. Мирзанын кыска формалы (һәм кыска булмаган да!) шигырьләрен өйрәнүне Көнчыгыш әдәбияты контекстында дәвам итү сорала.

Татар әдәбиятында кыска шигырь формасы турында бәхәс узган гасырның 60 елларыннан бирле дәвам итә. З. Мансуров фикеренчә, Р. Фәйзуллинның беренче кыска шигырьләре тәнкыйтьчеләр тарафыннан «Нәрсә бу?» дип кабул ителгән. «Сүзне олылау» дип исемләнгән хезмәтендә шагыйрь З. Мансуров кыска шигырьнең татар әдәбиятындагы тамырларын барлый, традицияләрен күрсәтә. А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, *«тормышта һәр нәрсәнен үз эчтәлеге һәм формасы бар»*. Әдәби әсәр эчтәлеккә ия булырга һәм шул эчтәлекне яшәтүче форманы табарга тиеш. *«Әдәби әсәрнен кыйммәте форма яки эчтәлекнен камиллеге белән түгел, бәлки эчтәлек һәм форма берлеге хасил иткән әдәби дөньяның үзенчәлеге аша аңлатыла»*. Сәнгатьтә эчтәлекнен беренчеллеге, форманың икенчеллеге хакимлек итүен дә онытмыйк.

Сурәтләнә торган уй-фикернен, тойгы-кичерешнен характерын, табигатен искә алып, лириканы гражданлык, күнел (мәхәббәт, интим), сәяси, пейзаж, фәлсәфи төрләренә аерып төркемләү бар. Лириканың шәхси хис һәм тойгыларга нигезләнүе мәгълүм. Әмма шигърияттә «фикер поэзиясе» дигән атама да яшәп килә. Шигырьдә хисләрдән бигрәк, фикер әйтү, мөнәсәбәт белдерү өстен чыккан очракта фәлсәфи лирика килеп чыга. Шулай да шигырьнең нигезендә хис, кичереш урын алырга тиешлеген кире кагып булмый. Фикер поэзиясендә дә хис бар, әмма ул хис кеше, яшәеш, галәм, яшәү мәгънәсе хакындагы уйланулардан туган хис-кичерешкә әверелеп бирелә. Шигырьне аңлау, кабул итү өчен анда яшеренгән фәлсәфи фикерне ачыклау сорала. Без шул яшерелгән фикергә форма аша килеп карыйк. Менә М.Мирза шигырьләреннән бер мисал:

*«Мин мин микән?!»—диеп,*
*Өнендә саташкан*
*Адәм баласының*
*Күзен ачтырыгыз*
*Әүвәле иң баштан.*

Прозаизм сизелгәнлектән, шигырьне чәчмә формага китереп карыйк: *«Мин мин микән?!»—диеп, өнендә саташкан Адәм баласының күзен ачтырыгыз әүвәле иң баштан»*. Синтаксик яктан дөрес формалы татар жөмләсе килеп чыкмады, соңгы ике юлдагы инверсия «комачаулый». Ә инверсия күренеше шигырьгә хас үзенчәлек. Шигырь шигырь булсын өчен формаль яктан ритм һәм рифма таләп ителә. Карыйбыз: бишьюллык строфалы тәмамланган шигырьдә икенче һәм бишенче юлларда рифма бар (абвгб). Шунысын да әйтеп үтик, әлеге жыентыктагы һәр шигырьдә алда күрсәтелгән рифма формасы төгәл саклана, кайбер шигырьләрдә

өчәр юл рифмалашу да күзәтелә. Һәр шигырь юлының алтышар иҗекле ритмик буыннардан төзелүе үзе үк ачык ритмны күрсәтеп тора. Менә тагын бер мисал:

*Чиксез мәңгелектә*
*Тыгыз янәшәлек...*
*Адәм баласының*
*Куышы—газиз җир,*
*Оҗмахтай яшәрлек...*

Мирза шигырьләрендә фикерне әйтеп бетермәү күзәтелә. Бер шигырьдә генә дә күпнокталарның ике-өч урында килүе шул турыда сөйли. Әйтеп бетермәү кебек синтаксик алым шигырьдә сурәтлелекне көчәйтү максатында кулланыла. Сурәтлелек дигәндә, подтекст формасында бирелгән киная күз алдында тотыла. Төгәл аерылып торган ике синтаксик бөтеннән төзелгән әлеге шигырьләрне бишьюллык формалы шигъри фикер буларак тану кирәклеге соралып тора. Мисал өчен:

*Кылган бар гамәле*
*Эшендә, ашында...*
*Адәм баласының*
*Иң соңгы хәбәре*
*Кабере ташында...*

Сүз дә юк, әлеге шигырьдә киная бар. Ул шигырьнең икенче өлешенә салынган. Әмма шагыйрьнең кинаясе сатирик юнәлеш алмый. Соңгы өч юлдагы фикергә, беренчедән, киная, икенчедән, мәсәлдәге кебек әхлакый вазифа үтәү йөкләнә. Шулай да, Мирза бишьюллыкларының, гәрчә кинаясе булса да, мәсәл жанры белән уртаклыгы шул бер «әхлак» өлешендә генә. Тагын да өстәп шуны әйтергә мөмкин: «Адәм баласы» шигырьләрендә аллегория юк.

Ә менә Равил Фәйзуллин бишьюллык шигыренә аллегорияне дә «сыйдыра алган». Мисал өчен 1978 елда ук язылган бер шигырь:

*Корт чебене белән бергәләп*
*Гөлгә кунып йөрде күбәләк...*
*Бер уйласаң бары шул гына!..*
*...Ак эшләргә хаклы тик гали җан,*
*Керсез вөҗдан, чиста күл гына.*

Ә менә Әхмәт Исхак Р. Фәйзуллинны да «уздыра»: дүртьюллык мәсәл иҗат итә.

*Бер әтәч уйлаган,*
*Карап таңга.*
*Ата, дип, көн дә таң*
*Мин кычкырганга.*

Күренеп тора: образ, аллегория бар, фикер ачык. Шул рәвешле тикшеренүне дәвам итеп, Якын һәм Урта Көнчыгыш шигъриятендә, кайбер Кавказ халыкларында, аерым алганда әрмән халкында, «мөхәммәс» исемле бишьюллык шигырь строфасына юлыгыла. Әмма мөхәммәс бер генә строфалы шигырь түгел. Аның беренче строфасында бер гомуми рифма яки рәдиф күренеше күзәтелә. Икенче строфаларның инде рифма төре бөтенләй башка була. Мәсәлән, төрекмән шагыйре Молланепеснның «Зөһрә һәм Таһир» дастаны шулай төзелгән. Тагын бишьюллык строфа формасы, испан лирик шигъриятендә «квинтилла» дип исемләнеп, абааб рәвешендә рифмалаша. Күренгәнчә, китерелгән мисаллар бишьюллык шигырьнең дөнья әдәбиятында очравын раслый. Әмма әлеге бишьюллыкларның поэтик үзенчәлекләре М. Мирза шигырьләре белән тәңгәл килми.

Җыентыкка туплап бирелгән шигырьләрне композиция, эчтәлек, күләм ягыннан миниатюралар дип исемләү дөрес булыр. Миниатюра дип аталган кече күләмле әсәр үзендә зур гомумиләштерүче яки ачык характерлы фикер яки образ йөртә. Поэтик сүзлектә: *«Миниатюра, лириканың иң катлаулы тирән эчтәлекле һәм тел тидермәслек дәрәҗәдә чарланган кыен формасы саналып, олы мастерларның гына кулыннан килә торган эш»*,—дип язылa. Миниатюраларга Гомәр Хәйямнең дүртьюллык фәлсәфи шигырьләрен, япон танкаларын кертәләр, шулай ук русларның частушкалары, фольклорда анекдот-мәзәкләр дә әлеге төркем кысаларында карала. Шулай да М. Мирзаны укуны дәвам итик:

*Хәерле сәгатьтә*
*Хәвеф-хәтәр чигәр...*
*Адәм баласына*
*Саваплы гамәлдә*
*Иман нуры иңәр.*

Әдәбиятта хискә эчтәлек ягыннан якын килеп карый торган «медитатив лирика» дип исемләнгән уйлану, уйга бирелү, көше тормышындагы проблемалар, дуслык, мәхәббәт, табигать һ.б.лар турында тирән уйга чуму характерындагы фәлсәфи шигырьләр күзәтелә. Әмма әлеге эчтәлекнең төгәл формасы билгеләнмәгән. Бу унайдан М. Мирзаның медитатив эчтәлекле шигырьләре үзләренең төгәл формасын тапкан дип уйларга мөмкинлек бар.

«Адәм баласы»нда тупланган шигырьләрне нәкъ менә шул яктан карау үзен аклар кебек. Беренчедән, шигырьләрдәге психологик киеренкелекне сизми калу мөмкин түгел. Икенчедән, медитатив подтекст булу киеренкелекне тагын да арттыра. Өченчедән, медитация термины фикергә нигезләнгән жанр төрен билгеләү өчен кулланыла. А. Пушкин, М. Лермонтов, Ф. Тютчевның да медитацияләре барлыгы мәгълүм. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Бабич, С. Сүнчәләйләрнең кайбер шигырьләре нәкъ менә шул жанрга карый.

Сүз уңаеннан Шамил Анакның (1928-2007) «Көзге сары яфраклар» исемле медитацияләре бар икәнлеген искәртеп китик. Аның әлеге төргә караган шигырьләре бер юлдан башлап биш юлгача формага салынган шигърияттле прозаны хәтерләтә. Анак медитацияләре белән Мирза шигырьләре арасында бердәнбер уртаклык, ул да булса, шагыйрьнең бер мизгелне тотып алуы гына. Форма башка, Мирзада эчтәлек тыгыз, кыска, ә Ш. Анак фикерне әйтергә теләгәндә «сүзне экономияләми» генә яза. Менә Ш. Анактан бер-ике мисал:

*Үлем түшәгендә ятканнар белән балалар гына*
*Дөреслекне әйтергә курыкмый.*

*Үткәннәрнең үз сүзләре булган, бүгенге*
*Көннең дә үз сүзләре бар.*
*Мин исә киләчәкнең сүзләрен эзлим.*

М. Мирза шигырьләрен япон танкасындагы кебек төгәл ике өлешкә бүлеп карарга мөмкин. Ә өлешләрне «Адәм баласы» шигъри юлы бәйләп тора. Биредә ул образ, символ мәгънәләренә дәгъва итә ала. Шигырьнең беренче ике юлына карата бу образ субъект вазифасында килсә, икенче өлешкә карата объект буларак карала ала. Башта Адәм баласының халәте, эше, гамәле күзәтелә, аннан соң аңа киңәш бирелә, нәрсәдер тәкъдим ителә. Шул рәвешле, М. Мирза «Адәм баласы»нда, беренчедән, эчтәлекне «эшләтә торган» үзгә форма таба алган. Икенчедән, моның белән генә чикләнмичә, тышкы форманы «эчке форма» белән дә «ныгытуга» ирешкән.

Беренче карашка ук сизелеп тора: мисалга китерелгән шигырьләр монарчы әдәбиятта күзәтелмәгән үзгә формалы шигырьләр. Беренчедән, ни өчен биш юл? Дөрес, татарда Хафиз строфасы дип аталган бишьюллык биш строфалы шигырь яшәп килә. Ләкин безнең очракта бер генә строфа күзәтелә. Шигърият өчен башта

мәкаль-әйтемнәрдә күзәтелгән, татар шигъриятенә Р. Фәйзуллин тарафыннан кертеп җибәрелгән берьюллык шигырь дә ят түгел. М. Мирза иҗатында да берьюллыклар бар, дөрес, шагыйрь «кош теле» дип исемләгән кыска шигырьләрен офицаль рәвештә икеюллыктан башлап кына «аера башлый».

Шагыйрьнең бишьюллык шигырьгә килү юлын күзәтеп карасак, анда «гыйбарәләр» исемендәге берьюллык шигырьгә юлыгыла. Менә берсе: *«Ризыктан разый булу фарыз»*. Билгеле, мәкальне хәтерләткән әлеге гыйбарә [ри—ра—фа] иҗекләрендәге сузык авазларны озайтыбрак укуны сорый. Әмма татар теле фонетикасы законнары буенча бу иҗекләрдәге сузык авазларга басым төшә алмый. Шигъри янгырашны [зык—зый—рыз] иҗекләре тәэмин итә, ә [Р] һәм [з] тартык авазлары аны көчәйтеп җибәрә. Шул рәвешле әлеге берьюллык гыйбарә шигырьгә куелган классик таләпләргә җавап бирә дип нәтиҗә ясау мөмкинлеге туа. Менә тагын бер шигырь: *«Шагыйрь энәсе һәрчак саплаулы»*.

Вакыт-вакыт Мирза үзенең бишьюллыкларына халык әйтем-мәкальләрен үзгәртмичә үк «кертеп куйган» кебек тоела. Шуңа аның кайбер шигырьләре пародияне хәтерләтә башлый. Тик пародия терминына бу очракта әдәби жанр буларак түгел, бәлки стилистик чара итеп карау сорала. Менә берничә мисал:

*Баш игән—бил бөгәр,*
*Бил бөккән—тез чүгәр...*
*Адәм баласының*
*Баш имәгәненнән*
*Тез чүккән йөз чөяр.*

*Сөяксез тел һәрчак*
*Артыгын сөйләгән...*
*Адәм баласының*
*Кәкре каенга*
*Аркасын сөягән...*

Дөрестән дә, алдагы шигырьләрнең беренче өлеше—мәкаль. Биредә цезуралар да идеаль урнашкан: ул алты иҗеклек юлларны өч иҗектән соң кисеп үтә. *«Баш—и—гән—/ бил—бө—гәр, // бил бө- кән—/ тез чү—гәр... //»* Ә икенче мисалдагы «сөяксез тел ни сөйләмәс» гыйбарәсе, рифма таләпләреннән чыгып, шигырьгә трансформацияләнеп кертелгән.

Мирза шигырьләренен, гәрчә һәрберсендә булмаса да, цезураның төгәл билгеләнгән урыны саклана. Менә мисал өчен берсе болай янгырый:

*...Тапканыннан артык*
*һични югалтмаган...*
*Адәм баласының*
*Кү-рә-сен / кү-рә-чәк /*
*Пәр-дә-се / кап-ла-ган. //*

Поэтика фәне буенча танылган белгеч Хәлиф Курбатов алты иҗекле шигырь юлларында цезураның нәкъ менә өчәр иҗектән соң килүен катгый таләп итә иде. Күренеп тора: әлеге таләп үтәлгән очракта, шигырьнең эвфония ягы күзгә күренеп яхшыра, янгырашы колакка ятышлырак була бара.

Ә икеюллык фәрд татарга «ана сөте» белән үк кергән форма, руслар аны «вирша» дип атый. Әдхәт Синугыл—Куганаклы бу жанрны үз итә иде. Ә М. Мирза иҗатында икеюллык шигырь «Киек каз юлында», «Тере су» җыентыкларында ук күзәтелде. Мисал өчен бер-ике шигырь:

*...Комганыннан көлә сәхнәдә*
*Тәһарәтсез татар баласы.*

*Гомер буе язган кызыл шигырь*
*Ак шигырьгә ничек күчсен хәзер?—*

дип шагыйрь, сүз уйнату аша, кинаяләп, ирония хисен белдереп кенә калмый, бәлки сатирага ук «дәгъва итә». Шагыйрьнең ирония-сатира тулы шигырьләре аеруча «Киек каз юлында» җыентыгында күп. «Адәм баласы» шигырьләре дә ирония белән

сугарылган. Ләкин, башка җыентыклардагы шигырьләрдән аермалы буларак, алар «усал» иронияле түгел, һәрхәлдә алда мисалга китерелгән ике шигырьдәге кебек «тешләми». Нигездә шагыйрьнең ирониясе лексик чаралар белән белдерелә, яисә антитеза кулланыла.

Мирзаның ирониясе тупас түгел, бәлки «нәзәкатьле ирония». Бигрәк тә әлеге үзенчәлек газәлләрдә чагыла. Дөрес, Мирза газәлнең традицион кабул ителгән темасыннан—мәхәббәттән читләшә, фәлсәфи якны көчәйтә төшә. Соңгы вакытта язылган газәлләренә Адәм баласы исемле гомумиләштерелгән образны да кертеп җибәрә. *«Бездәй атсыз яучабар бармы тагы? Без бер валчыгы зыялы затларның...»*—дип, әдәбиятта әлегә кадәр очрамаган өр-яңа метафора—оксюморон куллана. Мирзаның шигырьгә булган карашы да борынгы Көнчыгыш шагыйрьләрен хәтерләтә. *«Кичер, газәл, рөхсәтсез килеп керсәм, Син гүзәлне тупасланып «әрәнҗетсәм...»*,—ди ул.

Чыннан да, М. Мирза шигырьләре укучыдан киеренке акыл эшчәнлеген таләп итә. Шигырьнең ике юлын укуга, тизрәк фикерне шәрехләү теләге туа башлый. Чын фикер поэзиясе шулай булырга тиеш тә. Шагыйрь үзе дә юкка гына:

*Бу—минем шигырь бакчамда*
*Өлгергән тәү җимешләрем;*
*Өзеп алыгыз, кабыгыз*
*Үрелеп буегыз җиткәнен,—димидер.*

Өчьюллык терцет—шигырь, XIII йөздә Көнбатышта барлыкка килеп, татарда Дәрдемәнд иҗатында үсеш ала. Менә бер мисал:

*Болыт үтте./ Гөмберли күк/ еракларда.//*
*Сил шаулый, / сулар гөрли болакларда./*
*Тау-у-шы—/ колакларда... / озакларда...//*

Дәрдемәнд дүртәр иҗекле өч ритмик буын кулланган, әмма шигырьнең өченче юлында формаль рәвештә бер иҗеккә ким чыга. Шагыйрь әлеге «җитмәүчәнлек»не озын пауза белән «тутыра». М. Мирзаның үзендә төгәл алтыиҗекле өчьюллык болай яңгырый:

*...Мин бар кыйммәтләрне*
*Шигырь бизмәненә*
*Салып үлчим хәзер...*

Күренеп тора: шигырь чәчмә формага тартыла. Әмма бөтенләй үк «чәчелеп тә китми»: алтыиҗекле калып саклап тора. Шулай да Мирза шигырьләрендә цезуралар тәртибенең еш кына бозылуын да билгеләп үтү дөрес булыр.

Ә дүртьюллык тәмамланган робагый формалы шигырь соңгы елларда нык активлашты. Татарның «үз Гомәр Хәйямнәре» бар хәзер. Көнчыгыш шигъриятенең камил үрнәкләрен татарда шагыйрь Р.Гаташта очратырга була. Бу турыда галим Х.Миңнегулов «Робагый жанры һәм Гаташ» исемле хезмәтендә язып чыкты. Р.Гаташтан бер мисал:

*Ярый әле калды миндә сурәтең...*
*Шуңа карыйм, килсә сине күрәсем...*
*Сөйлим аңа, шигырь укыйм, баш иям...*
*Дәшми рәсем: ачуың зур, күрәсең...*

Робагыйның матур үрнәкләрен шулай ук Т. Миннуллин, Д. Гарифуллин, Г. Мөхәммәтшин, Ә. Саттар иҗатларында очратырга була. Башка күренекле шагыйрьләребез дә робагый жанрына еш мөрәҗәгать итә башладылар. Р. Харис үзенең робагыйларын туплап, «Шигырь язган каләм белән» җыентыгында өч телдә басып чыгарды. М.Мирзаның робагыйларыннан бер мисал:

*Бу дөньяның бердәнбер «Мин»нәре күп...*
*Һәрберсенең бәхетле «Миң»нәре күп...*
*«Миң»ле «Мин»нәр арасында тагы да*
*Мин-минлеге азынган тиңнәре күп...*

Дүртьюллык шигырь татарда еш очрый, юкка гына Р. Фәйзуллин әле 1977 елда ук «Мәгънә—робагыйларда!..» дип язмагандыр. Әмма аларның барысы да робагый жанрына куелган классик таләпләргә җавап бирми. Робагыйның рифмасы аааа, ааба, кайвакыт абаб рәвешендә килә. Бүген язылган робагыйларның һәрберсе дә робагый интонациясен биреп бетерә алмый, ярлырак килеп чыга. Бүгенге татар робагыйларына еш кына иҗтимагый яңгыраш «артыгы белән» килеп керә. Бары тик Р. Гаташ кына фәлсәфи һәм гыйшкый яңгырашны төгәл саклап яза. Аның робагыйларда фәнни һәм фәлсәфи эчтәлекне югары дәрәҗәдә саклавы турында галимә Р.Ганиева бик тәфсилләп язып та чыкты.

Робагыйлар М.Мирза иҗатында да шактый зур урын алып тора. Аның робагыйлары гыйшкый эчтәлеккә ярлырак, әмма фәлсәфи як күчлерәк, урыны-урыны белән иҗтимагый тенденцияне калкытып куюга нигезләнә.

Гомумән, М. Мирзага, гәрчә берничә поэмасы булса да, баштан ук кыска язу хас булды. Язу манерасында чичән шагыйрь Акмулла, Дәрдемәнд традицияләре ачык сизелә. Ә бишьюллыкларга килгәндә, бу үзенчәлекле иҗатта әлеге строфа формалы шигырь бүген генә килеп чыкмады. Шагыйрьнең алдарак чыккан җыентыкларында алар зур гына урын алып тора. Әмма алар «Адәм баласы» белән чагыштырганда бишьюллык строфа формасы буларак кына карала.

Ә менә Р. Фәйзуллинның махсус рәвештә формасын билгеләгән һәм һәрберсе исемле булган бишьюллыклары 1963 елдан бирле яшәп килә. Менә шуларның берсе:

*Һәр зат җирдә тигез булса—*
*кыя-таулар бөгелеп килеп,*
*үзәнгә тулыр иде!*
*...Каргалар шигырь укыса—*
*күгәрчен булыр иде!*

Р. Фәйзуллин шигырен нигездә өч һәм икеюллыклардан торган ике мөстәкыйль шигырьгә аерырга була (киресенчә булган очраклар да бар). Бередә шигырь юллары төрле үлчәмдә, ритмик буын тәртибе нигездә саклана, рифма бар, әмма ул төрле. Шигъри фикер туу барышы күзәтү һәм нәтиҗә чыгару өлешен аерып алырга мөмкинлек бирә. Ике шагыйрьдә охшаш яклар күренә. Шулай да образлылыкның Р. Фәйзуллинда күчлерәк булуын танырга кирәк (образлылык—төп сыйфат!). Тик ул бишьюллыкларын максатчан рәвештә билгеле бер системага салып дәвам итүне кирәк тапмаган, әйтик, япон поэзиясендәге «дэнтоси» традицияләренә нигезләнмәгән.

Ә менә М. Мирзада күпсанлы шигырьләрне билгеле бер системага кертү төгәл оештырылган. Аның шигырен уртада «Адәм баласы» образын кертү, мәкаль, халык әйтемнәрен күп куллану, шигъри үлчәмнең төгәллеге, метрсызлык, рифманың төгәл билгеләнгән урыны булу, инверсия алымы Р. Фәйзуллин бишьюллыкларыннан аерып тора. Шулай ук М. Мирзада кыскалыкка омтылу, афористик яңгыраш күчлерәк килеп чыккан. Ә Р.Фәйзуллин бишьюллыклары ирекле шигырьгә тартым, табигый сүз тәртибен инверсия формасында биреп, «шигырьгә куу» юк, шул сәбәпле бер төркем шигырьләрен җинел генә чәчмә формага китерергә дә була (мәсәлән, «Кайчак күбрәк ошый төшә мина...»), строфадагы юллар саныннан тыш, фикерне төгәл генә билгеләнгән башка формага салырга тырышу да сизелми. Шуның өстенә ул әйтергә теләгән фәлсәфәнең бер өлешен шигырьнең исеменә чыгара, ә Мирзада шигырь—исемсез, ягъни гомуми бер «Адәм баласы» исемле.

Сүз дә юк, «Адәм баласы» аерым игътибарга лаек. Бу шигырьләр шагыйрьнен яналыгын күрсәтә, һәр шигырьдә фикерне поэтик сурәт аша бирергә омтылу күзәтелеп, алар форма гына түгел, бәлки шигъри фикернең туу һәм яшәү рәвешенә дәгъва итә. Мисал өчен тагын бер шигырьгә игътибар итик:

*Үзе таңнан эштә,*
*Акылы төштән соң...*
*Адәм баласының*
*Кайчан, кайда, ничек*
*Авызы пешкән соң?*

Интонациясе буенча бу шигырь дә ак шигырьне хәтерләтеп куя. Ул төгәл ике өлешкә бүленә ала. Беренче ике юлда күренеш тасвирлана, ул картинаны, сурәтне хәтерләтә. Калган өч юл, шул халәткә карап, нәтиҗә чыгаруга яки бәя бирүгә юнәлтелә.

Әлеге яна шигырь формасын япон танкасы поэтикасына «куып кертеп карыйк». Танкага татар шагыйрьләре һәрвакыт сокланып караган, юкка гына З.Мансуровка *«Танка язып ятчы сау рухтан»*,—дигән фикер килмәгәндер.

Танканың борынгы формаларында урталагы өченче юл аерыбрак куела, ул бер үк вакытта шигырьне ике өлешкә бүлә дә, шул ук вакытта алар арасын тоташтыручы хезмәтен дә үти. Ә менә XIX гасыр танкаларында әлеге үзенчәлек күзгә бәрелеп тормый. Нәкъ менә әлеге «өченче юл» феномены М. Мирзаның «Адәм баласы»нда да күзәтелә. Танкада шигырь юлларындагы иҗек саннары биштән җидегә кадәр, барысы 31 иҗек була. М.Мирзада барысы 30 иҗек килеп чыга. Аерма зур түгел. Танкада төп фикер беренче өч юлга салына. Безнен шигырьдә—беренче ике юлга, ләкин өченче юл һәр ике өлеш өчен дә уртак. Нәтиҗә ахырдагы юлларда чыгарыла. Фикерне оештыру ягыннан М. Мирза шигыре япон танкасына форма һәм эчтәлек ягыннан өлешчә туры килә. Шунысын да искәртеп үтик, япон танкалары бөтен дөньяда поэтик осталыкның, форма кыскалыгы һәм ачыклыкның кабатланмас үрнәге буларак кабул ителгән. Ә кыскалык, ачыклык, үткен фикер—болар барысы да мәкальгә хас сыйфатлар. «Адәм баласы»нда алар, дөрестән дә, житәрлек. Менә берничәсе:

*Яман сүз—өшетер,*
*Мактау сүз—эретер...*
*Адәм баласының*
*Тел төбендә йөрер*
*Бер кашык дегете...*

Күренеп тора, монда мәкаль генә түгел, канатлы гыйбарә дә бар. Тагын бер шигырьгә мөрәҗәгать итик:

*Юрганына карап*
*Аягын сузмаган*
*Адәм баласының*
*Юраган тормышы*
*Хыялдан узмаган...*

Мәкаль, белем, фәлсәфә мәгънәләрен аңлата торган кече күләмле дидактик жанр Көнчыгыш поэзиясендә хикмәт дип атала. Аның асылында үтемле афористик формалы гыйбрәтле сүз әйтү ята. Хикмәт жанрында иң нәтиҗәле эшләгән шагыйрь ул—Мәүлә Колый, Акмулла һәм Дәрдемәнднен дә хикмәтләре булганлыгы билгеле. Әмма формасы буенча әлеге шагыйрьләрнең хикмәт жанрлы әсәрләре М. Мирзаныкына туры килми. Ә менә шигъри фикернең туу һәм яшәү рәвеше буенча Мирза шигырьләре хикмәт жанрына куелган таләпләргә җавап бирә. Беренчедән, хикмәт кечкенә күләмле, үткен, кинаяле сүзгә корылган дидактик характердагы жанр. Бу сыйфат хикмәт белән Мирза шигырьләре арасында уртаклык булуын күрсәтә. Икенчедән, кыскалык, афористик формада гыйбрәтле, акыллы фикер һәм мәгънә җиткерү ягыннан тагын бер уртаклык килеп чыга. Өченчедән, афоризм, халык әйтемнәренә нигезләнгән үтемле гыйбарәләр һәр ике шигырьгә дә хас. Ләкин хикмәтләр шигырь белән дә, проза катыш шигырь белән дә иҗат ителгән. Төрки-татар шигъриятендә беренче хикмәтләр Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганыйлар иҗатында күренә. XIII-XIV йөзләрдә Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» әсәренең 8 нче бүлеге хикмәт жанрында языла.

Димәк, Мирза бишьюллыклары эчтәлек һәм фикерне кую ягыннан хикмәткә якынайса да, форма күренеше буларак бөтенләй башка «исем сорый».

Шәрык поэзиясендә фәлсәфи яисә дидактик фикерне гәүдәләндергән кыска лирик шигырь кыйтга дигән исем белән йөртелә. Әмма аның формасы гаруз белән язылган икедән алып унгача булган икеюллык бәет строфасыннан гыйбарәт. Дөрес, азсүзлелек, фикер тыгызлыгы, ачыклык, афористик янгыраш ягыннан Мирза шигырьләре күпмедер дәрәҗәдә кыйтганы хәтерләтә, ләкин форма бөтенләй башка.

Әдәбият тарихында грекларнын антик трагедияләрендә күзәтелгән монологны тәмамлап куя торган, оригиналь уй, хикмәтле фикер әйтүгә корылган ике яки дүртьюллыклар күзәтелгән. Аларны гнома термины белән атыйлар. Гнома белән кешеләрнең үз-үзен тотышларына карата кыска анекдотлар чыгарылган. Әлеге афористик жанр Көнчыгыш әдәбиятында үсеш ала. Гнома чарланган формада оригиналь фәлсәфи фикер белдерү ягыннан Мирза бишьюллыкларына туры килә. Әмма шул фикерне формага салу ягыннан зур аерма килеп чыга. Димәк, Мирза шигырьләре «гнома» түгел дигән нәтиҗә чыга.

Димәк, татар әдәбиятында яна медитатив лирика үрнәге булган, яна миниатюр формалы хикмәт жанры традицияләрен янарткан «татар танкасы» барлыкка килүен танырга гына кала.

Билгеле, жанр ул—тарихи категория. Әдәбият белеме жанрларны кануни һәм кануни булмаганга аера. Мәгълүм бер үрнәккә таянып иҗат ителгән жанрлар кануни санала, аларда жанр билгеләре тотрыклы була, һәр әсәрдә янадан тергезелә, кабатлана. Ә кануни булмаган жанр үрнәкне кабатламый. Бу очракта кануни жанр билгеләре ачык сизелә. Шунысын да искәртеп үтик, кайбер жанрлар тарихи барышта үз позицияләрен югалтырга да мөмкин.

Дөнья әдәбият тарихында шагыйрьләрнең үзләре уйлап чыгарган шигырь формаларына исем бирүләре мәгълүм күренеш. Мәсәлән, борынгы грек шагыйре Анакреон, тормыш матурлыгын җырлый торган шигырьгә үз исемен биреп, тарихка кереп калган, антик шигырьнең спондей, дактиль, хорей стопаларын тезеп, яна форма уйлап чыгарган грек шагыйре Ферекрат исеме белән аталган шигырь дә яшәп килә. Әдәбиятта Хафиз яки Туфан строфасы, Онегин строфасы кебек атамалар яшәп килә. Ләкин бирedә сүз мөстәкыйль шигъри форма турында бара.

Шагыйрь, шигырьнең үзгә төзелешен (форма һәм эчтәлеген) уйлап тапкач, исемен дә, дөресрәге, бу лирик жанрның төрен (терминын) да билгеләр. Безнеңчә, бу очракта яна жанр формасын шагыйрьнең псевдонимыннан чыгып билгеләү ихтималы бар. Бәлки, ул «Мирза»дан чыгып, «мираз» (miraz), яки «римаз» (rimaz) дип исемләнә алыр. Русча аны «адамик» дип билгеләрләр кебек. Поэтикада кайбер жанр исемнәрен шулай атау кабул ителгән. Мәсәлән, couleur locale (французча) Couleur locale бер үк вакытта әдәби әсәргә җирле халыкның көнкүрешен, табигатен, менталитетын күрсәтә торган элементлар кертелгән текстта стилистик алым да булып санала. Ничек кенә булмасын, яна форма бар.

Димәк, әдәбият белеме сүзлегенә яна жанр формасын мондый рәвештә кертергә була: Miraz—татар шигъриятендә М. Мирза тарафыннан уйлап чыгарылган тәмамланган бишьюллык бер строфалы мөстәкыйль формалы шигырь жанры. Үзара тыгыз бәйләнгән ике күренешкә карата кулланыла. Мисрагълары, ягъни шигырь юллары алтышар иҗекле бердәй үлчәмле, ике һәм бишенче юллары үзара рифмалаша. Шигырьнең өченче юлында, борынгы япон танкасындагы кебек аерылып, гомумиләштерүче яки ачык характерлы Адәм баласы дип исемләнгән образ була. Баштагы ике юлда фараз итү урын алса, сонгы ике юлда киная, кинәш, тәкъдим йә булмаса нәтиҗә ясала. Композиция һәм тематикасы ягыннан зур картина шикелле була, ләкин Miraz аны кечерәйтеп сурәтләгән кебек тоела. Аның асылын акыллы, гыйбрәтле сүз әйтү, мәгънәле хәлне гәүдәләндерү тәшкил итә. Азсүзлелек, фикри тыгызлык, ачыклык, афористик янгырашны таләп итә. Текст эчендә әзер яки трансформацияләнгән мәкальләр кулланылырга мөмкин. Miraz әхлакый-фәлсәфи характерда була.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Яңгул

Янгул авылы Балтач районында, район үзәге Балтачтан—15, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән—31, Малмыж пристаненнән 25 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бу бик борынгы авыл. Ул Казан ханлыгы заманнарында ук булган. Яңгул авылы халкы июнь башында күршедәге Борнак, Ор, Сәрдегән, Алан авыллары белән бергәләшеп Тарлау жыены үткәргән. Бу жыен Янгул жыены дип тә йөртелгән.

Авыллар тарихын өйрәнүгә шәҗәрәләр шактый зур өлеш кертә. «Янгол шәҗәрәсе» Балтач районы Янгол авылын нигезләгән Янгол баба нәселенә нисбәтле. Янгол бабаның алты углы Түнтәр авылын да нигезләгәннәр. Олы буын авылны икенче төрле Янгол иле, Жангол иле дип тә атый.

Минем экспедиция дәфтәрендә авыл тарихы турында өлкән буын хәтерендә сакланган түбәндәге мәгълүматлар язылган: авылны беренче нигезләүче кешеләр Болгар дәүләтеннән чыккан. Татарлар башта хәзерге Түбән оч урынына килеп утырганнар. Алар килә башлагач, бу тирәдәге чирмешләр икенче урынга күчеп киткән. Кайберләре мөселманлык кабул иткән һәм татар арасында яшәп калган. Әле дә авылда чирмеш нәселләре дип йөртелүчеләр бар. Хәзерге Тау асты урамында элек чирмешләр торган. Авыл янында Чирмеш елгасы һәм Кирәмәт тау башы бар.

Янгул авылы элек урман белән әйләндереп алынган булган. Чәчүлек жирләр кирәклектән агачларны кискәннәр, басу-ышналар ясаганнар, шуна урман авылдан читенә барган.

Авыл Шушма суы буена утырган. Элек ул мул сулы булган. Анда тегермән эшләгән, хәзер инде аның амбарлары жимерелә башлаган. Монда балык тотарга хәзер дә бик еракларданкиләләр.

Шушма тирә-юнендә елга-инеш, күлләр, сазлыклар да шактый. Киндер чишмәсе суын Шушмага коя. Элек авылдан читкә бәхет эзләп чыгып китүчеләр, байлык белән кире әйләнеп кайтуларын теләп, чишмәдән су эчкәннәр һәм киемнәреннән берәр жеп алып чишмәгә салып калдырганнар. Элек, гадәттә, киемнәр киндердән булганлыктан, чишмәне дә Киндер чишмәсе дип атаганнар.

Авылны бер яктан таулар каплап тора. Бу гади генә тау түгел, аның буеннан-буена саф һәм шифалы сулы чишмәләр тезелеп киткән. Кешеләр чишмәгә юлны онытмый, су алырга, кер чайкарга киләләр. Чишмәләрне саклау эшенә жирле үзидарә һәм мәктәп укучылары зур көч куя. Һәр чишмәгә улак куелган, алар түбәле кечкенә өй эченә алынган.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Күлләрнең күренеклеләре: Сөлек күле, Якты күл, Үрдәк күле, Мунчала күле, Үтәй күле, Аю күле, Ташланган Шушма һ. б.

Мунчала күленең исеме чыпта сугу һөнәре белән бәйләнешле. Чыпта сугарга мунчала алу өчен юкә кабыгы батырылган сулыкларны Мунчала күле дип йөртәләр. Элек Янгулда мондый күлләр байтак булган, шуларның берсе авылдан якын гына, әлегә кадәр сакланып калган. Ташланган Шушма дип Шушма елгасының авылдан читтәрәк бер урынын атаганнар. Шушма елгасы су юлын үзгәрткәннән соң барлыкка килгән күлсымак сулык ул. Бу сулыкта берничә кеше батып үлгәч, анда коенмый башлыйлар.

Авыл читендә генә Тарлау бар. Ул хәзер үскән, зурайган, урман кебек булган. Анда кешеләр балан, җиләк, гөмбә, чикләвек һәм дару үләннәре җыярга баралар. Тарлауның бер почмагы Печмән дип, ә икенче бер почмагы Кортлык дип йөртелә. Анда колхозның умарталыгы урнашкан. Авылның югары оч ягында урнашкан Коры елганың суы юк, кешеләр анда җиләккә йөри, печән чабалар.

1929 елда авылда колхоз төзелгән һәм ана шул елның 7 маенда «Яна тормыш» дип исем биргәннәр. Тора-бара «Яңа тормыш» колхозы районда алдынгы колхозларның берсенә әверелә.

1941 елда башланган Ватан сугышына авылдан 500 гә якын кеше китә. 206 кеше анда башларын сала. Сугышта батырлык күрсәткәне өчен Гарифуллин Габдуллага Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ул —авылның горурлыгы.

Авылдан чыккан шәхесләрнең берсе—язучы Хәбра Рахман (Хәбибрахман Габдрахман улы Габдрахманов). Ул 1914 елда ярлы крестьян гаиләсендә туа. Кечкенәдән ятим кала, ике сеңлесен һәм энесен тәрбияләү аның өстенә төшә. Соңыннан туганнары белән балалар йортында тәрбияләнә. Хәбра Рахман Мәскәү янында барган сугышларда яралана һәм 1942 елның ноябрендә батырларча һәлак була. Ул «Батырлык өчен», «Сугышчан хезмәтләре өчен» һ. б. орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

Янгул Балтач районында зур авыллардан санала. Элек анда 1000ләп йорт булган, аны ике колхозга бүлеп йөрткәннәр. Ә хәзер авылда 300гә якын хуҗалык исәпләнә.

Авылда урта мәктәп эшли, мәдәният йорты, китапханә, икмәк пешерү комбинаты, элемтә үзәге, ашханә, даруханә, хастаханә, балалар бакчасы салынган. Сәүдә үзәкләре дә берничә урында.

Авыл тарихын өйрәнү өчен мәктәптә музей ачылган. Анда авыл тарихын, кешеләрнең тормыш-көнкүрешен сурәтләгән тарихи экспонатлар саклана.

Авыл янында ике зират бар. Аларның коймалары төзек, эчләре чистартылган. Зиратта шактый борынгы кабер ташлары да бар. Ул ташларны элек мәктәптә тарих укыткан, хәзер вафат булган Исмәгыйль абый укып өйрәнеп тә йөргән.

## Ямаш

Ямаш авылы Балык Бистәсе районында, район үзәге Балык Бистәсеннән —30, Арчадан 67 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы Казан ханлыгы чоры авылларын искә алу исемлегенә кергән. 1859 ел мәгълүматлары теркәлгән тарихи белешмәдән күренгәнчә, Суша суы ярына урнашкан Ямаш авылындагы 100 хуҗалыкта 304 ир-ат һәм 306 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет эшләгән.

Ямаш авылы халкы майның ахырында Иске Арыш, Яңа Арыш, Яншык, Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек, Күки авыллары белән бергә Байтирәк җыены, яисә икенче төрле Тегермәнлек җыены үткәргән.

Өлкән буын кешеләре сөйләвенә караганда, авыл оешканга кадәр бу урыннар калын кара урман белән капланып алынган булган.

Авыл исеменә бәйле бер кызыклы гына риваять тә бар. Ике кеше тау башына утырып чалбарларын ямый икән. Шул вакытта өченче бер кеше килеп: «Монда ни эш эшләп утырасыз?»—дип сораган. Тегеләр: «Безнең чалбар ямаш»,—дип әйткәннәр.

Авыл атамасы менә шулай барлыкка килгән, имеш. Бу—халык этимологиясенең бер үрнәге генә, әлбәттә.

Авылны беренче килеп нигезләгән кешенең исеме Ямаш булса кирәк. Татарстандагы күп авыллар беренче килеп урнашкан кеше исеме белән аталган.

Революциягә кадәр Ямаш авылы Казан губернасы, Лаеш өязе Урахчы волостена кергән. Авыл ике мәхәлләгә берләшеп яшәгән. 1908 елда икенче мәчет салына.

Аерым хуҗалык чорларында Ямаш халкы артык хәлле булмаган. 200 хуҗалыкларда төрле катлау кешеләре яшәгән. Авылдагы 80-90 процент халык кечкенә, түр якта ике генә тәрәзәле, салам түбә белән ябылган йортларда көн күргән. Капкалар «җил капка» дип йөртелгән. Крестьяннарның 35-40 проценты атсыз, бик күпләре җирсезлектән интеккән. Шуның өстенә, табигать шартларының начар, янгыр юклык аркасында иген уңышы начар, ашарга икмәк булмый. 1890, 1897, 1911, 1921 елларда көчле ачлык килә. Бу дәһшәтле елларда Идел буйларындагы халык, шул исәптән Ямаш халкы да ачтан кырыла.

Авыл халкының төп кәсебе юкәдән чабата үрү һәм агач башмак ясау булган. Берничә кеше җир өйдә яшәгән. Бик күпләрнең өйләрендә җир идән, карындык тәрәзәләр булган. Халыкның төп ягулыгы— салам. Урман авыл өстенә авып торса да, аңа керү мөмкин булмаган. Аны мылтыклар белән урман сакчылары саклаган.

Авыл халкы тыныч һәм тату гына яшәмәгән, ызгыш-талашлар да булгалаган. Бәйрәмнәрдә, аерым алганда җыеннарда, сабан туйларында сугышканнар. Күп вакытта бу сугышлар сыйнфый көрәш төсен алган. Ярлылар бай катлау кешеләрен ыратып бетермәгән.

Авылда халык урамнарны үзенчә атый: Иске урам, Тәкә тау урамы, Кибет урамы, Җыбанай урамы, Түбән урам, Чутай урамы, Солылы борай урамы һ. б. Көчләп чукындырылган һәм чиркәүдә теркәлгән, ләкин кире мөселманлыкка кайткан кешеләрне «солылы борайлар» дип атаганнар. Соңгы урам атамасы шуна ишарәле дип уйларга кирәк.

Авыл табигатьнең матур урынына утырган. Янында таулар да, елгалар һәм болынлыклар да бар. Такталык юлы, Тәбе тавы, Әче елгасы, Чошы елгасы, Алдырбиш болынлыгы атамаларын халык ярaтып куллана. Авылның нәкъ уртасында, иң матур, яшеллек белән капланган чирәмлек җирдә җир астыннан чишмә тибеп чыккан. Аңа Корбан чишмәсе дигән исем биргәннәр. Элеккеге вакытларда анда корбан чалып, учак ягып аш пешергәннәр. Җәй көне, янгыр яумаса, шунда төшеп янгыр боткасы пешергәннәр, янгыр теләгәннәр. Корбан чишмәсенең суы артык тәмле түгел. Чисталыгын чиста, ләкин суы күкертле. Шул сәбәпле аны эчмиләр, суны башка максатларда файдаланалар.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# К

**КӘРИМ** (Кәримев) Фатих Әхмәтвәли улы (9.1.1909, Уфа губ., Бәләбәй өязе, Әет а.—19.2.1945, Калининград өлкәсе Багратионовск ш.), шагыйрь. 1922-24тә Бәләбәй пед. техникумы каршындагы әзерләү курсларында, 1925-29да Казан Җир сөрү техникумында укый. 1933кә кадәр «Кечкенә иптәшләр» (Мәскәү) газетасында, «Яшь ленинчы», «Крестьян газеты», «Кызыл армеец» газеталары, «Атака», «Азат хатын» ж-ллары редакцияләрендә эшли. 1933-37 дә Татар китап нәшриятында балалар әдәбияты секторын җитәкли. 1920 нче елларда матбугат битләрендә басыла башлый. Иҗатының башлангыч чорында ул елларга хас булган кычкырып торган гражданлык, лозунгка тартым публицистикалык, Һ.Такташ, Х.Туфан, В.Маяковскийлар кебек новатор шагыйрьләр стилистикасы йогынтысы күзәтелә («Безнең һәйкәл», 1932; «Еллар каршысында», 1932). «Җиденче мич» (1931), «Яшен яктысы», (1932), «Тавышлы таң» (1933), «Аникин» (1936) поэмаларының тематикасы ш.у. замана рухын чагылдыра: алар Гражданнар сугышы, сыйнфый көрәш, хезмәт кешеләре тарафыннан төзелгән матур киләчәк турында. Иҗатына лирик-романтик интонация («Зәйтүнә», 1932; «Котәм сине», 1935; «Дулкынланып китте ак болыт», 1935; «Таныш бу күзләр», 1936), жанр төрлелеге (шигырь, эпиграмма, җыр, баллада, поэма, хикәя, повесть, драма, фельетон) хас. 1938 дә К.не, милләтчелектә гаепләп, кулга алалар һәм 10 ел лагерьга хөкем итәләр, ләкин 1941 дә азат итәләр. К. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942-45тә ул аеруча рухи күтәренкелек кичерә. Бу елларда ул татар әдәбиятында билгеле бер күренешне тәшкил иткән шигырь һәм поэмалар яза. Сугыш еллары шигырьләренең лирик герое—Ватаны өчен үз-үзен аямыйча көрәшкән батыр сугышчы тора («Теләк», «Ант», «Ак күгәрчен», «Бездә яздыр», «Ватаным өчен», «Кошлар», «Юл», барысы да 1942). Автор кешенең сугышта күргән барлык кичерешләрен чагылдырырга (күрсәтергә, тасвирларга) тырыша: якыннарына («Газиз әнкәй», 1943; «Һөҗүм», 1943; «Бизәкле ал яулыгын», 1945), туган табигатенә карата («Шомырт куагы», «Соңгы тапкыр карыйм Иделгә», икесе дә 1942) мәхәббәт, сугышның кешегә һәм тереклеккә карата дошман булуын тасвирлый. К. иҗатының иң югары ноктасы булып «Кыңгыраулы яшел гармун» (1942) поэмасы тора. Әсәрнең төп герое булган Фазыл образында совет солдатының батырлыгы һәм җиңүгә ныклы ышанычы чагыла. 1943 тә героик күтәренкелек автор иҗатында трагик чынбарлыкны тою, тиздән килеп җитәчәк үлемне сизү б-н алышына. Сугышта һәлак була.

Әсәр.: Илең турында уйла. К., 2000.

Әд.: Мазитов З. Поэзия Фатиха Карима. К., 1955; аныкы ук. Фатих Кәрим // Татар әдәбияты тарихы. К., 1989. 5 том.

*Н.М.Йосыпова.*

**КӘРИМ** (Кәримов) Хөсни (Хөснетдин) Минһаҗетдин улы (15.12.1887, Уфа губернасы Бөре өязе Тайморза ав.—25.12.1965, Казан), язучы, педагог, җәмәгать эшлеклесе. «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач (1911), үзлегеннән хәзерләнеп Царицын шәһ. реаль уч-щеда рус теле мөгаллимлегенә имтихан тота. 1914 елга кадәр Астрахань шәһ. рус-татар мәктәбендә укыта, «Идел» исемле җирле газетада актив хезмәттәшлек итә: хикәяләр, фельетоннар яза, халык мәгариф системасындагы җитешсезлекләр турында тәнкыйть мәкаләләре бастыра. К.ның журналистлык эшчәнлеге полиция күзәтчелеге астына алына һәм ул Уфа шәһәренә, аннан Бөре өязе Богдан ав. күчеп китәргә мәҗбүр була. 1917 елдан соң Бөре өязе халык мәгарифе бүлеген җитәкли. 1919-24 елларда Уфа шәһ. мәгариф бүлегенең мөселман әдәбияты секциясе мөдире, Идел буе хәрби округы каршында татар-башкорт гаскәриләре өчен ачылган курсларда лектор һәм сәяси җитәкче, аннан РКП(б)ның Уфа губерна ком-ты каршындагы татар-башкорт нәшрияты бүлеге мөдире булып эшли. 1924тән Казанда: 1926-36да Главлит җитәкчесе, Татарстан ҮБКның читтән торып уку бүлеге мөдире һәм Татарстан радиокомитетының әдәби-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

музыкаль тапшырулар секторы мөдире вазифаларын башкара. Нигездә крестьяннар тормышыннан алып язылган «Атна кич, яки Шакир хәлфә» (1910) драмасы, «Җан исәбен алганда» (1927), «Ертылган приказ» (1929), «Октябрьгә чаклы» (1935) дигән повестьләр авторы.

Әсәр.: Ике дус. К., 1969.

Әд.: Кәримова З. Онытылмас хатирәләр // Казан утлары. 1968. №9.

**КӘРИМИ** (Кәримев) Фатих (Мөхәммәтфатих) Гыйльман улы (17.3.1870, Самара губ., Бөгелмә өязе, Минлебай а.—27.9.1937, Мәскәү), язучы, нәшир, җәмәгать эшлеклесе. Башлангыч белемне өйдә атасыннан ала. 1892 гә кадәр «Камалия» (Чистай ш.) мәдрәсәсендә укый; берүк вакытта рус теле һәм әдәбияты дәресләренә дә йөри, моның өчен (һәм ш.у. шәкертләр арасында «Тәрҗеман» газетасы идеяләрен таратып йөргән өчен) мәдрәсәдән куыла. 1892-96 да чиновниклар тәрбияли торган «Мәктәп мөлкияшаханә» (Истанбул) югары уку йортында укый. Гарәп, фарсы, төрек, француз телләрен өйрәнә. 1896-98 дә Таврия губ., Ялта өязе, Дара күе мәдрәсәсендә укыта. 1899 нын февраль-маенда М.Рәмиев б-н бергә Европаның берничә иленә сәяхәт кылалар; шул ук елда Мәскәүдә нәшрият эшен һәм немец телен өйрәнә. 1899 нын июлендә гаиләсе б-н Оренбург шәһәренә күчеп килә. Җәен Каргалы бистәсендә җәдитчә укыта торган укытучылар әзерләү курсларында укыта. 1900 дә С.-Петербургта И.М.Борагинский нәшриятында практика үтә. 1902 дән, атасы вафатыннан соң, «Кәримев, Хөсәенев вә шөрәкясе» басмаханәсе б-н җитәкчелек итә. 1906 да мөселманнар әдәби түгәрәген оештыра. 1906 дан «Иттифак әл-мөслимин» партиясе Үзәк Комитеты әгъзасы була, 1906-17 дә—«Вакыт» газетасы баш мөхәррире, 1917 дә—Оренбург мөселманнары Бюросы рәисе. Бөтенроссия мөселманнары съездларына сайлана (1905, 1906, 1914, 1917). 1917нең маенда 1 нче Бөтенроссия мөселманнары съездында Оренбург делегатларыннан Милли Шура әгъзасы итеп сайлана. 1917 нен 1 ноябреннән «Яңа вакыт» газетасын нәшир итә башлый. 1917-24 тә Оренбургның төрле уку йортларында укыта. 1919дан «Эшчеләр дөньясы», «Юл» газеталарында язышa һәм аларның редколлегияләрендә тора (исәпләнә). 1925тән Мәскәүдә яши, СССР халыклары Үзәк нәшриятының татар бүлегендә эшли, Көнчыгыш ин-тында төрек телен укыта, «Эшче» газетасында язышa. 1937нең августында кулга алына һәм «Төркия файдасына шпионлык кылуда һәм партия җитәкчеләренә каршы террор актлары оештыруда» гаепләнә. Шул ук елның сентябрендә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе тарафыннан үлемгә хөкем ителә; 1959 да реабилитацияләнә.

К. иҗатының төп идеясе—иске укыту ысулларын тәнкыйтьләү, татар мәктәбендә реформалар үткәрү өчен көрәш. Авыл мәдрәсәсен тасвирлаган «Җиһангир мәхдүм» (СПБ., 1900) хикәясе—К.нең беренче әсәрләреннән. Автор мәдрәсә шартларының мескенлеген, укыту ысулларының искергәнлеген күрсәтә. «Салих бабайның өйләнүе» (1901) хикәясе герое—умартачы Салих бабай авыл балаларына үз тормышыннан вакыйгалар сөйли. К. геройның бай рухи дөньясын күрсәтә, «гади» кешенен дә тормышы кызык һәм бай икәнлеген дәлилли. «Бер шәкерт вә бер студент» (1899) повестендә язучы гротеск ярдәмендә кадимче муллаларның наданлыгын тасвирлый. Вакыйга шәрекъчы рус студентының Бохарада белем алган татар мөдәррисе б-н пароходта алып барган әңгәмә тирәсендә бара. Мөдәррис студентның гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә биргән гади сорауларын да аңламый. Кадимчеләрнең дошманы булarak, К. аларның наданлыгын күпертеп күрсәтә һәм шуның аркасында мөселман руханиларының каттый тәнкыйтенә дучар була. «Нуретдин хәлфә» (1899, нәшер ителә 1996) повестенда да К. кадимче мулла образына мөрәҗәгать итә. Мәгърифәтчелек романтизмы рухында язылган «Морза кызы Фатыйма» (1901) повестенең төп героинясы бакчачыга булган мәхәббәте хакына өен ташлап, сөйгәне б-н чит илгә китеп бара. Качып киткән яшьләрне куып җитеп, кызның әти-әнисе никахка ризалыкларын бирәләр. Язучы саф мәхәббәтнең тантанасын күрсәтә, укучыны кешенең дәрәҗәсе чыгышына гына түгел, ә күңел сыйфатларына бәйле икәненә дә инандыра. «Хыялмы? Хакыйкатьме?» (1908) повестендә 2 нче Дәүләт думасы депутаты һәм мәгърифәтле татар хатыны арасында барган әңгәмәдә милләт язмышы кайгыртыла. Язучы әңгәмә темасы б-н тирән кызыксыну күрсәткән, ә асылда бу кызны ничек итеп икенче хатынлыкка алырга икән дип уйлап утырган депутатны ирония б-н тасвирлый. К.—сәяхәтнамә жанрында язылган берничә китап авторы. «Европа сәяхәтнамәсе» (СПб, 1902) китабында ул 1899дагы сәяхәте турында яза, татар һәм Европа халыклары көнкүрешен һәм мәдәниятен чагыштыра, соңгыларының уңышларына сокланып карый. Татарның арттa калуын уку системасын үзгәртергә, укыту программаларына дөньяви дисциплиналарны кертергә теләмәве б-н аңлата. Шундый ук фикерләр 1903 тә Бакчасарай шәһәренә «Тәрҗеман» газетасының 20

еллыгын бәйрәм итәргә барганда алган тәэсирләре «Кырымга сәяхәт» (Оренбург, 1904) китабында да урын ала. 2 нче Балкан сугышы вакытында «Вакыт» газетасында басылган хат-язмалар җыентыгы «Истанбул мәктүбләре» (Оренбург, 1913) исеме б-н аерым китап булып нәшир ителә һәм К. иҗатында әһәмиятле урын ала. Бу очерк формасындагы хатларда К.нең Төркиянең икътисады, сәясәте, мәдәнияте, мәгарифе тарихына карата булган фикерләре урын алган. Төркиянең икътисади уңышсызлыкларын, хәрби потенциалы йомшаклыгының сәбәбен ул укыту системасының артта калганлыгы б-н аңлата. К. рус, француз, төрек фәнни-популяр әдәбияты тәрҗемәчесе булып та таныла. Ул ш.у. Польша язучысы Ф.Ф.Пуцековичның дөньядагы 30 халыкның тормышы һәм көнкүрешенә багышланган берничә брошюрасын, 1917 дән соң В.И.Ленин, ориенталист В.В.Бартольд хезмәтләрен тәрҗемә итә. К. тарих, география, педагогика буенча дәреслекләр авторы: «Мөхтәсар җәгърафия» (1899), «Мөгаллим вә мөрәббиләргә рәһнамә» (Оренбург, 1902), «Мөхтәсар тарихе гомуми» (Оренбург, 1911) һ.б. К.нең иҗаты һәм тормышына караган мәгълүматлар ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, ТРның Милли архивында, «Казан» милли-мәдәни үзәгенең Милли мәдәният музеенда саклана. Әлмәт р-ны Миңлебай авылында 1998 дән Кәрими музее эшли.

Әсәр.: Мәрһүм Гыйльман ахунд. Оренбург, 1904; Аннан-буннан. Оренбург, 1907; Ф.Кәрими әсәрләре. К., 1925; Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860—1905). К., 1979; Морза кызы Фатыйма: Сайланма әсәрләр. К., 1996; Istanbul mektuplari. Ist., 2001.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1997; Ямаева Л.А. Мусульманский либерализм начала XX в. как общественно-политическое движение. Уфа, 2002; Ахунов А. Запечатлённое слово Ф.Карими // Татарский мир. 2004. №5; Гайнетдинов М. Мәгърифәтче әдип // Мирас, 1995.№ 7/8; Абдуллин Я. Җәдитчелек хәрәкәте һәм Ф.Кәрими // Татарстан. 1996. №6; Әхмәтҗанов М. Ф.Кәрими мирасына яңа сәхифәләр // Казан утлары. 1999. №6; Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык—Фатих Карими: Научно-биографический сборник. К., 2000; Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. К., 2004.

*А.М.Ахунов.*

**КӘРИМОВ** Камил Әдһәм улы (1.7.1950, Питрәч р-ны Шәле ав. туа), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан мәдәният ин-тын тәмамлагач (1980), «Яшь ленинчы» газетасында хәбәрче булып эшли. 1982-88 елларда «Идел» альманахында җаваплы мөхәррир, 1988-2000 дә «Чаян» журналында җаваплы сәркәтип. 2000нән «Казан утлары» журналының проза бүлегендә мөхәррир булып эшли. К. беренче хикәяләреннән үк («Үндүрт яшьтә» җыентыгы, 1981), лиризм белән юморны оста бәйләгән, үзенчәлекле язу стиле булган автор буларак таныта. Аннан алдагы әсәрләрендә дә юмористик интонация тагы да көчәеп, сатирик мотивлар өстенлек ала бара («Бәхетле кеше», 1984; «Вәгъдә», 1985; «Күләгәдә төлке бар», 1990); «Үзеңне бел», 1997; «Өй артында шомыртым», 2003). Мелиораторлар тормышы һәм аларның хезмәтенә багышланган дилогиянең беренче китабы «Ком сәгате» (2000) романы тәнкыйтьчеләр һәм укучылар тарафыннан югары бәяләнде. 2003 тә дилогиянең икенче өлеше «Сакау күке» исеме белән «Казан утлары» ж-лында басылып чыкты. «Уен» романы («Казан утлары», №6-7, 2007). К. 1988-2000 елларда телевизион шаян тапшыруларның авторы һәм алып баручысы.

Әд.:Әдипләребез. Биобиблиографик белешмәлек. К; 2009. т.I.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Альфред
Халиков

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

**ТИМИРЯЗЕВЛАР.** 1408 елда Урдадан китеп Бөек кенәз Василий Дмитриевичка хезмәткә чыккан Ибраһим Тимиряздан (ОГДР VIII, 16). Бу князь башта Идегәйнен 1408 елда Мәскәүгә һөҗүм иткән гаскәрендә торган (ПСРЛ 34, 157). Фамилиянен нигезендә төрки *тимер язы* «тимер сугышчы» атамасы ята (Баскаков 1979, 215). Бу нәселдән атаклы галимнәр, хәрбиләр чыккан.

**ТУХАЧЕВСКИЙЛАР.** Н. А. Баскаков (1979, 201-203) фикеренчә, Тухачевкийлар төркиләрдән чыккан кешеләр булырга охшый, моны аларнын фамилияләре нигезендә яткан тухачи «байрак йөртүче» сүзе дә раслый. Бу нәселдән совет полководецы Тухачевский мәгълүм.

**УВАРОВЛАР.** XIV–XV йөзләрдә Урдадан Бөек кенәз Василий Дмитриевичка чыккан Минчак Касаев (Касаевич) улы Уварданн ( ОГДР V, 33). Давыдовлар, Злобиннар, Оринкиннар (к.) белән тугандаш. Нәселләрендә—графлар, галимнәр, хәрбиләр.

**УЛАНОВЛАР.** Төрки улан «егет, жайдак, булдыклы» сүзеннән ясалган, кин таралган фамилия (Веселовский 1974, 331). Араларыннан—Белоруссия Полесьесында җирләр алган, Польша-Литва татарларыннан булган Уланов. 1791-1792 елларда полковник Александр Уланов рус хезмәтенә күчә, Улановлар шунардан (В. D., 1986, 108).

**УРУСОВЛАР** (Урдадан чыкканнары). 1408 елда рус хезмәтенә чыккан кенәз Урустан Меньскийдан (Минскийдан) (ПСРЛ 25, 237). Анын нәселеннән Михаил һәм Григорий Евстафьевич Урусовлар 1540 елда Кашинда теркәлгәннәр, ахрысы. (Веселовский 1974, 333).

**УРУСОВЛАР** (Нугайныкылар). Нугай кенәзе Едигейнен (к.) туруны, кенәз Исмәгыйльнен (Йосыфнын ир кардәше, Казан ханбикәсе Сөембикәнен абзые) улы кенәз Урустан (Мәхмәт Айдаровичтан). Кенәз Урус XVI йөзнен 60нчы елларында рус хезмәтенә чыккан (ОГДР VI, 1; ИРРД I, 216). Фамилиянен нигезендә урус «рус» яки «сугыш чукмары, сугышчан» дигән төрки сүзе ята (Баскаков 1979, 187-188; Гафуров 1987, 197).

**УШАКОВЛАР.** Нәсел башы төрки булган Касуй Урданың князе Редегадан, анын ике улы булып, чукынганда Юрий һәм Роман исемнәре алганнар һәм киев-славян хезмәтенә күчкәннәр. Роман Редегич турунынын улы Григорий Слепойнын Ушак исемле улы

*Дәвамы. Башы үткән елгы 5, 6, 8, 9, 11, 12, быелгы 2 саннарда.*

булган һәм аңардан Ушаковлар башланган (ОГДР VIII, 9). Ушаков фамилиясенең нигезендә төрки *ушак* «кечкенә, кечкенә буйлы» сүзе ята (Баскаков 1979, 71).

**ХИТРОВЛАР.** XV йөзнең башында ир кардәше Салахмир белән Бөек кенәз Ольг Ярославич Рязанскийга чыккан Алтын Урда морзасы Едуган Сильно-Хитрдан (ОГДР I, 57; БК II, 395). Апраксиннар, Измайловлар, Татищевлар, Ханыковлар (к.) белән тугандаш.

**ХРУЩОВЛАР.** Төрки-мөселманнар арасыннан чыккан йомышлылардан, күрәсең, чөнки гербларында аларга хас ярым ай һәм ук бар (ОГДР II, 11). Кайберләре төрки исемле булу (Адаш Хрущов), шулай ук, гадәттә төрки мохиттән чыгучыларның күпчелеге урнаша торган Россиянең көньяк чикләрендә, бу очракта Тула өязендә төпләнүләре шул турыда ук сөйли (Веселовский 1974).

**ЧААДАЕВЛАР (ЧАГАДАЕВЛАР, ЧЕГОДАЕВЛАР).** *Чагатай* «батыр» дигән төрки-монгол сүзеннән (Баскаков 1979, 223). Бу исем башка руслар арасында XV йөздә үк күренә, мәсәлән, Муром янындагы җирләре белән Василий Чегодай (Веселовский 1974, 348). Ихтимал, ата-бабалары Казан белән бәйле булганнардыр, чөнки анда 1568 елда стрелецлар башлыгы Чаадаев Суббота Григорьев теркәлгән (ПКК, 29, 38-41). Чаадаевар дворян итеп 1621 елда язылганнар (ОГДР IX, 42). Нәселләрендә танылган рус фикер иясе П.Я.Чаадаев мәгълүм.

**ЧААДАЕВЛАР-СПЕШНЕВЛАР.** ОГДРда (VII, 36) Россиягә XVI—XVII йөзләрдән дә соңламыйча чыккан Чаадаевлар турында тагын бер язма бар: «Спешневларның Чаадай фамилиясе,ә изге чукындыруда Васильев Спешневка, 7118 (1610) елда Мәскәүне яклап сугышканы өчен җирләр бирелгән һәм шул хакта шушы грамота». Чагыштырмача соң чыгулары, бабаларының фамилиясе шулай ук казанлылардан икәнлекләре турында сөйләргә мөмкинлек бирә (РБС XIX, 268).

**ШАДРИННАР.** XV йөзнең икенче яртысында телгә алынган Иван Васильевич Шадра Вельяминовтан (к.). XY-XY1 йөзләр чигендә һәм XVI йөзнең икенче яртысында Шадриннарның Новгородта һәм Мәскәүдә яшәгәнлеге билгеле (Веселовский 1974, 359). Фамилиянең нигезе этимологиясе бәхәссез төрки—шадра сүзе.

**ШАЛИМОВЛАР.** 1568 елда Казанда яшәгән басурман Шалимов Истомнан (ПКК, 14), ләкин борынгырак та булуы ихтимал,чөнки Шалимовлар алпавытлар буларак Новгород белән Владимирда XV йөзнең икенче яртысыннан билгеле (Веселовский 1974, 360). 1741 елдан дворян булып расланганнар (ОГДР III, 117). Н.А.Баскаков (Баскаков 1979, 137) нәселнең төркиләрдән икәнлегенә шикләнми һәм фамилиянең нигезен *Шах алим* дигән төрки-фарсы кушаматы белән бәйли, ягъни «галимнәр патшасы».

**ШЕРЕМЕТЕВЛАР.** Россиядә бик мәшһүр фамилия, графлар, кенәзләр. Шереметевларның шәҗәрәсе белән махсус шөгыльләнгән А.А.Зимин (1980, 180) фикеренчә, соңгылары XIII йөздә Александр Невскийга чыккан Андрей Кобыла нәселеннән. Кобыланың бишенче буыны (турунының оныгы) Андрей Ширәмәт, ә аның ир кардәше Семен Епанча (XIV гасыр ахыры) булган. Андрей Ширәмәттән Шереметевлар башлана да инде, бигрәк тә Россия тарихында XVI (Казанны алу, ливон сугышлары), XVII—XVIII (Петр I нең дуслары) (РБС XXIII, 106-230). Н.А.Баскаков (1979, 82-84) фикеренчә, фамилиянең нигезендә *шеремет* «мескен» төрки-болгар (чуаш) сүзе яки «Шир Мөхәммәд» (батыр Мөхәммәд, намуслы) дигән төрки-фарсы сүзе (Гафуров 1987, 212) ята.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ФРОНТОВИК ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ХАТЛАРЫ

*Бөек Ватан сугышы чорында татар язучыларының күбесе фронтның алгы сызыгында булалар. Дошманга каршы көрәштә батыр сугышчы фронт газеталарында талантлы хәрби хәбәрче—болар безнең әдипләребез! Нинди генә шартларда да алар һәрвакыт язучы булып калалар, әсәрләрендә сугышның чынбарлыгын, совет сугышчыларының батырлыгын яктырталар. Фронтовик язучылар туган як белән бәйләнешләрен өзмәскә тырышалар, туганнары, китап нәшрияты, «Совет әдәбияты» журналы, тылда калган язучы иптәшләре белән хатлар алышып торалар. Әдип Гомәр Бәшировның архивында 18 язучының сугыш елларында фронттан язган 82 хаты саклана. Бу—татар язучыларының архивларында яткан хатларның, кадерле хәзинәнең кечкенә бер өлеше генә булырга тиеш. Ә ул хатларда дәһшәтле сугышның сулышы, язучыларның уй-хисләре, көндәлек тормышлары, иҗат планнары—барысы да бар. Ул хәзинә һичшиксез кайчан да булса тулысынча киң укучыга ачылырга тиеш.*

*Бөек Ватан сугышы җиңү белән тәмамланганга 65 ел тулган көннәрдә исемнәре һәркемгә билгеле булган татар фронтовик язучыларының Г. Бәшировка юллаган хатларыннан бер өлешен укучылар игътибарына тәкъдим итәм. Батыр сугышчы, ялкынлы шагыйрь Фатих Кәримнең 1944 елның ахырында язган хатында: «Онытмагыз мине!» дигән юллар бар. Бу сүзләрне шагыйрьнең аерым бер язучыга гына түгел, ә бөтен татар халкына, хәзерге һәм киләчәк буыннарга сугыш кырларыннан ил батырлары исемнәреннән дә әйтелгән изге әманәте дип кабул итәргә кирәк.*

**Зөфәр БӘШИРОВ**

Гомәр дус!

Сиңа һәм синең подразделениеңдәге барлык егетләргә һәм кызларга сәлам. Мин исән. Аннан да бигрәк, син исән икәнсең—шунысы өчен сөендек. Сәламәтләнеп житүең—бик сөенечле хәл. Югыйсә, синең хәлне мина бик хәвефле итеп сурәтләгәннәр иде.[1]

Син миңа хат язгансың. Алдым. Бик сөендем. Бергәләшеп, кәлә-кәлә, рәхәтләнеп укыдык. Мондагы егетләрнең һәммәсе дә сиңа сәлам тапшырырга куштылар.

Мин жибәргән әйберләрне тапшыра торасыз икән, анысы өчен дә бик зур рәхмәт.[2] «Генерал»ны тапшырдыгызмы? Тапшыргач, «К.Татарстан»га бирсәгез иде. Якуб абзый турында халык белеп торсын. Ул безнең сирәк картларыбыздан берсе.

Бу араларда сезгә очерклар жибәрә алмадым. Чөнки язмадым. Ни өчен дисәң, Казан өчен тагын бер китап хәзерләп ятам. Исеме «Ут сызыгында» булыр. Бу

[1] 1943елның март аенда Г. Бәшировны эштән кайтканда караңгы кичтә йөкле автомобиль бәреп, башын каты жәрәхәтли. 3 атна больницада ята,соңыннан озак кына вакыт укый-яза алмый.

[2] 1942-44 елларда Г. Бәширов ТАССР ХКС каршындагы Радиолаштыру һәм радиотапшырулар комитетында баш мөхәррир булып эшли.

турыда моннан берничә көн элек Кәшшафка хәбәр иткән идем. Зур әйбер өлгертеп булмады, 3-4 табаклык бер китап басып ташларга кирәк.

Син андагы хәлләр белән безне шулай таныштырып тор инде. «Совет әдәбиятының» 4 нче номеры килде. Әмирхан Еники хикәясеннән башка материаллар миңа бик сыек тоелдылар. (Тукай турындагы бер-ике мәкаләне искә алмыйм).

Минем хатынга сездән тиешле булган акчаны биреп җибәрә алмассызмы.

Хат яз.

Дусларча сәлам белән Хатип Госман.

22.7.43

***

Сәлам Сезгә Гомәр абый!

Дус күреп язган хатыгыз өчен зур рәхмәт. Казаннан бик күптәннән бирле хат алганым юк иде, бер бәйрәм булды. Туган илләр ифрат сагындырды. Әйтүе җиңел бит, өченче кышны инде ерак төньяк урманнарында каршы алабыз. Хәер, монсы соңгы кыш булыр инде дип өметләнәбез. Бу ел кыш безнең колхозларда да зур сабан туйлары булыр.

Хәзер кар яуды инде. Ләкин сазлыклар туңмаган әле—кар астында су. Шуңа күрә чаңгыда йөрүе читен. Безнең якта чаңгысыз беркая да барып булмый бит. Шуңа күрә сугышчылар җәй көне үк чаңгыда йөрергә өйрәнә башлыйлар.

Үзебез тату гына яшәп киләбез. Беребез кайтуга, икенчебез сәфәргә чыгып китә. Газетаны сугышчылар яраталар. Татар егетләренең хәбәрләрен күп итеп урнаштырабыз. Төрле яктан татар китаплары сорап аптыраталар. Ләкин китаплар юк диярлек. Миндә сезнең «Үч» китабыгыз бар. Мин аны сумкага салып кына йөртәм. Кайвакытта кайтару шарты белән почта аркылы да иптәшләргә җибәрәм. Укып, рәхмәт әйтеп кайтаралар. «Совет әдәбияты» да шундый ук сәфәрләргә чыгып йөри. Йөзе җил белән кискәләнеп, кояшта янып беткән сугышчы Заполярье кыясына сөялеп сезнең әсәрләрне укып рухлана. Ә сез, ерак Казанда, елы өйдә бу турыда, бәлки, уйламый да торгансыздыр. Үзегез анда булсагыз да, каләмегез монда, безнең белән бергә сугыша.

Минем сәламәтлек болай ярыйсы. Ләкин каһәр суккан яра янадан ачылды. Күп йөрсәң үзәкне өзеп сызлый башлый. Аякны кая куярга белмичә аптырыйм. Менә шулай эшләр.

Минем китапны карап чыгуыгыз өчен чын күңелдән рәхмәт укыйм һәм шуның белән бергә аны дөньяга чыгаруны тизләтүдә дә булышуыгызны үтенәм. Яңа язган хикәяләрем юк. Журналга «Байрак» исемле бер хикәя җибәргән идем, ошаса, алырсыз.

Гомәр абый, мөмкин булса миңа «Халык мәкальләре» дигән китапны табып җибәрсә идегез. Кайчагында бик кирәк була. Башка иптәшләрдән дә сорап караган идем, ләкин берсе дә җавап бирми.

Иптәшләр Москвадан кайтканнардыр инде. Нәтиҗәләре турында язарсыз әле. Мирсәйгә, Кәшшафка, Кавига, Фатихка, Әнәскә һәм башка иптәшләргә сәлам сөйләгез.

Бари Корбановтан сезгә бик күп сәлам.

Хөрмәт белән Г. Әпсәләмов.

2/XI-43

***

Гомәр!

Үзеңә, иптәшеңә, сөекле балаларыңа бик күп сәлам миннән. Шат, бәхетле яшәвегезне теләп калам.

Үзем исән-сау килеп җиттем. Инде Госэкзамен биреп бетереп исемнәр алдык. Фронтларга таралып ятабыз. Мин дә шушы көннәрдә фронтка чыгып китәргә җыенам. Менә шундый күңелнең бик дулкынланган көннәрендә синең җылы итеп язган хатың килеп тагын да әллә ни эшләтеп җибәрде.

Мин сина хат язам. Тирә-әйләнәмдәге иптәшләр гармоньга кушылып сугыш романтикасы белән сугарылган җырлар җырлыйлар. Алар күңел күтәрерлек төшереп алганнар. Берсен-берсе кочаклап үбәләр. Аерылышу, янадан сугыш хакыйкатенә юл тоту унае белән хисләр ташудан күзләре яшьләнә. Бер-берсеннән адреслар алалар, онытышмаска сүз бирешәләр. Менә шундый күңелнең дулкынланган сәгатьләрендә мин дә сезгә: «Онытмагыз мине!» дип язам.

Игътибар белән хат язуыңа һәм хикәя турында киң тукталуыңа чын күңелдән рәхмәт. Син әйткән җитешсезлекләргә кушылам. Анда әле син әйтмәгән җитешсезлекләрнең дә бар икәнен беләм. Ләкин ни эшлисең сон, минем язу шартларым бик авыр була бит. Минем, юк вакытны бар итеп, тез башына куеп кына язган әсәрләрем бит алар. Шуңа күрә алар начар да, кадерле дә минем өчен. Ләкин берәүдән дә кимчелекләремне гафу итүне сорамыйм. Нинди генә шартларда язсам да, бу минем өчен хурлыклы бер түбәнсеңү булыр иде.


*Ф. Кәрим. Г. Бәшировка 1944 елның 8 декабрендә язган хатында вәгъдә иткән фотографиясе шушы булырга тиеш. Бу фотография Татарстан китап нәшрияты фондыннан алынды.*

Инде синең әльманахка килгәндә, түбәндәге әйберләремне кертергә тәкъдим итәм:

1) Гөлсем; 2) Идел егете; 3) Тимер һәм тимерче; 4) Диңгез ярында; 5) Алга бара идек; 6) Теләк; 7) Мин гуманист; 8) Аерылганда; 9) Разведкада; 10) Иптәш; 11) Ак күбәләк; 12) Кыңгыраулы яшел гармонь; 13) Кала яшьлек; 14) Дулкын белән сөйләшү; 15) Халык үче (бусын «Совет әдәбияты»на биреп кенә калдырдым.) Калганнары «Мәхәббәт һәм нәфрәт», «Моң һәм көч» җыентыкларында. Кәдрия аларны табышырга ярдәм итәр. Соңгы кайткан көннәрдә (4.11.44 булса кирәк) «Кызыл Татарстанда, Казан» дигән ике җыр чыккан иде, алар да минем өчен характерлы булыр. Менә шушы күрсәткәннәрдән кирәк күләмдә сайлап алырсың инде. Рәсемне шушы көннәрдә Кәдриягә җибәрәм. Ул тапшырыр.

Ярый дус, хәзергә хуш. Тормыш юлында, иҗадыңда зур уңышлар телим. Иптәшләргә сәлам.

Кулларыңны кысып, Фатих Кәрим

8.12.44. Кострома.

***

Гомәр туган!

Вакыт иртәнге 5. Ә безнең йокларга ятканыбыз юк әле. Син, материалист кеше, бәлки «ник?» дип сорарсың. Урынлы соравыңа җавап бирәм. Башта, үткән елның соңгы көнендә һәм төнендә эш күп иде. Өстебезгә йөкләнгән бурычны үтәдек. Кич җиткәнне сизми дә калдык. Аннары, арылган булса да, кызып янган тимер мич янында тәнебезне юк-бар нәрсәдән тазартып утырдык. Яңа ел керим дигәндә, табынга утырдык, сине дә искә алып кәсаларыбызны күтәрдек. Телләр ачылып китте. Җитмеш тапкыр чәй кайнаттык. Әчтек тә соң, малай!

Гариф[1] бүген часть буенча дежурный, мин бу юлларны язганда ул постлар тикшереп йөри. Үзе түзми, яныма кереп чыга, сәлам язырга куша. Менә Ярмәкеев[2] тә «Мин дә аны беләм бит, миннән дә сәлам яз!» дип утыра һәм, Казанны сагынып, авыз эченнән генә нәрсәдер көйли. Ибрай Газый[3] исә, әдәбият турында гәп алып барып арыды да, йокыга талды.

—Мә укы,—дип Гариф синең хатларыңны миңа да укытты. Хатларың җылы

[1] Гариф Галиев (1903-85), язучы. Беренче Белоруссия фронтында чыга торган «Кызыл Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе.

[2] Ярулла Ярмәкиев. «Кызыл Армия» газетасының редактор урынбасары.

[3] Ибраһим Гази (1907-71), язучы. «Кызыл Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе.

язылганнар; без Шәрәфләрне дә искә алуың өчен чын күңелдән рәхмәт. Мин жавап итеп, сагыну сәламе юллыйм һәм яңа ел белән котлыйм.

Гариф ул озын хат язарга ярата, кыска язарга күңеле бармый, ә озын язарга йә кәефе, йә вакыты булмый. Әмма сине искә бик еш ала. Шуның өчен дә син аны озак язмый торуы өчен кичер. Ул нечкә күңелле кеше (гаҗәп яхшы иптәш икән). Чын әдип шундый булырга да тиеш.

«Намус» дигәнең намуслы булып чыксын, тынып калган әдәбиятыбызга җанлылык кертсен. Үзең әйтмешли, сиңа бәхет китерсен, аны укыячак без бәндәләргә дә күңелле сәгатьләр алып килсен.

Эшебез гөрли кебек. Йокысыз төннәр нәтиҗәсендә туган хезмәт күңелдә татлы канәгатьләнү тудыра. Мин үзем вакытның иң күп өлешен алгы кырыйда уздырам. Җәфасы тиңкәгә тисә дә, матур очрашулар бөтенесен дә оныттыралар. Разин, исәнме? Землянкадагы төтен эченнән сине күреп, искә алдым да сәлам язарга булдым. Миннән сәлам, ә мин Ярмакеев булам. Хатымны кулымнан тартып алып, бу юлларны Ярулла язды. Янәсе сагынганын белдерәсе килгән. Хатымны дәвам итәм. Әдәби әсәрләр өстендә эшләргә вакыт бөтенләй дип әйтерлек юк. Шулай да уйланырга, киләчәктә язар өчен булса да тәэссоратларны кәгазьгә теркәп калырга тырышабыз. Гариф шулай да 2-3 хикәя язып ташлау җаен тапты. Шулардан берәрсен Әльманахка җибәрер дип уйлыйм. Ибрай да, иҗат кыенлыкларын кичереп, хикәя тудырырга маташа. Миннән хикәя туармы, юкмы, туса, кайчан туар—белмим, һәр хәлдә, үзем канәгатьләнерлек әйбер яза алсам, җибәрермен. «Менә сиңа, туган ил» дигән шигырь җибәрәм, шуңа тагын «Иртәнге уйлар» шигырен дә кушарга мөмкин (Ул «Кызыл Татарстан»да гына басылып чыккан иде.) Хикәя бирү, әлбәттә, яхшырак булыр иде. Кем белә?—бик ихтимал, илһам килеп язылып та куяр.



*Гадел Кутуй. 1945 ел. Фотографияне Г. Кутуй Г. Бәшировка 1945 елның 1 гыйнварында хат белән бергә җибәргән. Фотографиянең арткы ягында «Разин иптәшкә сугыш еллары истәлеге. Г. Кутуй. 1.1.45е.» дип язылган. Фотография Г. Бәширов архивында саклана.*

Әмма язасы килә дә соң! Ел түгел, 2-3 ай гына булса да язу өстәле янында утыру бик тә кадерле булыр иде. Каһәрләнгән немецларны тизрәк җинеп өйгә кайтасы иде дә, җиң сызганып язып утырасы иде. Тизрәк тусын иде шул көннәр!

Сездә кыш дисен, матур бураннар була дисен. Ә бирәдә кар бөтенләй юк. Бары тик чеметеп ала торган салкын җил генә бар. Туган ил сагындыра. Карын да аның шикәр итеп ашар идем.

Хуш, туган. Иптәшләргә сәлам әйт.

Уңышлык һәм сәламәтлек теләп, сәлам белән:
Гадел[4]

1.1.45е.

Бу хатка кушып, ике рәсем җибәрәм. Кирәк булса, кайсын булса да файдаланырсыз. Ләкин үтенәм: көлеп төшкәнен югалтмагыз, гаиләмә язылган хат ул.

***

Гомәр дус!

Мин синең бер хатыңа җавап биргәнче синең икенче хатың килеп җитте һәм вәйран итте. Бу турыда нәрсә дип кенә әйтим соң. Болай да яралы йөрәк тагын да кискәләнде. Юк, моңа сугыш кына гаепле түгел. Без кешеләребезне саклый белмибез. Муса, Рахман, Шамиль Гәрәй, Алиш, Дәүли, Мифтах, Фатих... Безнең кечкенә семья өчен бу искиткеч зур югалту! Боларны тиз генә үстереп булмаячак. Әдәби кадрларны чәчеп бетердек. Эч бик поша, хәерле булсын. Үзбәк, казах, әзәрбайҗан һәм башкаларда бу эш болай түгел. Теләсәң ни әйт, бездә язучы итекче белән бер дәрәҗәдәрәк йөри диясем килә

[4] Гадел Кутуй (1903-1945),язучы. 1945 елда Беренче Белоруссия фронтында чыга торган «Кызыл Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе.

минем. Фатихнын талантына, фронттан йөрәк каны белән язган матур шигырьләренә барыбыз да сокланып йөрдек. Әгәр ялгышмасам, ул яраланып ике мәртәбә Казанга кайтты. Ләкин шунда берәү дә аны алып калыша алмады...

Синен үтенечне мин бик тырышып үтәргә ризамын, анын каберен бик эзләп табасым килә. Ләкин анын полевая почтасы белән генә берни дә эшләп булмый. Чөнки бу тирәдә бик күп халык сугышты, һәм хәзер аларнын күбрәк өлеше моннан китеп барды инде. Шулай да мин берничә төрле чаралар күреп карарга уйлыйм, ягъни тотынам.

1. Шул адреслар белән хат язып, анын кульязмаларын саклауны һәм анын нинди часть икәнен белдереп язуны сорыйм. Бәлки бу юл белән мин кайбер нәтиҗәләргә тизрәк ирешермен.

2. Үзебезнен тирәдәге махсус оешмалар аша бу адресларнын кайсы частьнеке икәнен белергә тырышам. Әгәр мөмкинлек чигендә булса, шунда ук юлга чыгам. Шулай итеп, бәлки бер очын таба алмаммы.

Гомәр, Фатих күпне күрде. 4 ел йөреп тә кайтты. Гаепсез булып табылды. Шунда ук сугышка китте. Анда чын патриотлыгын кайнар каны һәм кайнар, талантлы шигырьләре белән күрсәтте. Ул һичшиксез зур шагыйрь, талантлы егет, канаты, күнеле сынарлык бик күпләрне күрсә дә, язмышнын авырлыгына бирешмәгән лачын иде. Союз анын исемен мәнгеләштерүдә нәрсәләр эшләргә җыена? Онытасы түгел иде!

Фикерләрем бик таркау. Мин хәзер бер җылы сүз дә әйтә алмыйм. Тик анын семьясына һәм әдәби коллективка тирән кайгымны белдерүемне тапшыруынны гына үтенә алам. Анын байтак кына балалары бар иде бугай, ташламагыз!

Анын каберенә делегация җибәрү һәм Казанга мәетен алып кайту, дәүләт исәбеннән күмү, семьясына күзгә күренерлек рәвештә вакытлы ярдәм оештырып булмыймы?

Монда килү мәсьәләсен унайлы чишеп булыр бәлки, чөнки монда сугыш юк инде хәзер...

Сина монарчы хат язмавым, теге язуыгызнын берәр хәлен ишетмәмме дип тору иде. Ләкин бу көнгә кадәр андый язунын килү-килмәве, димәк нәтиҗәсе турында да ләм-мим ишеткәнем юк. Ахыры килмәгәндер, килсә—шулай сенгәндер инде.

Ярый, хуш. Тиздән сугыш бетә дип уйлыйм. Болай да кайтырбыз инде.

Кайнар сәлам. Ш.Маннур.

Мирсәй һәм Ярмигә дә әйт.

1 май.

Котлыйм!

***

Кадерле Гомәр абый!

6—июнь. Көн коточкыч эссе. Бу хатны, Сина биргән вәгъдәмне үтәп, Берлиннан, Рейхстагнын башында, ин биек җирендә торган килеш язам. Әйтәм ич, көн гаять эссе. Берлиннын үзәк өлешендә үләм дисән бер йотым су юк. Эх, белсән иде, су эчәсе килә! Менә хәзер төшәм һәм берничә карамый, Шпреенын сасы суын эчәм. Рейхстаг—ватык. Стеналар гына утырып тора. Ул стеналар ядкәр язулар белән тулган. Ак стенада ак җир, кара стенада кара җир юк. Мин дә язып калдырдым. Татарча яздым. Менә хәзер аскы катларга төшәм дә «Моннан торып, Казанга, Гомәр Разинга хатчык яздым. Шәрәф Мөдәррис» дип язам. Бүген үк өйгә, Балтыйк ярына, Штеттинга китәм. Бер үзем. Юлда кайтканда, Г. Кутуй, И. Газый, Г. Галиевлар янына кереп чыгарга уйлыйм.

Хәзергә хуш, эссе, үләм, су эчәсе килә. Менә бу түбәдән бөтен Берлин диярлек күренә.

Бүген үк юлга чыгам. Кайтасы юл ерак але. Биредә өч көн булдым.

Шәрәф.

6/VI45.



Ирек Сабиров

## Елау егет эшемени...

Чиләбене узып Өфегә якынлашканда һава чистарды, июль башының шау чәчәкле болыннары ешрак очрый башлады. Көн яктырып күләчләнгәч, Фәритнең күңелендә дә шатлыклы дулкынлануга охшаган бер хис туды, машинасы да җитезрәк оча башлаган кебек булды.

«Подумаешь—эштән төшерделәр. Фаҗигамени инде бу! Үзем дә бит егерме ел эчендә кул астымдагыларны күпме алмаштырдым! Әнә, министрларны да алып ыргыталар безнең заманда—елаганнарын күргән юк. Әти мәрхүм әйтмешли, аты булса, йөгәне табылыр...»

Унҗиде ел кайтканы булмады туган авылына. Унҗиде ел буе абыйсы Фикрәтнең һәм ике апасының Казаннан язган шелтәле хатларын укыр-укымас, унысының берсенә дүрт юллык җавап язып, башыннан аягына кадәр эшкә бирелеп, вакытын-саулыгын аямый яшәде Фәрит. Аның кырыслыгы, хәтта ки рәхимсезлеге турында әллә нәрсәләр сөйлиләр иде берләшмәдә. «Новогорскнефть» берләшмәсе генераль директоры урынбасары дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитте. Үзенең «биш минуттан генерал» булуын аңлый иде ул, чөнки «карт» директор, яше илледән генә авышуга карамастан, ике инфаркт кичерергә өлгергән иде инде.

Әмма көтмәгәндә дөньяның асты өскә килде. Илдә хосусыйлаштыру шаукымы башлангач, берләшмә «акционерлар җәмгыяте»нә әверелде, «генерал»ны кинәт Төмәнгә, өлкә идарәсенә күчерделәр дә, аның урынына әтәч кыяфәтле, Пинчук фамилияле бер маңка малай килеп төште. Яшь түрәнең беренче эше шул булды—приказ язып, биш урынбасарның бишесен дә вазифаларыннан азат итте. «Калырга теләсәгез, буровой мастерлар булып күчегез»—диде ул.—Теләмәсәгез—дүрт ягыгыз кыйбла.» Дөньясы җимерелгән кебек тоелды Фәриткә. «Патшалык» даны түгел, хуҗа булуның чикләнмәгән мөмкинлекләре турында хыялланып яшәгән иде ул, тәртипне ныгытып, булдыксыз җитәкчеләрне сөреп, берләшмәнең куәтен икеләтә арттырырга исәбе бар иде. Әй, нарасый!

Шуннан соңгы мингерәүле көннәр һәм йокысыз төннәр күпмегә кыскарткандыр гомерен—Ходай үзе белә. Ләкин эчендәге газабын тышка чыгармады Фәрит, зарланмады, шыңшымады, «теге приказ»га бергә эләккән бәладәшләре кебек эчкечелеккә дә сабышмады. Танышлары кызганган булып

аһылдый башласа, елмаерга тырышып: «Елау егет эшемени!»—дип кырт кисә торган булды. Чын кичерешләрен исә хатыны Сания генә белде.

Казанга кайтып килергә дә Сания үгетләп күндергәч кенә тәвәккәлләде Фәрит. «Туганнарын, мәктәп дусларың белән очрашырсын,»—диде хатыны. Тик поезд белән барырга теләмәде Фәрит. Менә дигән машинам барында ник тынчу вагонда тилмереп утырыйм дип, «Митсубиси»ен майлап-чистартып, җәйге таңда юлга чыгып китте.

Сүз дә юк, вакыт табып кайткаларга кирәк иде шул. Карендәш туганнар белән унжиде ел буена күрешми яшәү бернинди калыпка да сыймый ул. Тик шунысы да хак, вакыт бик тыгыз иде бит. Әтисе дөнья куйган җәйдә, аны җирләргә кайткач, абыйсы Фикрәт, шелтәләгән булып: «Институт тәмамлаганыңа өч ел, үзең әле һаман гади инженер гына,»—дигән иде. Бу сүзләр Фәритне әрнетеп, йөрәгендә уелып калды. Холкындагы кырыслык та шул мизгелдә ярадымы икән әллә? Шуннан соң ярты ел да узмады, әниләре вафат булды. Фәрит аның кырык дүрт яшендә тапкан төпчек баласы булгангамы—соңгы көннәрендә гел аны чакырган ди. Күнеле сызлап, хәсрәтеннән йөрәге ярылырдай булса да, бер тамчы яшен күрсәтмәде Фәрит, җеназа йолалары башкарылып беткәч тә, абый-апалары белән коры гына саубуллашып, Себеренә китеп барды.

Әлбәттә, шуннан соңгы унжиде ел буе бары тик эшкә генә бирелеп, дөнья рәхәтләреннән ваз кичеп яшәде дию дөрес булмас. Саниясе чибәр генә түгел, бик уңган һәм акыллы хатын булып чыкты. Зур фатир, затлы җиһаз, дача, машина—бу муллык үзеннән-үзе барлыкка килгәндәй булды. Бердәнбер уллары Фоатны Саниянең әти-әнисенә калдырып, ел саен йә Кырымда, йә Юрмалала ял итеп йөрделәр, бер елны хәтта Европа илләрен дә урап кайттылар. Әмма барыбер тормышының төп мәгънәсе эшендә булды Фәритнең, гомеренең һәр сәгатен бер максатка—хезмәтенә буйсындырып яшәде ул.

Хәзер исә, нишлисен, тешне чытырдатып кысып, көнкүрешнең бөтен рәвешен, юнәлешен үзгәртергә кирәк. Юкса төшенкелеккә бирелеп сафтан чыгуың бар бит. Әй, баш сау булса, бүрек табылыр әле, елау егет эшемени!

Юлның урман кырыеннан үткән җирендә туктап, машинасыннан чыкты да Фәрит, күктәге бер ноктада талпына-талпына сайраган тургайга карап, ниндидер онытылган бер вакыйганы исенә төшергәндәй булды. Дөнья куып йөргән елларның әшәкелекләрендә бозылырга өлгермәгән ниндидер сафлык бәреп керде күңеленә. Менә бит, әле генә хәтеренең бер кырыенда иде... Хәзер, хәзер... Әһә! Вәсилә! Кара кашлы, чем-кара күзле, кара толымлы Айбаш кызы Вәсилә! Айбаш Мәмдәлдән алты чакрым. Анда урта мәктәп юк, тугызынчы класска айбашлар Мәмдәлгә йөриләр. Ничекләр итеп юлында Вәсилә пәйда булгандыр Фәритнең, хәтерләми инде, әмма шунысы төгәл: май ае иде. Шау чәчәкле шомырт куагы хәтерендә калган. Әллә нинди тиле сүзләр мыгырдады теле, йөрәге чабышта типкәндәй тыпырдады. Вәсиләнең тулган иреннәрен суырып үбәргә кыюлыгы да житте хәтта ки! Әмма шундук өстенә сибелгән бер чиләк бозлы су кебек булды кызның сүзләре: «Әй, син бөтенләй үбешә белмисең икән. Әкбиләрнең Мараты синнән мең тапкыр татлырак үбешә!»

Ничә ел узды шул көннән? Егерме жидеме? Егерме сигезме? Ул чакта бу очрашу йөрәген җәрәхәтләгән иде Фәритнең. Вәсиләне төшендә Марат белән әллә нинди халәтләрдә күреп тетрәнеп уяна иде. Хәзер исә ирексездән елмаеп куйды: их, яшьлек, яшьлек!..

Марат чынлап та кыю гына түгел, әрсез, тупас егет иде. Әкби Мараты дигәненне ишетә күрмәсен—жене чыга. Авылда шулай бит инде ул, һәр йортның кушаматы бар. Жиденче класстан ук аракы капкалый, тәмәке тарткалый башлаганын сизә иде укытучылар, ләкин тәрбиянең бер ысулы да ана йогынты ясый алмады. Дәресләрен калдыруы да, тәнәфестә кычкыртып кызлар капшавы да, сабан туе көнендә исерек килеш кыйнашу оештыруы да

мәктәп директорының гомерен байтакка кыскарткандыр. Шул ук вакытта, әлбәттә, класстагы башка малайлар Маратның кыюлыгына, мөстәкыйль холкына кызыгыбрак, көнләшебрәк карыйлар иде бугай.

Күкрәген тутырып сулыш алды да Фәрит, машинасына кереп утырып, тагын юлга кузгалды. Кайда икән хәзер шул Вәсилә, шул Марат? Кемнәр булып яши икән? Очрашсак, танырбыз микән бер-беребезне?

Кинәт хәтереннең әллә кайсы катлавы астыннан актарылып чыгып, күз алдына Повар Илдары килеп басты. Боларның кушаматы ник «повар» булды икән? Бик тыйнак, оялчан иде Илдар. Аның үзенә генә хас әкәмәтлеге бар иде: зур һәм чиста, гаять матур Сөләнгер күленең суы бераз җылынгач, иске бүрәнәләрдән сал ясап, йөзеп кереп китә дә, сәгатьләр буе китап укып утыра иде шунда. Гаиләдә аннан башка өч абыйсы булгангамы—хуҗалык эшләренә сирәк тарталар иде аны. Хәзер дә күл уртасында утыра микән? Юктыр, гаиләле кешедер ул хәзер. Ә бәлки Фәрит кебек үк еракка китеп баргандыр. Күпләр киткән иде бит авылдан.

Классларында кемнәрнең авылда калачагы, кемнәрнең калага «сызарга» ниятләве сизелеп торды үзе. Морадыйм Сәлиме, мәсәлән, бишенче класстан ук колхоз персидәтеле булырга хыялланып үсте. Моны бөтен мәктәп белә иде. Аның Арыслан Зөлхәбирәсенә гашыйк икәнен дә белмәгән кеше булмады. Кушылдылар микән? Сәлим тырыш малай иде, хыялына ирешкәндер.

Фәрит, уйларының күңелсез чынбарлыктан якты хатирәләргә күчүенә куанып, бүтән классташларын да күз алдыннан үткәрә башлады. Менә Күселәрнең (әй, кушамат та инде!) Камиле—бусы, һичшиксез, галим булырга тиешле егет. Ничә яшь аңа хәзер? Кырык өчме? Бәлки, академиктыр.

Бер җырчы кыз бар иде бит әле. Люция... Фамилиясе онытылган. Шәйхетдиновамы? Шундыйрак. Люция. Бик чибәр иде. Ләкин—әй горур да инде! Якын да җибәрми. Хәтта Марат та шүрли иде аңа бәйләнергә. Ике ел буе Рафаил белән бер партада утырды Люция. «Лабазчы» Рафаил белән. Бусы гаилә кушаматы түгел. Рафаилнең үз кушаматы. Җиде яшендә, шырпы белән уйнап, колхозның салам түбәле лабазын яндырган иде ул. Үзе ничек исән калган диген. Кушаматына беркайчан да үпкәләмәде, мактаулы исем итеп кабул итә иде ул «лабазчы»ны. Ә иң зур горурлыгы—көчле, матур тавышы иде Рафаилнең. Алар Люция белән дус булсалар да, үзара көнләшеп, дан өчен ярышып йөргәннәре сизелә иде.

Мәктәпне бергә тәмамлаган егерме ике классташының унтугызын хәтеренен ерак почмакларыннан эзләп тапты Фәрит. Калган өчесен очрашкач искә төшерермен дип юанды. Казанга якынлашканда унтугызы да күз алдында, кичә генә аерылышкан кебек, елмаеп торалар иде. Шуңа күрә Фәритнен күңеле һәр чакрым саен ныграк дулкынланды, һәм, ниһаять, ул, түземе җитмәгәннән, Казанда туктамыйча, әүвәл авылын урап килергә булды. Дөрес, монда түземсезлектән башка тагын бер сәбәп бар иде: абыйсы Фикрәт белән очрашу мизгеле бераз тәшвишләндереп торды Фәритне. Бер ел чамасы элек язган соңгы хатында Фикрәт, бик тиргәнеп, туганнарыңны санга сукмыйсың, фәлән-фәсмәтән, әгәр дә үзем үлеп китсәм, сиңа хәбәр итмәскә кушам, дип язган иде. Юкса чынлап та йөрәге авыру бит аның, «ишемический» дип язганы бар иде. Ярый, очрашып күрешкәч, аңлашырбыз. Әмма очрашу сәгатен бераз кичектерәсе килде Фәритнең, шуңа күрә турыдан-туры Мәмдәленә юнәлде.

Ерактан ук авылының кечкенәдән таныш билгеләрен эзләргә тотынды. Юк, әллә ни үзгәрмәгән Мәмдәл. Бары тик күрше Юртыш белән кушылып беткән диярлек. Югары очта калкып торган җил тегермәне юкка чыккан.

Дулкынланудан каушап, хәле китте Фәритнең, тиргә батты, кулы калтырады. Җебемә, елау егет эше түгел, дип үз-үзен юаткан булса да, тигез җирдә авария ясамагаем дип юл кырыена борылды да, машинасын

туктатты. Зират коймасы янында ук туктаган булып чыкты ул. Ярар, алай булгач, зираттан башлыйк. Анысы дөресрәк тә булыр—туган илгә кайтуны әти-әни кабереннән башламыйча нидән башлыйсың.

Мәмдәл зираты зур һәм мәһабәт, монда уналтынчы гасыр каберләрен дә очратырга мөмкин диләр. Коймасы таза, эчендә чисталык, тәртип.

...Моннан өстәрәк һәм ундарак булырга тиеш алар. Чардуганың хәтерли әле Фәрит. Кара әле, үлән нинди куе. Ә жиләк, жиләк! Таптавы да кызганыч. Менә таныш абагалык—димәк, юнәлеше дөрес. Хәзер ул чардуган күренергә тиеш.

Кинәт Фәритнен тәне тетрәнеп китте. Күзенә коточыргыч бер нәрсә чалынгандай булды аның. Башта анламады. Ни булды бу? Хәвефләнеп, үзен шомландырган әйберне янадан эзли башлады. Тапкач, аяклары хәлсезләнеп, чирәмгә тезләнде.

Янәшәсендәге кабер ташының түгәрәк сурәтеннән йөрәк сызландыргыч таныш ике күз карап тора иде. «Ибраһимов Марат Габдулла улы. 1953-1982» дигән язуны укыгач, ике көн буе уйларында, күз алдында кайнаган егетнең ундүрт ел кабердә ятуы акылына сыймады.

Көч-хәл белән торып басты. Игътибарын туплап, зираттагы бүтән кабер ташларын тикшерә башлады.

«Морадимов Сәлим Габделәхәт улы. 1953-1984.»

«Галиев Камил Харис улы. 1953-1980.»

«Гәрәев Илдар Нургали улы. 1953-1981.»

«Морадимова Зөлхәбирә Хәмидулла кызы. 1953-1984.»

Аякларын өстерәп, Фәрит янадан зират кырыена чыкты. Коймага сөялде. Янәшәдә, зират янындагы калкулыкта, корамалы жәймәдә бик бирелеп дога укып утырган бер әбине күрде дә, калкулык ягына утырып, дога беткәнен көтә башлады. Әби сөйләшергә ярата икән.

—Исәнме, улым, Аллаһы Тәгалә ярдәмен бирсен, атан-анан янына килденме?

—Шулай иде дә, әбикәй, монда балачак дусларымның да каберләре бар булып чыкты әле.

—Кем алар, улым? Мин монда бар халыкны беләм.

Шушы карчыкны күпме вакыт тынлап утырганын абайламады Фәрит. Ишеткәне күргән кабер ташларыннан да фажигалерәк булып, акыл-зиһенен томалады.

Марат авылдан китеп Казаннын сабын заводында эшләгән. Эчкән, фатиры булмаган, еллар буе тулай торакта этләнеп яшәгән. Тукай урамы чатында исерек килеш трамвай астына эләккән.

Сәлим, авыл хужалыгы институтын тәмамлап, Мәмдәлгә колхозның баш механигы булып кайткан. Зөлхәбирәдән ике малай таптырган. Ниһаять, шаугәр килеп колхоз рәисе итеп сайлап куйганнар үзен. Шул ук кичне сайлану унае белән оештырылган мәжлестә райком инструкторы белән бәхәсләшкән: янәсе, төннәрен Зәет болынының данлыклы Салкын чишмәсеннән алсу төс бөркелеп тора, имеш. Үзен чын коммунист, материалист дип санаган инструктор, әлбәттә инде, ышанмаган. Кул астында бүтән машина-фәлән булмаганлыктан, икәүләшеп бер «Беларусь» тракторын кабызып, Зәет болынына киткәннәр һәм, Убса тавын төшкәндә тракторлары капланып, икесе дә һәлак булганнар. Зөлхәбирә исә, шул фажигадән сон сүрелә башлап, ике айдан дөнья куйган.

Илдар, институтка керә алмагач, тракторчылар курсын тәмамлап кайткан. Әйләнәсендә күп чибәрләр бөтерелсә дә, өйләнмәгән. Елга ике тапкыр, график буенча диярсен, эчкечелеккә сабышкан. Чираттагы чуалуының берсендә, галәтенчә салга утырып, Сөләнгер күленә кереп киткән дә, салы янтаеп, батып үлгән.

Камил егерме жиде яшендә кандидатлык диссертациясен яклаган. «Акчарлак» ресторанында узган банкеттан соң төн уртасында Әбҗәлилов урамыннан кәләше белән җәяү киткәннәр. Каршыларына очраган егетләрнең үзара сүгенешүләренә ачуы чыгып, шелтә сүзе әйткән Камил. Тегеләр аның үзен дә, кызын да кыйнап ташлаганнар. Кәләше турында мәгълүмат юк, Камил исә хастаханәдә аңына да килмичә вафат булган.

Васильә, педагогия институтын өченче курсыннан ташлап, «Татарстан» ресторанында официант булып эшләгән. Шунда очраган бай бер таҗикка ияреп Кургантүбә каласына киткән дә, шуның ничәнчедер хатынымы, сөяркәсеме булып яшәгән. Соңра, Таҗикстанда чуалышлар башлану белән, хәбәре өзелгән, исәнме-юкмы—билгесез икән.

Рафаилнең дә язмышы карангы икән: шундый шәп тавышы белән филармониягә йә консерваториягә керер дип торганда, БАМ төзелешенә китеп барган, шунда эзе югалган. Үзен БАМда түгел, Колыма лагеренда күргәннәр дигән имеш-мимеш тә булган.

Люция атказанган артистка, М. Җәлил театрында җырлый икән.

Фәрит, әбигә сәдака итеп бер йомарлам кәгазь акча калдырды да, әйләнәтирәдәге кабер ташларына карамаска тырышып, ерактагы ике миләш агачы арасыннан күренеп торган таныш чардуганга таба атлады. «Әти-әни янында бераз утырам да, Казанга китәм, авылга кереп тормыйм. Кем белән очрашып сөйләшим ди мин анда.» Йөрәгендә әллә нинди утлар дөрләп, башында саташулы уйлап чайкалды. Ара якынлашкан саен, таныш чардуган кинәя бара кебек тоелды аңа. «Нервылар какшаган, күз алдана бугай, ике кабер урынына өчәү күренә,»—дип, чардуганның тимер баганасына таянды Фәрит.

Әмма, күз алдындагы чынбарлык үзгәрмәде. Иске каберләр янәшәсендә өченчесе калкып чыккан, ә яңа гына куелган кабер ташына: «Абдуллин Фикрәт Хәсән улы. 1940-1995»,—дип уелган иде. Абыйсы!

Шул басып торган урыныннан бер адым атларга да хәле җитмичә, билгә җитеп үскән абагалар арасына ауды Фәрит. Еллар буе кырыслыкка күндерелгән йөрәк бу юлы сынатты. Елауның нәрсә икәнен дә оныткан мәһабәт ирнең кайнар яше, бәреп чыгар сәгате җиткән чишмә суы кебек тибеп, карт зиратның кара туфрагына акты.

### Тугыз ел үткәч...

Вагон тәгәрмәчләренең ялыктыргыч шакылдавыннан изрәп черемгә китә башлаган иде Мидхәт, каеннарның юл кырыеннан артка чапкан кәүсәләре артыннан июль кояшының иртәнге нурлары җемелдәп сискәндерә башлагач, йокысы качты. Сагышлы уйлары кабат аңын, акыл-зиһенен томалады.

«Менә нинди икән ул аерылышу газабы.Жимерелде тормыш, жимерелде...»

Тугыз ел бергә яшәделәр. Тугыз ел бусна Мидхәтнең йөрәгендә үтергеч көнләшү хисе белән бергә ярсулы мәхәббәт кайнады.

Казан авиация институтының өченче курсында, дөрләп кабынган тойгыларыннан башын җуеп, әтисенең әрнүле карашын һәм әнисенең сүзсез күз яшьләрен шәйләмичә, өйләнде дә куйды. Чиләбе кызы Наташа Мидхәткә кадәр күпләрнең башын әйләндерергә өлгергән иде инде. «Опомнись, Мишка,—диде бүлмәдәше Алексей Мидхәткә.—Андыйларга өйләнмиләр. Алар бары уенчык кына бит.» Ачуыннан шартламады гына Мидхәт. Шулчак Алексейга әйтеп ташлаган сүзләрен кабатлавы да оят инде хәзер. Әй, ул көннәрдә аның тилергән акылын айнытырлык көч юк иде шул. «Үзең уйлап кара, улым,—диде әтисе,—яшь еллар тиз уза ул. Бераз олыгаеп, акыл утырткач, туган туфрагың тартыр сине, туган каның, туган

телен, үз көй-моннарыбыз сагындырыр. Үкенмәссенме, балам?» Колагы ишетте бу сүзләрне, күңеле ишетә алмады.

Туй дигәннәре курчак туе кебек әллә нинди ясалма булып чыкты. «Әтием-әнием каргышы»,—дип искә ала аны хәзер Мидхәт. Туй алдыннан әтисе, диабеты көчәеп, больниска кереп ятты. Туйда Мидхәт ягыннан, туганнары Казан тулы булуга карамастан, өлкән абыйсы Мансур гына булды. Наташа да, аның Чиләбедән атналык отпуск алып килгән әтисе белән әнисе дә бу хәлгә кайгырмадылар гына түгел, хәтта гаҗәпләнмәделәр дә. Ә менә Мидхәтнең үз әтисенең күңеле катты. Хәзер дә Казанга кайтканда утырып сөйләшәләр, әмма бар темалары—завод хәлләре йә сәясәт, ә теге тыелган темалар утырып кала бугазда, элеккеге эчкерсезлек юк.

Тормышында өр-яңа бер чор башланганын сизде Мидхәт. Шуңа күрә яңа гына туган гаиләсе алдындагы җаваплылыгын аңлап, төшенкелеккә бирелмәскә, рухын сүрелдермәскә тырышты. Бәлки, Наташасын алиһәләштереп, артыгратын да кылангандыр, тик хатынына яңа кофта, йөзек йә туфли алып кайтып куандыру хакына ул вагон бушатудан да, төзелешләрдә төнге каравылчы булып эшләүдән дә йөз чөермәде. Әйе, ул бүләкләр күтәреп кайткан көндә чынлап та сабыйларча шатлана иде Наташа. «О, Мишель!..» Мидхәт исә: «Күзләреңнең ләззәтле сихере өчен бу»,—дип пышылдый иде.

Шул беренче елларда ук гайбәтләр дә булмады түгел, булды. Наташаның ятлар алдында чытлыкланырга яратуын күреп тора иде Мидхәт, шуңа күрә ишеткән имеш-мимешләр аны бик тә сызландырды; ышанмыйм дип төкерә дә алмады, ышанып гаепләргә дә рухы җитмәде. Үз-үзенә Наташаның чисталыгын исбатлау өчен булмаган дәлилләрне табарга өйрәнә башлады. Әй, акылдан шашып яратты ла инде ул хатынын. Ничектер бер сәбәпсез үз-үзен гаепләү хисе барлыкка килеп, йөрәген телгәли башлады. Кем белә, бәлки, нәрсәдер аңлап бетермидер ул, назы, игътибары җитмидер Наташага? «Көндәшен—Алексей»—дигән хәбәрне «яхшылык теләүчеләр» диплом яклау алдыннан китереп җиткерделәр. Шул туй алдыннан үзенә фәлсәфә саткан Алексей бит, ходаем. Алсу тәпи йөри башлаган иде инде. Якынлашкан һәлакәтен сизгән-тойган кебек булды Мидхәт, газапларын тышка чыгармаска булып, тешен чытырдатып диплом яклап документларын алгач та, Наташасын үгет катыш наз белән ашыктырып, үзләре билгеләнгән Чиләбегә алып китте гаиләсен.

Яшәгән шәһәрчекләре һәм бергә эшләгән заводлары Чиләбедән алтмыш чакрымда булды. Ниһаять, әкренләп тормыш җайга төште шикелле. Ике елдан гөрләп үз фатирларына күчтеләр. Алсу җәйләрнең бер аен Чиләбедә, Наташаның әниләрендә икенчесен Казанда, Мидхәтнекеләрдә яши торган булды. «Баба-деда»сын да, дәвәти-дәвәниен дә һушы китеп яратты шул...

Эштә бик тиз үсте Мидхәт. Өч елда бүлек башлыгы булырга өлгерде. Фатирны җиһазландырырга да, хатынын киендерергә дә җитәрлек булды хезмәт хакы. Наташаны бүләккә куандыру, аның йөзенә туры карап: «Күзләреңнең ләззәтле сихере өчен бу,»—дип пышылдау бер йолага әверелде Мидхәт өчен. Узган күңелсезлекләрнең берсен дә искә алмады, монда иске танышлар булмавы сәбәпле, яңа, бәхетлерәк дөньяда яши башлаган кебек иде Мидхәт. Әти-әнисенең рәнҗүе йөрәгендә боз кисәге булып ятса да, якты йолдызы, чәчәге, нуры, һәр кылган эшендә дәртләндереп торган рухы, билгеле, Наташа иде. Ул көн саен үзен өр-яңадан гашыйк булган кебек тойды. Их, яшисе дә яшисе иде кана!

Әмма гайбәт сүзләре монда да колагына килеп иреште. Онытылган иске авыруы кире кайткандай булды Мидхәткә. Тырышып, кирпечен кирпечкә тигезләп, чәчәген чәчәккә бәйләп төзегән тормышының кинәт асты-өскә килде. Кем белән чуалган диген. Мидхәт белән әшнәләшеп йөргән Генка икән аның сөяркәсе. Инструмент цехы башлыгының урынбасары.

Ул чорны искә алу да кыен хәзер Мидхәткә. Сөйләшүләр, аңлашулар...

«Ни җитми сиңа?» «Бар нәрсә дә җитә. А что, мин гаепкә алырлык эш эшләмим бит.» «Яратам бит мин сине, Наташа...» «Мин дә яратам. Глупенький, мин Генка белән эш буенча гына очрашам.»

Ә гайбәт көннән-көн куерды. «Аларны төш вакытында цехның аулак бер бүлмәсендә күргәннәр. Кыяфәтләре—тфү...» «Генка тагын кабинетында бикләнгән. Наташка беләндер инде...»

Түзмәде Мидхәт, канлы йөрәген учлап дигәндәй, кискен итеп әйтте: «Утсыз төтен булмый, җилсез яфрак селкенми. Син кем белән яшәргә телисең, минем беләнме, әллә Генка беләнме?» «Господи, как я тебя ненавижу!»—дип кычкырып җибәрде шунда Наташа. Ул сикереп торып киенде дә, пыр тузып, ишекне шапылдатып ябып чыгып китте. Дүртенче көннең иртәсендә кайтып керде. Тезләнеп, идәндә үрмәләп гафу үтенде. Тешләрен шакылдатса шакылдатты, дәшми калды Мидхәт. Алсуның исә шуннан соң йөзе сулды, боегып уйчанланып калды ул. Берничә ай шулай салкын, ярым ят мөнәсәбәтләрдә яшәделәр. Давыллар басылып, аралар җылына башлады дигәндә генә яңа гайбәт килеп ирешә колакка. Әй, гайбәт кенә булса икән. Бөтен вак-төяге белән җентекләп сөйләп бирде «дус күрүчеләр». Ул кичне Наташа, Мидхәтнең йөрәген телгәләгән уйларны сизгәндәй, үзе сүз башлады. «Мин бу квартирдан китмим,—диде ул, битараф карашын телевизордагы Якубовичка текәп.—Без сине канәгатьләндермәсәк, ишек ачык, юл такыр. Кызымны да, квартирымны да бирмим сиңа.»

Ул минутта Мидхәтнең каршында әллә нинди ят, таш бәгырьле хатын утыра иде. Кая китте икән аның башын җуеп гашыйк булган күз нуры, назлы иркәсе? Хыялында туган гүзәл образ күзләрен томалаган булганмы? «Сөеклем, Наташам, җанкисәгем, бәгърем, син чынлыкта булмагансыңмени дөньяда? Бу хатын—мин белгән нәфис Наташа түгел бит...»

Җыенып чыгып китте Мидхәт. Дошман булып түгел, өзелеп яратса да китәргә мәҗбүр булган кеше булып чыгып китте. Завод директоры, бу турыда ишеткәч, нәзакәт-фәлән саклап тормыйча: «Ул минем хатын булса, мин аңа фатирымны калдыру түгел, соңгы ыштанын салдырып, урамга шәрә килеш акыртып куып чыгарыр идем,»—диде, әмма Мидхәтне вакытлыча бер бүлмәле фатирга урнаштырды.

Шул көннән алты ай вакыт узды. Аерылышуларын рәсмиләштерделәр. Наташа, заводтагы эшеннән чыгып, фатирын Чиләбегә алыштырды да, җиһазларын ике КамАЗга төяп, китеп барды. Билгеле, күченү мәшәкатьләре—фатирны күчереп яздыру, машина юнәлтү, төяү-бушатулар—барысы да Мидхәт өстенә төште.

Директорның «...акыртып куып чыгарыр идем»—дигән сүзе колагында яңгырап торса да, йөрәгенең шушы газаплы мәхәббәт белән мәңгегә агуланганын аңлады Мидхәт. Үзенең хезмәт хакын ай саен тулысыча диярлек Наташага биреп баруы да Алсу өчен генә түгеллеген дә белә иде ул. Бәхетле елларда Наташаның һәр бүләккә сабыйларча куануын күреп шатланырга күнеккән шул, хәзер исә шул шатлыкка сусау хисе тырный иде йөрәген.

Аерылышкан чакта, Алсуның җәйге каникулын элеккечә үткәрәбез, дип сүз куешырга акыллары җиткән иде. Менә хәзер Казанга кайту чираты. Отпуск алды Мидхәт, кичә Наташага шалтыратты. «Кил,—диде Наташа,—Алечканы юлга әзерләп куярмын.» Тавышы шактый ягымлы булып ишетелде, Мидхәткә теге «үз» Наташасы белән сөйләшкән кебек тоелды. Шунда ук йөрәкнең ерак түрендә өметкә охшаган бер рәхәт тынгысызлык туды. «Бәлки, әкренләп яңадан башлап карарга дыр?» Бәлки, беренче елларда, эшкә бирелеп, карьерасы белән мавыгып, хатынына игътибарын киметкән көннәре булгандыр. Хәзер исә андый хаталарны җибәрмәс. Шундый хис-фикерләр эчендә кайный-кайный каенаталары фатирының ишек төбенә килеп басканын сизми дә калды Мидхәт.

Фатирлары янәшә булганга, шимбә иртәсендә Наташаның да, Алсуның да монда булырга тиешлегенә шикләнмәде ул.

Шакыды. «Туп-туп» итеп йөгереп килгән тавышны ишетеп, ирексездән елмаеп куйды. Ишек ачарга килгән Алсуны һәм аның артыннан ашыгып чыккан Наташаның мөлаем йөзен ишек ачылганчы ук әллә нинди тылсымлы тойгы аркылы күргәндәй булды.

Ялгышмаган икән, ишекне Алсу ачты. «Папочка! К бабайке поедем?» Мидхәт кызын очыртып күтәрде дә, күкрәгенә кысты. Йөрәген тыярга тырышса да, күз яшьләре саркып чыкты. «Җыен, хәзер китәбез,—диде ул.—Бар әле, әниеңне чакыр.»

Шул арада кухнядан Наташа—юк-юк, Наташа түгел, ә нәкъ Наташа рәвешендәге ят һәм әшәке бер хатын—килеп чыкты. Чәче тузган, күзендә зәһәрлек дөрләп тора. «Марш бүлмәгә!—дип чыелдады ул Алсуга әллә нинди чиркандыргыч тавыш белән.—Бабаң да, дедаң да монда гына синең, аңладыңмы?»

Алсу, әтисе кулыннан шуып төшеп, мөлдерәмә күзләрен әнисенә төбәп, тынсыз калды. Наташа аны иләннән ачу белән куптарып алып, култык астына кыстырды: «Мин Алечканы сиңа бүтән күрсәтмим дә, безнең янга килеп йөрмә. Будь здоров, Мишаня.»

---

Ирек Нәгыйм улы Сабиров 1950 елның 14 апрелендә Татарстанның Биектау районы Мәмдәл авылында укытучылар гаиләсендә туа. Күп балалы гаиләдә, китап тулы өйдә әти-әнисенә, апа-абыйларына ияреп, җырлап, рәсем ясап, шигырь язып, гармун уйнап үсә ул. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Казан химия-технология институтына укырга керә. Шул чорда институтның зур тиражлы газетасында аның шигырьләре даими басылып килә.

Институтны тәмамлагач, И. Сабировны Чиләбе өлкәсе Еманжелинск шәһәрендә урнашкан «Сигнал-Полимер» заводына эшкә җибәрәләр. Биредә ул гади мастердан баш инженер дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 1998 елда аны шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары итеп билгелиләр. Хәзерге көндә дә Ирек Сабиров—Еманжелинск районы хакимияте башлыгының икътисад, сәнәгать, сәүдә һәм инвестицияләр буенча урынбасары.

Җитмешенче елларда Уралда татар матбугаты булмаганлыктан, И. Сабиров шигырьләрен рус телендә дә яза. 90 еллар башыннан аның әсәрләре Чиләбе өлкәсе, Татарстан һәм Башкортстан газета-журналларында күренә башлый. Шигърият белән берргәттән, публицистика өлкәсендә дә эшли язучы. 2002 елда аны Татарстан Язучылар берлегенә, 2003тә—Россия Язучылары берлегенә, 2004 елда Россия Журналистлар берлегенә кабул итәләр.

Ирек Сабиров, актив җәмәгать эшлеклесе буларак, узган гасырның туксанынчы елларында башта Чиләбедә, соңрак үзе яшәгән Еманжелинск шәһәрендә татар-башкорт культурасы үзәген оештыра һәм күп еллар буе аны җитәкләп килә. 1990 елда Салисә Гәрәева, Рөстәм Вәлиев, Рәшидә Сиражиевалар белән бергә, татар телендә «Дуслык» өлкә газетасын чыгара башлый.

Ирек Сабиров—1997 елдан Чиләбе өлкәсе татар Конгрессы башкарма комитеты әгъзасы, 2004 елдан—шул башкарма комитетта рәис урынбасары, Мифтахетдин Акмулла исемендәге өлкә татар һәм башкорт әдәби берләшмәсенең татар бүлеге һәм «Элегия» исемле рус әдәби берләшмә җитәкчесе.

1997—2002 елларда Урал төбәге нәшриятларында Ирек Сабировның проза һәм поэзия жанрларында берничә китабы дөнья күрә: «Яшим!», «Аваз», «Люблю и верю», «Апрель», «Манзара» һ.б.

Ул 2005 елда Икенче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләнә, 2008 елда исә «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була.

## Әнәс Галиевнең тууына 90 ел

1920 елның 3 апрелендә Татарстанның Арча районы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә туа Әнәс Галиев. Заманына күрә яхшы гына белем алып, район һәм республиканың финанс өлкәләрендә инспектор булып эшли башлаган егет Армия сафларына алына, сугышның беренче көннәреннән үк фронтка җибәрелә. 1942 елның сентябрендә, Майкоп шәһәре тирәсендә барган бәрелешләр вакытында, артеллирист Ә. Галиев чолганышта калып авыр контузия ала, дошман кулына эләгә, 1945 елның апреленә кадәр әсирлектә була. Әсирлектән котылып бераз вакыт госпитальләрдә дәваланганнан соң Казанга кайта, озак еллар буе финанс оешмаларында эшли.

Үзенең иҗат эшен Ә. Галиев 1937 елда шигырьләр язудан башлый. «Кызыл яшьләр» газетасында дөнья күргән шигырьләре 1938, 1940 елларда «Җилфердә, байрак»!», «Сөю» исеме белән аерым китап булып басылып чыга. Коточкыч кыен шартларда—фашистлар тоткынлыгында—язылган әсәрләрен эченә алган «Кыен юл» исемле шигырь китабы 1958 елда басыла. Ул шигырьләрдә адәм баласының ныклыгы, сабырлыгы, киләчәккә өмет белән каравы чагыла.

Тормышында күргән авырлыклар финанс оешмаларындагы эш тәҗрибәләрен яктырткан уйланулары аңа проза әсәрләре язарга да этәргеч бирә. «Йолдызлар шаһит» (1958), «Намус кушканча» (1990) исемле китаплары чыга.

Әнәс Галиев—1985 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

1996 елның 26 июлендә Казанда вафат була.

## Таһир Нурмөхәммәтовның тууына 80 ел

Таһир Мирзагаллəм улы Нурмөхəммəтов 1930 елның 14 апрелендә Казакъстанның Семипалатинск шәһәрендә туа. Утызынчы еллар башында, Таһирның әти-әниләре туган якларына кайталар һәм Казан шәһәрендә төпләнеп яши башлыйлар. Шунда Таһир 12 нче номерлы ир балалар мәктәбендә укып урта белем ала, 1949-1953 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аны тәмамлагач, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә мөхәррир булып эшли башлый. 1966-1990 елларда ул нәшриятның яшьләр-балалар әдәбияты бүлегендә өлкән мөхәррир һәм бүлек мөдире, 1991—1999 елларда «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара.

Т. Нурмөхәммәтов—язучылык сәләтен әдәби тәрҗемә жанрына багышлаган автор. Аның беренче тәрҗемә китабы—рус әдәбияты классигы А. Купринның балалар өчен язган хикәяләрен үз эченә алган «Сыерчык» («Скворцы») исемле җыентык—1955 елда басылып чыга. Шуннан бирле аның дистәгә якын тәрҗемә әсәрләре дөнья күрә: А.Рыбаковның «Хәнҗәр», «Бакыр кош» («Кортик», «Бронзовая птица») повестьлары, Ю. Томинның «Алмаз сукмаклар» («Алмазные тропы») исемле хикәяләр җыентыгы, Р. Фраерманның «Кыргый эт, яки Беренче мәхәббәт турында хикәят» («Дикая собака Динго, или Повесть о первой любви»), Г. Троепольскийның «Акбай Караколак» («Белый Бим Черное Ухо») исемле повестьлары һ.б.

Узган гасырның сиксәненче елларыннан башлап Т. Нурмөхәммәтов заман әдәбияты яңалыкларын, тормышның яңа үзенчәлекләрен чагылдырган әсәрләрне тәрҗемә итү юнәлешендә актив эшли. Аны бигрәк тә рус прозасының күренекле вәкиле В. Астафьев иҗаты кызыксындыра. Ул бу язучының дүрт әсәрен—«Бәхилләшү» («Последний поклон»), «Талау» («Кража»), «Сүнмәс йолдызлар» («Звездопад») һәм «Патша-балык» («Царь-рыба») повестьларын тәрҗемә итә.

Т. Нурмөхәммәтов тәрҗемә әдәбияты проблемаларына багышланган мәкаләләр, рецензияләр авторы буларак та билгеле. Ул шулай ук Татарстан Язучылар берлеге каршындагы тәрҗемәчеләр секциясе эшендә актив катнаша, 1974-1979 елларда бу секциягә җитәкчелек итә.

Т. Нурмөхәммәтов Татарстан китап нәшриятында утыз биш елдан артык мөхәррир булып эшли. Бу вакыт эчендә ул йөзләрчә әдәби әсәрләргә фатиха бирә, күп язучыларның ярдәмчесе була. Матбугат өлкәсендәге күпьеллык хезмәтләре өчен 1980 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Т. Нурмөхәммәтов—1973 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Ул 1999 елның 25 сентябрендә Казанда вафат була, Буа районының Норлат авылы зиратында җирләнә.

## Хәлим Җәләйгә 70 яшь



Язучы, тәрҗемәче, Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләй (Хәлим Бәдретдин улы Җәләлов) 1940 елның 27 апрелендә Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Олы Солтан авылында колхозчы гаиләсендә жиденче бала булып дөньяга килә. Әтисе 1942 елда Ватан сугышында һәлак булганлыктан, әнисе Мәгъфура тәрбиясендә, бала чактан ук йорт һәм колхоз эшләрендә эшләп үсә. 1957 елда Олы Солтан урта мәктәбен көмеш медальгә тәмамлап, Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга килә. Икенче курстан читтән торып уку бүлегенә күчеп, 1958-1961 елларда Казан киез итек фабрикасында слесарь-ремонтчы булып эшли. Мәктәп елларыннан ук әдәбият-сәнгать белән кызыксынган, үзешчән сәхнәләрдә төрле тамашаларда актив катнашкан Хәлим Җәләй, 1961 елда Казанда театр училищесы ачылгач, бернинди икеләнүсез фабрикадагы эшен һәм институтта укуын ташлый да, имтихан тотып, театр училищесына укырга керә. Аны 1965 елда тәмамлый. Шул елны ук талантлы егетне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына актер итеп эшкә алалар. Инде менә кырык елдан артык ул шунда, спектакльләрдә төп рольләрне башкаручы сыйфатында, оста уены белән тамашачы мәхәббәтен яулаган татар актерларының алгы сафында фидакарь хезмәтен дәвам иттерә. 1976 елда аңа Татарстанның атказанган һәм 1992 елда Татарстан Республикасының халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Татар театрының күренекле артисты һәм нәфис сүз остасы булу өстенә Хәлим Җәләй шигъри җанлы, йөгерек телле каләм иясе һәм оста тәрҗемәче дә. Ул— балалар өчен татар халык иҗаты сюжетларына таянып язган һәм нәни укучылар тарафыннан яратып кабул ителгән «Корчаңгы тай һәм Таз малай» (1992), «Турай батыр» (1993), «Шәрә бүре» (1994), «Аю белән Төлке» (1997), «Пәриле күл буенда» (1998) исемле әкият-поэмалар авторы. Узган гасырның туксанынчы елларында Г. Камал исемендәге театрның кече сәхнәсендә яшь тамашачыларга Х. Җәләйнең берничә әкият-пьесасы («Тылсымлы йозак», «Шәрә бүре», «Шомбай эшләпәсе») буенча мажаралы спектакльләр дә күрсәтелә һәм уңыш казана.

Тәрҗемәче буларак, Хәлим Җәләй татар театрларының репертуарын төрләндерү һәм баету юнәлешендә эшли. Аның тәрҗемәсендә Г. Камал театрында А. Вампиловның «Булмас димә, дөнья бу!», Чыңгыз Айтматовның «Ахырзаман», А. Галинның «Сагыш» («Ретро»), норвегияле классик драматург Һенрик Ибсенның «Өрәкләр» пьесалары сәхнәгә куела. Артист-язучының оста каләме белән Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе ихтыяжлары өчен А.Островскийның «Кичеккән тәүбә» («Не живи как хочется»), Ж.—Б. Мольерның «Дон Жуан, яки Таш кунак» әсәрләре тәрҗемә ителә. 1987 елда Татарстан китап нәшрияты исә Хәлим Җәләй тәрҗемәсендә А. Вампиловның дүрт пьесасын эченә алган «Провинция мәзәкләре» дигән күләмле җыентыгын дөньяга чыгара.

Х. Җәләй—1998 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Юбилярны олы бәйрәме белән кайнар котлыйбыз, аңа яңа иҗади уңышлар, нык сәламәтлек телибез!



Алия Габделхакова

# «БЕЛМӘҮ ЯХШЫРАК...»

ФАНТАСТИК ХИКӘЯ

Ишек тавышсыз-нисез генә ачылып китте. Бүлмәгә очып диярлек 2044нче килеп керде. Ул, туктап та тормастан, туп-туры 114нченең өстәле янына узды.

—Миңа рух ясарга кирәк иде.

1141нче ашыкмыйча гына күзлеген салды, пыялаларын парландырып сөртте һәм аны яңадан борынына элде. Шуннан соң гына 2044нчегә күтәрелеп карады:

—Йә?

2044нче 114нченең салмаклыгына күнеккән иде инде. Шуңа да үтенечен сабыр гына кабатлады:

—Миңа рух ясарга кирәк иде.

114нче күзлеге өстеннән генә 2044нчегә карап тора башлады.

2044нче—яшь кыз. Хәер, «Дуслык» станциясендә кешенең яшен билгеләү мөмкин түгел. Яңа вакцина уйлап табылганнан бирле станциядәгеләр картаймыйлар, барысы да 20-30 яшьлек булып кала бирәләр. Чынлыкта күбесе 300нең теге ягына чыккан булса да. Ә 2044нче 114нче өчен һәрвакыт япь-яшь кыз ул. Чөнки аны кечкенә кызчык итеп хәтерли. 114нче эшкә киткәндә 2044нче комлыкта уйнап кала иде. Аның исеме ... Сөмбел иде. Станциядә, узганнарен онытыру максатыннан, кешеләргә исемнәре урынына саннар таккач, барысының да исеме онытылган. Хәтта үзенеке дә. Ә 2044нченеке истә менә: Сөмбел...

114нченең уйга калуын күреп, 2044нче сабыр гына көтеп торды. Карт белән бу еш була иде. Әйе, хәзер аңа 25тән артыгын бирә алмыйсың. Әмма кыз аны кечкенә ак сакаллы уйчан бер карт итеп хәтерли иде әле. 2044нче уйнаган комлык яныннан үткәндә ул аңа гел тәмле прәннекләр бирә торган иде. Аның әтисе белән бергә эшли иде 114нче.

114нченең уйга калып торуларына «Дуслык»та иялəшкəннəр инде. Станция тирәли ниндидер билгесез инерция белән әйләнеп йөрүче Ай кебек үк, гадәти бер күренеш иде бу.

Ай дигәннән, күпме тырыштылар ошбу үткән калдыгын ирекле очышка җибәрергә. Булдыра гына алмадылар. Ай, хуҗасын югалткан эт беренче

очраган кешегә ияреп киткән кебек,«Дуслык» артыннан инде ничәмә-ничә еллар ияреп йөри ул.

Җир белән бәйле хатирәләрне яңартучы бердәнбер нәрсә булып шул Ай гына калды. Нәрсә әйтәсең инде, кешеләр үзләре үк үткәннәре белән бәйле бөтен нәрсәне эзлекле рәвештә юкка чыгардылар. Станция төзелгәндә үк Җирдән «Дуслык» ка артык бер нәрсә дә алмаска диган килешү төзеделәр. Бер нәрсә дә. Хәтта исемнәрен дә. Бу килешүне үтәмәгән һәркем Җирдә кала ала иде. Тик тиздән юкка чыгачак планетада калу үлемгә тиң иде. Әлбәттә, берәүнең дә күрәләтә үз-үзен үтерәсе килмәде. Шуңа да станциялеләр «Дуслык»ның язылган һәм язылмаган кануннарын бер карусыз үтиләр дә. Ниһаять, 114нче дөньялыкка әйләнеп кайтты. Ул 2044нчегә туры карап:

—Сурәт каян алдың?—дип сорады.

2044нче башын аска иеп,идәнгә төбәлде.

«Дуслык»та сурәт саклау тыела. Йөзләрчә еллар элек качырып Җирдән алып килгәннәрен дә вакыт юкка чыгарган. Ә нәрсәне дә булса кәгазьгә сурәт итеп төшерү катгый тыела.

114нченең күзе кысыла төште.

—Сөмбел?

Кыз дертләп китте. Болай итеп аны 114нче генә атый иде. Һәм бары—икесе генә калгач. Башкалар ишетсә,бу гап-гади исем икесенә дә үлем белән яный. Шуңа да 114нче аны бик сирәк,бик мөһим очракларда гына куллана иде.

—Миңа кирәк.—Кызның тавышы ныклы иде. Каршы килүдән файда юк. Бөтен станциядән бер шушы кыз гына 114нчегә якын-үз иде. Башкалар эш турында гына сөйләшә,эш буенча гына аралаша иде. Ә 2044нче белән ул Ай турында да,кайчандыр аларга тормыш биргән Җир турында да сөйләшергә курыкмады. Чөнки 2044нченең шымчы булмавын төгәл белә. Станциягә килгәндә яңа 7 яше тулган кызчыкны шымчы итеп билгеләргә берәүнең дә башына килмәс иде. Бу кызчык станциядә булырга тиеш тә түгел иде. Аның әтисе 114нче белән бергә эшли иде. Станция төзелгәч, анда җибәреләчәкләр исемлегенә кертелде. Гади кешеләр өчен Җир тиргәлеген өйрәнү үзәге дип аталса да,«Дуслык»ның кешелек яшәп калачак бердәнбер нокта икәнен институтта һәркем төгәл белә иде. Тик аңа Җир шарының барлык халкы сыймый иде шул. Шуңа күрә исән калырга лаеклы шәхесләр исемлеге төзелде. Җиргә якынлашучы комета турында кешеләргә берни дә әйтмәделәр—нигә алдан куркытып куярга ди?

2044нченең әтисе үзе урынына «Дуслык»ка кызын җибәрү өчен барысын да эшләде. Кызының үзенчәлекле зат икәнен исбатлаучы тикшеренүләр,гадәти булмаган геннарны билгеләүче анализлар,кирәкле кешеләргә ришвәт төртү—берсе дә калмады. Нәтиҗәдә, җиде яшьлек кыз зур абый-апалар арасына килеп эләкте. Уйнар, аралашыр яшьтәше булмаган кыз бердәнбер таныш кешесенә—114нчегә тартылды. Ул да берөзлексез «Дуслык» кирәк-яраклары турында гына сөйләшеп һәм уйлап арыганнан соң кызчык янында чын-чынлап ял итә иде. Күңеленә рәхәт булып китә иде аның. Кызга әтисе турында да,ничек бергә эшләүләре турында да бәян итә, хәтта хәтер төбендә сакланып калган әкиятләрне дә сөйли иде һәм үзе дә кызның киләчәкне күзаллап сөйләвен рәхәтләнеп тыңлый иде.

2044нче чынлап та үзенчәлекле зат булып чыкты. Ул киләчәкне күрә иде. Шуның белән, станциядә яшәүчеләрне ялгыш адымнардан, киләчәксез тикшеренүләрдән саклый иде. Аның өчен бу—гадәти хәл, калганнар өчен могҗиза иде.

—Ярар,—114нче бүлмә уртасында эленеп торган үтә күренмәле элпә янына килеп басты да,һавадагы бер ноктага төртте. Элпәгә җан керде. Ул зәңгәрсу төс белән балкый башлады.

—Нәрсәнең рухын ясарга җыенасың,йә?

Ул тагын бер-ике ноктага кагылып,элпәгә катлаулы бер схема чыгарды.

—Тик бел,—114нче кызга җитди-кырыс кына карап алды.—Син миннән берни дә сорамадың! Рух ясау турында берни белмисең! Килештекме?

—Мин берни дә белмим,Әхмәт абый.

Кызның тыныч, ишетелер-ишетелмәс тавышы 114нчегә яшен суккан кебек

тәэсир итте.

Әхмәт! Аның исеме—Әхмәт! Ничек оныттырга мөмкин булган моны? Кара әле, хәтерендә саклап калган бит Сөмбел. Аның исемен саклаган.

114нче беркавем югалып торганнан соң, башын чайкап алды. Аннары Сөмбелгә бакты.

—Йә, кемне ясыйбыз инде!?

Бу юлы аның тавышы тыныч-сабыр иде. Сөмбел куеныннан кечкенә кәгазь битен чыгарып, уңайсызланып кына 114нчегә сузды.

—Песи...

—Песи?—114нче кулындагы кәгазь битендә бик оста итеп төшерелгән мәче баласын күрде.—Үзең ясадыңмы?

Сөмбел башын ия төште. Күзләрен яшереп кенә:

—Әйе,—диде.

114нче елмаеп куйды. Сәләтле кеше һәрьяктан сәләтле шул инде. Югыйсә Сөмбелне «Дуслык»та берәү дә рәсем ясарга өйрәтеп утырмады. Кемнең дә булса сурәт төшергәнен күргән булуы да мөмкин түгел. Нинди оста ясаган үзе.

Кыз 114нченең уйларын укый иде, ахрысы.

—Әти мине 5 яшьтән рәсем мәктәбенә йөртте.

—Аңлашылды. Ә нигә кирәк сиңа песи?

—Минем кечкенә чакта песием бар иде. Ялгызлыктан куркам мин. Бүлмәмдә үзем генә калудан куркам.

Бу вакытта һавада эленеп торучы элпәдәге схема хәрәкәткә килеп, бүлмәнең диварларында чагыла башлады. 114нче схемадагы кызгылт ноктага кагылды һәм хасил булган турыпочмаклыкка Сөмбел ясаган песи сурәтен терәде. Сурәт кәгазьдән турыпочмакка күчте. Буш калган кәгазь идәнгә төшеп җиткәнче эреп юкка чыкты. Бу вакытта турыпочмактагы песи сурәте тулылана, гәүдәгә ия була башлады. Ясалган йон бөртекләре чынга әйләнеп кабарды, яссы гәүдәсе тулыланды, яшькелт күзләре очкын чәчеп яна башладылар. Күз ачып йомганчы кечкенә мәче баласы һавада эленеп тора иде инде. Ул, үзенең кайда икәнен аңлап, кызганыч тавыш белән мяулап та куйды әле һәм шунда ук идәнгә егылып төште. Сөмбел мәче баласын тиз генә тотып алды да, 114нчегә сузды. 114 нче мәченең баш артындагы йонын капшый-капшый бер ноктаны эзләп тапты. Шул ноктага басуга, песи баласы юкка чыкты. Аның урынына Әхмәт кулында нечкә генә беләзек барлыкка килде. Сөмбелнең кулына кигезгәндә, 114нче сорап куйды:

—Куша беләсеңме?

—Әйе.

—Акрын гына тартырга кирәк...

—Әйе.

—Акрын гына...

—Әйе.

Беләзек кулына күчү белән, 2044нче тизрәк китү ягын карады.

—Әй, гел оныткanмын! Мин бит 5589нчыга килешү төзеп кертергә тиеш идем.

—Ярар. Бар.

144нче схемадагы кызыл ноктага кагылды. Схема элпәгә җыелды. Элпә читенә төрткәч, ул да төссезләнеп юкка чыкты.

Бик ашыгып чыгып киткән булып кыланган Сөмбел ишек төбендә басып игътибар белән 114нченең элпә өстендәге эшләрен карап торды. Шуннан соң гына бүлмәдән чыгып, тавыш-тынсыз ишек артында бераз уйланып торды. Кинәт, ниндидер мөһим нәтиҗә ясагандай, башын селкеп куйды һәм кабат 114нченең бүлмәсенә үтте. 25 яшьлек карт инде кабат ниндидер мөһим эшләренә батып өстәл артында утыра иде. 2044нче кергәч, ул башын калкытты:

—Элпә берәр нәрсәңне оныттыңмы?

2044нче баш какты һәм, «Рәхмәт», диде. Аннары 114нченең маңгаена беравык иреннәре белән кагылып торды ул.

—Рәхмәт!

һәм ишек артында юк булды.

114нче исә, чынмы бу дигәндәй, ишеккә текәлеп карап торды. Аннан булган хәлнең чынлыгын исбатларга теләгәндәй, маңгаена кагылды. Бер минут элек кенә кызның иреннәре кагылган урын ут кебек яна иде.

2044нче исә бүлмәсенә кайту белән язу өстәле артына утырды. Тик ул берниндидә килешү төзергә уйламый иде. Кыз яңа гына 114нче биргән күренер-күренмәс беләзеген акрын гына тартып карады. Мизгел эчендә беләзек урынына кечкенә мәче баласы пәйда булды. Сөмбел куркынган песине сыйпап тынычландырырга тырышты. Йөзенә якын ук китереп, аның яшел күзенә бакты.

—Беләсеңме, нәнеш, Әхмәт абый иртәгә безне калдырып китә бит.—Кызның күзенә яшь тыгылды, тавышы калтырый башлады.—Әйе, китә. Ләкин курыкма син. Мин хәзер ничек рух ясаганнарын беләм. Мин барысын да, барысын да хәтерлим. Курыкма...

Кыз песинең баш артындагы ноктасына басты. Аннан, өстәл тартмасыннан чиста кәгазь алып, ашыга-ашыга рәсем ясый башлады. Ун минуттан кәгазь битеннән аңа 114нче карап тора иде инде. Кыз берара сурәткә текәлеп торды. Күзенә кабат яшь бөелә башлагач кына кәгазьне түшенә яшерде. Стена янына килеп, аңа алты урынлы сан сызды. Бүлмәдә станция белән идарә итү берлеге башлыгының тавышы яңгырады:

—Нинди яңалыклар бар, 2044нче?

—Иртәгә 114нче безне калдырып китәчәк.

—Аңламадым, 2044нче.

—Иртәгә 114нче үләчәк.

—Үләчәк? Сез ялгышмыйсызмы?

—Минем моңарчы ялгышканым булдымы, 1нче?

—Юк та бит... Ләкин картлыкны җиңгәчтен...

—Сез әҗәл даруы уйлап таптык дип уйлыйдыгызмы?

—Әйе ... Юк! Ләкин моңа ышану авыр бит.

—Мин сезгә мәгълүмат бирдем. Ышану-ышанмау—сезнең эш.

—114нче үзе беләме?

—Юк. Тиеш тә түгел. Белмәү яхшырак. Шулай бит?

2044нченең тавышында Җирнең гади халкына тиздән юкка чыгачаклары турында әйтелмәвенә үчегү яңгырый иде. 1нче, аннан йөзләрчә чакрым ераклыкта булса да, моны сизде. Уңайсызлыкны бетерү өчен йөткереп алды.

—Ммм... Ярар. Нәрсә эшләргә тиеш инде без?

—114нченең бүлмәсен миңа бирергә. Тентүсез.

—Риза. Тик...

—Булды, мин арыдым.

Бу сүзләрдән соң сөйләшү тәмамланырга тиеш. Шуңа да 1нче кыска гына:

—Ярар. Килешәм,—диде.

Элемтәне өзү хокукы һәрвакыт 2044 нчедә. Ул, дивардагы саннарны сөртте дә, шул диварга башын терәп үксеп елап җибәрде.

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ ИЛҺАМ

## Остазым табигать булды

Һичбер арттырусыз әйтәм: мине җырларга табигать үзе өйрәтте. Ләкин сез бер дә гаҗәпләнмәгез. Әйе, табигать чынлап та минем беренче укытучым һәм остазым булды. Безнең авыл урманга якын гына урнашкан. Тәрәзәне ачып куйсаң, сандугачлар сайраганы, кәккүкләр кычкырганы аермачык ишетелеп тора һәм шул чакта кошлар оркестрына кушылып җырлап җибәргәненне үзең дә сизми каласың.

Тагын шунысын да әйтим: вакытлы-вакытсыз җырлап йөргәнне өйдәгеләр дә бик өнәп бетермиләр иде. Шул җырлавым аркасында кайвакыт Кыям абый белән чәкәләшеп алган чакларыбыз да булгалый иде. Шуна күрә мин бик җырлыйсым килгәндә еш кына урманга барып, усак егетләре, каен кызлары алдында «концерт» куя идем.

## Беренче концертлар

Биш-алты яшемдә үк инде авыл халкы минем җырларга һәвәс икәнемне белеп алган иде. Клубта берәр концерт булды исә, абый-апалар: «Гыйльметдиннең төпчек малае да җырласын»,—дип, кул чабарга тотыналар. Һәм мине шундук сәхнәгә күтәреп тә менгерәләр. Үзем каушыйм, дулкынланам. Кулларымны да кая куярга белми аптырыйм. Бер мәлгә җырның сүзләрен дә искә төшерә алмыйча азапланам. Житмәсә, гармунчы абый да ашыктыра: йә, кайсысыннан башлыйбыз соң, энекәш?»—ди. Билгеле, «Сарман»нан инде. Иң яраткан җырым ич ул минем.

Җырны тәмамлавым була, залдагылар: «Давай, тагын җырласын»—дип дәррәү кул чабарга тотыналар. Ә мин ялындырып тормыйм—җырлыйм.

Шулай да минем беренче «зур концертым» 1943 елның 31 декабрендә булды. Миңа ул чакта сигез яшь иде. Чыршы бәйрәме буласы. Ул чакта әле уенчыклар да юк иде. Аларны үзебезгә ясарга туры килде. Безнең тамашаны карарга бөтен авыл халкы җыйналды.

Менә концерт башланды. Мине нишләптер иң ахырдан җырлаттылар. «Шахта» һәм «Сарман» көйләрен башкардым.

Концерттан соң мине иптәш малайларым—Нурулла, Йосыф, Габделхәйләр сырып алды. «Илһам, син җырлаганда әниләр җылап утырды»,—диде алар. Миңа бик уңайсыз булып китте. Әниләрне җылатканга үземне гаепле санадым. Болай да ут йотып яшиләр ич. Авылга кара пичәтле хат килеп төшкән саен җаннарын кая куярга белмиләр.

Бераз үсә төшкәч кенә аңладым: чын халык җырлары кешене җылата да, сагышландыра да, шатландыра да ала икән.

## Күрде инде башлар...

Әй, ул чабата заманнары...

Лесник күрмәсен дип, юкәгә урманга төнлә чыга идем. Әйткәнемчә, әле бит аның чабатасын сату үзе бер әҗәл. Лесник алып калмасын дип, йә Нөркәй, йә

Teлəнче Тамак базарына сатарга төнлə китəм. Шул тегеннəн-моннан кергəн акчага көн итəбез. Чабата эше бөтенебезгə житə. Абый Кыяметдин тезə, мин кайтарам. Бу эшне миннəн дə оста башкаручы юк иде. Хəерчелек итəктəн тарта. Шул юклык аркасында бишенче класска жибəрмəделəр. Укырга йөргəн булсам, болай ук монлы да булмас идем. Əнием белəн икəү генə калгач, жырларга тотынабыз. Урамнарга тиклем ишетелгəндер тавышыбыз. «Житте, тагын кемнен башына житəргə жыенасыз, əтиегез башына життегез бит»,—дип тə карыйлар. Юк...

Əтине утыз жиденче елны алып киткəннəр дə, бер хəбəре дə килмəде.



Тимерче булган, бик укымышлы кеше иде дилəр. Авыл халкы аны тынларга гел тимерчелеккə жыелган. Мин аны хəтерлəмим. Кая хəтерлəү ике яшьлек балага. Авылда халык дошманы баласы дип бик кимсетмəделəр. Ə менə Алабугага укырга керергə барып ике имтихан биргəч, борып кайтардылар. Шуннан сон Казанга инженерлар мəктəбенə киттем. Баксам, анда 5 ел укый торганына кеше тулган, ə өч еллыгы агач мастерлары гына əзерли икəн. Инде армиягə бармас өчен музыка училищесына кердем. Кердем дə авылыма кайттым. Кайтышыма военкоматтан повестка килгəн. Бер кулга сохари капчыгы, икенчесенə кешелеккə киярге дигəн кəчтүмне тотып Казанга юл тоттым. Пристендə бөтен нəрсəне урладылар, паспорт та юк, чурт та... Миннəн бəхетсез бала юк икəн. Башыма əллə нинди шомлы уйлар килə башлады. Ярый əле апам Зəйнəптəн матур эчтəлекле хат алдым. «Синнəн бəхетле кеше булмас əле».—дигəн иде ул анда.

## Юктан килгəн бəхет

Дөньяда ин авыры—хəер сорашу. Май башы булгандыр—кычыткан да, алабута да юк чак. Əнкəй белəн үргəн чабаталарны алдык та, Пəке дигəн керəшен авылына бəрəнгегə алмаштырырга киттек. Алмыйлар чабаталарны. Көчкə телəнеп бер потка якын бəрəнге жыя алдык. Арбага салып кайтыр юлга чыктык. Арбасы да кешенеке бит əле анын. Юл шактый, тау да менəсе бар. Ачлыктан аякларнын хəле китте—бөтенлəй атламас булдылар. «Əни, башка бара алмыйм, Чыршы авылына кереп ял итик»,—дим. Авыл читендəге бер йортка кердек. Аларда да шундый ук хəерчелек, өс-башлары юк, үзлəре дə чабата үреп утыралар. Бəрəнгене пешереп ашагач, хəл кереп китте. Тоз юк икəнен əйтеп тə тормыйм инде. Кайтсак, Зəйнəп апам—каян тапкандыр—кычыткан ашы пешереп куйган. Менə бəхет иде инде ул, ичмасам!

## Тегермəндə

Сугыштан сонгы еллар... Хəерчелекнен чиге юк. Бəлəкəй чана тартып күрше авылга тегермəнгə бардым. Чанада, капчык төбендə, ярты пот арыш.

—Һəй, энем!—ди тегермəнче кызганыпмы мине, хəлемə керепме.—Синен бу арышын тегермəн ташына сыланып кына бетə бит!

Ə анын сыланып бетми торган хəтлесен каян аласын? Булса бер-ике капчык алып килер иден дə бит... Ашыйсын килгəч, нишлəмəк кирəк? Шушы кадəресенə дə риза булырсын. Житмəсə, чираты бит əле анын сыер койрыгы чаклы—озак көтəргə туры килер инде. Уйнарга хəл юк, нишлисен? Капчыгым өстенə утырып, монаям. Тегермəн ташы əйлəнə тора. Жылы, рəхəт, он тузаны борынны кытыклый. Тегермəнченен дə керфеклəренə он кунган. Карыны ачкан кешегə он исеннəн дə лəззəтле ис юктыр!

Онытылып кычкырыбрак жырлый башлаганмын, ахрысы. Он тарттыручыларнын тын калып тынлап утыруларыннан унайсызланып киттем. Авыз кутəреп жырлап утыр əле син көпə-көндез! Берсе:

—Бигрәк шәп жырлый,—дип куйды.

Ниһаять, кеше арышына кушып минем капчыкны да өстәге бүрәнкәгә бушаттылар. Жайлап кына мөшкәдән аккан онны бәләкәй көрәк белән капчыгыма тутыра башладым. Хәйран гына була икән ул тарткач. Байтак кына тутыргач, тегермәнче күреп, көрәгемне тартып алды да:

—Житәр, егет! Артыграк китте түгелме?—дип капчыгымдагы онны кабат ларга аудара башлады.

—Абый, бик аз кала бит...

Тегермәнче дә нишләсен, башкалар өлешенә керә алмый ич.

Урман юлыннан чанага салып он алып кайтам. Үзем тарттырган он—жып-жылы арыш оны.

Ул чакта шул оннан пешергән ипидән дә тәмле нәрсә булды микән?



## «Күке» Илһам

Кайсы авылда юк инде ул кушаматсыз кеше? Санап тормыйм, үзебезнеке дә—«Күке».

Малайлар белән ачуланышсак, күзне ачырмыйлар. Күке дә күке.

—Күке, әйт әле, минем ничә ел яшисем калган?—диләр.

Нәрсә дип әйтергә дә белмим, гарьлегемнән елап ук жибәрәм. Өйгә хәтле үксеп кайтам. Нигә шулай дип әйтәләр? Минем бит күке булып кычкырганым да юк.

—Әнкәй, нигә мине күке дип үчеклиләр?

—Нигә исең китә ана шулхәтле,—ди әни.—Бер дә күз яше түгәсе түгел. Бабаннан калган кушамат ул. Сөенергә генә кирәк! Гомер-гомергә күке Шакир балалары булып йөргәнне!

Әнием Шакир бабам белән булган хәлне сөйләп бирде. Бабайның Илһам кебек кечкенә вакытта ялан тәпи генә йөгереп йөргән чагы икән. Боларның күршесендә генә сырхау түти яшәгән. Көннәрнең берендә бу түти басу капкасыннан чыгып бара ди.

—Кая киттен, апа?—дип сораган аннан Шакир.

—Урманга,—дип жавап кайтарган теге түти.—Күкедән сорыйм әле: ничә ел гомер юрар икән...

—Ничә ел кирәк сон сиңа, апа?

—Ничә ел дип... Якты дөньядан кем тиз генә аерылырга теләсен?!

Нишләсен инде Шакир, кыш буе кипкән жиләк-жимеш белән сыйлаучы апаның озын гомерле булуын ул да тели ич! Һәм малай түти артыннан урманга китә. Урманга аяк басуга күрше апа эндәшә:

—Күке! Ничә ел яшисем бар?

Куаклар артында качып торган Шакир күке булып йөз мәртәбә кычкыра. Теге апа урманнан бөтенләй сәламәтләнеп кайткан. Менә шушы хәлдән соң Шакирга күке кушаматы тагылып кала. Шушы кыйссаны тынлагач, мин күке кушаматының бер дә начар түгеллегенә ышандым.

## Икенче исәнләшмәс идем

Ул елларда ачлы-туклы яшәсәк тә безне өлкәннәр олыны—олы, кечене—кече итәргә, бер-береңә миһербанлы булырга, урамда очрашканда исәнләшеп үтәргә өйрәттеләр. Авылларда ул хәзер дә әле бер-берен белән сәламләшү, хәл белешү гадәтләре яши бирә. Шәһәрдә кеше кешене белми—бәреп китсәләр китәләр, борылып карау юк—кая ул исәнләшү.

Шулай—балачак—урам буйлап барам. Үземне инде егет булып үстем дияргә

маташкан чагым булгандыр. Чама белән тартып-сузып алты-жиде яшьләр тирәседер... Жә, ярый, күпме булса да... Сүзем ул турыда түгел. Каршыма Каз Габдулла абый килә. Аны күрүгә мин житдиләнеп, бераз аяк очларына күтәрелеп (үсеп житкәнне белдерәсе килүемдер инде) атлый башладым. Габдулла абзый әллә мине күрми дә?! Мин кычкырып сәлам бирергә булдым.

—Нихәл, Каз Габдулла абзый!

Габдулла абзый мина борылды да, колактан күтәреп:

—Бирермен мин сина Каз Габдулла!—диде.

Мин әйтәм:

—Әл-ләл-лә, әл-ләл-лә! Авырта бит! Икенче исәнләшмәс идем, Каз Габдулла абзый. Үлсәм дә!..

Кем белгән аны шул вакытта Габдулла абзыйның кушаматы өчен колактан күтәргәнен. Мин бит исәнләшкән өчен дип торам.

---



## Өмет сүнмәде

**Нәрсә генә булды безгә,**
**Нишләдек без?!.**
**Әллә шулай араларны**
**Бутады көз?!**

**Чыгып киттең тормышымнан**
**Берни әйтми.**
**«Кайтырмы?»—дип сорасам да,**
**Җилләр дәшми...**

**Бер кулымнан җитәкләгән**
**Шашкын сөю.**
**Икенчесен—ялгызлык һәм**
**Сагыш, көю...**
**Синсез атлыйм... Никләр киттең—**
**Аңламадым.**
**Ә ишекләр ачык калды—**
**Мин япмадым...**

**Китүеңнең сәбәпләрен**
**Белалмадым.**
**Йөрәккә йозак шулай да**
**Элалмадым...**

## Сөю бар әле!

**«Яратам»,—да димә, «Сагынам»,—да димә,**
**Кулларымнан гына ал әле.**
**Назларыңнан хисләр елмайса,**
**Аңлармын мин: сөю бар әле!**

**«Авыр»,—димә, «Синсез авыр» ,—димә,**
**Күзләремә генә карале.**
**Карашыңнан йөрәк җылынса,**
**Аңлармын мин: сөю бар әле!**

**«Бәләкәчем»,—димә,—«матурым»,—да димә,**
**Кочагыңа гына ал әле.**
**Өшегән күңелем уянса,**
**Аңлармын мин: сөю бар әле!**

**Айгөл СӘЛАХОВА,**
*Казан*

## АЧЫШЛАР ҺӘМ ЯБЫШЛАР

### Каләм белән планета табу

1781 елда инглиз астрономы Уильям Гершель озак еллар, гасыр буена диярлек йолдыз дип исәпләнгән бер күк җисеменең чынбарлыкта Кояш тирәсендә йөрүче планета икәнен ачыклый. Аны Уран дип атыйлар. Яна планетаның орбитасын өйрәнгәндә астрономнар аңа үзенең тартуы белән тәэсир итүче тагын да ераграк билгесез бер планета барлыгын ачыклыйлар. Астрономнар алдына бик кыен мәсьәләләр килеп баса: Уранның теоретик орбитасыннан аз гына булган тайпылышларын тикшереп, әнә шул тайпылышларның «провокаторын фаш итү", X тамгалы планетаның орбитасын өйрәнү, орбитаның рәвешен һәм кинлекләрдә торышын белеп, күк йөзендәге күренмәле траекториясен, ягъни эфемерида дип атала торган «юлын»билгеләү. Оныкларның холкын өйрәнеп, аларның әби-бабаларының психикасын тасвирлауга охшатам мин андый катлаулы тикшеренүләрне. Шундый кыен математик мәсьәләне бер үк вакытта ике галим, француз У. Леверрье һәм инглиз Дж. Адамс чишеп бирә. Хәер, Адамс ул чакта студент кына була әле. Гринвич һәм Кембридж астрономнары студент галимнең нәтиҗәләренә ышанмыйлар, ул тәкъдим иткән эфемериданы файдаланып яна планетаны эзләү турында уйлап та карамыйлар. Студентның мәкаләсе фәнни журналда бастырылмый да. Шул арада Адамсның эше турында берни белмәгән Леверрье үз тикшеренүләренең нәтиҗәсен матбугатта да бастыра, хат язып, Берлин обсерваториясенең астрономы И. Галлега да житкерә. Галле 1846 елның 23 сентябрендә хат алгач та күк йөзенең Леверрье атаган өлкәсендәге эфемерида нокталарын күзәтә башлый һәм шул кичтә үк яна планетаны таба. Аны Нептун дип атыйлар. Ф. Энгельс яна планетаны «каләм очында»ачу фактын Ньютон раслаган бөтендөнья тартылыш законына иң көчле дәлил дигән иде.

Ике Академия, Париж Фәннәр академиясе һәм Анлия Король җәмгыяте арасында бу хакта, ягъни «иң башта кем: Адамсмы, әллә Леверрьемы «әһә!»дип кычкырды?»темасына бик ямьсез бәхәсләр башлана. Адамс белән Леверрье гомерлек дуслар булып китәләр. Кызык бит: «фән фанатлары»арасында ызгыш бара, ә «фән локомотивлары»хезмәттәшлек һәм дуслыкка омтыла.

XX гасыр башында америкалы астроном П. Ловелл, Леверрье һәм Адамсның алымнарын кулланып, Нептуннан да ераграк тагын бер планета барлыгын раслый. Әмма аны йолдызлар арасыннан эзләп табу өчен озак еллар буена фоторәсемнәрне өйрәнергә, йөзләрчә меңләгән йолдызларның торышын тикшереп, «яшеренеп»йөргән планетаны «фаш итү»кирәк була. Бу тикшеренүләр 1930 елда «Плутон»дип аталган яна, тугызынчы планетаны ачу белән тәмамлана.

### Ачылганны ябу мисалы

Шундый зур хезмәт нәтиҗәсендә табылган Плутон сиксән ел чамасы Кояш системасының «абруйлы»әгъзалары, ягъни планеталар исәбендә йөрде. Әмма берничә ел элек галим халкы Плутон белән аның табигый иярчене Харонның үзара охшашлыгына игътибар иткән иде. Иң мөһиме: алар массалары белән бертуган шикелле. Әгәр үз планетабыз Җирнең массасы иң якын космик күршебез Айныкыннан 81 мәртәбә зуррак булса, Харон үзәк планетасы Плутоннан ике генә тапкыр җинелрәк. Шуңа күрә Халыкара Астрономия Союзы Плутонны планета дип түгел, ә шактый зур, массасы Җир массасының 1/500 өлешен тәшкил иткән астероид дип исәпләү хакында карар кабул итте. Ягъни сиксән ел элек башкарылган ачыш хәзер инде «ябылган»дип исәпләнә.

**Ким ШАКИРОВ**

## *Интер-кайтаваз («WWW. matbugat. ru»дан)*

### Әйтмәскә! (№ 2)

Мәхәббәтнең була төрлесе...

Мәхәббәт—ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта...

Ә минем яратып йөргән егетем өйләнде, хисләребез уртак иде, бәлки, ялгышканмын...

Мин аны беренче күрүдә үк ошаттым, елмаеп кабинетта утыра иде.. «И, Ходаем, мине эшкә алсыннар да, бергә эшләсәк иде», дип теләдем. Теләгем кабул булды.

Без кычкырышмадык, сугышмадык, матур аерылыштык.. Чөнки ул өйләнде.. «Бәгырь, сине сөям, ләкин баланы ташлый алмыйм», диде. Мин аңа рәнҗергә тиеш булганмындыр, булдыра алмадым, чын күңелемнән бәхет теләдем.. Юләрлек, көчсезлек.

Еладым, тик күз яшьләремне ул күрмәде. «Еламадың да, сөймәгәнсең, димәк», диде.

Хәзер дә бергә эшлибез. Аны күз кырые белән генә күрү дә мина канатлар үстерә, яшисем, эшлисем килә башлый! Шул ук вакытта йөрәк әкрен генә үлә бара... Бернине дә кайтарып алып булмый... Тиздән бала туачак.

Бәхетле булсын сабый!

Сөйгәннәрегезне тилмертмәгез, алдамагыз.

Кызлар бит бәллүргә тиң, егетләр, сакларга кирәк аларны, якларга.

**Мин дә сөям**

### Арча Ләйсәненә... (№ 3)

...Тулай торакта калса, имеш, «автор» бу кызны яратудан туктаячак икән («анда калсам, минем хыялларым пылт итеп сүнәчәк иде...») Чөнки (бу—минем аңлавымча инде) ул кыз яки автор белән яки башкасы белән йоклаячак. Кем белән йокласа да, хыяллар челпәрәмә киләчәк. Хи-хи. Яки, тагын да куркынычрагы, авторның башка кыз белән йоклап алу «куркынычы» бар... Хәзер автор ул кызны аудиториядә генә күрә, шуңа күрә аңа әлеге кызның «йөзе дә, тавышы да матуррак булып тоела...» Логика да юк монда, хисләре дә аңлашылып бетми. Боламык язганнар.

Автор үзен Ләйсән хәлендә дип язган. Юк, бозау хәлендә ул! Кыскасы, теге 3-4 хатынлы гаилә «атасы» точно чыкмый да чыкмый инде...

**Нух**

Мансур, мин беренче язманы укымадым, тик шулай да сүзнең нәрсә турында барганын аңлыйм. Сиңа киңәш: әйт син ул кызга үзеңнең мәхәббәтең турында. Кыю булса да, нинди генә булса да ул хатын-кыз, ул аңлар сине, әлбәттә, аңлар, аннан соң йә кабул итә инде синең мәхәббәтне, йә юк. Синең кебек студент булганда мин дә бер кызны яраттым, башта курыктым әйтергә, аннан соң әйттем дә салдым. Бик җиңел булып калды. Әлбәттә, ул минем сөюне кабул итмәде, әмма монысы инде бүтән мәсьәлә. Уңышлар телим сиңа.

**maturmalai**

# ЯХШЫ ДУС—ҖАН ЗИННӘТЕ

ДУСЛЫК ТУРЫНДА ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ

**Көнчелсез кеше дус тапмас.**

**Дус дусының этен дә дус күрер.**

**Дусың дус булып калсын дисәң, аңа баш булма, иш бул.**

**Корымнан корым йогар, начар дустан сөрем йогар.**

**Кеше кеше белән дус булса да, кесә кесә белән дус түгел.**

**Дус көлгәндә беленми, бөлгәндә беленә.**

**Атаң-анаң—чын дусың, дус-ишләрең—юлдашың.**

**Ялган дус—мәче: алдан ялый, арттан тырный.**

**Яхшы кием—тән зиннәте, яхшы дус—җан зиннәте.**

***

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*

---




*Бөек Җиңүгә 65 ел*

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЕЛЪЯЗМАСЫ

ЖУРНАЛЫБЫЗ—БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА

**1941 ел.** «Совет әдәбияты»ның 6 (июнь) санында Михаил Лермонтов шигырьләре: «Маскарад», шигырь белән язылган драма (Г. Кутуй тәрҗемәсе), «Тоткын» (Ә. Ерикәй тәрҗемәсе), «Качкын», тау халыклары легендасы. (Ш. Маннур тәрҗемәсе), «Бер ялгызым гына юлга чыгам», «Кыя» (Кави Нәҗми һәм Ә. Ерикәй тәрҗемәләре) дөнья күргән.

**1942 ел.** «Совет әдәбияты»ның 6 (июнь) санында Фатих Кәримнең «Идел егете» поэмасы басылган.

**1943 ел.** «Совет әдәбияты»ның 6 (июнь) санында Зәки Нуриның «Шәһәрне алгач» шигыре, Фатих Хөснинең «Сержант» хикәясе, Шәйхи Маннурның «Мәхәббәт атавында» очеркы, Хәйретдин Мөҗәйнең «Малай белән сөйләшү» парчасы чыккан.

**1944 ел.** «Совет әдәбияты»ның 6 (июнь) санында Әмирхан Еникинең «Бер генә сәгатькә» хикәясе, Гадел Кутуйның «Рөстәм мажаралары» хыялый романы, Локман Бадыйкшанның «Матрос бирелми» хикәясе, Гамир Насрыйның «Минометчы Нуретдинов» очеркы басылган.

**1945 ел.** «Совет әдәбияты»ның 6 (июнь) санында Афзал Шамовның «Дустым кабере янында» хикәясе, Кәрим Әмиринең «Керчькә десант» поэмасы, Шәраф Мөдәрриснең «Чәчәк ускән». Сәхаб Урайскийның «Татарстан», Фатих Кәримнең «Бизәкле ал яулыгың» һәм «Күнел кошым» шигырьләре дөнья күргән.

# «МАТБУГАТ.РУ»ДАН БЕЗНЕ УКЫГЫЗ

## *Рәфикъ Юныс. Бу—төкәнмәс көрәш! 2010, гыйнвар*

Афәрин, Рәфикъ агай! Барча фикерләрегез дә урынлы. Татарча китаплар турында аерым сөйләшү зарур. Район үзәкләрендәге китап кибетләре юкка чыкты. Шаушу тудырган Нурулла Гариф китабын алдыра алмыйм, башка тарихи китаплар да районнарга барып житми—укучысына ирешми! Ата-аналар да зарлана. Китап кибетләре бетерелүгә борчылучы күп.

Яшь муллаларга килгәндә, аларның шәһәрдә өелеп ятуына гажәпләнәсе юк. Авылларда кем акча түли аларга, хезмәтләре өчен? Бездә халык элекке вакыттагы кебек мулла гаиләсен тулысы белән үз жилкәсендә асрарга әзер түгел. Мулла үз гаиләсен кайгырту өчен кайдадыр эшләргә дә тиеш, халыкка хезмәт күрсәтергә дә... Жыен жыеп, муллага һәм гаиләсенә мәшәкатьсез яшәр өчен житәрлек сәдака, анын төрләрен, тапшыру вакытын, күләмен билгеләп, халык шуңа риза булса, шул чагында гына мулла чын күнеленнән халыкка хезмәт итә башлар, минемчә.

**Шөпшә**

Уф! Аллага шөкер! Рәхмәт, админ, ярты елга бер булса да укырлык, баш миләрен селкетерлек язма элеп куйдыгыз. Гөлназ-Айгөл темаларыннан соң синең гамәлең дә чын батырлык булып кабул ителә! Менә бездә нинди авыр проблемалар бар икән бит. Язарлык кешеләр дә бар, бастыручысы да үзләре.

**Ата мачы**

«Ләкин татарның эчке, потенциаль егәре барыбер зур. 90нчы еллар «киләчәк фондына» ниләр салып калдырганын бер күрербез әле». Шушы сүзләр бигрәк тә ошады. Бу мәкаләне чыгарып алып, берничә хезмәттәшемә тараттым әле. Калганнары чират көтә.

**Ланди**

Рәфикъ абыйга рәхмәт бу язмасы өчен. Йөрәгеннән кан тамызып язган. Татар матбугатында андый язмалар һәм андый фидакарьләр сынар кулның бармаклары белән генә санарлык. Язган очракта да бастыруы шактый авыр... Монысы беренчедән. Икенчедән, инкыйраз процессы тизләште. Ул Гаяз Исхакый фаразлаган сроклардан да алдарак килергә мөмкин. Без чаң суккалап алабыз, әмма конкрет рецептлар тәкъдим итмибез. Сыктап кына булмый. Эш эшләргә вакыт житте. Поезд китәргә тора.

**Н. Шәриф**

Россия хөкүмәтенең бу илдә барлык урыс булмаган милләтләрне, бигрәк тә, беренче чиратта, татарларны урыслаштыру һәм аларның телен, мәдәниятен, тарихын юкка чыгару сәясәтен алып баруы күпләребезгә билгеле. Әмма ләкин бу коточкыч гаделсез сәясәткә каршы тору юллары «Казан утлары» журналының беренче санында басылган баш мәкаләдәгечә күрсәтелгән конкрет фикерләр юк иде әле.

**Милләт өчен борчылучы**

## *Газинур Морат. Ике икең биш була. 2010, гыйнвар*

Газинур абзыкаем! Татарнын барлыгын «сикыс», «бәби» сүзләренә таянып искә төшерү—ул әле мөмкин булганнын яртысын гына эшләү дигән сүз! Байрак итеп күтәреп алырлык көчле сүзебез кайда безнен?! Бүген урыснын иң усаллары «бабай китте, татарлар куркып , посып калды!» дип бездән көлә түгелме?! Әнә, кайберсе «ул мескеннәр үзләренә президент та сайлый белми икән!» дип хихылдый. Билгеле, Рәсәй президенты тиз арада иң акыллы татарны тапкан, ни дисәң дә бергә эшлисе... Ә безгә бабай сызган юлдан тайпылмый күп атлыйсы бар әле!

«БР» фиркасында торучыларнын гына ил башлыгы йөген сөйрәргә хакы бар!..» Ишеткәнегез бармы? Имеш, шундыйрак тора хәзер дөньялар! Президент, суверенитет—ул модага кергән сүзләр генә ди!

Чынлыкта, шартларны Мәскәү куя ди. Абзыкаем, безнен Татарстан законнарында ил башлыгын сайлау-озату турында ни язылган соң әле?! Ә Татарстанда ничәү без—фиркалы, ничәү фиркасыз? Шуны беләсе иде... Һм... фиркале идарә итә, фиркасез салымнарын вакытында түләп торса да, идарә итүченең авызына карап тора... Юк, Газинур абзыкаем, бу дөрес хәл түгел.Юк, юк, һәм тагын бер кат юк! Кемнең җаны бу хәлгә кымырҗып тора—тынычландырырга ашыгам—хәлне төзәтеп була! Башлыйк үзебездән! Эреле-ваклы оешмаларга йөкләмә куйыйк, сайласыннар үзилбашын. Мәскәү куйган кешене дә сайлыйк! Анысы да үзебезнеке! Бер казанга ике тәкә башы сыймый дисәләр дә, бу—аерым очрак! Безнең илбашы Мәскәү куйганнын уң кулына әйләнергә тиеш—анын максатлары теркәлгән рәсми кәгазе Мәскәү куйган илбашы өчен юл күрсәткеч булачак. Шунда без отабыз да инде, җәмәгать! Ике илбашы бер максатка—халыкка хезмәткә киләчәк! Урысларның кайберләре, бу ни хәл дип шәрран ярачаклар! Без татарлар югалып калмабыз! «Булдырабыз!» дип язылган байракны югары күтәреп, киләчәккә атларбыз!

**Шөпшә**

## *Рамилә Майорова шигырьләре. 2010, февраль*

Мәгънә бар! Ләкин хәзерге шагыйрь-шагыйрәләр ритмны санга сукмый. Хәер, теге помидорлардан соң, Мәскәү малаен укыгач, бу кызны бүген тотып язучылар берлегенә алып була.

*...Ялтыравык кәгазь-тәнең*
*Бу фани дөньяда калыр...*

«Фани дөньялыкта калыр» дисән унышлырак булыр иде кебек.

**Үпкәләмәгез**

Мин «Казан утлары»н гел карап, күп әйберне укып барам. Яшьләр арасыннан мондый хисле каләме, кителмәгән фикере булган шагыйрьләрне очратканым юк иде әле. Тормыш мәшәкатьләренә күмелеп югалып калмаса гына инде бу кыз. Көнче ирләрдән (бик чибәр бит), кысан кухнялардан Ходай сакласын! Сенелкәш, алга!!!

**Керпе**



*Яңа төзелгән Татарстан Республикасында мәдәният һәм мәгърифәт өлкәсенең күренекле җитәкчеләре Шәһид Әхмәдиев, Галимҗан Ибраһимов. Үткән гасырның 20нче еллары.*



*Чагыштырмача аз мәгълүм, әмма татар халкы өчен күп изге гамәлләр кылган галим, сәясәтче Галимҗан Шәрәф. Узган гасырның 20нче еллар фотосы.*



*Заманында Идел буйлап шундый саллар аккан.*



*Республика җитәкчеләре язучылар белән бергә.*
*Шигырь бәйрәме. 1996 ел.*



*Журналыбызның актив авторы,*
*тарихчы галим Булат Солтанбәков.*



*Безнең кызлар эштән*
*курыкмый! Күренекле*
*каләмдәшләребез—шагыйрә*
*Гөлшат Зәйнәшева (сулда),*
*прозаик Мәдинә Маликова*
*өмәдә. 1991 ел.*

# МАМАДЫШ МӘЗӘКЛӘРЕ

### Өч исемле укытучы

Атаклы фольклорчы галим, язучы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов үзенең хезмәт юлын 1951 елда, Мамадыш урта мәктәбен тәмамлагач, Көек-Ерыкса җидееллык мәктәбендә физика һәм математика укытучысы буларак башлап җибәрә. Җор телле, юморны яратучы 18 яшьлек Түбән Ушмы егете хезмәттәшләре белән дә, укучылар белән дә уртак телне тиз таба. Яшь укытучы үз фәннәренең укучыларга җиңел бирелмәвен яхшы аңлый. Авыр темаларны үткәндә әледән-әле мәзәкләр кыстырып, кызыклы хәлләр турында сөйләп, аларны ял иттереп ала. Укучылар аны үз итәләр, иптәшләре итеп күрәләр. Шуңа күрә үзенә Хуҗа, Мәхмүт, Әхмәт дип эндәшүләренә дә исе китми аның. Укучылардан берничә яшькә генә олырак ич ул. Араларында хәтта яшьтәшләре дә бар.

Беркөнне ата-аналар җыелышы барганда Рәхимулла абый мәктәп директорына:

—Салих белән Камилне күптәннән беләбез, балалар өйдә ниндидер Әхмәт, Мәхмүт, Хуҗа исемле укытучылар турында сөйләшәләр. Таныштырыгыз әле шулар белән,—ди. Өч исемле укытучыга ата-аналар алдына чыгып басарга туры килә. Барысы да көлеп җибәрәләр.

Балаларга ике ел белем биргәннән соң, яшь укытучы Казанга укырга китеп бара.

...Хуҗиәхмәт Мәхмүтовка филология фәннәре докторы, академик дәрәҗәсенә күтәрелү, мәртәбәле исемнәргә ирешү өчен, табигый сәләте өстенә, өч-дүрт кеше тартырлык йөкне җигелеп тартырга туры килгәндер. Авылым халкы телендә дә тикмәгә генә өч исемле укытучы булып калмагандыр ул.

### Габдулла Тукай түгелме?

Алтмышынчы еллар башы. Язучы Мирсәй Әмирнең РСФСР Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән чагы. Кандидат белән Мамадышта очрашу үткәрелгәннән соң, ул безнең Яңа Комазан авылына киләчәк икән. «Әзер булып торыгыз, яхшылап каршы алыгыз»,—райкомнан шундый телефонограмма алына.

Колхоз, авыл советы житәкчеләре, милли киемнәр кигән, кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан мәктәп балалары олы юлга чыгып, Мамадыш ягын күзәтәләр. Тик кандидат кына күренми.

Язучы белән очрашу мәсьәләсендә бераз үзгәреш булган икән. Башта»Таң» колхозына керергә булганнар. Андагы очрашудан соң Мирсәй Әмирне безнең авылга Мамадыш юлыннан түгел, башка юлдан китереп куялар.

Шуна күрә әлипне клуб янында да, колхоз идарәсе янында да каршы алучы булмый. Олы күпернен аргы ягында жыелган халыкны күргәч, Мирсәй Әмир жәяүләп кенә шул якка юнәлә. Юморга бай язучы төркем артында басып торучыларнын берсеннән (ул колхознын партоешма секретаре Әхкам Мөфәхаров булып чыга) бирсдә ни өчен жыелып торуларын сорый.

—Бер язучы кисәге килергә тиеш иде. Мирсәяф диләрме шунда. Нишләптер күренми һаман,—дип жавап бирә тегесе.

—Мин булам Мирсәяф...

Парторг, бераз сәерсенеп карап торганнан сон, әйтеп куя:

—Габдулла Тукай түгелме тагын ?! Аны да алып килергә иде!

## Ничек өйрәтте икән?

1971 елнын август ае. Яна Комазан авылына композитор Заһид Хәбибуллин, шагыйрьләр Галимжан Латыйп, Рәшит Әхмәтжанов һәм Рәдиф Гатауллин килеп төште.

Кичке якта авыл клубында Казан кунаклары белән очрашу башланып китә. Шагыйрьләр кызып-кызып үзләренең шигырьләрен укыганнан сон сәхнәгә композитор Заһид Хәбибуллин чыга. Ул скрипкада Әхмәт Фәйзинең «Бал корты» шигыренә музыкаль этюд башкара. Менә бер заман, чыннан да, композиторнын баш өстендә дистәләгән бал кортлары очып йөри башлый. Аларга яналары өстәлә. Алгы рәттә композиторнын һәр хәрәкәтен жентекләп күзәтеп утыручы Гайнижамал апа, урыныннан торып, болай ди:

—Карагыз әле, карагыз чукынмышны. Андый гына көйләрне үзе ясаган эскрипкәдә безнең авылнын Хатыйп та уйный. Ә менә бал кортларын баш өстендә шулай бөтерелеп очарга ничек өйрәтте икән ул?

Сәхнә артындагы ишек ябып куелганнан сон, бал кортлары очып керү туктала.

## Кечкенә гармун нинди була

60нчы еллар башы. Гармунчы Гали абый Жәмлиханов берсеннән-берсе кечкенә гармуннары белән клубта чыгыш ясый. Халык тын да алмыйча анын уйнавын тынлый. Тынлый һәм... күзәтә, чөнки гармуннар гел алышынып тора. Сәхнәгә бераз «чеметеп» чыккан оста үзе уйный, үзе залга әледән-әле реплика ташлый:

—Апа, йоклап утырма, егылып китәсең бит!

— Абый, авызын белән түгел, колагын белән тынла!

—Сеңлем, сина урын калмаганмыни? Ә-ә-нә тегендә бер егет ике урында утыра.

— Апа! Шул тикле гырлама, иренне уятасын бит.

Уен-көлке яраткан гармунчы, әнә шулай сөйләнә-сөйләнә, чират көтеп утырган гармунны кулына ала. Ә анысы ярты кирпеч зурлыгында гына. «Шомыртым» көе башкарылгач, ул тагын да кечкенәрәгендә уйный башлый. Алгы рәттә утырган Нәсимә апа, бөтен залга ишеттереп, болай дип әйтеп куя:

—Карале, Зәйтүнә, мондый кечкенә гармун да булыр икән, име?!.

Бу сүзләргә гаять кәефе килгән Гали абый:

—Була, апа, була. Моннан кечкенәрәкләре дә бар әле,—ди дә, кәчтүм кесәләреннән тагын ике гармун тартып чыгара. Аларнын берәр башын култык асларына жайлап урнаштыргач, берьюлы ике гармунда « Сандугач» көен уйный башлый.

Көй тәмамлануга, гармунчы, серле елмаеп, залга мөрәжәгать итә:

—Иптәшләр, гаеп итмәгез инде, болардан кечкенә ике гармунымны онытып килгәнмен.

Бу сүзгә янә Нәсимә апа кушыла:

—Шаяртасыңдыр әле, энем. Андый гармун булса да, ничек уйнамак кирәк?

—Уйнавын уйныйбыз ла анын. Шулай да, борчылмагыз әле. Алары килмәсә, менә монысы килгән анын,—дип, Гали абый куен кесәсеннән шырпы кабы тикле генә гармун чыгара, һәм, бер кулында аны селки-селки, башкорт халык көе «Баек»ны уйнап җибәрә.

## Сиңа ышанып...

Сугыштан соңгы еллар. Авылыбызның бер төркем кызлары-егетләре Мамадыш педагогия училищесенда укыйлар. Атна саен авыл белән шәһәр арасын җәяүләп йөреп тора алар. Ачлы-туклы яшәгән заман бит. Шуна күрә 18 чакрым араны үтү җинел түгел, билгеле. Янгырлы-буранлы көннәрне әйткән дә юк. Шулай да яшьлек үзенекен итә: алар уен-көлкедән, шаярудан туктап тормыйлар.

Шулай бервакыт, чатнама суык көнне, яшьләр тагын авылга кайтырга чыгалар. Яковка куаклыгы турына житкәч, Рәйхана исемле кыз жинелчә бушанып алырга уйлый. Башкаларга кайта торырга кушып, үзе арткарак кала. Суыктан куллары тынламас хәлгә килгән кыз, чияләнгән ыштан бавын чишә алмагач, кызлар кебек тыйнак, ярдәмчел Мулланур Мостафинны (Сонрак ГИТИС тәмамлый, озак еллар Минзәлә Татар дәүләт драма театрының баш режиссеры булып эшләде.Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Хәзер мәрхүм инде. Урыны жәннәттә булсын) ярдәмгә чакыра. Мулланур куаклыкка юнәлгәч, шаян, мут күзле Әхсән, шаярып:

—Рәйхана! Мин дә булышыйммы?—дип кычкыра. Кызның җавабы кыска була:

—Сиңа ышанып ыштан бавын чиштерсәң.

Яшьләр бу сүздән соң бөгелә-сыгыла көләләр.

## Иртә китте

Сиксәненче еллар уртасында урамыбызда Гражданнар сугышында катнашкан өч карт яшәде. 88 яшьтәге иптәшләрен күмеп кайткан көнне, кичке якта, 91 яшьлек Хажиәхмәт һәм 96 яшьлек Миннәхмәт бабайлар капка төбендә сөйләшеп утыралар.

—Менә бит, күрше, ничек булды. Без сугышка бер урамнан өчәү чыгып киткән идек. Азин дивизиясендә дә сугышырга туры килде. Нинди авыр елларны үткәреп җибәрдек—исән калдык,—ди Миннәхмәт бабай.—Әйбәт яши башлагач кына Халик безне ташлап китте. Урыны ожмахта булсын инде.

Күршесенең сүзен Хажиәхмәт карт болай дип җөпләп куя:

—Шулай шул,яшьли китте. Аңа әле 90 да тулмаган иде кана!

**Рәим ГОБӘЙ**

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАТАРСТАНДА ЯҢА ПРЕЗИДЕНТ

25 мартта Башкалабызның Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Татарстан Республикасының яңа Президенты Миннеханов Рөстәм Нургали улының үз вазифасына керешүе унаеннан зур тантана булып узды. Бәйрәмгә дөньяның төрле төбәкләреннән 800гә якын кунак килгән иде. Алар арасында—Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Григорий Рапота, Россия Дәүләт Думасы рәисенең беренче урынбасары Олег Морозов, төбәк җитәкчеләре, министрлар, Ислам конференциясе оешмасы җитәкчесе Акмалетдин Ихсануглы. Төрекмәнстан һәм Казакъстан рәсми делегацияләре, депутатлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, дин әһелләре, спортчылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, иҗат оешмалары вәкилләре, журналистлар чакырылган иде. Рөстәм Миннеханов әнә шул абруйлы халык алдында «Татарстан Республикасы халкына тугры хезмәт итәргә, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасының дәүләт суверенлыгын тәэмин итәргә, Россия Конституциясен, Татарстан Конституциясен һәм Татарстан законнарын үтәргә, Татарстан Президентына йөкләнгән югары вазифаларны намус белән башкарырга» ант итте. Тантананы алып барган республика Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исә Рөстәм Миннехановны Татарстан Президенты дип игълан итте.

РФ һәм ТР дәүләт гимннары яңгыраганнан соң, Татарстанның гамәлдәге Президенты Минтимер Шәймиев Рөстәм Миннехановка Президент штандартын тапшырды.

—Татарстан җитәкчесе булу абруйлы да, җаваплы да. Яңа Президентның тормыш тәҗрибәсе, компетентлылыгы, кешелеклелек сыйфатлары татарстанлылар өчен генә түгел, ил күләмендә дә уңыш китерәчәгенә шик уятмый. Татарстан зур сәнәгате, кадрлар потенциалы белән аерылып тора. Республика куәтле социаль-икътисади үсеше белән Россия чикләреннән читтә дә танылa бара. Казанның XXVII җәйге Универсиада уздыру хокукы яулавы шуның бер дәлиле. Шул ук вакытта федераль хакимиятнең төптән уйланган милли сәясәтне бәялəп бетермәве дә борчу тудыра.

Шушы еллар эчендә миңа ышаныч күрсәткән, хезмәттәшлек иткән һәм ярдәмен белдергән Татарстан җәмәгатьчелегенә зур рәхмәт әйтәсем килә. Алга таба да, кулымнан килгәнчә, Татарстан мәнфәгатьләре өчен хезмәт итәргә һәм яңа Президентка төрле формаларда ярдәм кулы сузарга тырышачакмын,—диде Минтимер Шәймиев.

—Сез республиканы бик яхшы хәлдә кабул итеп алдыгыз. Әгәр хәл начар булса, иң кечкенә генә уңыш та сизелер иде. Ә монда үсеш планкасы югары булганга, уңышка ирешү катлаулырак булачак. Рөстәм Миннеханов—югары дәрәҗәдәге профессионал, үз эшенең остасы, кайсы эшкә алынса да—шуны булдыра торган кеше. Татарстан «Без булдырабыз!»—дигән шигарь белән яши. Берникадәр вакыттан: «Без булдырдык!»—дип әйтерлек булсын. Мин Сезгә шуны телим»,—диде Григорий Рапота үз чыгышында.

Казан мэры Илсур Метшин республика шәһәр һәм район муниципаль берәмлекләре җитәкчеләре исеменнән чыгыш ясады. «Теләсә нинди хакимият—ул зур хезмәт һәм җаваплылык. «Ил—иргә, ир илгә таяныр», диләр. 12 елга якын Татарстан хөкүмәтенә җитәкчелек итү вакытында Сез зур тәҗрибә тупладыгыз, республиканың инновацияле технологияләр, сәламәтлек саклау, спорт һәм башка өлкәләрендә үсешкә ирешүенә армый-талмый хезмәт иттегез. Яңа вазифада да уңышлы эшчәнлек телим»,—диде ул.

Тантана барышында Рөстәм Миннехановны яңа вазифага керешүе белән котлап, бик күп телеграммалар килде: чит илләрнең Президентларыннан, шулай ук Россия Президенты Д. Медведевтан, РФ хөкүмәте рәисе В. Путиннан...

Ахырдан сүз Рөстәм Миннехановка бирелде.

—Мин бу вазифаның никадәр җаваплы икәнлеген аңлыйм. РФ җитәкчелеге, республика гражданнары һәм сез, залда утыручы хезмәттәшләрем—барыгызның да теләктәшлеген тоям. Шул ук вакытта бүгенге икътисади һәм социаль пробле-

маларны да бер көн эчендә генә хәл итеп булмавын аңлыйм—моның өчен вакыт кирәк. Ләкин мин ышанам: ул безнең көчтән килә,—диде Президент.

Шул ук көнне яна Президент имзасы куелган беренче указлар да игълан ителде. Алар—«Татарстан Республикасы Президентының үз вәкаләтләренә керешүе турында»гы һәм «Татарстан Республикасы Премьер-министры вазифаларын башкаруны Равил Моратовка йөкләү турында»гы, шулай ук Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиевне «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләү һәм Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үз өстеннән төшергән затка өстәмә дәүләт гарантияләре тәртибе турындагы Указлар.

### М. ШӘЙМИЕВ—ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ КИҢӘШЧЕСЕ

12 мартта Татарстан Республикасы дүртенче чакырылыш Дәүләт Советының тугызынчы утырышы булды. Депутатлар игътибарына көн тәртибендә күп мәсьәләләр тәкъдим ителде. Шулар арасында берничәсе гомум игътибарны җәлеп итте. Беренчесе—«Татарстан Республикасы Президентының үз вазифасына керешүе турында» Татарстан Республикасы законының 2 нче маддәсенә үзгәреш кертү хакында»гы закон проекты. Икенчесе—«Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе турында»гы мәсьәлә. Әлеге закон Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесенең статусын, аны вазифасына билгеләп кую һәм вазифасыннан азат итү тәртибен, компетенциясен, эшчәнлеген оештыру рәвешләрен һәм шартларын билгели.

Законда каралганча, Дәүләт киңәшчесе вазифасына Татарстанның Президент вәкаләтләрен үтәвен туктаткан зат кына билгеләнеп куела ала. Бу вазифадан ул шәхси гаризасы нигезендә, Татарстан Президенты тәкъдиме буенча, Дәүләт Советы тарафыннан гына азат ителә. Дәүләт киңәшчесе үз эшчәнлеген түләүсез нигездә гамәлгә ашыра. Аның бурычлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары системасын үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү, милли әдәбиятны, телне үстерүгә ярдәм итү, татарларның, шул исәптән республикабыздан читтә яшәүче татарларның һәм шулай ук Татарстан территориясендә яшәүче башка милләт халыкларының да үзенчәлекләрен саклап калуга булышудан гыйбарәт булачак. Дәүләт киңәшчесенең эш урыны Кремльдә калачак.

### ЫШАНЫЧ—ЗУР БӘЯ

Февраль ахырында Татарстан Министрлар Кабинетында Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы коллегиясенең узган елгы эш йомгакларына багышланган утырышы булды. Анда төп доклад белән агентлык җитәкчесе М. Моратов чыкты. Ул үзенең чыгышында гаммәви мәгълүмат чараларына гавамның ышаныч белән каравын билгеләп үтте. Чыннан да, бары тик шундый шартларда гына җәмгыять белән хакимият арасында нәтиҗәле диалог булырга мөмкин.

Премьер-министр (хәзерге Татарстан Республикасы Президенты) Р. Миннеханов журналистларны хакимият эшчәнлегендәге объектив җитешсезлекләрне кыюрак күрсәтергә, кискен проблемаларны ачканда гадел булырга, аларның асылын төрле яклап аңлатып бирергә чакырды. «2010 елга җинел кермәдек,—диде ул.—Хәл ителмәгән мәсьәләләр шактый. Татарстан федераль проектларда катнаша икән, безнең алдагы адымнар да федераль министрлык белән киңәшеп эшләнгән булырга тиеш».

Хөкүмәт җитәкчесе Республика агентлыгы җитәкчелегенә китап бастыру эшенә мөнәсәбәтне яңадан карарга кушты. Дөресен генә әйткәндә, соңгы елларда Татарстанда китап чыгару шактый кимеде. Средстволар җитмәүгә карамастан, бу мөһим эшне җайга салырга кирәк. Әлбәттә, республикада гамәлгә салынган электрон китапханә системасы проекты безнең заманнан калышмыйча иҗтиһат кылуыбызны күрсәтә. Әмма ул китап бастыру эшенә зыян салырга тиеш түгел.

Киңәйтелгән коллегия утырышында ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, РФ элемтә һәм гаммәви коммуникацияләр министры урынбасары А. Жаров, «Татмедиа» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры А. Сәлимгәрәев, «Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире А. Латышев, «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры И. Әминов чыгыш ясады.

Утырышта ТР Президенты аппараты җитәкчесе Ю. Камалтынов катнашты.

### ПРЕМИЯГӘ КАНДИДАТЛАР

11 мартта Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре буенча комиссия утырышы булып узды. Анда Дәүләт премиясенә кандидатлар ачыкланды. Шулай итеп, 2010 елда мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге иң дәрәҗәле республика премиясенә дәгъва итүчеләр арасында «Мәгарә: Шигырьләр, поэмалар» һәм «Ташка ордым башны: хикәяләр, эсселар» дигән китаплары өчен **Ркаил Зәйдулла**, «Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе өчен **Фоат Садриев**, «100 татар халык җыры» аудиоҗыентыгын туплаганы һәм татар халык җырларын танытканы өчен **Мирсәет Сөнгатуллин**, «Җинүнен хатын-

кыз йөзе» исемле бишенче симфониясе, «Минем Казаным» дигән фортепиано һәм оркестр өчен 1нче концерты өчен **Шамил Тимербулатов**, 1995-2009 елларда концерт программаларын югары сәнгати төзегәне һәм башкарганы өчен **Владимир Федотов** бар.

Танылган актер В. Качаловка, шулай ук Казанда Хәйриячегә һәйкәл сыннарын ясаган өчен **Асия Миңнуллина**, Татарстанның шәһәр һәм районнарында сыннар, монументаль-декоратив композицияләр иҗат иткән өчен **Илдар Ханов**, «Тукай рухы—мәңгелек» исемле серия өчен нәкышчылар **Ринат Харисов** һәм **Расих Әхмәтвәлиев**, нәкышчы, график **Васил Ханнанов**тан торган **«Чыңгызхан» иҗат берләшмәсе** рәссамнары да кандидатлар исемлегендә.

Театр әһелләре арасында быел Тукай премиясенә «Бурлак» пьесасы өчен **Чаллы Татар дәүләт театры иҗат коллективы** дәгъва итә.

## НӘҖИП ҖИҺАНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУНЫ БӘЙРӘМ ИТҮ ТУРЫНДА

*Композитор, җәмәгать эшлеклесе, Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, СССР һәм Татарстан Республикасы дәүләт премияләре лауреаты Нәҗип Гаяз улы Җиһановның илебез һәм бөтендөнья музыка мәдәниятенә зур өлеш кертүен исәпкә алып, шулай ук аның тууына 2011 елда 100 ел тулуга бәйле рәвештә, карар бирәм:*

1. 2011 елда Нәҗип Җиһановның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына өч ай эчендә:

Нәҗип Җиһановның тууына 100 ел тулуга багышланган чаралар әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты төзергә.

Нәҗип Җиһановның тууына 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү буенча төп чараларның республика планын эшләүне һәм раслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Нәҗип Җиһановның тууына 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү буенча төп чараларның республика планын гамәлгә ашыруда актив катнашырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында әлеге вакыйгага багышланган тантаналы чаралар оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, шулай ук «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә, республиканың башка һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Нәҗип Җиһановның тууына 100 ел тулуны бәйрәм итүне киң яктыртуны, аның иҗат эшчәнлегенә багышланган материаллар, телевизион һәм радиотапшырулар әзерләүне тәэмин итәргә.

5. Республика оешмаларына, җәмәгать берләшмәләренә, иҗат берлекләренә, кызыксынган башка органнарга һәм оешмаларга Нәҗип Җиһановның тууына 100 ел тулуга багышланган чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә актив катнашырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге Указ ана кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. Ш. ШӘЙМИЕВ**
*Казан, Кремль,*
*2010 ел, 13 март*

## БӨЕКЛЕК БИЕКЛЕКТӘ КАЛА

Лондонда XX гасырның бөек биючесе Рудольф Нуриев иҗатына багышлап Татарстан Хөкүмәте һәм Казан мэриясе ярдәмендә оештырылган гала-концерт узды.

Англиянең төп матбугат басмалары концертка берничә атна кала ук, берничек тә игътибарсыз калдырып булмый торган вакыйга көтелә, дип язып чыккан. Нәтиҗәдә, зал тамашачыларны көчкә сыйдырган. Алар хозурына Зур һәм Мария театрлары, Англиянең Королева һәм Милли балетлары, Париж һәм Вена операсы балеты йолдызлары башкаруында Рудольф Нуриевнең иң яраткан партияләре тәкъдим ителгән.

Гала-кичә Лондонның иң атаклы театрларының берсендә—«Колизей»да булган. Бу кичә Нуриевнең балет дөньясына йогынтысының елдан-ел артуын, күренекле татар биючесенең исеме дөньякүләм афишалардан төшмәвен тагын бер кат раслаган.

## КАЛӘМ ИЯЛӘРЕ ИГЪТИБАРЫНА!

Быелның октябрь аенда узачак Бөтенроссия халык санын исәпкә алу кампаниясе уңаеннан, массакүләм мәгълүмат чаралары арасында иң яхшы материалга конкурс игълан ителде. Кампания барлык авыл-шәһәрләрне дә колачлаганлыктан, бу конкурста шәһәр, өлкә, республика гына түгел, ә районнарның матбугат чаралары да катнаша ала. Конкурсны оештыручылар әйтүенчә, журналистларның төп бурычы—Россия гражданнарына халык санын исәпкә алуның нинди мөһим һәм зур вакыйга икәнен аңлату, аның нечкәлекләренә төшендерү. Конкурска 2010 елның 1 гыйнварыннан алып 30 октябренә кадәр матбугатта басылган, яки эфирда яңгыраган материаллар кабул ителә. Җиңүчеләр биш номинациядә билгеләнәчәк. Гомуми премия фонды 4,3 миллион сум тәшкил итә. Конкурска нәтиҗәләр 2010 елның но-

ябреннән соң ясалачак. Конкурс турында тулырак **www. perepis—2010. ru/konkursy** сайтында танышырга мөмкин.

### ЯҢА КОНКУРС

Татарча көрәшне пропагандалау, үстерү, көрәшчеләрнең исемен таныту һәм мәңгеләштерү максатыннан конкурс игълан ителә. Аны ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгы, ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы һәм ТР Язучылар берлеге оештыра.

Әлеге конкурста теләге булган һәркем катнаша ала. Анда татарча көрәшкә багышланган яки көрәш буенча зур уңышларга ирешкән спортчылар турында шигъри, чәчмә яисә драма әсәре кабул ителә. Эшләрне 420012 индексы белән, Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 14 нче йорт адресына почта аша җибәрергә мөмкин. Конкурста катнашучының әтисенең исеме, фамилиясе, адресы, элемтәгә керү өчен телефон номеры күрсәтелү мәҗбүри. Әсәрләр 2010 елның 1 декабренә кадәр кабул ителә. Нәтиҗә 2010 елның 24 декабрендә махсус комиссия тарафыннан ясалачак. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы 2011 елның февралендә М. Җәлил призына уздырыла торган көрәш турнирында үткәреләчәк. Алар иң яхшы шигъри әсәр, иң яхшы чәчмә әсәр һәм иң яхшы драма әсәре номинацияләрендә билгеләнә. Һәрберсендә 1 нче, 2 нче һәм 3 нче урын каралган.

*1 нче урын—30 мең сум.*
*2 нче урын—20 мең сум.*
*3 нче урын—15 мең сум.*

Иң яхшы әсәрләр китап булып нәшер ителәчәк.

### ФӘН ӘҺЕЛЛӘРЕ ХИСАП ТОТА

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2009 елдагы фәнни эшчәнлегенә багышланган йомгаклау конференциясе булды. Директор Ким Миңнуллин 20 фән докторын, 50 дән артык фән кандидатын үз канаты астына алган коллективның еллык хезмәтенә нәтиҗә ясады. Ул былтыр 20дән артык китап басылуны, 7 фәнни-гамәли конференция үткәрелүне, галимнәрнең Казанда, Россия өлкәләрендә, чит илләрдә 300дән артык доклад ясавын искә алып узды.

Аннары Мордовия Республикасының Зур Иса авылында яшәгән, татар фольклорын саклаучы һәм башкаручы җырчы-баянчы Абдулла Кротовның компакт-дискы һәм китабы тәкъдим ителде. 40 мең сүз һәм сүзтезмәләрне үз эченә алган 839 битле «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (Казан, 2009) басылып чыгу да халкыбыз тарихында зур вакыйга дип бәяләнергә хаклы. Бу хезмәтнең авторлары Флера Баязитова, Дөррия Рамазанова, Зидә Садыйкова, Тәнзилә Хәйретдиновага рәхмәт сүзләре әйтелде.

Шуннан соң, ике көн дәвамында тел, әдәбият, фольклор һәм сәнгать белеме, текстология һәм кульязмаларны өйрәнү мәсьәләләре секцияләрендә 50дән артык нотык тыңланды, 2010 елга яңа бурычлар билгеләнде.

### РУХАНИЛАР ДАИРӘСЕНДӘ

***

Татарстан мөселманнарының IV корылтае булды. Аның эшендә республикабыз төбәкләреннән 600 гә якын делегат катнашты. Корылтайның шәрәфле кунаклары арасында ТР Президенты М. Шәймиев, Россия Президенты аппараты киңәшчесе А. Гришин, Россия мөфтиләр шурасы рәисе Р. Гайнетдин, Үзәк Диния нәзарәте рәисе Т. Таҗетдин, Башкортстан, Карачай-Чиркәс, Чиченстан, Дагыстан мөфтиләре, илебезнең төрле төбәкләреннән килгән дини оешма җитәкчеләре катнашты.

Корылтай делегатлары бертавыштан Татарстан мөфтие вазифасына яңа срокка Госман хәзрәт Исхакыйны, аның беренче урынбасарын—«Болгар» мәчете имамы Илдус хәзрәт Фәизне, баш казый итеп Җәлил хәзрәт Фазлыевны сайладылар.

***

Шул ук көннәрдә Казан мәчетләре руханилары баш имамны сайлады. Моңа кадәр әлеге вазифаны 15 елга якын «Мәрҗани» мәчете имам хатибы Мансур Җәләлетдин башкарды. Тавышка дүрт кандидат—хәзерге мөхтәсиб Мансур Җәләлетдин, «Мәдинә» мәчете имамы Гыйльмулла Хәлиуллин, «Мәрҗани» мәчете имамы Илфар Хәсәнов, ТР Мөселманнары диния нәзарәте рәисе урынбасары, «Апанай» мәчете имамы Вәлиулла Ягъкуб куелган иде. Соңгы өчесе үз кандидатураларын кире алды. Нәтиҗәдә җыелышта катнашучылар бертавыштан Мансур Җәләлетдинне яңадан баш имам итеп сайлады.

### ЙОЛДЫЗЛАР КҮБӘЯ

Март уртасында Татарстанда «Созвездие-Йолдызлык» телевизион яшьләр фестиваленең зона турлары үтте. Фестивальдә катнашыр өчен 5-21 яшьлекләрдән 80 мең гариза килде. Алар арасында Татарстан балалары белән бергә, Мәскәү, Әстерхан, Кырымның Судак шәһәре һәм тагын бүтән калалардан үз көчләрен сынап карарга теләүчеләр дә бар.

Быел Шанхай Хезмәттәшлек Оешмасы илләре—Иран, Һиндстан, Монголиядән яшь талантлар кунакка киләчәк. Бу хакта Татарстан Мәдәният министрлыгы белән халыкара оешма секретариаты

арасында узган ел ук килешү төзелгән иде. Фестивальнең финалы Казанда 30 апрельдә «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә узачак. Әмма анарчы сәләтле балаларга Казан консерваториясе профессоры Зилә Сөнгатуллина, РАТИ-ГИТИС проректоры Гумет Алиев, әлеге уку йортының эстрада сәнгате кафедрасы житәкчесе Михаил Борисов кебек абруйлы шәхесләрдән торган жюриның жиз иләгеннән узасы бар әле.

## «ШҮРӘЛЕ» ГАРӘПЧӘ СӨЙЛӘШӘ

Мисыр шагыйре һәм язучысы Әшраф Әбүл Язид Г. Тукайның атаклы «Шүрәле» поэмасын гарәп теленә тәрҗемә иткән.

Гарәп телендәге «Шүрәле» 150 мең тираж белән дөньяга чыгачак. Укучылар аны журналга кушымта сыйфатында инде шушы айларда ук күрү бәхетенә ирешәчәк. Матур бизәлешле 32 битлек әкиятне дөньяның 22 илендә яшәүче балалар рәхәтләнеп укыячак. Әшраф Әбүл Язид әйтүенчә, тәрҗемә гарәп укучыларының яшь буынына багышланган. Алар поэма битләрендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тәрҗемәи хәле белән дә таныша алачак. Моннан тыш китапта иллюстрация сыйфатында Татарстан рәссамнары әсәрләре дә кулланган. Тукай «Шүрәле»се бүгенгә дөньяның 15 теленә тәрҗемә ителгән инде.

## МУЗЕЙ МӘГАРИФНЕ ҮЗ ИТӘ

Февраль-декабрь айларында Казан мәктәпләре, махсус урта, югары уку йортлары укытучылары, педагогик белем алучы студентлар өчен ТР Милли музее һәм аның бүлекләренә керү бушлай булачак.

Милли музей, зур белем-тәрбия бирү мөмкинлегенә ия буларак, озак еллар буе Казан һәм республикабызның мәгариф органнары белән тыгыз элемтәдә эшләп килә. Уку елы дәвамында балаларны музей эшчәнлеге өлкәсенә җәлеп итәрдәй «Музей—мәктәпкә» проекты уңышлы хәл ителә, шул исәптән җәйге лагерьларда күчмә чаралар оештырыла.

## ҖИҢӘРГӘ ҖЫР ДА БУЛЫШТЫ

Татарстан Милли музееның музыка мәдәнияте бүлегендә Татарстанның халык артисты, 95 яшьлек Усман ага Әлмиев белән очрашу булды.

Белгәнебезчә, Ватан сугышы елларында сәнгать әһелләре, концерт бригадалары оештырып, сугышчылар алдында концертлар куеп йөргән. Татарстанда шундый 17 бригада оештырылган һәм алар сугышның буеннан-буена 2 меңләп концерт биргән. Болар филармония, опера һәм балет театры артистлары, радиокомитет хезмәткәрләре булган. Өстәвенә, җырчыларның өчтән икесе сугышка алынган. Камил Басыйров, Рәшит Гобәйдуллин, Габделхак Шаһиев, Җәваһирә Сәлахова, Разия Тимерханова, Фәйзи Биккининнар концертларының афишалары, сугышчылар арасында төшкән фотолары филармония музеенда бүген дә саклана.

Сәнгать ветераны Усман Әлмиев госпитальләрдә, вокзалларда ничек итеп чыгыш ясаганын сөйләде. «Солдатлар сугышка киткәндә вокзалда көненә 15әр концерт бирә идек. Кыш димәдек, яңгыр димәдек—үзебезнең бурычны үтәргә тырыштык. Сугышчылар елый-елый рәхмәт әйтә иде»,—диде ул. Усман ага очрашуга килгән укучыларга Муса Җәлилнең үз куллары белән язып биргән шигырен һәм Фәрит Яруллинның ноталарын күрсәтте. Алар тыныч тормышта да дуслар булган, сугыш вакытында да хатлар алышып торганнар. Соңыннан легендар җырчы үзенең озак еллар яратып җырлаган җырын—«Башмагым»ны башкарды.

## КҮРШЕЛӘРЕБЕЗДӘ

26нчы февральдә Удмуртия башкаласы Ижевск шәһәрендә Удмуртия Язучылар берлегенең чираттагы съезды булып үтте. Съезд соңгы биш елда ирешкән уңышларны барлап, берлек эшендәге аерым кимчелекләрне дә билгеләп үтте.

Берлекнең рәисе Егор Загребин үз докладында ике ел элек кенә Удмуртия Язучылар берлегенә кергән татар язучыларының эшләрен уңай бәяләде. Ринат Баттал, Гыйммран Сафин, Ибраһим Биектаулы, Гөлфия Исхакова удмурт язучыларының шигырьләрен, хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итеп Удмуртиядә чыгучы «Яңарыш» газетасында еш кына бастыралар. Әсәрләр татар укучысының уңай бәясен алалар.

Берлекнең рәисе итеп шактый катлаулы сайлаулар аша үтеп, тагын Егор Загребин сайланды.

## ӘНГАМ АТНАБАЕВНЫ ОЛЫЛАУ

Февраль аенда шагыйрьләр Роберт Миңнуллин һәм Рәдиф Гаташ Башкортстанда булдылар. Башта Уфада яшәүче шагыйребез, журналыбызның күптәнге авторы Рим Идиятуллинны 70 яше тулу һәм Һ. Такташ исемендәге абруйлы әдәби премиягә лаек булуы белән котладылар. 25 февральдә исә татар телендә чыгучы «Кызыл таң» газетасы коллективы белән очраштылар. Аннары Казан кунаклары Благовещен, Бөре, Балтач, Борай районнарын кичеп, Башкортстанның иң төньяк районы Тәтешлегә килделәр. Биредә һәр елның 25 февралендә—Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаев туган көндә «Күрдем чишмәләре» исемле шигърият фестивале уздырыла. Мәктәп балаларыннан башлап,

өлкән яшьтәгеләргә кадәр язучыларның шигырь конкурсы, Ә. Атнабаев әсәрләрен сәнгатьчә уку, жыр, бию, кобаер әйтү һ. б. ярышлар уздырыла. Тәтешледән бу төбәктән чыккан Г. Чокрый, К. Әмири, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, Л. Кәшфи, галим Р. Хәйбрахманов, жырчы С. Фәтхетдинов, Х. Фәрхи исемнәрен хөрмәт белән искә ала. Ә. Атнабаевның туган авылында урта мәктәп аның исемен йөртә, шунда ук һәйкәл-бюсты куелган, музее бар.

Шигърият фестивалендә шигырьләр өч телдә—татар, башкорт, рус телләрендә яңгырады. Р. Миннуллин һәм Р. Гаташ белән Тәтешледә район китапханәсендә, урта мәктәптә һәм Кодаш авылында да кызыклы очрашулар булып узды.

## ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМЫЙ

2010 елның 26-27 февралендә Пермь краенын Барда районында шул төбәктә туып үскән фольклорчы галим, шагыйрь һәм жәмәгать эшлеклесе Рәшит Фәйзрахман улы Ягъфәровка багышланган «Рәшит Ягъфәров укулары» булып узды.

Инде икенче мәртәбә уздырыла торган бу чарада Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Татарстанның Язучылар берлеге исеменнән танылган шагыйрә Флера Тарханова катнашты.

Барда муниципаль районы хакимияте башлыгы Ихсан Шакир улы Урстимеров, аның урынбасары Сәлим Нәжип улы Назин, мәдәният бүлеге мөдире Елена Николаевна Кәлимуллина, мәктәп директоры Әлфия Хәниф кызы Таразова һ. б. әлеге чараны әзерләүдә һәм үткәрүдә күп көч куйган.

Бу чара 26 февральдә Ягъфәровның туган авылы Күчтәнтидә башланып китте. Иртәгесен район мәдәният йортында дәвам итте. Әүвәл Рәшит Ягъфәровның үзе турындагы язмаларны туплаган «Жәгъфәр» исемле китапны тәкъдим итү булды. Бу китап «Тан» газетасы баш мөхәррире Эльмарт Уразов, аның хезмәткәре, шагыйрь, ТР Язучылар берлеге әгъзасы Идият Әширов һәм Ягъфәровның хәләл жефете Әкълимә ханым тырышлыгы, Барда хакимиятенең матди ярдәме белән дөнья күргән.

Аның соң Р. Ягъфәровның фольклор әсәрләренә нигезләнеп сәхнәләштерелгән чыгышларны башкаручы балалар һәм өлкәннәр, фольклор ансамбльләре, Р. Ягьфәров шигырьләрен укучылар, ана багышланган үз шигырьләрен укучылар конкурсының II туры булды. Рәшит Ягъфәровне искә алу чараларында аның улы, күренекле кинорежиссер Илдар Ягъфәров, «Азатлык» радиосы журналисты Ландыш Әбүдарова һәм яшь жырчы Гөлгенә Кәлимуллина да катнашты.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

***

Татар фольклористикасын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтижәле фәнни эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты халык ижаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Мәхмүтов Хужиәхмәт Шаһиәхмәт улы** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Татарстан хакына нәтижәле эшчәнлекләре, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы хезмәткәрләре: житәкче урынбасары **Журавлев Сергей Николаевич**, эшләр идарәсе башлыгы **Мардамшина Резида Равил кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булдылар.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республикабыз җәмәгатьчелеге зур югалтуга дучар булды. 13 мартта Татарстан Республикасы Премьер-министрының элеккеге беренче урынбасары, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, филология фәннәре докторы, профессор **Мансур Хәсән улы ХӘСӘНОВ** каты авырудан соң 80 нче яшендә вафат булды.

Мансур Хәсән улы 1930 елның 25 июнендә Татарстан АССРның Зәй районы Бигеш авылында дөньяга килә. Хезмәт эшчәнлеген 1948 елда, Алабуга китапханә техникумын тәмамлаганнан соң, китапханә мөдире буларак башлап җибәрә. 1955 елда Казан дәүләт университетын тәмамлап, укытучы булып эшли. М. Х. Хәсәнов 1961 елдан алып ун ел дәвамында партия өлкә комитетында—мәдәният бүлеге мөдире, идеология мөдире бүлеге урынбасары, фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире вазифаларында хезмәт куйды. Бу елларда аның эшлекле һәм кешелекле сыйфатлары, эшкә гаять зур сәләте, җаваплылыгы, бурычларны оператив төстә хәл кыла алу осталыгы ачык күренде.

М. Хәсәновның оештыру сәләте 1971-92 еллар дәверендә Татарстан АССР Министрлар Советы Рәисе урынбасары, беренче урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары вазифаларында аеруча ачык чагылды. Татарстан АССРда фән, мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль-тәэминат, физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләре М. Х. Хәсәновның аерым игътибар үзәгендә торды.

Мансур Хәсән улының турыдан-туры актив катнашында Казан мәдәният институтын (хәзерге сәнгать һәм мәдәният академиясе), Чаллы педагогия институтын, Волгоград физик культура һәм спорт институты филиалын, башка югары белем, мәдәният һәм сәламәтлек саклау объектларын ачу турында карарлар кабул ителде. Г. Камал исемендәге Татар академия театры бинасы төзелде.

М. Хәсәнов, Республика Хөкүмәте җитәкчеләренең берсе буларак, үз бурычларын фәнни-тикшеренү эше белән үреп барды. Ул озак еллар дәвамында татар мәдәнияте тарихы, Татарстанның иҗтимагый фикере һәм тарихы буенча махсус курслар алып барды.

М. Х. Хәсәнов Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен оештыручылардан берсе һәм аның тәүге президенты булды. Аны ул 1992-2006 елларда җитәкләде.

Мансур Хәсән улының фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре борынгы чорлардан алып бүгенге чорга кадәр татар әдәбияты тарихын өйрәнү белән бәйле булды. Ул Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ. б. иҗатларын тикшерү буенча нәтиҗәле эшләде. Бигрәк тә татар әдәбияты классигы, галим һәм иҗтимагый эшлекле Г. Ибраһимовның иҗади мирасын өйрәнү буенча нәтиҗәле эшләде. М. Х. Хәсәнов XIX гасыр башларыннан алып XX гасырның икенче яртысына кадәрге рус-татар әдәби элемтәләрен өйрәнде. Аның бу эшләр циклы СССР Фәннәр академиясенең рус әдәбияты институты

(Пушкин йорты) белән хезмәттәшлеге нигезендә алып барылды. Әдәбият белеменең методологик проблемаларын эшләү, иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер, милли мәгариф һәм педагогика тарихын, сәнгать һәм культурология проблемаларын өйрәнү белән актив шөгыльләнде. М. Хәсәнов 1980 еллардан башлап татар халкының милләт буларак уянуы, аякка басуы проблемалары буенча тикшерүләр алып барды. Татар халкы һәм Татарстанның күп гасырлык тарихының үзәге буларак, Казан шәһәре тарихын өйрәнүгә яңа методологик якын килүләр эшләүдә турыдан-туры катнашты. М. Хәсәнов биш монография, 250дән артыграк фәнни язма авторы булды.

М. Хәсәнов бер үк вакытта, 1993 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр Татар энциклопедиясе институты директоры, Татар энциклопедик сүзлегенең һәм күп томлы Татар энциклопедиясенең фәнни концепциясен эшләүче һәм баш редакторы булып торды. Үзенең бөтен гомерен республика һәм аның күпмилләтле халкы мәнфәгатьләренә хезмәт итүгә багышлады.

М. Хәсәновның хезмәттәге казанышлары югары дәрәҗәдәге дәүләт бүләкләре белән билгеләнде. Ул ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Халыклар дуслыгы, «Мактау билгесе», «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» IV дәрәҗә, «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» орденнары, медальләр, Мактау грамоталары белән бүләкләнде. Аңа "Татарстан АССРның атказанган икътисадчысы», «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелде. Ул фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты булды.

М. Хәсәнов алты чакырылышта Татарстан АССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Мансур Хәсән улы хезмәт сөючәнлеге, оптимистик рухы, кешелеклелеге, ихтирамлы мөгамәләсе белән хезмәттәшләре һәм республика җәмәгатьчелеге алдында зур абруй һәм хөрмәт казанды.

Мансур Хәсән улы Хәсәновның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

**М. Ш. ШӘЙМИЕВ, Р. Н. МИҢНЕХАНОВ, Ф. Х. МӨХӘММӘТШИН,**
**Ю. З. КАМАЛТЫНОВ, Р. Ф. МОРАТОВ, З. Р. ВӘЛИЕВА,**
**А. Х. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ, И. К. ХӘЙРУЛЛИН,**
**Ә. М.МӘЗЬӘРОВ, И. Р. МЕТШИН, Т. В. ВОРОПАЕВА,**
**М. Х. СӘЛАХОВ, К. М. МИҢНУЛЛИН, И. М. ИБРАҺИМОВ,**
**Р. Х. ӘХМӘТҖАНОВ**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Язгы ташу.

*Дүртенче биттә:* язучы **Илдус Диндаров**.

# Яңа китаплар



**Рәдиф Гаташ.** Сайланма әсәрләр. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009 ел. Тиражы—2000 данә.

Күренекле шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташның җыйнак (томлыклар 250-300 бит тәшкил итә), әмма ныклап уйланып, сайлап төзелгән 3 томлыгы дөнья күрде. I томга—1961-1971 еллардан шигырьләр, лирик цикллар, шигъри хатлар; II томга—1972-1993 еллар шигырьләре, поэмалар; III томга—соңгы еллардан «хиссият аятьләре»—газәлләр, робагыйлар һ. б. классик жанрлардагы шигырьләре туплап бирелгән. Һәр томлык күренекле галимнәр һәм әдипләрнең (Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Р. Зәйдулла) тәфсилле мәкаләләре белән ачыла. Тулаем алганда, бу китаплар аша шагыйрьнең ярты гасырлык иҗатын күз алдына тулырак китереп була.




**Халисә Ширмән.** Язмышлардан юк ла узмышым: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.—287 бит. Тиражы—2000 данә.

Халисә Ширмән— соңгы елларда галимә һәм язучы буларак, шактый ук таныла бара. Аның берничә әсәре безнең «Казан утлары»нда да басылып чыкты, хикәяләр конкурсында журнал премиясенә дә лаек булды. Бу китап яшьлек һәм мәхәббәт турында. Автор раславынча, яшьлек янәшәсендә гыйлемле һәм тәҗрибәле дөнья, ә мәхәббәт янәшәсендә нәфрәт тә бар. Язучы шул хакта бергә-бергә уйланырга чакыра.



Илдус Диндаров

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)